ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

8.2009



# ХАЛЫКАРА КҮРГӘЗМӘГӘ 100 ЕЛ

*1909 елның җәендә Казанда, Арча кырында (хәзерге Горький паркы тирәсе) булып узган Халыкара күргәзмәдән күренешләр.*













**Казан утлары**

**Qazan utları**

2009

# 8

**(1042)**

*ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:*
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

*НАШИРЕ:*
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Газинур МОРАТ. Дуңгәләктәй үтеп бара дәвер... *Шигырьләр.* ........ 5
Гөлчәчәк ГАЛИЕВА. Газзәбану. *Роман.* ........ 11
Рашат НИЗАМИ. Меңәр яфрак—урман күзләре... *Шигырьләр.* ........ 78
Суфиян ПОВАРИСОВ. Утлы дуга кыңгыравы. *Роман-хатирәдән өзек.* ........ 83
Луиза ЯНСУАР. Дөньялыкта, фани мәңгелектә... *Шигырьләр.* ........ 114
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Итле пәрәмәч. *Хикәя.* ........ 118

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Фидаил. Йолдызлы болытларда. *Шигырьләр.* ........ 136

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. Газинур—батырлар исеме ........ 139

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Амазонкалар ирдәүкәме? ........ 146

**СӘНГАТЬ**

Нәгыйм МӨХИБУЛЛИН. Сәхнәдән—фронтка ........ 151
Альфрет ӘБДРӘШИТЕВ. Безнең күргәзмә ........ 156

Мөнир АБДУЛЛИН. Псевдоним—кушамат түгел ........ 157

**КАЙТАВАЗ**

Миргазиян ЮНЫС. Батып барган карабны кем, ничек коткара алыр? ........ 164

**ТАРИХ**

Альфред ХАЛИКОВ. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе ........ 173

**ХӘТЕР**

Гомәр БӘШИРОВ. Күңел дәфтәре ........ 175

«Казан утлары» архивыннан ........ 162
Котлыйбыз! ........ 182
Безнең календарь ........ 184
Төртмәле бит ........ 185
Берлекнең яңа әгъзалары ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 187

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Г. ГАЛИЕВОЙ «Газзабану» (окончание); отрывки из романа-воспоминания С. ПОВАРИСОВА «Колокол огненной дуги» (начало);
рассказ Т. ГАЛИУЛЛИНА; стихи Г. МУРАТА, Р. НИЗАМИ, Л. ЯНСУАРА.
«Творчество молодых»: стихи Фидаиля.
«Литературная критика»: статья Н. ХИСАМОВА посвященная 50-летию Г. Мурата.
«Книжное обозрение»: Л. МУХАМЕТЗЯНОВА. Рецензия книги Р. Сагди «Амазонки».
«Искусство»: Н. МУХИБУЛЛИН. «Со сцены—на фронт»;
статья М. АБДУЛЛИНА о псевдонимах.
«Эхо»: М. ЮНУС. «Кто и как спасет тонущий корабль».
«История»: А. ХАЛИКОВ. «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения» (продолжение).
«Память»: Г. БАШИРОВ. «Дневниковые записи» (продолжение).
Из фотоархива журнала.
«Юбилеи».
Новые члены Союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: В Казани—День республики;
писатель-публицист, политик Рафаэль Хакимов.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by G. GALIEVA «Gazzabanu» (ending); fragments from novel-memoirs by S. POVARISOV «Bell of fiery arc» (beginning);
story by T. GALIULLIN; verses by G. MURAT, R. NIZAMI, L. YANSUAR.
«Youths' creation»: verses by Fidail.
«Literary criticism»: article by N. HISAMOV devoted to 50th anniversary of G. Murat.
«Book review»: L. MUHAMETZYANOVA. Review of book by R. Sagdi «Amazons».
«Art»: N. MUHIBULLIN.
«From stage to front»;
Article by M. ABDULLIN about pseudonyms.
«Echo»: M. YUNUS. «Who and how will rescue sinking ship».
«History»: A. HALIKOV. «500 Russian surnames of Bulgar-Tatar origin» (continuation).
«Memory»: G. BASHIROV. «Diary records» (continuation).
From photo archive of magazine.
«Anniversaries».
New members of Union of writers.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Republic day in Kazan;
writer-publicist, politician Raphael Hakimov.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 27.07.2009, график буенча 27.07.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–1067. Тираж 3036.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2009 ел.



Газинур
Морат

# ДҮҢГӘЛӘКТӘЙ ҮТЕП БАРА ДӘВЕР...

## Чатыр

**Өнсез чагы әле чатырымның,
Көйсез мәле әле көемнең.
Гази кылычы да кисә алмас
Бер чуалган гомер төенен.**

**Бөгәрләнеп ятам чатырымда,
Карындагы сабый шикелле.
Үкси-үкси бу дөньяга кабат
Кайтуларым гына икеле.**

**Нарасыйдай ятам бөгәрләнеп,
Дала карынында—чатырда.
Ә кылганнар гүя гөслә кылы—
Киңлекләргә мине чакыра.**

**Киңлекләргә дәшә Дала җиле...
Күгем—биек, түбәм—тәбәнәк.
Дүңгәләктәй үтеп бара гомер,
Җилләр уңаена тәгәрәп.**

**Дүңгәләктәй үтеп бара дәвер,
Җилләр гүя чаптар аңарга.
Чатыр булып тын курганнар гына
Тамырланып калган далада.**

**Тамырланып калган хәрабәләр,
Исем-атамалар, дагалар...**

Газинур МОРАТ (1959)—*шагыйрь, публицист; "Мин дөньяны тыңлыйм", "Түбә", "Төнге әверелеш" һ.б. китаплар авторы. М. Җәлил һәм Г. Исхакый исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

Шул дагалар мәллә
Дала җанын
Ялалардан торган аралап?

Шул дагалар мәллә, дога булып,
Чал Даланың серен саклаган?..
Атамалар гына кала икән,
Бер егылып төшкәч атлардан.

Ияләргә ияләсе икән,
Бер мәтәлеп төшкәч иярдән.
Үксез Дала җиле исә...
Аңа
Өнсез дуңгәләкләр иярген.

Нарасыйдай ятам бөгәрләнеп,
Дала карынында—чатырда.
Ә кылганнар гүя гөслә кылы—
Киңлекләргә мине чакыра...

## Дәрвиш

Табынганы—Күк-Тәңредер,
Очар коштыр,
Сагынганы—туган тияктер...
Бу дөньядан аңа берни кирәк түгел,
Ул дөньяга, бәлки, кирәктер...

## Чингачгук

Бу җырләрнең алтын белән
Исәпләнгән бәясе...
Дала буйлап килә берәү.
Атсыз. Уксыз. Җәясез.

Кылганнар кыштырдавы да
Сагайтып куя аны.
Ерак түгел ишетелә
Бүреләр улаганы.

Яргаланган иреннәре
Дога пышылдый сыман...
Чү, әнә бөркет калыкты
Кыялар арасыннан.

Шул каракош урлады ич
Ыруның соңгы кызын.
Берүзе калды. Ә алда—
Юллар. Маяксыз. Озын...

...Тарих күмелгән зират бу.
Изге җир! Юк бәясе!
Дала буйлап килә берәү.
Атсыз. Уксыз. Җәясез.

## Сыенчыбагар

Үз бәясен ул бик яхшы белә,
Шуңа да ул алиһә күк тыныч.
Сокланырга хәтта хәтәр аңа,
Сокланырга хәтта куркыныч.

Карашларың белән орынсаң да,
Әверелер кебек таш сынга ул.
Юк, юк, сынчы карашыннан түгел—
Гарип дөньялыктан ятсына ул.

Юк, юк, сынчы карашыннан түгел—
Үз-үзеннән яшерә ул тәнен.
Мәңгелеккә күчәчәк бу мизгел!—
Гүзәллеккә сабырлык бир, Тәңрем.

Сабырлык бир, Тәңрем, бу мизгелгә—
Фәрештәңә сынчың куя канат.
Иреннәрең белән орынсаң да,
Алиһәгә әйләнер сын кабат.

Сынчы китәр...
Остаханәсендә
Хуҗа булып калыр бер үкенеч:
Яратырга хәтта хәтәр аны,
Яратырга хәтта куркыныч.

## Төнге этюд

Күл уртасында—Зөһрә кыз,
Ярымай гүя көймә.
Салмак кына ишә сылу,
Ямансу бер көй көйләп.

Ишетәм аның сагышын,
Ишетәм чорлар аша.

...Бер-берсенә күз кысышып,
Йолдызлар пышылдаша.

Көмеш балкыш чыңы күктә,
Җәй шавы—тирә-якта...
Төнге тынлык төнбоекны
Йокысыннан уята.

## Син

Горурлыгым. Мескенлегем.
Таянычым. Абынуым.
Тугрылыгым. Хыянәтем.
Ихтыярым. Табынуым.

Бергәлегем. Ялгызлыгым.
Нәфрәтем. Мәхәббәтем.
Әсирлегем. Хөрриятем.
Яшәешем. Һәлакәтем.

## Төнге идиллия

Төн—гүяки арфа...
Һәрбер кылы
Ай нурыннан аның үрелгән.
Тынлык сонатасы аһәңенең
Шавы килә галәм түреннән.

Галәм түрләрендә шытып чыккан
Чәчкәләре җәннәт багының.
Без ауныйбыз шунда...
Арабызга
Тын соната керә агылып.

Җәннәт чәчкәләре безне күзли,
Диләр бугай: менә тамаша!
Синең гүзәллекне көйгә салып
Уйный арфа...
Күзләр камаша.

## Диптих

*1. Картлар йорты*

Дөнья кадәр сагыш сыйган монда,
Дөнья кадәр кайгы сыенган.
Дөньялыкта сый-тәгамең калса,
Шөкер, Ходай өзми сыеннан.

Дөнья көтеп арган карт-корының
Исе китми монда юк-барга.
Сагыш эчеп, сусауларын баса,
Кайгы йотып ята йокларга.

Ә балалар дөнья куып уйный
Дөнья дигән сары йортларда.

*2. Җиһангирлар кәрт суга*

—Сезгә дә булсын тамаша,
Безгә дә булсын кызык,—
Чыңгызхан белән Бонапарт
Кәрт суга кызып-кызып.

—Ә син, Леонид Ильич,
Торма кызыкны бозып.

—Бөек җиһангир кылычын
Бик җиңел димсең әллә?

—Тузны да каплый алмагач,
Король түгел син, кәрлә!

—Ә син, Гайсә, чәпчемә,
Үзең дә безнең хәлдә.

—Дөньясына баш булгач та,
Ник баса икән нужа?

—Олуг казый әйтеп бирсен:
Кем бу җиһанда хуҗа?

—Башөсте, Корыч бабай,
Хөкемең чыгар, давай...

## Карт һәм чабак

Җилкәннәрдә җилләр черем итә,
Калкавычка кунган төклетура.
Кабан күлдәй кадим каегында
Йокымсырап ялгыз карт утыра.

Каек төбендәге күлдәвектә
Чәбәләнеп ята сыңар чабак.
Сыңар чабак—гүя соңгы өмет,
Сыңар чабак—гүя соңгы чара.

Чабак чаклы гына соңгы өмет
Бәргәләнеп ята күлдәвектә.
Казан казнасының алтыннарын
Юкка гына күлгә күммәдек лә?!

Хан йөзеген йоткан картлач чуртан
Капмый калмас кебек кармагына.
Су кызлары табып бирер төсле
Ханбикәнең алтын тарагын да.

Сөйрәп чыгарыр күк албастылар
Казаланган Казан байлыгын да...
Йокымсырап утыра карт шулай
Кабан күлдәй кадим каегында.

Җилкәннәрдә җилләр черем итә,
Калкавычка кунган төклетура.
Кала чыр-чуына оеп, ярда,
Чабак көтеп, әнчек эт утыра.

## Метаморфоза

*Триптих*

1

бәбәгемә агып керә тыкрыклар урамнар
агып керә машиналар чаганнар һәм кешеләр
агып керә бәбәгемә матур тезле хатыннар
бүген оҗмахтан сөрелгән Хәва ханым төсләләр

керфегемә тиеп үтә тулышкан күкрәкләре
күзләремнең алмасы ла яньчелә аһ яньчелә
бәбәгемә агып керә буйга узган хатыннар
...бәбәгемнән агып чыга
яшь кенә

2

колагыма очып керә канаты сынган сүзләр
очып керә анекдотлар гайбәтләр һәм талашлар

очып керә колагыма бәхилләшкән авазлар
әнә сугым сараена кереп бара карт алаша

колак яфракларым лепердәшә ачы җилләрдә
көзен саргаер алар да саргаер дим аз гына
колагыма очып керә саргаешкан авазлар
...колагымнан очып чыга
кайтаваз гына

3

бугазыма шуып керә формулалар төркеме
шуып керә икмәк һава һәм тәмәке төтене
шуып керә бугазыма улым сулыйсы һава
улым сулыйсы һавадан тончыгып гөлләр ава

катлам-катлам сөрем ята бугазыма үпкәмә
гомер учагым шым гына сүрелә аһ сүрелә
бугазыма шуып керә икмәк һава һәм шәраб
бугазымнан шуып чыга
сүз генә

## Юл чатындагы кибет

...Бу кибеттә чиратлар юк.
Теләсә кем сатучы
йә сатылучы бу кибеттә.

Витриналарда—манекеннар түгел,
көяз кызлар тора ымсындырып;
үтә күренмәле күлмәкләре
биһуш итә һәрбер узгынчыны.

Үтә күренмәле узгынчылар
сер алырга керә бу кибеткә,
телсезләр тел сатырга килә,
шигырьчеләр—илһам...

Акылсызлар акыл сата монда,
акыллылар—акылсызлык...

Алдакчылар хаклык белән сәүдә итә,
сугымчылар гомер сата ваклап-ваклап.

(Бу кибеттә
тауарларның төгәл хак-бәясен
тик риясыз яшәгәннәр белә.)

Бу кибеттә бәхет кошының итен
саталар—
әшнәләргә генә...

Гөлчәчәк Галиева

## ГАЗЗӘБАНУ

### Коръән ашы

Икенче көнне Зарифлар өендә бик күркәм Коръән ашы уздырылды. Өй тулы чакырылган кунак. Нургалинең кендек әбисе Бибиҗамал карчык белән Хафизның кендек әбисе Гыйззелбәнатны бик зурлап, икесен рәттән Хаҗәрбикә абыстай каршына утырттылар. Коръәнне абыстай укыды. Мәҗлеснең барышын, аның бөтен тәртипләрен үзләрендә уза торган мәҗлес тәртипләре белән чагыштырып, зур игътибар белән өйрәнеп утырды Мәһирә. Абыстайның Коръәнне яттан, мәкам белән укуына һәм сүрәләрнең мәгънәләрен аңлатып бирүенә таң калды ул. Аның үз-үзен тотышы, сөйләм теленең бай булуы тәмам әсир итте Мәһирәне. Абыстайның үзенә битарафлык күрсәтеп, йә Зариф вә Зөлкамалның икенче килене, йә Нургалинең яшь кәләше дип тә әйтмәве, фәкать ерактан килгән кунагыбыз Мәһирә дип кенә атавына күңеле кителеп куйса да, сиздермәде, йөзенә дә чыгармады. Никахларын яңартмыйча торып, мәчетнең үзен танымавын аңлады, ниһаять.

Хаҗәрбикә абыстай, үзенә тапшырылган вазифаны җиренә җиткереп тәмамлаганнан соң, «миңа китәргә рөхсәт булса, кузгалыр идем, хәзрәт көтәдер», диде.

Абыстайны озаткач, Бибиҗамал карчык хуҗалардан сүз сорап алды:

—Җәмәгать, сез барыгыз да җыеннан соң, кичке уенда Мәһирәнең скрипкә, Нургалинең гармун уйнап җырлаганнарын ишеткән кешеләр. Минем күршеләрем шаккатканнар, сөйләп бетерә алмыйлар. Ә минем ишеткәнем юк, бик тә ишетәсем килә.

Коръән ашы бик күркәм үтте, Хак Тәгалә кабул итсен. Аш ашка, урыны башка, дигәндәй, ишек алдына, йә бакчага чыгыпмы җыр, музыка тыңлап алсак шәпнең дә шәбе булыры... Газзәбануым да җырларые дип өметләнәм. Нургали киткәннән бирле ни моңлы җырлаган кеше Зарифны да ишеткән булмады.

Шул вакыт өйалдыннан Хафизның тавышы яңгырады:

—Бабай, бабай дим, тизләк, шомолт янындагы колт аела.

—Рәхмәт, улым. Егетләр, әйдәгез минем белән. Болай булгач, бу тирәдә концерт ясап булмас. Бибиҗамал әбиегез ятып торсын, урын салып бирегез,—дип Зариф егетләрне алып чыгып китте. Сәҗидә тиз генә өстәл арасыннан чыкты да:

—Менә, җәмәгать, күрше-күләнне җыеп Коръән укытуга Аллаһы Тәгаләнең

*Ахыры. Башы 7нче санда.*

рәхмәте шушыдыр,—диде.—Шушы йортка үрчем бит бу. Хаҗәрбикә абыстай әле өенә дә кайтып житмәгәндер. Читкә жибәрмичә жыеп кына ала күрсеннәр инде. Быел үрчем ишлерәк булса, бер үрчемне сезгә бүләк итәрмен дигән иде әле Зариф абый. Бирсен Ходай. Коръән артыннан монда жырлап утыру килешеп бетмәс. Мин барыгызны да үзебезгә чакырам, жәмәгать,—диде.—Мин чәй әзерли торам, ә сез битләрегезне яулыкларыгыз белән урагыз да, шыпырт кына безгә элдерегез. Мондый вакытта кортлар кешеләрнең бимазалап йөрүен яратмыйлар. Әйдә, Маһирә, син скрипкәңне ал, Газзә гармунны алсын. Зөлкамал апайның монда кирәк булуы бар. Гыйззелбәнат апа, син Бибижамал әбине култыкла,—дип өстәде ул.

—Сөйләвең дә бик дөрес, Сажидәкәем, рәхмәт яусын! Миңа, бер сукыр карчыкка, үтенечемне аяк астына салмыйча, бәйрәм ясарга алынганыңа мең рәхмәт. Раббем сиңа үрчемне юмарт бирсәе, Зариф абыеңнан бер умарта бал корты. Үзеңә дә корт анасы бәхетен биреп, Нурисламыңны да бәхеткә күмсәңие,—дип Сажидәне сөендерүдән үзе дә сөенде әбекәй.

—Бибижамал әби, сезгә нинди жырны жырлыйк соң?—дип сорады Маһирә.

—Мин аның исемен әйталмыйм. Күршемдә Жәмилә исемле ундүрт яшьлек, иллә дә моңлы тавышлы кыз үсә. Ул аны язып та куйган, инде жырлап та маташа. Тагын бер тыңласам, өйрәнеп бетәрием ди. Мин аңа сездә буласымны әйттем, бәлки әле үзе дә күренер. Бар икән моң ул балада, аны тыңлап сукыр күзләремнән яшь чыкты. Бер жырыңның исемен «Әллүки» диде бугай. Анысын да язып алган инде, үзең киткәнче шул кызга тагын бер-ике жырыңны өйрәтсәң, бу авылда синең исемең, Маһирә, югалмас дип уйлыйм. Читенсенмә, бик зиһенле кыз ул. Мин белгән мөнәжәтләрне ике тыңлауда өйрәнеп бетте. Мине жылаткан жыры күңеленнән очып киткән кош турында...

—Ә-ә, «Тәфтиләү» дигән жыр ул!—дип, жырның исеме табылуына Нургали белән Маһирә сөенеп куйдылар.

—Сез мине шулкадәр кызыксындырдыгыз ул кыз белән. Бик теләп өйрәтер идем мин аны. Әйдә, Нургали, Бибижамал әбине илтә барганда, мин дә барыйм әле синең белән. Бүген үк танышыр идем,—диде Маһирә.

—Ай, рәхмәт, балакаем. Газзәбануны да калдырмагыз, аның да тавышы моңлы бит. Жәмиләне белә дә торгандыр әле ул. Бергә йөрегез, балалар, китәр көннәрегез дә якыная бит. Һай, ул ялгызлыкның ачыдан да ачы газаплары... Башына төшмәгән кеше генә белми аны. Үземнән беләм...

Маһирә скрипкәсен алып бераз көйләде дә, Нургали белән килешеп, башта көйне генә яңгыраттылар. Аннан Маһирә жырын да сузды.

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы.
Шат яратса да жиһанга, ят яраткан Раббысы.

И, мөкатдәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз ахрысы.

Тыңлаучылар барысы да моң эчендә, күзләр мөлдерәмә. Бу йөрәкләрне сулкылдатырлык жырны кабат тыңлау бәхете Бибижамал карчыкның үтенүе буенча оештырылгач, аны да күзәтәләр. Ул бит Жәмиләне тыңлаганда да, (скрипкәсез бит әле) сукыр күзләремнән яшь чыкты дип сөйләде. Әйе, бары да күрде, әбекәйнең күзләреннән яшь таммый, ул—ага. Хәзер Маһирә үзе дә бу жырны тыныч кына жырлый алмый. Элек ул аны бик жиңел жырлый иде. Авылга кайткач, монда төрле каршылыклар—төртмә сүзләр, никахны яңарту кирәклеге үзе генә дә күпме айкады аның күңелен, күз яшьләрен түгеп, ялгыз

үткән төннәре, Нургалиенә карата да шик-шөбһәләр, саный китсәң күп инде алар. Менә болар барысы да үтә хисле, нечкә күнелле бу кызнын үзен дә «Тәфтиләү» жырын күз яшьләрсез жырлый алмау халәтенә китерде.

Беравык тынлык. Ник бер тавыш, ник бер сүз чыксын. Тыңлаучыларның барысы да Бибижамал әбинең сүзен көтә. Менә шунда кемнендер әкрен генә үксеп алгалаганы ишетелеп китте. Ниһаять, әбекәй телгә килде:

—Маһирә, ерактан кайткан кунагыбыз, абыстай әйтмешли, ул белми әйтмәс, үзәк өзгеч жырыңны тыңлаганда сине йөзең, төсең, бөтен кыяфәтең белән күрәсем килде. Күрдем дә шикелле... колакларым белән. Янымарак кил әле...

Маһирә скрипкәсен калдырып, кыяр-кыймас кына әбекәй каршына килеп басты. Әбекәй аның кулларын назлап кына сыйпап, жыерчыклы яңакларына куйды. Аннан соң иреннәренә китереп, үбеп тә алды. Сүзсез генә йөзенә кагылды, башыннан, чәченнән сыйпап, үзенчә (дөресрәге, хатын-кызларча) назлап, сыпыргалап, буй-сынын да «күрәсе» килгәнен яшереп тормады. Иң кызыгы—Тәскирә белән Хафиз балакайларның әле сузылып, әле чүгәләп, әбекәйнең куллары йөреше артыннан калышмаска тырышып күзәтүләре булды. Барысын зур кызыксыну белән күзәтеп торган кунаклар, ни дияргә дә белмичә, әбекәйнең соңгы сүзен көтте.

Ниһаять, Бибижамал тынычланды булса кирәк.

—Мин бүген, яшемә күрә, колакларымның ишетү сәләтен югалтмавыннан, сукрайган күзләремә тугры ярдәмче булып калганын аңладым. Моны бер Аллаһымның кодрәте дими ни дисең... Әлхәмдүлилләһ! Фәкать чәчләрендә генә хаталанганмын икән. Мин Маһирәне Газзәбануымныкы төсле озын толымнар белән күргәнием.

—И-и, әбекәем, бер дә хаталанмагансыз бит. Минем дә толымнарым озын вә калыннар иде. Яңа модага ияреп кистереп ташладым бит, жүләр баш. Миндә алар бик тиз үсә. Икенче кайтуымда, Аллаһы боерса, әниемнеке төсле озын толымнарым белән күрерсез. Кистерәсемне белгәч, әтием дә каты тормады шул, ризалашкандай итте. Ә кистереп кайткач: «Девушка легкого поведения» дигән булды булуын, йомшак кына итеп. Үземә ошагач, аңа да исем китмәде,—дип, Бибижамалны бүлдереп, үзенең чәч тарихын кыстырды Маһирә.

—Бу жырыгыз өчен нинди генә рәхмәтләр әйтсәм дә аз булыр. И, үкенгәнием соң шул кечке уенны күрми калганыма. Син анда жырны язган шагыйрь Тукайның үзе турында, аның авыруы, үлеме турында да сөйләгәнсең икән. Бер көтү балаларга аның «Бала белән күбәләк», «Туган тел», «Гали белән кәжә» жырларын да жырлап күрсәткәнсең әле...

Түзмәде, Гыйззелбәнат та сүзгә кушылып китте:

—Беләсезме, ул балалар: «Нургали абый авылга бөтенләйгә кайтсыные да, Маһирә апай безнең мөгаллимәбез булсыные, рәхәтләнеп, сүзен тыңлап укырыек. Безгә Тукайның бик күп әкиятләрен сөйләрмен әле дигәние, үзе күренми,—диләр икән.

—Әйтәсе сүземне әйтеп бетерим әле,—дип, әбекәй янә сөйли башлады.— Нургали белән Нурислам—яшьтиләр. Икесе дә сүз куешкандай, бер төнне бер-бер артлы туып яталар бит. Шактый йөгерттеләр алар мине. Буйга житеп, өйләнүләрен дә бер көнгә туры китергәннәр, аллә белеп, аллә белми... Туйларын, тагы икесе килешеп, беренче көнне Нургалинеке, икенче көнне Нурисламныкы булды. И, ул туйлар, онытылырлык кынамы... Анда да нинди генә жырлар жырланмады.... Газзәбану белән Нургали Галиябану жырын жырладылар.. Әйдә, бүген туйларын искә алып, жырласыннар әле,—диде.

Шуны гына көткәндәй гармунын алып уйнап та, жырлап та жибәрде Нургали:

Читән аша төшкән чакта
Бүрәнәгә абындым.
Минуты ай, сәгате ел,
Газзәбану, сылуым иркәм,
Шулкадәрле сагындым.

Газзәбану аңа кушылып:

Таң әтәчләре кычкыра,
Аерылуның билгесе.
Бу бүләгем сине сөеп,
Хәлил бәгърем, җан кисәгем,
Чын күңелемнән кайнап чыккан
Вәгъдәләрем билгесе.

Маһирәгә шулкадәр үзенчәлекле булып яңгырады бу җыр, ачыклыйсы килеп, соравын да бирми калалмады.

—Нургали, чыннан да Газзәбану дип җырладыңмы? Әллә бүген генәме?

—Нәкъ шулай, Маһирә. Менә шуна күрәдер дә, туй кунаклары (ярты авыл халкы) бу җырны алардан, белмим, тикмәгә генә әллә ничә кабат җырлатмаганнардыр...—дип, сөенеп җавап бирде Бибиҗамал.

—Ә хәзер чират Нурислам белән Сәҗидәгә,—дип тә өстәде.

Янә Маһирә тынгы бирми:

—Сәҗидәләрнең җырласы җырларын никтер әйтмисең әле, әбекәй.

—Алар үзләре белә, кызым. Нургали, уйнап җибәр әле,—диде Бибиҗамал.

Нурислам Сәҗидәсенә тутырып бер карап алды:

Каш карасы күзендә лә,
Буй зифасы үзендә,
Ай-ли, Сәҗидә,
Агым суда, басма өстендә
Керләр чайкый сай җирдә,

—дип җыр сузса,

Сәҗидәсе исә:

—Ай туганда тудың мәллә,
Ай нуры бар йөзендә,

—дип дәвам итте.

Аннары икесе бергә:

Ай-ли, Сәҗидә,
Агым суда, басма өстендә
Керләр чайкый сай җирдә,

—дип җырладылар.

Нургали, Газзәбану, Нурислам, Сәҗидә—дүртесе бергә җырның кушымтасын җырлап, җырны тәмамладылар. Бибиҗамал:

—Һай, рәхмәт төшкерләре, күптәннән моның хәтле җан рәхәтлеге кичергәнем югые, әйтерсең лә, мин сезнең туегызда ләззәтләнеп утырам. Зариф, Зөлкамал, сезнең өчен бу җырлар бигрәк тә кадерледер. Ул вакытта нәкъ шулай җырладылар бит алар,—дип, сагынып искә алды. Маһирә үзенең көндәш икәнен дә онытып җибәрдеме:

—Газзәбану, карале, әгәр Бибиҗамал әби теге кичке уенда булган булса,

нинди генә хикмәтләр чыгармаган булырые. Сез белгәнсез бит инде аны. Ни Нургали, ни син искә алмагансыз,—диде.

—И-и, Маһирә, жыен көнне мин шуларны гына уйлый алырлык идемме? Нургали туксан жиде яшендәге карчыкны ничек борчымак кирәк, дип уйлагандыр. Торып-торып шаккатам мин сиңа, Маһирә.

—Гафу ит, Газзәбану,—дип, Газзәбануга жылы гына карап, башын иеп куйды Маһирә.

—Рәхмәт, гафу үтенергә кирәкми, Маһирә. Бәлки синең гаебең дә юктыр. Ирләр ир булып калалардыр инде. Хатын-кызның түземлелеген Раббем аларга, бәлки, белеп бирмәгәндер.

Көндәшләр арасындагы менә шушы кыска гына сүз алышу—аларның беренче чирканчык алып караулары булмады микән...

## Ташлыярга бару

Ул көнне барысы да Чаптар тирәсендә мәш килде. Дугадагы жиз кыңгырауны, шөлдерләрне кабат ялтыратып алдылар. Зур кара лаклы тарантаска чәчәкләре янып торган түшәген салды Газзәбану. Зариф кучәрләрне, тәгәрмәчләрне һәм башка дирбияларны да тикшереп чыкты. Бу төр эшләрдә бабайның иң зур «ярдәмчесе» һәм дә «кинәшчесе» билгеле инде—Хафиз. «Ир орлыгым бит ул минем, эшкә кулы ятып тора балакаемның»,—дип сөя ул аны.

—Улым, кузлага кайсы сырманы салыйк икән?—дип сораган булды бабасы.

—Теге калын, матул сылманы салыйк. Тышын әни чиккәнен. Миңа әти, син кучел булылсын, ди. Яла-а-л, дидем. Бабай, ул сылма кайда икән?

—Әниең беләдер, улым. Әнисе, ишетәсеңме?—дип, үзе белсә дә белмәмешкә салышып, килененә дәште Зариф.

—Кунак апай йоклый торган чоланда ул, балам,—дигән тавышка, бу матур ыгы-зыгылы манзараны кызыгып та, көнләшеп тә күзәтеп торган Маһирә, уянып киткәндәй:

—Хәзер, хәзер үзем алып чыгып бирәм,—дип, ашыгып өйгә йөгерде.

Бу вакытта атны чистартып, ялларын тарап торган Нургали әтисенең бу акыллы хәйләсенә рәхмәтле калды. Ник дисәң, иртәдән бирле Маһирә өчен күңеле борчулы иде аның. Баядан бирле келәт янында, кимсетелгән ятим баладай, сүзсез генә басып торган Маһирәсе бик кызганыч булып тоелды. Инде барасы килмәгән икән (барасы килмәвендә дә Нургали үзе гаепле түгелме соң? Хатынының теләген үтәп чакырмады бит ул аны), шомырт төбендә китабын гына укып утырса соң... дип уйлап та куйды әле. Шул вакыт Маһирәнең:

—Хафиз, менә ул син сораган сырма, әйдә, бергәләп куйыйк әле,—дигән үтә ягымлы тавышы Нургалинең күңелен күтәреп жибәрде.

—Ай, рәхмәт, кунак апасы, син булмасаң каян табарыек без аны. Улым, сырманы куйгач, икегез бергә Чаптар янына килегез әле. Аның сезгә нидер әйтәсе килә бугай,—дип, үзе янына чакырды ул аларны. Менә алар житәкләшеп килеп тә життеләр.

—Йә, Чаптарны карагыз әле, матурайганмы? Ерак бабайларга кунакка барырлык булганмы? Шуны ишетәсе килә аның...—дип, Маһирәнең иңбашларына назлап кына кулларын салып, ат янына якынрак китерде ул аны.

—И-и әти, матул булмыйчы... зелә матул. Мин бел нәлсә эшләсәм бабай миңа «маладис», улым, булдылгансың ди гел. Син дә маладис, әти, жылык-жылык итеп тола, чичти булган. Сыйпап кына толасы килә,—дип Хафиз атны сыйпаштыргалап та алды.—Кая, шикәл каптылыйм әле

үзенә,—дип кесәсеннән бер кисәк шикәр алып учына салды да Чаптарга сузды. Маһирәнең коты алынып:

—Һай, җаным, кулынны тешләмәсен,—дип, Хафизны үзенә таба тартты.

—Нишләп тешләсен... син биглӓк инде...—дип көлеп җибәрде Хафиз.

—Мә, үзең билеп кала...

—Юк, юк, куркам, әйтә генә күрмә,—дип, чигенеп, Маһирә Нургалиенә елышты һәм икесенә дә рәхәт булып китте... (Бу минутларда аларны баядан бирле күз уңыннан җибәрмәгән Газзәбану нишләргә дә белмәде. Соңгы көннәрдә бераз тынычланган кебек йөрсә дә, ниһаять, көндәшлек утында гомере буе туктаусыз яначагын аңлады.)

—И, кулкак куян. Мин кулыксам, бабай шулай дип әйтә. Әти, әти дим, кунак апай да балсын әле безнең белән, көләсене кителә ул,—дип, Хафиз әтисенә дәште.

—Үзең чакырдыңмы соң? Ул сине күбрәк ярата бит.

—Яла-ал, чакылам алайса. Кунак апай, әйдә син дә бал безнен белән Ташлыярга. Талантас зул, син әни белән утылылсың. Әти белән без кучелал, кузлада утылылбыз. Чапталдан да кулыкмый башлалсын,—дип, күңелендәгесен тезеп китте сабый. Кунак апай «ә» дә димәде, «җә» дә димәде. Бары «и, сабый» дип Хафизны кочаклап, яшь аралаш көлде генә.

***

Жигүле Чаптар «нигә утырмыйлар инде» дигәндәй тынгысызлана башлады. Аякларын да тыпырдаткалап куя. Әнә, әти-әнисе белән Тәскирә дә, Хафизны озатып калам дип, кереп җиттеләр. Тәскирә кулында кечкенә төенчек, Нурислам кулында да нидер бар. Урам як капкадан Гыйззелбәнат, үзенең ашап түгел, карап та туйгысыз катлы паштетын күтәреп килеп керде. Өйдәгеләр никтер озаклыйлар... Чаптарның «башка көтәр чамам юк» дигәндәй кешнәп җибәрүе булды, шуны гына көткәндәй, әче балы белән тулы чирекле шешәсен күтәреп Зариф килеп чыкмасынмы... Аның артыннан, гадәттәгечә, шактый зур төенчек тоткан Зөлкамал күренде. Ниһаять, гармунын кочаклап, кулларына Ташкент күчтәнәчләре салынган затлы сумкасын тотып, яшь кәләшен җитәкләп Нургали дә күренде. Малкайның сагынып яшәгән яшь хуҗасы чыкканны күргәч шатланганын сиздерергә тырышуы үзе бер могҗиза. Ул аның күзләрендә дә, башын борып, муенын сузып Нургалигә якынаерга теләвендә дә, иреннәрен дерелдәтеп, нидер әйтергә теләп, тамак төбеннән кыска-кыска гөрелте авазлары чыгаруында да... Бәлки, ул, безне ташлап китмә, кал туган өеңдә,—дип әйтергә телидер. Аңлады Нургали, ничек кенә аңлады әле. Малкаеның үзенә сузылган башын кочаклап, яңакларыннан үпте. Икесе дә мөлдерәмә күзләре белән бер-берсенә карап тынып калдылар. «Рәхмәт, Чаптарым, минем сагынуымны башкалар да синең кебек аңласалар иде»,—диде ул. Әйе, ат белән ир-атның бер-берләрен тирән аңлый алуы—серләрнең-сере.

Менә шунда көтә-көтә тәмам түземлеге төкәнгән Тәскирә балакайның:

—Хафиж кайда, нигә чыкмый ул?—дип кычкыруы барысын да айнытып җибәрде. Кунак апай тиз генә янына килеп, инде җылый ук башлаган сабыйга:

—Хәзер чыга, әнисе аңа яңа киемнәрен киертә калды. Белә бит ул синең үзен озатырга керәсеңне, матур булсын дигәндер,—диде. Тәскирәгә бу сүзләр ошады, күрәсең.

—Менә минеке дә яңа күлмәк. Матулмы, шиңа ошыймы? Минем дә Хафизга күлшәтәшем килә,—дип, күлмәгенең бөтен җирен күрсеннәр өчен әйләнгәләп тә алды.

—Сүбхәәналла, күз тимәсен.

—Бигрәк матур күлмәген,—дип җырлап җибәрерлек булган бу! Кесәләре дә бар икән... Яна күлмәкне котлап бүләк бирим әле,—дип, кунак апасы кул сумкасыннан кечкенә генә бик матур кульяулык алып кесәсенә салды. И, шатланды да соң сабый... Менә шул вакытта әнисе белән Хафиз да пәйда булды. Тәскирә анын баскычтан төшеп җиткәнен дә көтмичә, каршысына йөгерде. Күлмәген күрсәтте, кулындагы кечкенә төенчекне биреп:

—Монышы шина, Фәлгат белән Маншулага. Төеншекне шунда белгә шишегеж, Тәшкиләдән күчтәнәш, диген, йәме. Шау бул, тиж кайт, йәме,—дип, саубуллаштылар сабыйлар. Мәһирә аларга карап сокланып «Гөлҗәүһәр белән Мөхәммәтнур да шушылай үскәннәрдер, бичаралар» дип уйлап куйды. Нургали башта, «бу тел бистәләренең сүзләрен тыңлап кына бетерерлекме» дип уйлап, «главный кучерны» назлап күтәреп кузлага утыртты. Газзәбануын да шулай кулларында алып килеп утыртмакчы иде дә, Мәһирәсе тоткарлап, аз гына сонга калды шул. Аннан моңсу гына басып торган яшь кәләше янына килеп, анын өйрәтүенчә (рус теле укыта бит):

—Ну, милая моя, не скучай без меня, жди,—дип, янакларыннан үбеп алды. Шулчак түземсез Тәскирә:

—Әни, әни, нәлшә диде ул, нәлшә әйтте?.. Әйт инде,—дип тыпырдый ук башлады.

—Туктале, кызым, әтиен әйтер әле... «Әнә әтиеннән сора»,—дип, әнисе Мәһирәдән күзләрен алмады. Газзәбануны әйткән дә юк инде... Көндәшләрнен әле монарчы тел яшергәннәрен Сажидә белмиме сон?

Мәһирә сүзсез генә, күзләрен мөлдерәтеп Нургалиенә карап алды да, мангаеннан, бит урталарыннан кат-кат үпте. Һәм ни генә булса да, иренә булган мәхәббәтенең сүрелмәячәген, хәтта шушы шартларда да көчәя генә барганын аңлады. Башкаларга да шуны сиздерәсе килде, ахры.

Инде Нургали дә тарантаста үз урынын алгач, күчтәнәчләрне дә урнаштырып бетергәч, Зариф: «Әйдәгез, күршеләр, дога кылыйк» диюгә, һәрбере урын табып утырыштылар. Юл догасына сабыйлар да бик теләп кушылды. Дога тәмам. Нурислам капканы ачып җибәрсә, шаккаттылар. Янәшә-тирәдәге бала-чага бары да урамда, капка каршында җыйналып көтеп торалар. Аларны күрүгә Зариф: «Ай, рәхмәт төшкерләре. Кызым, бар әле, өстәлдәге кәнфитләрне алып чык та, сөендер үзләрен,—дип Мәһирәгә дәште. Ә балалар: «рәхмәт, кунак апай», «рәхмәт яусын, кунак апай» дия-дия чыр-чу килделәр. Менә шунда Мәһирә уйга калды. «Күнелемә бик якын вә кадерле бу авылның балалары өчен миңа «кунак апай» гына булып калырга язгандыр, күрәсең». Ә Чаптарның үз уе—кузгалып китәргә әзерлеген белдергән бөтен җаны, тәне хәрәкәттә. Бу хәрәкәттән—җиз кыңгырау вә барча шөлдерләр бәгырь кылларыңны тибрәтерлек итеп чыңлыйлар. Өстәвенә малкайның дәртләнеп кешнәп җибәрүләре... Хафизның куанычы эченә сыймый, тиз генә әтисенә борылып: «Әти, дилбегәне бил үземә, син галмуныңны уйна,—диде.

Зариф та оныгына кушылды:

—Авылны чыкканчы Хафиз алып барсын, ә син улың кушканны үтә, уйнап бар. Ташлыяр җыенына барасыз бит. Атыбызның холкын, малаеңның атны йөртә белгәнен күрдең бит инде, тыныч бул.

Ә Хафизга:«Әйдә, балакаем, бисмилланны әйт тә, Аллага тапшырып кузгат атыңны»,—диде дә, үзе читкә тайпылды.

Кечкенә генә кучер, нәкъ бабасына охшатып, «Әйдә, малкай, атла!» дип чак кына дилбегәне тартып куюына, Чаптар кузгалып та китте. Нургали Газзәбану ягына башын кыңгыр салып, әнисе яраткан «Ал Зәйнәбем» көен уйнап җибәрде. Озатучылар барысы урамга чыгып, һәркайсы үз уе, үз теләкләре белән кадерлеләрен күздән күмелгәнче карап калдылар.

***

Нургалиләр Ташлыярга киткәч, өйдә ниндидер эч пошыргыч бушлык хасил булды. Янында «кунак апа» дип бөтерелеп йөрүче, сөйләшергә яратучы Хафизның да юклыгы Маһирә өчен бу бушлыкны тагы да тирәнәйтте. Шушы йортка илаһи ямь өстәп, бөтенесен авызына каратып торган сабыйны әбибабасы да бик юксына. Хафиз булмагач, Тәскирә дә керми. Аларның икесенә карап, үзара сөйләшкәннәрен тыңлап йөрү Маһирәгә аеруча зур юаныч булган икән. Аның хәзер иң борчылганы—никахларын яңартуның болай озакка сузылуында төп сәбәпче Нургали үзе түгел микән? Бәлки ул минем белән араны бөтенләйгә өзеп, авылда үзләре генә яшәүне телидер... Алай була калса миңа нишләргә? И, Раббем, рәхмәтең вә ярдәмеңнән ташлама!

Әгәр миңа ялгыз калырга туры килсә, сөйгәнемнең төсе дип карап юанырга балам да юк бит ичмасам. Газзәбанудан көнләшүләрем дә аның ике тамчы су кебек Нургалиенә охшаган баласы булуында түгелме соң?.. Нигә, нинди гөнаһларым өчен мине ана булудан мәхрүм иттең икән, Раббем? Үзем дә гаепле бит... Бары бер гинекологның фаразлавына ышанып, бер чара күрмичә еллар буе ваемсыз йөр инде.

Нургалиемнең һәрвакыт янымда булуы, өстәвенә бик яратып җырмузыка белән шөгыльләнүләребез, аның гыйлем эстәүдә дә барыбызны сокландырып ирешкән уңышлары—барысы да уртак мәхәббәтебезне гел ныгыта барды. Күрәсең, соңгарак калып килгән шашкын мәхәббәтем тәмам сукрайткан ахры мине. Нургалигә нәрсә—баласы бар, Газзәсе миннән дүрт яшькә яшьрәк тә бит әле. Әнә, малае белән ничек масая ул... Мине «матур апай» дип әйтүеннән дә бик тиз туктатты. Ә ничек матур итеп, яратып әйтә иде ул аны. «Матур апа» дигәнне ишетү үземә дә бик рәхәт булган иде шул. Шуны сизеп туктаткандыр да әле. Хәзер янадан икенчесенә узу өчен дә бөтен чарасын күрәдер әле... Гыйззелбәнаты янында. Көн дә мунча, бик тыныч ак келәт төнен дә, көнен дә гел алар хозурында, нишләп узмасын ул... Ә мин җүлә-ә-әр... Әгәр монда Нургалиемә охшаган бер кечкенә балам белән кайткан булсам, «никах яңарту», «теге ярамый», «бу ярамый» дигән эчпошыргыч сүзләр булыр идемени. Өч айга якын мулла никахы белән ир хатыны булып яшәп, иреңне бер кочаклап алырга да ярамасын әле... Янымда балам булган булсамы, хәтта гел никахсыз булса да, ничек кенә яратырларые... Сабыйның ни гөнаһысы бар? Мин Хафизны карап туялмаган кебек, Газзә дә карасына коелып йөрмәсие. Барысы да килешеп, кайткан көнне үк никахын да укыткан булырлар иде.

Тукта әле, тегеләр Ташлыярда чакта нигә миңа да Гыйззелбәнат апа белән сак кына киңәшеп карамаска...

***

Кыяр-кыймас кына килеп кергән Маһирәне ачык чырай, тәмле сүз белән каршы алды Гыйззелбәнат. Хуш исле үләнле чәе, тәмле ризыклары белән сыйламакчы булса да, «юк-юк, әле генә өстәл яныннан, бер кабар урыным да юк, рәхмәт, мәшәкатьләнмәгез»,—дип тиз генә тынычландырды ул аны.

—Кайтканнан бирле сезнең белән сөйләшәсем килеп йөрдем, моңарчы җае чыкмады. Әгәр бүген вакытыгыз булса, сезнең белән икәүдән-икәү генә сөйләшер сүзләрем, кайбер ачыклыйсы сорауларым да бар.

—Аллага шөкер, бүген тыныч әле. Төнге өченче яртыда үз җае белән, мине дә, әнкәсен дә артык азапламыйча гына туган, тупырдап торган, бик күркәм ир бала кабул иттем. Ходайның рәхмәте белән сөннәтле булып туды. И-и, әти-әнисенең сөенгәннәре инде... Үзем дә бик сөендем... Бәхетле бала булсын, саклагыз, кешегә бик күрсәтмәгез, дидем. Андый балалар гадәти генә булмыйлар. Алар физик яктан да, акыл үсеше ягыннан да, зирәклеге,

чибәрлеге белән дә башкалардан аерылып торалар. Менә бүгенге сабый да берничек тә анлатып булмый торган нурлар бөркеп туды, әле ул гынамы, кулларыма алуыма таң нурлары гел ана юнәлгәндәй булды. Нәкъ таң атканда туды бит, җанашым. Алар дөньяга килгәндә үк чиста булып туалар. Аллаһының рәхмәте белән, мондый ир балалар фәрештәләр тарафыннан чистартылып, сөннәтләнеп туалар. Андыйларны—Аллаһы Тәгаләнең сөйгән бәндәсе диләр. Гадәттә алар күркәм холыклы, сабыр, барлык җан ияләренә мәрхәмәтле, игелекле булып гомер кичерәләр.

Бүген төнге йокым бүленсә дә, бер тамчы армадым, кәефем дә әйбәт. Без синең белән тынычлап сөйләшә алабыз. Шулай да, капкамны эчтән бикләп керим әле, кирәгем чыкса дөбердәтерләр,—дип Гыйззелбәнат җәһәт кенә чыгып китте. Маһирә тиз генә бөтен өй эченә: тәрәзә төпләрендәге шау чәчәктә утырган гөлләренә, өй җиһазларына күз йөртеп алды. Мондагы пөхтәлеккә, затлылыкка сокланып, әйе, Бибиҗамал әби сөйләгәннәр бары да дөреслеккә туры килә,—дип уйлап куйды.

Бүгенге изге хезмәтеннән бәхет тапкан кендек әби балкып килеп керүгә:

—Гыйззелбәнат апа, сөннәт белән туганнар турында ишеткәнем юк иде. Безнең Нургали дә шулай тумады микән? Син сөйләгәннәр бары да ана туры килә бит...—диде ул.

—Мин Хафизның гына кендек әбисе. Аны сөннәткә Зариф бабасы утыртты. Нургалиең турында берни дә әйтәлмыйм. Бибиҗамал әбиең беләдер инде аныкын,—дип елмаеп куйды.

—Тагын нинди сорауларың бар икән, күрше?

—Анысы үзем турында,—дип, үзенең борчуларын оялып кына сөйләп бирде.

—Ярар, җаным, оялма. Сәбәбен ачыклый алсам, соңыннан ярдәм дә күрсәтә алсам, миннән эш калмас, тырышырмын. Әмма бер шартым бар—моны беркем дә белергә тиеш түгел, хәтта Нургалиең дә...

—Мин караганда эчең буш һәм йомшак булырга тиеш, затлы киемнәреңне сал, менә сиңа үземнең чиста халатым. Безгә юынып алырга кирәк,—дип, тәрәзә пәрдәләрен ябып, Маһирәне өйалдына алып чыкты һәм бөтен әзерлек эшләрен шунда башкардылар. Аннары ятагына җайлап кына яткырды да, үзе чаршау артына кереп китте. Аннан ап-ак халаттан, кулларына бик юка резин перчаткәләр кигән Гыйззелбәнат килеп чыккач, башта күзләренә ышанмады Маһирә. Караңгы бер татар авылына каян килгән ул? «Юк, бу ханым Көек авылының гади кендек әбисе генә түгел, гыйлем-мәгълүматы булган шәфкать туташы булырга тиеш,—дип нәтиҗә ясады. Ә бәлки, Бибиҗамал әби әйткәнчә, «духтыр» да булырга мөмкин.

Өйгә спирт исе таралды. Маһирә өмет тулы күзләре белән аның һәр хәрәкәтен күзәтеп ятты. Карап, тикшереп бетергәч, үзенә нәрсә дип әйтәчәген, балаларга хас хыял катыш фаразлый ук башлады. «Бер дә борчылма, балагыз булачак, аның өчен бераз дәваланырга гына кирәк булыр»,—дияр ул. Юк, алай димәде шул. Бераз уйланып торды да:

—Минемчә, балага уза алмавыңның сәбәбе бер генә. Аналыгың өлгереп җитмәгән. Урысча аны «детская матка» диләр. Ничә яшьләрдә син хәзер? Җавап бирәсе урынга сулкылдап елап җибәрде Маһирә.

—Менә монысы кирәкми-и... Минем сиңа хөкем карары чыгарганым юк бит әле. Кечкенәне зурайтырга була, аның юллары бар. Менә сиңа бер белгеч: «балагыз булмаячак» дигән. Ул вакытта син ничә яшьтә идең?

—22 яшьтә идем.

—Сиңа берничә курс массаж, диңгездә йөзү, күбрәк җәяү йөрү кирәк дип тә әйтмәделәрме?

—Юк шул.

—Шуннан соң ничә ел үтте инде?

—Өч ел, өч ел, Гыйззелбәнат апа җаным, мина хәзер 25 яшь. Мине «яшь кәләш» диләр. Ә мин Газзәбанудан дүрт яшькә зуррак. Шуны белдерәсем килмәгәнгә яшемне әйтәсем килмәгән иде шул.

—Менә нәрсә, акыллым, бераз соңгарак калмадык микән дигән шигем бар барын... Тик «өметсез шайтан гына» дигәндәй, нигә өметне югалтырга... «Ятып калганчы атып кал» диләрме әле, башлыйк без ул чараларны, шыпырт кына. Монда тагын бер атна торасыгыз бар. Ташкентка кайткач дәвам итәрсез. Ничек тә хәбәрләшербез.

—Бик күп рәхмәт сезгә. Диңгезенә дә барып була, мин тырышачакмын, Аллаһы боерса! Үзегез әйтмешли, «өметсез шайтан гына»,—диде Маһирә.—Гыйззелбәнат апа, зинһар ачулана күрмәгез. Тагын берничә соравым бар. Үзегез турында бик тә беләсем килә. Әгәр ул сезнең ниндидер яшерен сер икән, ышана күрегез—ул миндә, фәкать минем күңелемдә генә калачак. Беләсем килгәннәре: сез кем, кемнең баласы, кайда укыдыгыз, нигә сез ялгыз, ничек бу авылда калдыгыз?

—И, бала, бала, минем иң авырткан җиремә кагылдың бит... Биш сорау. Шушы биш сорауның бөтен җаваплары—ул минем авыр, фаҗигале тарихым. Бу авылда аны бары бер кеше, бары бер изге җан иясе генә белде. Һәм ул аны чәчми-түкми үзе белән алып та китте. Ул минем ирем иде, урыны җәннәттә булсын! Бары кырык җиде яшендә дөнья куйды. Үзем дә саклый алмадым, ахры. Балаларыбыз булмады, менә ни өчен мин ялгыз...—Ярар, акыллым, бар сорауларыңа да җавапларымны ишетерсең. Әллә ни гомерем дә калмагандыр. Авыр язмышымның тарихы тагын кемнеңдер күңеленә салынып, вакыты җиткәч, аның дөньяга чыгар көне дә якынаядыр. Бәлкем, бер Раббем Үзе минем хозурыма сине җибәргәндер. Тик шуны онытма, вафатыма кадәр бу бары синең үз күңелеңдә генә сакланырга тиеш. Тыңла.—Казанның татар бистәсендә туып-үскән гади генә бер кыз мин. Иң элек әтием-әнием турында (урыннары җәннәттә булсын!)... Әнием Бибисара—бистәнең генә түгел, бөтен Казанның иң оста кәләпүшчесе булган. Ул үзенең өч кызын да—Фәхрелбәнат, Сәйделбәнат, Гыйззелбәнатны (анысы мин инде) кечкенәдән үк кәләпүш чигү сәнгатенә өйрәтте. Әтием Хәмидулла—оста тегүче, ирләргә каракүл бүрекләр, каракүл якалы затлы пәлтәләр текте.

Ул бала чагында бер урыс авылында ике елдан артык тегермәнче малай хезмәтен башкарган. Анда ул урысларның үзләреннән дә остарак итеп урысча сөйләргә өйрәнгән. Аларның диннәрен, дини бәйрәмнәренең мәгънәләрен дә яхшы белгән. Шул урыс авылында чиркәү каршындагы школга үзе теләп укырга йөргән. Язуын да дөрес язган. Әти турында: безнең Хәмидулла поп янында поп төсле, мулла янында муллага әйләнә, дип сөйли торган булганнар. Әтиебез гыйлемгә тартылган. Үзенең ике улын да Апанаев мәдрәсәсе каршында башлангыч мәктәпкә укырга биргән. «Аена өчәр тәңкәдән, икегезгә алты тәңкә түлим, ярый әле ат асрагач, сезне үзем йөртәм, тулай торакта торсагыз ун тәңкә түлисе булыры. Ишетсен колагыгыз, сабагыгызны тырышып укыгыз, минем йөземә кызыллык китермәгез. Апанаев мәчете бу мәктәпкә үз кесәсеннән өстәмә акча да биреп тора. Кирәк вакытларында аларга атым белән дә, мәчет файдасына сәдакам белән дә булышырга тырышам. Барысы да сезнең өчен бит»,—дип тукып торырга ярата иде. «Кызларымны да шунда укытырыем әле, кызларны алмыйлар шул», дип көрсенеп тә куйгалый иде. Без үз өебез, үз көнебез дигәндәй, үз көчебез белән дөнья көттек. Баеп та китмәдек, ярлы да булмадык. Барына шөкер итеп, югына зарланмый гына сабыр итеп яшәдек. Мин үзем түбәтәйне матур чиксәм дә, яратып башкармадым ул эшне, әни кушканга, акча кирәк булган өчен генә. Абыйларымның дәрес әзерләгән вакытларында гел алар янында булырга

тырышаем. Кумадылар алар мине, киресенчә, күңелемә эләктергәннәрне тынлап карарга яраталарые, бигрәк тә кече абыем Сәлимҗан. Әтигә еш кына әйтерие: «Без белгәнне су кебек эчә бит бу. Ана малай булып туарга кирәк булгандыр, мөгаен. Әти, син дә бер тынлап карале төпчегенне!» Әти мыек астыннан гына көләрие. Әни бик каршы булса да, мине урысча укырга, язарга өйрәтте әти. Сөйләшергә дә өйрәтү өчен, минем белән урысчалап сөйләрие, әни югындарак. Ну, әнинең кәефе китә иде инде... «Нәрсә, син аннан маржа кызы ясамакчы буласыңмы, Бер Аллаһым, Үзе сакласын! Әйттем исә кайттым, тәүбә, тәүбә, тәүбә, дияр иде җанашым.—Әнә түбәтәен чиксен, хатын-кызның үз эше дә баштин ашкан...» «Син бит, кызым, кеше кешесе булачаксың. Абыйларың, әтиеннең коткысына бирелмә. Алар ир кешеләр, аларга килешә дә, кирәк тә ул. Син хас үзеңә төшкән вазифаларны тирәнрәк үзләштерергә тырыш. Вакыты җиткәч, кияүгә чыгарсың, алдыңны тутырып балалар табарсың, боерган булса»,—дип, еш кына мине дә үгетләрие. Мин ул чакта бала гына бит әле, әнинең әйткәннәре миңа «ике ятып бер төшемә керде» кебек, бер колагыма керсә, шунда ук икенчесеннән чыгып оча торды. Әтиемнең атлы йомышларын күтәп кенә торам, әни күрми дә кала, мин чыгып таям. Әти янында утырып йөрергә, аның сөйләгәннәрен тыңларга яраттым. Абыйларым мәктәптә гарәпчә укырга, язарга өйрәнде, алар янында мин дә. Аннан дин сабаклары, догалар өйрәнү. Коръән белән танышу, арифметикадан дүрт гамәлне өйрәнү китте. Сәлим абый мине дә өйрәтә. Әти рәхмәт укый һәм яратып, «безнең хәлфәбез» ди. Ә абыем аңа бик куана иде. Менә бу дәресләребезгә әни дә каршы килмәде. Киресенчә, «тырыш, кызым, тырыш, бәлкем, бер яшь муллага кияүгә чыгып куярсың да, абыстай булып китәрсең...»—ди башлады. Еллар үтә торды, абыйларым мәдрәсәнең икенче бүлегендә укуларын дәвам иттеләр. Анда атнага ике мәртәбә рус теле, география, татар һәм гарәп телләре грамматикалары, динебез тарихы һәм башка фәннәрне өйрәнделәр. Әтием алар белән бик горурлана иде. Ул бүлекне тәмамлагач, аларны Малмыж ягындагы ике зур мәчеткә указлы мулла—имам хатиб итеп җибәрделәр. Фәхрелбәнат апайны үзеннән шактый олырак бер муллага кияүгә бирделәр.

Беркөнне әти мине үзе янына утыртып, күптәнге дуслары Иван Васильевич дигән кешеләргә алып китте. Юлда сөйләп барды, ул кеше теш врачы, хатыны Мария Федоровна хатын-кызларны дәвалый икән. Болак буендагы ике катлы кирпеч йортта яшиләр икән. Барып кердек, бик мөлаем кешеләр, урыслар димәссең дә. Татарча да беләләр. Минем белән татарча сөйләшә башлаганнарые, әтием: «Үзегезчә генә сөйләшегез, сезнең телне белә ул»,—дип тора бит әле. Кая инде ул, минем алар кебек сөйләшә алуым. Мине калдырып, әти Иван Васильевич белән каядыр китте. Мария апа исемемне сорады. «Безгә әйтергә катлаулырак икән. Гюзялбанат дисам ачуланмыйсыңмы»? «Юк, ничек телисез, шулай әйтегез», дидем. Ошаттым мин ул исемне. Үзе җуан гына маржа икән, иренә караганда шактый карт төсле күренде. Юк, хатыны түгелдер, йә аның апасы, йә берәр ерак теткасыдыр әле дип уйлап куйдым. Ул миңа өйләренең бөтен җирләрен күрсәтә башлады. Андагы бүлмәләрнең саны да чутсыз, эчендәге байлыкны әйтеп тә торасы юк. Идәннән түшәмгә кадәр көзгеләрдән, идәннән минем биеклектәге сәгатьнең сукканындагы тавышыннан гына да «абау, нинди сихри дөньяга эләктем» диярсең. Икенче катка алып менеп китте бу мине. Барысына да шаклар катып, артыннан барам. Булса да булыр икән җуанлык, бөтен Казанына бердер ул, мөгаен. Шунда янадан күрер-күрмәс кенә калган Иван абый күз алдыма килә. Озын буйлы, киң җилкәле, якты йөзле нинди мәһабәт ир кеше. Безнең әти дә кечкенә түгел юкса, ә бу абый аннан бер башка биек кебек күренде. Йортның икенче каты Мария апаныкы булып

чыкты. Анын эш бүлмәсендә әллә ниләр бар... Монда идеальный чистота булырга тиеш, ди бу. «Рәзе иты чистота?» дим тузанлы идәненә күрсәтеп. Шундый итеп, арт саннарын дерелдәтеп көлеп җибәрде, минсинайтим, көлгәндә чибәрләнеп тә китә икән үзе.

—Гюзялбанат, матурым, мина хазер бер бик важный ханум килә, шушы булмане гына юа алмассынмы?—ди.

—Нишләп юмаска, пажаласты, кайда сезнең чиләктер, чүпрәктер и таки дали?—дигән булам бит әле, кыюланып китеп. Ярты сәгатьтә бөтен бүлмәсен ялт иттердем. Сүзсез калды җуан апаен, исе китеп, телен шартлатып куйды.

—Аста аш бүлмәсендә мискада итле шулпа бар, киросинканы ягып, шунда гына утыртып куйсаң, бик яхшы булыр,—ди.

—Харашо, мука, картушка, лук таммы?

—Там, там...—тагы әллә нәрсәләр, диде шунда... Чыннан да, барын да бик җайлы гына таптым. Үзебезчә токмач ясадым. Аш әзер булганда әтиләр дә кайтып җитте. Үзебезнең тәртип белән өстәлләрен дә көйләдем. Мария апа исе китеп:

—Ай, жаным, Гюзялбанат, мына рахмат,—дип минем ничек итеп бүлмәсен чистартканымны да сөйләде. И, әтинең сөенгәннәре шул чакта... Ашны да бик тәмле дип ашадылар, рәхмәт төшкерләре.

—Зрягя гына яратмыйм мин татарларны, алар бик чиста, тамле пешералар, главный—ялкау тугел, матур итеп яши белалар. Акыллы кеше татар, укыган кешене уважать итялар. Граматныйлар алар, честныйлар,—дип, мина да карап-карап ала Иван абый.

—Иван Васильевич, сез каян өйрәндегез безнен телне?—дип, сорады әти.

—Мин Рязаньга тугел, хан иленә, татарлар Казанына килдем эшка. Анын телен билярга тырышмасан, кайсы татар сине уважать итсен. Аннан врачларнын үз законнары бар—ул авыруны башта теле, ачык юзе белан давали башларга тиеш,—дип җавап бирде Иван абый. Менә шул көнне мине үзләренә эшкә чакырдылар. Без ризалаштык.

«Яхшы хезмат итса, хакын да яхшы туларбыз»,—дип кәгазъгә төрелгән нәрсәдер бирделәр мина. Кайтканда ачып карасак, йөз илле сум акча булып чыкты бу. Күзләребез шар булды, ни әйтергә дә белмибез...

—Бу бик күп, артык күп, кызым, болай ук килешмәс. Мин үзем сөйләшермен икесе белән дә,—диде әтием.

Менә шулай итеп мин аларда эшли башладым. Әти иртәгесен ат белән китерә дә, кичен алып кайта мине. Атнага бер көн ял бирәләр. Мина ул чакта ундүрт яшь иде. Дүрт ел эшләдем. Бернинди училище да бирә алмаслык гыйлемне дә, кем уйлаган, гомерем буена үкенерлек коточкыч фаҗигамне дә шуларда алдым. Алар минем, бәһаләп бетергесез бөек остазларым да, һәм шул ук вакытта мина табигатьнең иң зур бүләге булган хатын-кыз бәхетеннән мәхрүм итүчеләр дә... аеруча Мария Федоровна...

Соңгарак өйгә ял көнемдә генә кайта башладым. Үземә аерым бүлмә бирделәр. Эш күп, барын да яратып, теләп башкардым... Мария Федоровна үзенең чын практикантына әйләндерде мине. Зирәклегемә, һәр нәрсәне тиз аңлавыма исе китә иде.

—Син бик талантлы кыз булып чыктын бит але, Гюзялбанат, иң зур ярдамчыма айланып барасын,—дип гел мактап торды.

Бу йорттагы тәртипләргә гаҗәпләнгән чакларым аз булмады. Минем өчен бүлмәне беренче катта көйләделәр. Кухняга да якын, килгән-киткәннәрне каршы алырга, озатырга да җайлы дигәннәрдер. Үземнең икенче катта, Мария Федоровна тирәсендәрәк буласым килгән иде. Беренче катта Иван Васильевичның йокы бүлмәсе һәм ике эш бүлмәсе, ул аларны беренче,

икенче кабинет дип әйтә иде. Беренчесе—теш суыра һәм яна тешләр куя торганында чисталык, Мария Федоровна әйткәнчә, идеальный булырга тиеш. Үзләре белән таныштырганда супруг, супруга диделәр, ягъни ир белән хатын булалар инде. Ә үзләре аерым йоклыйлар, хәтта йокы бүлмәләре дә икесенеке ике катта. Йокларга ятканда бер-берсенә «Машенька милая», «Ваня дорогой» дип үбеп, тыныч йокы теләп, һәрберсе үз бүлмәсенә кереп китә. Иртән торгач, тагын шул ук хикмәти хәлләр. Иртәнге ашта очрашканда шул ук назлы сүзләр белән бер-берсенә хәерле иртә телиләр. Мин аларынаияләндем шикелле, әмма һәр ашау алдыннан һәм соңыннан өйнең бер почмагына куелган, үзләре икона диләр, шунын каршына басып чукыналар. Ярар, өлкән яшьтәге җуан маржа чукынсын да инде. Ана килешә шикелле. Ә менә япь-яшь, типсә тимер өзәрлек, урыска бөтенләй ошамаган матур ир кешегә чукыну килешми төсле күренә иде мина. Икесенең дә күкрәкләрендә алтын чылбырга эленгән алтын тәре. Кайвакытларда аны үбеп тә алалар әле. Башта бик сәерсенсәм дә, әнигә дә, әтигә дә берни дә әйтмәдем. Шулай да бер көнне әнигә үземнең иярә алмаган кайбер якларын сөйләргә булдым.

—Кызым, син күпне күрмә, алар бит без түгел, урыс кешеләре. Аларнын үз диннәре, үз гадәтләре. Сине какмыйлар, сукмыйлар. Эшләгәненә әйбәт түлиләр.

—Әни, синең аларны күргәнең бармы?—дип сорадым.

—Юк, кызым. Каян күрим ди. Атаң сөйләгәннән генә беләм. Әтиең бик мактый аларны,—ди.

—Әни, әйдә минем ял көнемдә бәлеш пешереп кунакка чакырыйк әле үзләрен. Әтигә әйтеп карале. Чакыруын әти үзе чакырыр,—дидем.

Әтиебез шатланып риза булган.

—Кызым, әниенә акыллы фикер биргәнсең. Ул турыда мин үзем дә уйлап йөри идем. Пешеренегез генә, чакыру миннән калмас,—ди.

Әтинең шундый җылы сүзе чыккач, мин дә кыюланып китеп:

—Әти, чыннан да алар ирле-хатынлымы, супруг-супругамы?—дип сораганыем, әти башта көлде. Аннан:

—Нигә кирәк ул сина, алар үзләре беләләрдер. Әниенне дә аптыраткансың. «Нигә аерым йоклыйсыз?» дип үзләреннән сорашма тагын. Алар укыган, зур кешеләр, житмәсә әле урыслар. Андый галим кешеләр культурный булалар, бай булалар. Бүлмәләре күп булгач, аерым иткәннәрдер. Бүлмәләре аерым булгач, нигә аерым йокламаска,—дип аңлатырга тырышты.

Шулай көндезге ашка, татар бәлешенә дип үзләрен кунакка чакыртып, әнигә дә күрсәттем мин аларны. Ачык чырай, якты йөз белән каршы алырга чыккан әнине күргәч:

—Ассаламагалайкем, Бибисара ханум,—дип исәнләшүләренә әниебез каушап ук калды.

—Һай жаным, һай жаным, сөбхәналла! Вәгаләйкүм-әссәлам, хуш киләсез кунаклар. Әйдәгез, әйдәгез, рәхим итегез, түрдән узыгыз,—дип, тагын ни әйтергә белмичә, шул ук сүзләрен кабатлый гына бит.

—Син, карчык, каушабрак киттең дип әйтимме...—дип әйтә генә башлаган әтине дә бүлдереп:

—И-и, атасы, каушасам да гаеп түгел, сөенүемнән нәрсә әйткәнемне дә белмим инде. Бәрәкалла, төпчек кызым бигрәк тәрбияле кешеләр кулында икән дип сөендем әле. Тикмәгә генә урысча укырга-язарга өйрәтеп йөрмәгәнсең икән кызыбызны. Ә мин сине «нигә аннан маржа ясыйсын дип гел ачулануымны белдем, гөнаһ шомлыгым белән,—дип тә әйтеп жибәрмәсенме... Әнинең: «кунакларыбызнын хәтерләре калыр» дип тә чамалый алмавыннан үземнең котым очты. Менә шул чакта кунак урыс-

маржаларыбызның ничек итеп шаркылдап көлеп җибәргәннәрен күрсәң, исең-акылың китәр... Ул Иван абыйның үзенең күк күкрәгән шикелле гөрселдәп торган калын тавышыннан, өйләр дер селкенгәндәй булды. Ә Мария апайны күрсәң, егылып китәрсең, үзенең иләмсез җуан ботларына куллары белән шап-шап итеп чаба-чаба көлде. Ә без өчебез аларга карап көләбез дә көләбез, туктый алмыйбыз гына бит... Көндезге ашка гына дип чакырылган кунакларыбыз бездә бик озак булдылар. Әни урысча сөйләшә белмәгәч, бик рәхәтләнеп гел татарча сөйләштеләр. Иван абый бигрәк матур сөйли, аңа гел карап, тыңлап кына торасы килә. Үзенә дә әйттем. «Сезнең татарча сөйләшүегез урысчадан матуррак» дип. Тагын рәхәтләнеп көлде. Иң гаҗәбе, нишләптер алар бездә бер мәртәбә дә чукынмадылар. Ә мин боларның чукынганнарын әни күрсә нишләр инде дип куркып утырдым. Алар сөйләштеләр дә сөйләштеләр...

Сүз артыннан сүз дигәндәй, кунакларыбызның язмышлары турында без белмәгән шактый күп нәрсәләр мәгълүм булды.

Алар яшәгән Болак буендагы искитмәле бай йорт Мария Федоровнаның әти-әниләренеке булган икән. Әтиләре нәкъ Иван Васильевич шикелле врач, әниләре—Мария Федоровна кебек хатын-кыз врачы булган. Укыган, зур мәгълүматлы кешеләр булганнар алар. Ике ир бала, бер кыз үстергәннәр. Малайлары кыска гомерле булган.

Мария Федоровнаның әтисе унөч яшьлек ярлы крестьян малаен—Иван абыйны үзенә ярдәмче итеп эшкә алган. Аның тырышлыгын, гыйлемгә тартылуын күреп, бу малай өчен мөмкин булганның барын да эшләгән. Мариясын ничек укыткан булса, Иван абыйны да, үз улыдай, университетның медицина факультетына әзерләгән. Практик яктан әзерләүне үз өстенә алган. Аны физик яктан көчле итеп тәрбияләүдә дә зур игътибар күрсәткән, акчасын да җәлләмәгән. Иван абый инде унсигез яшендә озын буйлы, киң җилкәле, көчле, таза, искитмәле чибәр ир-егет булып өлгергән. Мария Федоровна исә, ул чакта утыз сигез яшьлек ялгыз кыз. Табигатьнең хатын-кызга бүләк иткән иң көчле чоры—нәкъ шул яшьләргә туры килә дә инде. Егетнең дә энергия вә дәртенең түгелергә торган мөлдерәмә чагы. Яшь чагында Мария апа да чибәр булган икән. Гәүдәләре дә бик килешле, спай, бөдрә чәчле, түгәрәк йөзле—мәхәббәтле кыз булган. Соңыннан нишләп шулай котырып симергәндер инде. Стенада эленеп торган карточкалары белән чагыштыра да торган түгел. Тәүлекләр буена бер йортта яшәгән ошбу егет илә кызның бер-берләренә тартылулары гаҗәп тә түгел шикелле, гәрчә араларында егерме яшь аерма булса да. Әти кеше дә сукыр түгел бит, барын сизеп йөри. Хатынының кинәт, хушлашырга да өлгермичә, бакыйлыкка күчүе аның да канатларын сындыра. Кызының язмышын да хәл итәргә кирәк. Гомерләре буена туплаган бай мирасны көчле, гадел ир кулына тапшырасы килә аның. Кызы белән Иван абыйны үз янына чакырып, аларга үзенең иң газиз һәм изге дип санаган соңгы теләген белдерергә мәҗбүр була. Ниһаять, икесенең дә ризалыгын алып, максатына ирешә һәм чиркәү аша законлаштырырга да өлгерә. Шунда Гыйззелбәнат үзен йотлыгып тыңлаган Маһирәгә текәлеп карап алды да:

—Маһирә, минемчә, синең дә әти-әниең нәкъ шундый уйлар белән, Нургалине өзелеп яратканыңны да белгәч, көндәш өстенә булса да, гадел, нык куллы мирасчым, кызым өчен ышанычлы ир булыр дип Нургалине сайламадымы икән? Әйтә башлагач, шунысын да әйтим инде. Тик Газзәбануны ялгыз итмәгез. Кабат утларга сала күрмәгез. Иң гаделе—Нургалиенне монда кайтырга, барыгызга да монда, бергә яшәргә күндерергә тырыш. Мин соңгы вакытларда Газзәбануны, Мария Федоровна күк, үз һөнәрләремә тарта башлаганыем. Берсе дә югала торган һөнәрләр түгел. Аларны үзләштерә

алса, үзе дә югалмас. Үзем өчен, шушы изге хезмәтләрне башкара алырлык дәвамчы калдыралсам, бер Раббем каршында саваплы булалырыем дип өмет итәм. Гөнаһларым бик зур бит минем, Маһирә...

—Нинди гөнаһлар сон ул, Гыйззелбәнат апа?—дип, аны күбрәк шулар турында сөйләтәсе килде Маһирәнен.

—Сонгы ике елымда Мария Федоровна мине йорттагы вак-төяк эшләрдән азат итте. Бөтен көчен, вакытын биреп, мине медицина факультетына укырга кертү өчен тырышты. Дүрт ел эчендә, абыйларым әйтмешли, урыс телен су кебек эчтем. Бүлмәмне медицина турындагы китаплар белән тутырдылар. Анламаганнары хәттин ашкан. Остазларым икесе ике яктан минем өчен шундый гадиләштереп анлаталар... Сезгә бит укытучы булырга кирәк, дим, нигә шул университетта гына эшләмисез, дим. Менә шулай, алар шикелле зур врач булам дип хыялланып кына йөргәндә...

Беркөнне кичкырын икенче каттан поднос белән савыт-сабалар күтәреп төшеп киләм. Ничектер, уйланып китеп микән, сыртым белән баскычка шундый каты килеп төштем ки, күземнән утлар күренде. Кычкырып та җибәрдем. Җайлырак та егылырга булае, кулымдагы кыйммәтле чәй сервизын саклыйм дип үземне сакламаганмын. Кулымнан поднос та шуып китте, чынаяклар да челпәрәмә килде. Аларны җәлләп тә, хуҗаларымнан куркып та билемнен авыртуын сизмәгәнмен. Торырга дип кыймылдавым булды, кисәк авыртудан тагын кычкырып җибәрдем.

—Торма, торма!—дип, Иван Васильевич килеп җитте. Мине җайлы гына итеп күтәреп, үз кабинетындагы кушеткага алып барып салды.

—Тыныч кына ят,—дип халатымнын төймәләрен чишә башлады.

—Юк, юк, оят бит,—дип анын кулларына ябыштым.

—Нинди уят, глупенькая, если там перелом? Вот тогда не до уята будет, Аллам сакласын. Закрой глаза и замри,—дип кырыс кына әйтсә дә, йөзе шулкадәрле мөлаем, ана карап сокланмый калу мөмкин түгел иде.

—Не смотри на меня, не трогай мои руки,—дип сак кына шудыра-шудыра халатымны, эчке күлмәгемне салдыруын дәвам итте. Ә мин шунда кискен хәрәкәт белән кыска ыштаныма ябыштым. Әмма янә коточкыч авыртудан ихтыярсыз чыраемны сытып, ынгырашып җибәрдем.

—Зачем мне твои штаны? Лежи спокойно, никаких движений. Булай булсан син врач була алмыйсын. Понятно?—ди. Ә мин, тынычлана төшкәч:

—Мария Федоровна нигә күренми? Нигә монда төшми?—дим.

—Она уже давно храпит,—дип шундый тупас итеп әйтте, әллә нишләп киттем.

—Зачем так грубо? Сезнен күк матур күнелле кешегә килешми. Иван абый, Сез бер дә усал кеше түгел бит. Йокласын, арыгандыр,—дим.

—Арыган, арыган... Кем арымаган?—ди, ә үзе күзләремә карап шундый матур итеп елмая... Бигрәк мәхәббәтле кеше иде шул.

—Ул син гына кычытмаган җиренне кашып, эш табып юрисен,—ди, үзе һаман елмая. Бу юлы бер күзен серле генә итеп кысып та куйды әле. Һай, җаным, шул вакытта озын кара керфекләренен тибрәнеп куюлары... Мина бүген шуларны күрү кирәк идеме... Башка вакытта ана күтәрелеп карарга да ояла идем бит. Бүген нәрсә булды сон мина... «Мария Федоровна нигә төшми?»—дип сорасам да, «Төшмәсә генә ярарые» дигән уемнан гына иде түгелме сон...

—Иван абый, нигә сез татар түгел?—дигәнемне сизми дә калдым.

—Ә мин сина: нигә син маржа түгел?—дип сурамыйм да, алай булуын телямим да,—ди.

Сискәнеп киттем. Ниндидер бер рәхәтлектә изрәп яткан тәнем кисәк

куырылып куйды. Аңлаттымы Иван абыең, шул кирәк сиңа, әйдә тор. Билеңнең авыртуы бетте. Халатыңны ки дә, ычкынуыңны бел, дип уйлап, халатыма үрелдем. А-а-й...

—Что ты делаешь, ярамый бит булай. Только для себя хуже делаешь. Слава Богу, сезнеңча Аллага шөкер, перелома нет. Но кое-что нужно на место посадить, а для этого с твоей стороны нужен полный покой, поняла? Мин сина бер да начар айтмадым. До тебя здесь работала одна маржучка—Шурочка. Чиста эшлами, тамлы пышырми. А рюмкага урела. Незнали как избавиться. Мария Федоровнага: «Шурочка мины кочаклап маташа»—дигач, шул кунны ук расчет ясады. Хазер анладынмы инде, а син уйладын, мин маржаларны гына ярата дип, да?—Икебез дә көлеп җибәрдек.

—Успокойся, сейчас очень больно будет,—дип билемне кисәк әллә нишләттереп алды, шунда нәрсәдер «чырт» итте. Бу юлы авырту кычкыртып кына түгел, акыртып җибәрерлек булды. Ихтыярсыз Иван Васильевичның беләгенә чытырдап ябыштым. Гаҗәп, ачуланмады.Киресенчә, кулларымны сөеп куйды, миңа шул кадәр рәхәт булып китте. Иван абый сизә күрмәсен дип кулларымны тартып алмакчы булам... ала да алмыйм.

—Астан иң соңгы умырткаларың янында нык кызарган ике урын бар. Иртәгә алар кара янып чыгачак. Каты бәрелүдән бераз кан сауган, аларны күргәч, аптырап калма. Үзең йомшак кына массаж ясаштыргалап куя аласың.

—Ә бүген үзегез генә ясый алмыйсызмы соң? Минем массаж нәрсә инде ул, мин аның кай төш икәнен дә белмим бит әле,—дидем.

—Юк, Гюзялбанатым, бүген ярамый. Бир кулларынны,—дип кулларымны алды да, үз куллары белән йөртеп, менә шушы урыннар булыр,—диде. Аңлата алмаслык, гаҗәп бер рәхәтлек бөтен тәнемә таралды. Ул инде тәнемә генә түгел, җаныма да кучте. Бу халәтем күзләремдә дә чагыладыр. Иван абый күрсә ни уйлар дип, күзләремне йомдым. Үзем оялам, үзем кузгалып та китә алмыйм. Сизде ул, ник сизмәсен, утыз яшьлек ир-егет бит ул. Минем йомык күзләремнән, битләремнән үбә башлады. Иреннәремә үк кагыла башлагач, инде назлы кулларының да башка, куркыныч юнәлеш алуын тоеп: «Иван абый, кирәкми, не надо, Аллаһ нас накажет, вы же русский, женатый, ә мин саф татар кызы»,—дип сөйләнеп, шул ук вакытта, ниндидер бер илаһи ләззәттән изрәп ятудан башка берни дә эшләмәдем бит. Ул гынамы әле, үземнең дә аны кысып кочаклыйсым, үбүенә үбеп җавап бирәсем килә. Шөкер, үземне тыя алдым. Кычкыра да ала идем, башка физик каршылыклар да күрсәтә ала идем. Күрәчәкне күрми—гүргә кереп булмый димәсләр иде. Берсен дә эшләмәдем, дөресрәге, карышырга да теләмәдем. Ниһаять, мин аны яратуымны, ничәмә еллар аңа гашыйк булып, әмма үземне тыеп яшәвемне аңладым. Ә иң кызганычы, аның да мине, бары мине генә яшерен яратуы—менә шундый фаҗигагә китергән дә инде. Монысын мин соңыннан белдем.

Ул мине назлап кына күтәреп, үз бүлмәмә чыгарып салды. Таплы җәймәмне хәсиятләп төрде дә, «Рәхмәт, Гюзялбанатым» дип, җәймәне үзенә бирде һәм яшьле күзләремне үпте дә үпте. Ә мин шунда, кинәт муеныма нидер, ят каты әйбер кагылып киткәнен тойдым. Йа, Ходаа, Иван абыйның тәресе... Ни кылганымны да аңламыйча, мин аны этеп җибәрдем һәм ниндидер бер чиркану белән читкә борылдым. «Гафу ита алсаң, гафу ит, ты моя единственная радость, Гюзялбанатым»,—дип әкрен генә чыгып китте.

Йокысыз газаплы төн. Өзлексез аккан күз яшьләре... Йа, Хода, күз яшьләре генә юарлыкмы соң бу кылган гөнаһымны. Таң алдыннан гына йоклап киттем, ахры. Әллә төш, әллә саташу, күктә йолдыз атылган кук булды. Шул йолдыз нурлар чәчеп миңа таба төшә башлады. Якынайган саен зурая. Зурайган саен, йә Хода, тәре сурәтенә керә түгелме соң? Саташканда

женнәрне куркыта торган догаларымны укый башладым. Юк, һаман төшә... Беттем «диюем булды», тын да алалмыйм, кыймылдый да алмыйм. Кычкырмакчы булам, тавышым чыкмый. Бастырылдым... Ниһаять, шабыр тиргә батып уянып киттем. Нинди төн булды бу хәерсез...

Иртәгесен иртүк: «Мария Федоровна, извините, сегодня я у родителей. Завтра приду. Вчера я ничаянно разбила Ваш самый любимый чайный сервиз. Очень переживаю. Будьте здоровы. С приветом Ваша Гюзялбанат»,—дип яздым да, аны аш өстәленә куеп, шыпырт кына үземнең туган йортыма киттем, дөресрәге, качтым. Әниләр бик куандылар, билгеле. Бүген кунарга да калам дигәч, әни бәлеш пешерергә әзерләнә башлады. Әти дә:

—Кызым, мин дә бүген өйдә генә булам, алайса. Хәзер мунча ягып җибәримме?—дип сорады.

—Рәхмәт яусын, әтием. Бүген миңа иң кирәге дә шулдыр, мунчадыр,—дидем. Ярый әле берни дә аңламадылар.

Иртәгесен әти үзе илтеп куйды мине. Шөкер, Иван Васиьевич өйдә юк иде.

Мария Федоровна бик жылы каршылады. «Ой, как мы соскучились без тебя»,—дигән була. Чәй сервизы өчен борчылганыма шелтәләп тә алды. «Не о чем не думай, только занимайся,—ди.

Инде Иван абыйны көтәм. «Аның күзенә ничек күренермен?» дигән уй белән үз бүлмәмә кердем. Күрәм, караватымда записка: «Дорогая, это тебе на память. И. В.»,—янында кечкенә генә бер тартма. Ачып карасам, әнекәйгенәм, әллә нинди нурлар чәчеп торган зур кашлы алтын йөзек. Нәрсә уйларга да белмәдем. Бик матур, киеп тә карадым, таман гына. Бик кыйммәтле икәнен дә чамалыйм, әмма аңламыйм. Әгәр минем үзем өчен куелган бәһа булса, бу бик арзан. «Үз бәһасен белмәгән кызга шул да житәр»,—дип уйлаганмы? Ятсын шунда, куелган урынында, үзе теләсә нишләсен дип уйлап, яулыгым белән каплап куйдым мин аны.

Мария Федоровнаның тавышын ишетеп холлга чыктым. Ул миңа тиздән бер ханым киләсен әйтеп, үземә дә аның белән бергә менәргә кушты. Мин риза булмадым.

—Иван Васильевич кайда?—дип сорарга батырчылык иттем.

—Ул авылга китты. Атисы авырый икан. Салырга ярата ведь ул. Кубрак салгандыр, наверное. Кайчан кайтасын айтмады,—ди. Күңелсез булып китте. Үзем очрашырга да оялам, күрәсем дә килә. Ниһаять, бу йорттан мөмкин кадәр тизрәк китәргә кирәклекне аңладым шикелле. Укырга да керәсем килә...

Иван Васильевич төн урталарында гына кайтып керде. Әле йокламаганыем, чыкмадым, ул кермәде. Иртәгесен күрештек, кочаклап алмакчы булды, ә мин тиз генә халат кесәмнән йөзекне алдым да:

—Иван абый, бу нәрсә, миңа ни өчен?—дидем, мөмкин кадәр кырыс булырга тырышып.

—Глупенькая ты моя, яраткан кешедан шулай сурамыйлар ведь инде. Яратам, бик яратам, Гюзялбанатым. Яратканым учун ал,—ди.

Мин дә яратам, дип ничек мин ана әйтә алыйм?!

—Иван Васильевич, мин сезнең мәхәббәтегезне дә, бу бүләгегезне дә кабул итә алмыйм. Яратуыгыз чын икән, онытыгыз, бүген үк сезнең йорттан китүемне теләмәсәгез, башка бу турыда сөйләмәгез,—дидем дә, йөзекне өстәлгә куеп, үз бүлмәмә кереп бикләндем. Мин үзем гаепле бит, бары үзем... Монысы инде газап өстенә газап алуым булды, дип жыладым.

Әмма газапларның иң олысы алда көткән икән әле. Шул гөнаһлы төннән соң бер ай да үтмәде, нык кына кәефсезләнә башладым. Күңелем болгана, ашау артыннан коскалый башладым. Мин бит врач булырга әзерләнгән кеше, барын да аңладым. Мин авырлы, инде нишләргә? Ялга

өйгә кайтырга батырчылык итмәдем. Ә хуҗаларым сизеп, миңа берни әйтми генә шатланып йөргән кебек тоелдылар. Мин аптырап калдым, тычканга үлем, мәчегә көлке дигәндәй, нәрсә бу? Иван Васильевич белән сөйләшергә уйладым. Ә ул миңа:

—Бер да борчылма, Мария Федоровна бела. Үзебез тарбиялап устырырбыз,—ди.

Имәнеп киттем. Минем әти-әнием ни дияр, ике абыем укымышлы муллалар, ике апам күренекле генә муллаларның җәмәгатьләре—абыстайлар. Алар өчен мин кем булып калам? Нәселемне былчыратучы зиначы булып каламмы?—дип җылый ук башладым.

—Юк, Гузалым, син мине анламадын. Син минем никахлы хатыным, яшь хатыным булып, шушы йуртта без берга яшарбыз. Мария Федоровна безнен бергә булуыбызны икенче кунне ук белде. Мин яшермадем. Ул минем сине яратуымны болай да бела иде. Шулай килешик, минем синнән башка яратырлык бер кешем дә юк, син бердәнберем,—дип хәтта ялына ук башлады.

—Юк!—дидем.—Мария Федоровнага әйт, минем үземә кул салуымны теләмәсәгез, котылдырыгыз мине бу гөнаһымнан,—дип каты тордым. Мария Федоровна үзе дә сөйләшеп, ризалатырга тырышып карады. Ниһаять, үз вазифасын үтәргә мәҗбүр булды ул. Ә мин икенче коточкыч гөнаһымны алдым. Үз карынымдагы яралгыны, булачак баламны үзем теләп юк иттем.

Ата-ана сизенмиме соң, сизгәннәр алар. Миңа әйтмичә генә борчылганнар. Ничек түзгәннәрдер җанашларым... Аборттан соң рәтләнеп бетүгә, әти мине алмага килергә тиеш иде.

Әтием алмага киләсе көнне иртүк Иван абый, рөхсәт сорап, бүлмәмә керде.

—Гузалым, мины аз гына булса да якын итсан, ал син шушы исталыгымны. Только гафу ит. Син бик яшь, мин олырак кеше ведь, гаеп минда. Мин сины никогда не забуду. Бу йортта дурт ел сины курып, сина карап яшауым белан мин бахетлы булдым. Мария Федоровнаны мин ташлый алмыйм. Айбат кеше ул. Атасы Федор Сергеевич мины кеше итты. Мирасын калдырды. Мин чиркауда ант бирдым. Безнен динда хатын аеру, чиркауга каршы бару гафу ителми, зур гунах. Миным бидам еще атам эча, анам ауру, миннан башка кечкена дурт туганым мина карап торалар. Мария белән балаларыбыз булмады. Ул хаман мина поздно диды. А синен карындагы баламны югалту минем учун сина караганда бик купка авыр булды. Синен балан булыр алы, дай бог. Федор Сергеевич шикеллы, сине укытып врач итасыбыз килган иды, булмады.

—И-и, Иван абый җаным, болай булгач мин дә әйтәм инде. Мин дә яраттым бит сине. Татарча сөйләшүең белән дә күңелемнең түренә үттең. Арабызда синең күкрәгеңдә алтын тәрең, икона каршында чукынуларың, өстәвенә хатынлы булуың минем күңелемне дә җанымны да тимер коршауда тотты. Сез дә шундый ук коршау кысанында булгансыз икән.

—Синен баскычта егылуың ул кыршауларны ватып, яратуларыбызны ташкын кебек ирекка чыгарган,—ди Иван абый.

—Миндә дә гаеп зур бит. Шуңа күрә оялуымнан иртүк үз өебезгә качып китәргә мәҗбүр булдым. Соңыннан муеныгыздагы тәренең аз гына кагылып киткәнен дә тойдым. Хәтерегездәдер, сезне хәтта этеп тә җибәрдем. Ә гөнаһ кылган вакытыбызда ул бит минем бөтен гәүдәм буйлап шуышкан, ә мин исә тоймадым да, ул турыда уйламадым да. Минем гаебем зуррак булып чыга бит, Иван абый... Бу аңлашу кирәк булган безгә. Болай булгач, бүләгегезне кабул итәм. Фаҗигале мәхәббәтем билгесе итеп, үз кулларыгыз белән кидертегез дә инде,—дидем.

Менә ул йөзек, Маһирә, ирем белән яшәгәндә мин аны кимәдем, вөҗданым кушмады. Хәзер дә алай еш кимим.

—И-и, Гыйззелбәнат апа, сезнең белән беренче мәртәбә очрашканда ук күрдем бит мин аны. Бу йөзек зур каратлы бриллиант кашлы бит. Шул вакытта ук үз-үзегезне тотуыгыз, кигән киемнәрегезгә, бизәнү әйберләрегезгә карап мин сезнең авыл хатыны булуыгызга шикләнгән идем. Бу бит искиткеч кыйммәтле йөзек,—диде Маһирә.

—Әйе шул. Иван абый бармагыма кидерткәндә әйткән иде.

—Бәхетле булыгыз, Иван абый, бу йөзеккә караган саен, мин сезнең кайчан да булса үз балагыз булуын да теләрмен. Бирсен Ходаем!—дидем.

—Хуш, Гюзялбанат. Укырга теласаң кил, ярдам итарбыз,—диде дә Иван абый, яшьле күзләрен күрсәтмәскә тырышып тиз генә чыгып китте. Менә без шулай аерылыштык. «Әйдә, кызым, син әзерме?»—дип әти дә килеп житте. Һәм ул мине туры Фәхрелбәнат апамнарга кайтарып куйды. Жизни бик яхшы күнелле кеше иде. Мин аларда өч ел яшәдем һәм яшь кендек әби вазифасын үтәдем. Беренче зур тәҗрибәне шунда алдым. Әти мине алмага килгәч, бер дә җибәрәселәре килмәде. Ике мәхәлләле зур авыл иде ул. Яучылар да булды, турыдан-туры үзем белән сөйләшеп кияүгә сораучылар да булмады түгел... Үз хәлемне үзем белгәч, берәүгә дә кара шәлемне сөйрәп килергә теләмәдем.

Ә менә бу авылда әтиемнең чыбык очы туганы, булачак иремнең әтисе яшәгән. Әллә ни аралашмаганнар. Ә улының безгә берничә мәртәбә килгәне булган. Ничек килешкәннәрдер, ул үзе мине сорап килгәнме, әллә әтием үзе яучылап биргәнме, анысы мина мәгълүм түгел. Сөнгатулла белән мине Казан мулласыннан никахландырып, шактый зур бирнә белән Көеккә озатып җибәрделәр. Менә шулай итеп, шушы авылда гомерем үтте. Бик теләсәм дә, балага уза алмадым. Мария Федоровнаның гаебе беләнме, әллә инде гөнаһыма бирелгән җәзамы... Тәгаен икенчесе—кылган гамәлем җинаятькә тиң. Менә ни өчен җәзаның да иң катысы бирелгәндер, дип уйлыйм... Иван белән очрашу вакытындагы илаһи ләззәтне башка кичерә алмадым мин. Беренчесе дә, соңгысы да шул булды. Никахлы ирем өчен хатын булу бурычын гына үтәп яшәдем. Сизенгәндер дип уйлыйм мин аны, ана да бик рәхәт булмагандыр, әмма ризасызлыгын беркайчан да белдермәде бичара. Урыны җәннәттә булсын! Яратып яшәмәсәм дә, аның белән дөм ялгыз булмаганмын икән. Бу йортта: «Бик арымадыңмы, чәйләп алмыйбызмы?»—дип, төннең ни вакытында булса да бердәнбер көтеп алучым булган ул минем.

Маһирә күпмедер вакыт телгә килалмый торды.

—Рәхмәт, Гыйззелбәнат апа! Сез мина күпме гыйбрәт бирдегез. Кыюланып бу авылга кайтуыма үкенгән чакларым да булмады түгел. Ә дөресен генә әйткәндә—ничек кайтканмын әле!—дип куанганнарым да күп булды, мең шөкер, чиксез шөкер! «Гөлҗәүһәр белән Мөхәммәтнур кыйссасы» һәм менә бүген сезнең сөйләгәннәрегез минем өчен «Гыйззелбәнат—Гюзялбанат» кыйссасы булып күңелемдә гомерем буе сакланачак. Мин аларны чәчми-түкми язып та куярмын әле.

***

Ташлыяр җыенында Газзәбанудан да бәхетле кеше булмагандыр, мөгаен. Мондый зур бәйрәм көнне ач үлемнән исән калган әти-әнисе, якын туганнары белән бергә булу үзе олы бәхет. Янында гаҗәеп затлы киемнәрдән, Ташкенттан тагын да чибәрләнеп, шәһәр зыялысына әйләнеп кайткан сөйгән ире—Нургалие—кайсы гына хатын-кыз горурланмас мондый ир белән. Үзләре янында җан көеге Маһирәнең булмавына сөенеп бетә алмады Газзәбану. Эченнән генә ана рәхмәтен дә укыды әле. «Мин дә барам» дип чат ябышса, Нургали аны калдыра да алмаган булырые. Юк, чат ябышмады Маһирә.

Әтисе житәкләп йөргән үскән улы, күз нуры Хафизы—үзе генә дә күпме кешенең игътибарын җәлеп итте. «Һай, жаным, ни арада үскән бу малай». «Карале, жаным, әтисенә шулкадәр охшаса да охшар икән, суйган да каплаган. Сөбханалла, күзләр тимәсен!», «Сөйләшүен, терелеген генә күр әле! Яман күзләрдән Үзе сакласын бу баланы!». «Баланы гынамы, ахирәт, өчесен дә диген. Алар өчесе дә жыенybызның күрке, иң кадерле кунаклары. Кияүгә киткәннән бирле бер жыенybызда да була алганы югые бит Газзәбануыбызның, әнә ничек матур итеп килгәннәр». «Жыенybызга дип алып кайткан бүләкләренә дә шаккатмаган кеше калмады бит. Нургали үз авылына да шулай алып кайткан диделәр». «Ну, баеп та караган икән, малай. Әҗере үзенә кайтсын. Рәхмәттән башка берни дә әйтеп булмый. Әле аны Көектә клуб белән мәктәп салдырырга ярдәмем булсын дип әллә никадәр акча да биргән икән дип сөйлиләр. Исән-сау эшләсен, килер жирен мул кылсын!»

Газзәбанунын үзеннән читтәрәк, үзе танымаган, бәлки читтән килгән яшь киленнәрдер, ике жилкенчәкнен сак кына сөйләшкән мондыйрак сүзләре дә колагына чалынды: «Карале, Ташкинда да өйләнгән икән Нургали абый. Авылга яшь хатынын да алып кайткан диләр. Син ишетмәденме?», « Юк, ишетмәдем дә, ишетсәм дә ышанмас идем. Яшь хатыны булса монда килми каламы соң?! Газзәбану апай шикелле матур да, унган да кыз табарга... Ай-һай, белмим. Көеккә көндәш булып кайтырга, ике башлы булса гына инде».

Үзләре турында мактау, сокlanуларны гына ишетеп йөргән Газзәбану, бәхете ташудан, әйтерсең лә, күкнең жиденче катында оча. Анын да өс-баш, аяк киемнәре шәһәрчә, башында чын энжеле калфак, ак ефәк шәл япкан. Толымнары, аның очларындагы көмеш чулпылары күренебрәк торсын өчен ефәк шәлнең шарф кимәлендәгесен япкан. Ну, малай, чылтыратып та карады инде көмеш чулпыларын... Белә бит ул нинди хәрәкәтләрдә аларнын ныграк чылтыраганнарын. Нургалие дә:—И-и, Раббем, Үзең сакла! Хозыр Ильяс канаты астында йөртсәңие ошбу гөнаһсыз жанны, вә нарасыем Хафизны!»—дип ничә мәртәбәләр генә ялвармады икән... Хәтта үз күзе тиюдән дә курыккалаган чаклары аз булмады. Әнә хәзер дә мәйдандагы хикмәтләрне карамыйча, Газзәбануыннан күзен дә ала алмыйча күзәтте дә күзәтте.

—Газзәбану, әйт әле дөресен генә, ни өчен син үз авылыбызда болай киенмәдең? Маһирә белән без берничә мәртәбә «безнең бүләкләребезне кисәң иде»,—дип әйткәләп карасак та, син безне ишетергә дә теләмәдең. Сәбәбе нидә?—дип сорарга мәжбүр булды Нургали. Әллә көнләшеп куйды инде, белмәссең... Уйга калды гына бит егетең...

Бу авылда Газзәбануга гашыйк булып, бик яратып йөргән бер егет барын ишеткәне бар иде. Анын исеме Габделгаббас иде шикелле. Тукта әле, безгә жыенга килүендә шул егет турында нидер сөйләде түгелме соң әби... Ташлыярда ачлыктан бик күп кешеләрнең үлгәне турында, шул исәптән күршеләренең, Газзәбанунын әллә ничә дус кызларының гаиләләре белән гүр иясе булулары турында сөйләде. Аларның исемнәрен дә санады бит әле ул. Менә шунда теге егет турында... точно, исемә төште. Әти-әниләре вафат инде. Габделгаббаслары да шешенгән дип Ибраһим кайтып әйтте. Без аны бик жәлләдек. Хәтта, Газзәбану киткәч, егет сүнде, бер кыз белән дә йөрмәде, өйләнмәде дә, дип тә әйтте бит әле әби. Шуннан без бабан белән син жибәргән ризыклардан аз-маз өлеш чыгаргаладык. Шөкер, исән калды егет, диде бит. Кем ризыгыннан исән калганын белде, бик рәхмәтле булды. Газзәбанунын хәлен сорады дигәнен дә әйтте бит. Кайда икән ул хәзер, анысын әйтмәде. Әбидән шыпырт кына сорарга кирәк әле. Бәлки,

ул бүген монда, җыенда да йөридер әле...

Менә шулай инде ул ир-егетләребез. Үзе еллар буе кайтмады, барган җирендә типтереп яшәде, өйләнде, хәтта хатыны белән баласы янына яшь хатынын да алып кайтты. Ә хәзер үзе Газзәбануыннан көнләшеп маташа түгелме?

Шау-гөр килеп җыен да үтте. Ташлыярның яшьләре Нургалиләрне зур хөрмәт белән кичке уенга чакырдылар. Нургалинең тальян уйнавын, ана кушылып Газзәбануның җырлавын исләре китеп тыңладылар. Өйдә әби белән бабай «кияү-кияү» дип нишләргә белми торалар. Менә шундый хәлдә Маһирә белән никах яңарту турында ничек сүз башламак кирәк?.. Нургали юлда сөйләшеп аңлашуны мәгъкуль күрде. Бер бик матур урында, урман почмагында Хафизны тарантаста калдырып сүз башлады ул.

—Нинди никах яңарту турында сөйлисең син, Нургали? Сезгә ни җитми? Безнең ничәмә еллардан соң кавышуыбызга ун көн дә юк бит әле. Маһирәң шуны да күпсенәмени?

—Маһирәнең монда бер катнашы да юк. Бары мулла абзыйның тәкъдиме белән эшләнергә тиеш, әйе, әтиемнең дә ризалыгы белән...

—Бу—никах яңарту түгел, бу—минем ачыдан-ачы хәсрәтләремне яңарту була түгелме соң? Син шуны да аңламагач, Маһирә ничек аңласын?! Аптырабрак йөри идем аны, ничек әле бу инде ничәнче төнен ялгыз уздырырга риза икән дип. Юк, риза түгел икән шул. Минем ризалыгымны алып, мулладан тизрәк никахыгызны яңарттырып, кыска вакытлы шушы төннәремне дә минем белән бүлешү кирәк икән... Синең белән йоклар өчен шул барлы-юклы ике атнаны без чиратлашып бүлешергә тиеш булабыз, шулаймы?

—Газзәбану, җанкисәгем, тынычлан әле. Бөтенләй ярсып киттең, Хафиз ишетүе бар,—дип тә карады Нургали.

—Ишетсен, минем өчен хәзер бала ишетмәскә тиеш дип бала алдында әдәп саклауның бер мәгънәсе дә калмады. Үзегез шул сабый алдында, газиздән газиз улыңның туган йортында никахыгызны яңартырга да тайчанмагансыз. Ул бик зиһенле бала, барын да аңлар. Бердәнбер балаң үзеңнән баш тартса, нишләрсең? Маһирәң сиңа тупырдатып малай табып куандырыр дип әйтә алмыйм. Табасы булса, әллә кайчан тапкан булыры. Хафизымнан күзен дә алалмый, кызганам да әле мин аны, беләсең килсә... Бирсен Ходаем ана да, һич күпсенмим. Начар ана булмаячак ул. Мин бит ана түгел, сиңа үпкәлим, Нургали. Безнең арадагы мәхәббәт шулай мескенгә әйләнеп, сүнеп бара түгелме? Мин хәтта күз алдыма да китерә алмыйм, мөхтәрәм Фарук мулла каршында, өзелеп яратышуыбызның беренче җимеше—балабыз алдында, ниһаять, барыбер мин җиңдем бит дип утырачак Маһирә өчен син теләгәнне үти алмыйм. Син яратуың хакына дип әйтмәкче буласың. Юк, Нургали, яратуым хакына да түгел, муеныма пычак салганда да, никахыгызны җиренә җиткереп, законлы ирле-хатынлы булып яшәгез, мин риза, дип әйтә алмаячакмын. Моны фәкать мин синең ирлек ихтыяҗларыңны үти алмаганда, йә булмаса үзем икенче кешене яратып, синнән баш тартканда гына мөмкин дип саныйм. Яратуымның хакын шулай бәяләвең белән син мине генә түгел, нинди чиста, чык тамчылары кебек саф мәхәббәтебезне кимсеттең, коточкыч мескен хәлгә төшердең.

И, газиз Раббем, дустыма түгел дошманыма да бирмә күп хатынлы гаилә булып яшәүләрне! Синең кодрәтең чиксез зур бит, бер Аллам!!. Шәригатеңдәге законнарыңнан монысын юкка чыгара күр!!

Сине яратуым хет аз гына кимесә дә, ризалыгымны бирү җиңелрәк булыры. Ә ул көчәя генә бара, ни хәл итим...—дип, Газзәбану үкси үк башлады.

Шул вакыт көтә-көтә түземлеге тәмам төкәнгән Хафизның:

—Әйдәгез, тизләк булыгыз, Чапталны кигәвеннәл ашап бетелә бит инде,—дип ачыргаланып кычкырганы ишетелде. Үзенә таба килүче әнисенең күз яшьләрен сөртүен күреп, кигәвеннәр куып азапланган малай:—Әнием, ни булды, ник жылыйсың?—дип, әнисенә атылды.

—Улым, әниеңнең бераз башы авырта. Син аны борчыма инде, яме,—диде әтисе. Аптырап калган бала бер әтисенә, бер әнисенә карый-карый ни булганын аңларга тырышты, жавап көтте...

—Әллә кигәвен тешләдеме? Аның зуллалы шундый каты итеп тешли... Әнә Чаптал да нишләлгә белми. Тибенеп тә калый, койлыгы белән дә куып калый, чичти котылдылал юньсезләл... Малкай жәл...

Сүзсез генә шактый юл үттеләр. Кайтып житәрәк кенә Нургали:

—Сынатма, бәгърем. Гафу ит. Барысы да үз ихтыярында. Әйе, син хаклы. Тик бер генә үтенечем бар. Маһирәнең бер гаебе дә юк. Рәнжемә син ана... Ул рәнжешнең барыбызга да уртак төшү мөмкинлеген дә онытма...

Нургали гармунын уйнап, шау итеп кайтып керерләр дип көткән өй хужалары аларны бөтенләй икенче халәттә күреп ни әйтергә дә белмәделәр. Ярый әле кузлада утырган Хафизның көр тавышы белән:

—Ачыгыз капкагызны, нишләп йоклап ятасыз,—дип кычкырып жибәрүе барысының да күңелләрен күтәреп жибәрде.

Көндәшенең сулыгып киткән йөзен, озак кына жылаудандыр инде, күзләренең кызарып, күз тирәләренең шешемсенеп киткәнен дә күреп барын да аңлады Маһирә. Үзенә дә читен булып китте. Көндәшенә ниндидер бер эчкерсез кызгану белән карап, ничек сүз башларга белмичә каушабрак калды. Газзәбану да аңлады.

—Маһирә, менә бу рәхмәтле кучтәнәчләрне әти-әниләрем хас үзеңә тапшырырга куштылар. Аның эчендә кодабыз Локман белән кодагыебызга дигәннәре дә булыр, үзе тапшырыр, диделәр. Безнең белән бергә кайтмавына бераз үпкәләп тә куйдылар,—дип, шактый гына күләмле төенчекне алып Маһирәгә сузды. Шулай итеп, ике арадагы авыр киеренкелекне алып ыргыта алды Газзәбану. Ә шул чак йөрәгенең сулкылдап китүен үзе генә белде...

Ни генә булмасын, күпне күргән, күпкә түзгән, сабырлыкның чын бәһасен белгән авыл баласы шул ул.

—Әнкәй, минем бераз башым авыртып тора, сез чәй әзерләгәнче келәттә, салкынча һавада азрак ятып алырыем. Көне дә бүген артык кызу. Кучтәнәчләрне өйгә кертерсез, Гыйззелбәнат апайныкы белән Сажидәгә дигәне ак сөлгеләргә төрелгән,—диде.

—Кызым, бер дә борчылма, өстәлләр бар да көйләнгән. Әтиегез бүген иртүк теге көрән сарыкны суеп эш итте. Иллә дә тәмле икән ите. Күршеләр дә безгә керәселәрен беләләр. Сез лутчы Нургали белән юынып чыгыгыз, мунча бик әйбәт. Әтисе малайны да юып чыгарыр. Кара, Хафиз күренми, өйдәме соң ул?—дип, Зөлкамал тирә-ягына күз салгалап алды.

—Әни, Хафизың егет кеше бит. Тәскирәгә кучтәнәч кертәм дип Тәскирәсе янына элдертте генә, син күр дә, мин күр,—диде Нургали.

—Балакаем, бигрәк үзеңә охшаган инде. Үзең дә кызлар янына чабуның кимен куймадың. Бар улым, көттермә Газзәбануны. Хафиз чыккач, үзем әйтермен.

Маһирә кучтәнәчләрен өйгә кертеп куйды да, тынычлана төшеп, Зөлкамалга дәште.

—Әнкәй, әгәр сез каршы булмасагыз, теге жырчы кыз Жәмиләне чакырып кайтыр идем. Нургали белән Газзәбануның да күңелләре ачылып китәр, икесе дә кәефсезрәк кебек күренделәр...

—Нишләп каршы булыйк? Бар, кызым, бар, без дә рәхәтләнеп тынларбыз.

Китәр көннәрегез дә житә бит. Ни хәлләр итеп озатасы булыр инде сезне. Шуны уйласам, йөрәгем жу итеп китә...

—Нәрсәдер әткәй күренми, берәр яры киттеме әллә?

—Кортлар янында. Тагын берсе аерырга маташа дигәние. Быел үрчем ишле булырга тора. Аякларыгыз жинел булды, балалар. Жәе дә бик кызу. Кортларга килеште, шөкер.

Төрлесен уйлады Газзәбану мунчада. Болар тиздән китәрләр. Монарчы ирле-хатынлы булып яшәгәннәр бит әле, тагы да шулай яшәрләр. Никахларына ризалыгымны бирмичә, үземнән дошман ясап калдырудан мин нәрсә отам әле? Нургалиемнен авылга кайтып, гел янача яшәү хыяллары да бар. Әнә, әткәйгә нәселле ат алу өчен һәм каралты-кураны да янартырга кирәк кадәр акчасын бирде, алма бакчасын да кинәйтергә хыяллана. Маһирәнен янә Нургалидән калмыйча монда кайтуы да бик мөмкин. Чамасын белмичә киреләнүем аларны үземнән биздерүгә генә китерәчәк бит. Ул вакытта Маһирә дә: «Без анда кайтмыйк, Нургали. Баласын алсын да, үзе монда килсен. Минекеләр мона берсе дә каршы түгел», диярге дә мөмкин. «Эт оясында көчле дигәндәй», мин аларнын күзенә карап, дер калтырап торырга тиеш буламмы? Аллам сакласын... Әтиемнен теге вакытта әйткән сүзе дә шул булды бит: «Үзеннән биздерә күрмә, кайнешенә сыен, сабыр бул!» Ничек дөрес әйткән ул, рәхмәт төшкере, ә мин үпкәләп йөрдем. Әнә бит бүген дә Нургали ничек күнелсезләнде. Юл буе бер генә авыз сүз дә әйтмичә кайтты. Көеккә килеп житкәндә генә йомшады, жанга ятыш жылы сүзе чыкты. Ин кулае, никахларын монда түгел, Маһирәләр йортында янартсыннар. Шуна разый булсалар, мин дә күнелемнән зар жылап булса да, ризалыгымны кулдан язып, үзләренә биреп жибәрермен. Шушы сонгы фикереннән сон тынычланып китте Газзәбану. Иренен исә:

—Әнисе, жан кисәгем, мин керәм,—дигән сүзләре жанын эретеп үк жибәрде.

—Нишләп озакладын? Сине көтә-көтә уйламаган уем калмады. Әллә Маһирәгә юлда ниләр булганын, минем ничек пыр тузганнарымны сөйләденме?

—И, жүләркәем, юк, Маһирә өйдә дә юк. Чәй янына Жәмиләне алып кайтыйм әле дип, әнидән сорап, шуларга киткән. Әни без югында Маһирәнен тәмам авыл кешесе булып беткәнен сөйләп шаккаттырды. Ә мин атны су эчереп мендем, ашарына салдым. Әти кортлар белән мәш килә, ана да булышырга туры килде, тагын берсе аерган. Ничәмә еллар корт аерганда әти янында йөреп, монын кадәр ишле кучне күргәнем югые әле. Нурисламга кучереп утыртам,ди.

—Бигрәк юмарт инде безнен әткәй. Бу ишлесен, ишлеләр алар бик көчле дә булалар, үзебезгә калдырыргае.

—Мин дә әйтеп караганыем, кая ул... Ана атаганымнын шундый булуына куанам әле, бик ярдәмле күршем бит, өстәвенә синен дустын, ди. Карале, умарталар саны ишәйгән, балы да шактый буладыр. Нишләтәсез сон аны?

—Сатабыз, сезнен күк без дә акча эшлибез,—диде, Газзәбану көлә-көлә.—Аннары әче бал ясарга да шактые китә. Авыр эш вакытларында, син булмагач, ярдәмчесез дә булмый. Хафиз тугач, анын өлеше белән жиребез дә артты. Тырышып, тагын бер кечкенәбез дә була калса, Аллаһы боерса, янадан жиребез артыр. Син жир эшләрен инде бөтенләй оныттын бугай. Менә шулай тырышабыз, тырмашабыз инде, Нургали. Тиздән кайтсаные, жаным. Маһирән белән кайтсан да бер сүзем дә юк. Әткәй дә олыгаеп бара бит... Син кирәк монда, син, Нургалием,—дип, мөлдерәмә күзләрен яшерергә тырышып, башын хәләленен күкрәгенә салды Газзәбану.

—Сүз дә сүз, сылукаем, мунчада сүз сөйләмиләр... мунчада, мунчада... беләсенме нишлиләр?—Икесе дә көлеп җибәрделәр.—Мунчада-а... чабыналар, ят әле, тәгәрәтеп ике миллек белән назлый-назлый бер чабыйм әле үзеңне. Һай, җаным, нинди генә хуш исләр юк боларда, рәхәтләнеп иснә әле башта.

—Ә син беләсенме, бу миллекләргә ниләр кушып бәйләдек без әткәй белән. Ике төрле бөтнек һәм мәтрүшкәләр араларында. Каен яфраклары үзләре дә хуш исле бит... Нургали җаным, туктале, тагын бер генә сүзем бар бит әле әйтәсе. Шуны гына әйтим дә башка сүз сөйләмим,—диде Газзәбану (белә бит ул үзенә кирәк сүзне кайчан әйтәсен). Ниһаять, дулкынлануын сиздермәскә тырышып, нинди шартларда гына икесенең никахларына ризалык бирәчәген әйтте. Ничек разый булмасын ди Нургали. Чыннан да, нишләп моңа минем башым җитмәде икән дип уйлап та куйды әле.

—Рәхмәттән башка һич сүзем юк. Гафу ит, бәгърем. Зинһар, рәнҗемә. Алдан килешенгән буенча Кытайга барып, тауарларыбызны алып кайтуга, Маһирә кайтса да, кайтмаса да мин монда кайтачакмын. Көзге авыр эшләр вакытында ничек тә кайтып җитәргә тырышырмын.

## Кичке уен—озату кичәсе

Калган санаулы көннәр искән җил кебек үтеп тә киттеләр. Иртәгә китәсе дигән көнне авылның иң актив яшьләре Нургалиләрне кичке уенга чакыра килде.

«Маһирә апа скрипкәсен, Нургали абый, сез гармуныгызны алырга онытмагыз инде»—дип шаяртып та куйдылар.

Уен урынын авылның икенче башындагы Шәрәфи инеше буенда булачагын да искәрттеләр. Нургалинең бала чагындагы иң яраткан урыннарының берсе ул. Андагы ераклардан ук сузылып аккан тар гына инештә малайлар белән маймыч тотарга яраталар иде. Инештән шактый читтә, каршыда биек тау. Кышларын анда чана, чаңгы шуалар иде. Тауның каршы ягында, авылга якынрак урында—җәйрәп яткан түгәрәк күл.

Нургалиләр бөтен тирә күршеләр белән бергә килделәр. Бибиҗамал әби белән үз карчыгын тарантаска утыртып алып килде Зариф. Авылның олысы-кечесе бары да шунда, тау итәгенә тезелешеп утырганнар. Яшьләр җырлы-биюле түгәрәк уен уйныйлар. Кыз балалар кырыйдарак «чәбәк-чәбәк» уйныйлар. Ир малайлар, чын көрәшчеләр сымак, ихластан бил алышалар. Шуннан аз гына читтәрәк икенче төркемә «арка сугыш» уйный. Тыкрыктан төшкәндә бары да бик ачык күренә. Нургали кисәк туктады.

—Бер генә минут карап торыйк әле бу матур тамашаны...—диде ул.—Их, егетләр, безнең авыл төсле матур авыл бер җирдә дә юктыр. Мул җиләкле, бөрлегәнле урманнары, артышлы биек таулары, коеныйм дисәң, ничәмә урында бөялгән тирән сулары, эчим дисәң, иң тәмле чишмә сулары—кайда бар тагы?.. Дистәдән артык чишмә генә бар бит бездә. Һәрберсенең үз тәме, үз шифасы...

Урманнарыбыз да чишмәле бит безнең. Кирәмәт чишмәсенең суын бер татып карау да җитә, син инде аның тәмен дә, ярсу йөрәгенә сихәтен дә оныта алмыйсың.—Авылыбыз үзе дә, нәкъ йөзен яшергән кыз сыман, тәмам килеп җитмичә күренми. Гаҗәеп саф, бәлзәм һавасын бер сулар өчен генә дә, әллә ниләр бирерсең. Ә, кешеләре-кешеләре—күңел җәүһәрләре... Сагынып яшәдем мин аларны. Юк, Маһирәкәй, ни генә булса да, без монда яшәргә, табигать биргән бай хәзинәнең кадерен белеп яшәргә тиешбез.— Нургалинең чын күңеленнән ихлас әйтелгән бу сүзләре Газзәбану йөрәгенә сары май булып ятты. Ул аның үзен җитәкләп барган кайнар кулын

янакларына куеп, беркемгә дә игътибар итмәчә, үпте дә үпте. Газзәбану үз авылы жыенындагыча, шәһәрчә киенгән иде. «Нәрсәгә дип алып кайттык без аларны, шушы көнне дә кимәгәч. Ә, ничек килешә үзенә,—дип Нургалие бик теләде шул. Фатыйхның күзләре кич буе Газзәбануда иде... Яшьләрнең кул чаба башлауларыннан айнып киткәндәй булдылар. Ул да түгел, каршыларына Хәниф килеп житте.

—Сез нигә туктап калдыгыз әле? Әнә, үзәндәге бар халык сезне көтә. Бу уен кичәбезне үзебезчә сезне озатуга багышлаган идек.

—Рәхмәт, Хәниф, үзәнгә күзем төшү белән аңладым. Хәтта Фатыйх галижанәбләре үзе дә килгән икән...

—Нургали абый, син ана алай салкын карама инде. Бу очрашуны Фатыйх абый үзе оештырды. Саубуллашу сүзе дә әйтергә жыена. Ни дисән дә хужа кеше бит инде, үзенчә тырыша, яшьләр, балалар өчен дә кайгыра. Синең ярдәмеңә күңеле бик булган аның,—дип, шыпыртлабрак Нургалине жайларга тырышты Хәниф һәм аларның өчесен дә әйлән-бәйлән түгәрәге эченә алып керде. Шунда жыен батыры, күрше авыл егете Әхтәм белән очрашу Нургали өчен сюрприз булды. Ташкент бүләге—гармунын да алып килгән. Янында батыр асты калган Көек егете Сабиржан да басып тора. Өчесе дә бик шатлар... Якын туганнарча исәнләштеләр.

—Нәрсә, Әхтәм туган, уйнарга өйрәнеп булмас, лутчы Сабиржан уйнасын дип китердеңме?—дип сорады Нургали.

—Юк, уйный башладым башлавын, тик сезнең күк оста гармунчылар янында уйнарлык түгел әле. Киләсе жыенда, Аллаһы боерса, сезнең төсле уйный алырмын дип ышанам. Кайтыгыз гына... Исәнлектә күрешсәк ие... Бүләгегезне жаным кебек саклармын. Мин аны бүген Сабиржанга уйнап торырга алып килдем. Мә, агайне, уйнап жибәр әле. Кызлар кунакларга жыр жырлыйбыз диләр.—Рәхмәтен әйтеп, бик куанып алды гармунны Сабиржан. Дәртләнеп уйнап та жибәрде. Кызлар жыр башлады.

—Алма бакчасының юлы тәрәзәләргә туры,
Әллә сезгә сибелгәнме бөтен дөньяның нуры

Бер карыйм кашыгызга, бер карыйм күзегезгә,
Сөбханалла, күз тимәсен дип карыйм йөзегезгә.

—Кадерле кунакларыбыз, хәзер чират үзегезгә. Жырчыларыбызга үз һөнәрләрегез белән жавап бирәсез. Үзегез уйлашыгыз. Бәлки, читтән дә тәкъдимнәр булыр,—диде егетләрнең берсе.

Шуны гына көтеп torгандай, тау итәгендәгеләрдән дә, яшьләр арасыннан да китте сораулар—чыдап кына тор. Ду килде халык. Менә, бар халыкны шаккаттырып, Бибижамал әби сүз алмасынмы...

—Башта Нургали белән Газзәбану «Галиябану» жырын жырласыннар әле. Икенче кунагыбыз Маһирә аларга скрипкә уйнасын.

—Рәхмәт, әбекәй,—дия-дия барысы да ризалыкларын белдереп кул чаптылар. Нурислам тиз генә скрипкәне китереп бирде.

Нургали:

Нурлы йөзеңне күрермен
Кайтырга язса әгәр.
Нихәлләр итеп түзәрмен,
Газзәбану, сылуым-иркәм,
Кавышыр көннәргә калдәр.

Газзәбану:

Таң әтәчләре кычкыра,
Таң атуның билгесе.
Бу бүләгем сине сөеп,
Хәлил бәгърем, җан кисәгем,
Вәгъдәләрем билгесе

дип, Газзәбану кульяулыгына төрелгән нидер бирде Нургалигә. Нургали яулык эчендәге кәгазьгә тиз генә күз төшереп алды. Йә, Хода! Никахка ризалык биргән шәһадәтнамәсе бит бу. Монарчы бирмәде, мин сорамадым. Сорасы да түгел идем бит инде. Нигә болай эшләден икән?.. Нигә бу җырың белән?.. Хәлил язмышыннан үзең сакла, Ходаем!

Маһирәнең скрипкәсеннән агылган илаһи моң ул көнне берәүне дә тетрәндерми калмагандыр. Күрәсең, ул моңга Газзәбануның кабат аерылып, ялгыз калу газаплары да кушылгандыр, мөгаен. Көек халкының, балачагасыннан башка, барында да бер генә уй. Ничек аерылышыр бу гүзәлләр иртәгә?

Халык кул чаба, җырның дәвам ителүен сорыйлар... Маһирә якында гына басып торган Җәмиләне чакырып алды. Хәнифкә «Җәмилә» җырын игълан итүен сорады.

Җәмилә җыр башлады:

Тәрәзәгә үреләсең,
Гөлләргә күмеләсең:
Гөлгә карыйм, сина карыйм,
Син матур күренәсең.
Ай-ли Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

Салкын сулар сибеп кенә
Үстерәм гөлләремне.
Серләремне сөйләр идем,
Тыңласаң серләремне
Ай-ли Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә.

Җырның кушымтасына олысы-кечесе бары да кушылып җырлады. Җәмиләнең Маһирәдән өйрәнгән барлык җырларын да сорый-сорый җырлаттылар. Араларында «Гөлҗамал» белән «Һай, җаныем Бибисара»ны тыңлап туялмады халык. Скрипкә белән гармун моңы бергә кушылгач, бу җырларның тәэсир көче бәһаләп бетерерлек кенәме соң... кичке авылда, күл буенда, тау итәгендә...

Тукайның Хафиз белән Тәскирәгә өйрәткән «Әйт әле, күбәләк» җырын да тыңлатасы килде Маһирәнең. Балалар һич тә каушап тормадылар, менә дигән итеп җырлап та бирделәр. Ул да булмады, «мин дә «Гали белән кәҗә» җырын җырлыйм дип чәчрәп чыкмасынмы бер малай. И Маһирәнең сөенгәннәре... бу малайны да җырлатты ул. Ниһаять, барыннан да бик канәгать калган авыл советы рәисе Фатыйх уртага чыкты. Һәм килешле генә итеп сүзен дә әйтте. «Иң әвәле шушы кичәне оештыручы яшьләргә, аеруча Хәнифкә, күрше авыл егетләрен дә алып килгән Әхтәмгә, уен кичәләребезнең оста гармунчысы Сабирҗанга һәм бүгенге кичәгә килгән өлкән авылдашларыбызга, бигрәк тә Көекнең почти йөз еллык тарихын үзе белән йөрткән, зур хәтер иясе мөхтәрәм Бибиҗамал әбиебезгә рәхмәтләребезне белдерик,—диде ул. («Кара сөйләргә

дә өйрәнеп килә икән»—дип уйлап куйды Нургали.)— Япь-яшь җырчыбыз Җәмиләгә ничек рәхмәтләр укымый каласың ди тагын. Барыбыз да шаккатып, сокланып тыңладык. Бу очракта зур кунагыбыз Маһирәгә рәхмәтләребезне җиткермәсәк, Бибиҗамал әбиебез риза булмас. Сезнен исемегез, Маһирә ханым, яшьләребез һәм балаларыбыз күңелендә гомерләре буена сакланыр. Нурислам дуска да рәхмәт. Маһирәне алып, балаларны төяп, күпмесен ат артыннан җәяү чаптырып, Кирәмәт урманына алып килгән ул. Кичкә каләр шунда нинди генә дәресләр бирмәгән Маһирә апалары. Ә балалар әниләре әбәдкә биреп җибәргән ризыклары: кемдә кабартма, кемдә пешкән күкәй белән йомшак ипи, кемдә кортлы сумса, кечкенә шешәләрдә тәмле куе сөт, берсендә мичкә салган бәрәңге һәм башка санап та бетермәслек ризыклар белән укытучы апаларын сыйлаганнар. Чәй урынына Кирәмәт суын тәмләп эчкәннәр. Безгә бары да мәгълүм, аларны укытучыбыз Габдрахман абый белән Хәнифебез бәйнә-бәйнә язып куйганнар. «Урманда Маһирә сабаклары» дигән исем белән үз тарихыбызда калачак ул. Юкка гына укытучы түгел икәнсез. Монда кайтып дөрес эшләгәнсез. Сезнең скрипкә кылларыдай нечкә күңелегез бу авылда җырга, моңга гашыйк, зәвыклы кешеләр яшәгәнен сизгәндер, күрәсең. (Нургали эченнән генә: «Ну, малай, безнең белән үскән ата ялкау Фатыйхмы соң бу? Чибәрләнеп тә киткән. Кем өчен тырыша?—дип тә уйлап куйды.)

—Рәхмәтебезнең иң олысы, әлбәттә, авылдашыбыз Нургалигә. Төзелеш эшләрендә тәмам килеп терәлгән идек. Аның ярдәме белән суыклар башланганчы клубны төзеп бетерергә уйлыйбыз. Бу мәсьәләдә җиен көнебездә мәрхүм булган Газимҗан абыйның улы Мәхмүт белән килене Мәфрүзәгә аеруча зур рәхмәт. Алар иң актив төзүче камсамулларыбыз. (Ул да булмады, әллә каян гына Газзәбану каршына Мәфрүзәсен житәкләп Мәхмүт килеп басты. Яшь килен Маһирәнең бүләге яшел атластан, билләренә сыланып торган, бала итәкле, гаҗәеп матур тегелгән күлмәктән, Газзәбану бүләге—ак ефәк шәлдән—күз яуыңны алырлык кыз! Газимҗан абый исән булса ничек куанган булыр иде. «Шатлыгым да, бәхетем дә сез» диеп яшәр иде дә яшәр иде. Аның изге теләге белән яшьләрнең матур гаилә коруларын үкенечләр белән үрелеп килгән монсу бәхет дими ни дисен...)

Игелекле Зариф абый гаиләсенә, шундый мәшәкатьле вакытларында да тулы бер көннәрен безнең төзелешкә багышлаганнары өчен, рәхмәтләребезнең чиге юк. Шушы көннәрдә яна мәктәпнең нигезен сала башларга җыенабыз. Бу эштә ата-аналар ярдәме дә бик кирәк булачак. Якты киләчәгебез өчен көчебезне кызганмабыз.

Ярый кунакларыбыз, хушлашыйк, юлларыгыз уң булсын, исән-сау кайтып житегез. Киләсе кайтуыгызда яна зур клубта очрашырга насыйп булсын!—диде.—Камсамулларыбыз сынатмас, нинди клуб булыр әле ул!

«Житте сиңа читтә йөрергә, кайт туган авылыңа. Төп гаиләң дә монда бит. Күреп торасың, никадәр эшлисе эшләр бар. Авылны бергәләп күтәрү җиңелрәк булыр иде. Синдәй кешеләр кирәк монда» дип әйткәнен көткән иде Нургали... Юк шул, әйтмәде Фатыйх. Димәк, теләми ул аның бөтенләйгә кайтуын. Сәбәбе ни? Әллә өмете һаман Газзәбанудамы? Күзен дә алалмый бит ул аннан, кешеләр сизәр дип тә уйламый, ичмасам. Өйләнергә дә исәбе юк диләр.

Зарифныкылар күршеләре белән бергә кайттылар. Араларында нигәдер Сәҗидә бик күңелсез иде.

—Ни булды сиңа, күрше? Тәскирәң чын күбәләктәй, ничек матур итеп җырлады. Синең түбән күктәдер дип уйлаган идем. Ә син...,—диде Гыйззелбәнат.

—Анысы, Аллага шөкер, бик куандым. Маһирәгә рәхмәт яусын, ул тырышты.

—Чыннан да, син бүген бөтенләй башка, Сәҗидә, нигә балтаң суга төште әле?—дип Нургали дә сүзгә кушылды.

—Нигә, нигә... Үзегез дә китәсез, минем Нурисламымны да алып китәсез. Әле ул: «барган көе бераз эшләп тә алырмын» дип күңелемне төшерде. Син котырткансыңдыр әле, Нургали. Акчаның аның күпме булса да җитәсе юк. Акчада гына микән әле сәбәп... Менә нигә әчем поша, җаным борчыла минем.

—Ярар, ахирәткәем, иртәгә иртүк торасыбыз бар, болай да төн кыска,—дип, Сәҗидәне озатасы килде Газзәбануның.

—Ярый, җаным, аңладым. Ну, мала-а-й, Фатыйхның күзен яндырдың бүген. Фатыйхныкын гына микән әле, бик күпләрнең күзе янгандыр сиңа карап. Бу киемнәрең белән син чын ханбикә буласың. Иртәгә дә шулай киен, бел аны. Гел шушы киемнәрдә, Ханбикәләргә охшатып, күз алларында калдырсыннар әле үзеңне Нургалиең дә, көндәшең дә...

## Соңгы төн вә аерылышу

Ак келәттә калган Нургали үз уйлары, үз борчулары белән Ханбикәсенең керүен көтте. Нишләргә? Ризалык кәгазе турында сүз кузгатыргамы? Нигә ул аны «Галиябану» җыры белән бәйләде? Әллә гел калдырып кына китәргәме?

Фатыйх турында да уйланмый калалмады. Егет күзгә күренеп үзгәрә бара. Бүген ул хәзер элеккеге Фатыйх түгеллеген күрсәтергә тырышты.

Димәк, ул мин уйлаганча ук төшеп калган егетләрдән түгел икән.

Ташлыярдан соң Габбасы да күңелемне чеметкәләп ала бит, каһәре. Ә, нигә шаярган булып кына сорап карамаска дип уйлап кына бетерде Нургали, тулган айдай балкып, «әллә йоклап киткән инде», дип сөйләнеп Газзәбану килеп керде. Ул инде чайканып, өр-яңа затлы эчке киемнәрен киярга дә өлгергән. Үзеннән беленер-беленмәс кенә хушбуй исе дә килгәләп китә.

—Бигрәк озак көттерден. Ай-һай, әнисе, нинди йокы ди ул. Йокы бүген бездән еактарак йөрер дип уйлыйм әле мин. Бабасы Хафизны да үзе янында калдырды. Әйдә, ялыктырмасана шулкадәр...

—Кадерлем, Нургали, бүген син ахырдан ник бер сүз дә әйтмәдең? Кичке уен гына булмады бит бу. Нык әзерләнгәннәр алар. Фатыйх ничек тотты үзен. Ә син авызыңа су капкандай тик утырдың.

—Нәрсә әйтергә тиеш идем соң мин?

—Тиздән мин дә бөтенләйгә кайтам, бергәләп эшләрбез, авылыбызны ал да гөл итәрбез диярга кирәк иде,—дип, көлеп җибәрде Газзәбану...—Менә шулай, җаным, тавык төшенә тары кергән, чүпли-чүпли арып беткән ди.

—Кайтам, һичшиксез, кайтам... Дөресен генә әйткәндә, китәсем килми, һай бер дә китәсем килми бит, Газзәбану. Хәзергә китми дә булмый шу-у-ул... Нихәл итмәк кирәк. Вәгъдә—Иман. Әйтсәм-әйтим инде, көлсәң-көләрсең... сине калдырып китәсем килми. Көнлим бугай мин, беләсеңме? Көнлим... Вәт, черт возьми, көнлим бит, җаным...

—Чынлапмы? Чын-чынлапмы, Нургали, әллә шаяртасың гынамы? Әйт дөресен... Миңа иң, иң дөресе кирәк. Шаяртсаң шаяртам диген, анысына да үпкәләмәм...

—Үзең әйтмешли, чын-чынлап, бәгърем. Бәлки, миннән көләсеңдер...—диде Нургали.

—Юк, бер дә көләсем килми, куанасым, бик тә куанасым килә... Димәк, безнең мәхәббәтебез мескен түгел, ул искечә үз көчендә, ул яши, яши,—дип, икесе дә бердәм ашкынып, бер-берсенең куеннарына сыендылар. Газзәбану әкрен генә сорап куйды:

—Йә, кемнән көнлисең инде мине? Мин белергә тиешме аны?

Ташлыярда бераз сизгән күк булганыем. Әмма ышанмадым, кылана гына бугай дип уйладым.

—Сезнең авылның Габделгаббасмы, әллә Габбас кынамы шунда? Жыенда булды бугай ул, име?—диде Нургали. Һәм ул Газзәбануын кычкырып көлеп жибәрер дип көтте, ышанып көтте...

Тегесе көләргә жыенмады да, киресенчә житдиләнде генә, һәм сабыр гына болай диде:

—Әйе, жыенга килгән иде ул.

—Очраштыгыздамы? Күрештегездәме?

—Әйе, Нургали, очраштык та, күрештек тә, сөйләштек тә.

—Син нәрсә мине үчеклисең әле, ә? Болай да ут капкан йөрәгемә йөге белән ялкын өстисең. Кайчан, кайда күрештегез? Ә мин кайда идем?

—Син дә шунда, жыендаең. Син мәйданның үзәгендә бүләкләренне тапшыра идең.

—Шуннан, нәрсә сөйләштегез? Вакытын да жайлагансыз бит, ай-яй... Тикмәгә генә сөйләмидер халык, «кыз-хатын камыр басканда да иренә хыянәт итә ала», дип Газзәбануның түземлеге тәмам төкәнде шунда, шаркылдап көлеп жибәрде.

—И, Нургали, Нургали, болай жүләр булмале.

—Жүләрләнерсең дә шул. Ну, мала-а-й, таяк болгап ата каз котыртамыный. Сөйлә инде әйбәтләп кенә. Өйләнгәнме, кайда яши? Әллә һаман сине көтәме? Фатыйх шикелле,—дип, бераз тынычлана төшеп, сорашуын дәвам итте Нургали.

—Әлегә өйләнмәгән. Донбаста яши, шахтер. Жәй саен авылга жыенга кайта икән. Синең шикелле үк чибәр, ул да затлы киемнәрдән. Үз бәһасен белә. Әмма сиңа көнләшергә бер сәбәп тә юк. Тик шунысын гына әйтә алам, әгәр сине очратып гашыйк булмаган булсам, Габбас белән без, бәлки, бергә булган булырыек. Бәлкем, бәхетлерәк тә булган булырыем. Әмма, мин сине, бары сине генә яраттым һәм яратам, үлеп яратам бит, Нургали. Сине генә көтәм, кирәкми миңа бүтән, дип жырлаган күк.

Сызылып таң атканда да аларның сөйләшеп сүзләре бетмәгән иде әле. Күбрәк киләчәкләре турында сөйләштеләр.

—Нургали бәгърем, бу очрашуыбызда янә авырга узмадым микән дип уйланам. Нишләптер борчылып та куям.

—Нигә борчыласың, чыннан да шулай була калса, мин бик шатланырыем. Әгәр без ерак сәфәргә чыгып киткәнче билгеле булса, син шунда ук хәбәр бир. Ул хәбәр, туачак балам турындагы хәбәр, юлларымда миңа очар канатлар куяр. Башым вә жанымны да саклар иде дип өметләнәм, бирсә иде, Ходаем...

Иртәгесен иртүк Нургалиләрне озатырга дип Ташлыярдан кодалар да килеп життеләр. «Сез үз жаегыз, мин үз жаем белән бара торыйм» дип, күршеләре белән дә хушлашып, Нурислам инде китеп тә барды.

—Кая шулай ашыкты ул?—дип, Ибраһим кода кызыксынуын белдерде.

—И, Ибраһим абый, кая булсын, шунда, шул Ташкинга инде. Мәхмүт кемнәрендер каршыларга станцыга бара икән. Нурислам шулар аты белән китте.

—Нурисламның ние калган соң анда? Нургалиебез инде ничарадан бичара дигәндәй... Исән-имин генә йөреп кайта күрсеннәр, Ходай кушып.

—Безнекенең элек эшләгәне өчен күпмедер акча аласы калган икән. Барган көе, уракка төшкәнче, бераз эшләп тә алмакчы була бугай. Бер дә жибәрәсем килмәгәние, юкса. Ашкынды гына бит. Хәерлегә булсын, йә Раббем,—дип, мөлдерәмә күзләрен сөртеп алды Сажидә.

Ат жигүле, Хафиз кузлада. Монсулы ыгы-зыгы, хушлашу...

Ике кодагый, ни тырышсалар да, күз яшьләрсез генә саубуллаша алмадылар. Барысының да гаҗәпләнгәне—Газзәбану тыныч. Анын Маһирә белән хушлашуын берәүнең дә күз уңыннан җибәрәсе килмәде.

—Сау бул, Маһирә. Бергә кайтыгыз. Нургали янында булгач, бу йортта син дә кадерле кеше, шуны онытма. Мин юк җирдә сакла Нургалине, ул барыбыз өчен дә иң кадерле кеше. Хәерле юл сезгә,—диде ул тыныч кына. Әмма Нургалие белән аерылганда анын бу тынычлыгы ахырга кадәр саклана алмады шул. Бигрәк тә үз урамнарын чыгар алдыннан атның туктап калуы, тарантастан Нургалинең сикереп төшеп, кире борылып йөгерә башлавы Газзәбануны бөтенләй әллә нишләтте...

—Җаным, нәрсәнне онытып калдырдың,—дип анын да Нургали каршына йөгерүе... аягындагы үкчәле башмакларын ташлап алга ыргылуы... нәрсәне онытканбыз, нәрсәң калган дип кычкыра-кычкыра йөгерүләре... Ниһаять, бер-берсенең кочагында килеш Нургали:

—Син каласың, бәгърем, син. Кабат хушлашмыйча урамыбызны да, сине дә калдырып китә алмадым,—диде һәм бер-берсенең күз яшьләренә чыланып, менә шулай әллә нинди эчке газаплар белән аерылыштылар алар.

## Нургалиләрнең Ташкентка кайтуы

Вокзал янында әрле-бирле йөргән халык арасында басып торган Локманны ерактан ук Нурислам чамалап алды.

—Ә-ә-әнә, күрәсезме, Локман абый бит ул бу якка карап басып торган кеше. Ул бит?!.

—Әйе, точно эти. Эти шул, этием шул,—дип кабатлый-кабатлый Маһирә алга ыргылды. Егетләр дә адымнарын тизләтте.

—Нигәдер янында әнием күренми, авырып китмәде микән? Мин кайчан гына, кайдан гына кайтсам да алар гел бергә каршы алалары,—дип Маһирә борчыла ук башлады.—И, Раббым, исән-сау гына була күрсен!—Кинәт бернигә дә карамый, бар тавышына «Эти-и-и»—дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды ул. Ишетте Локман һәм шунда ук кулларын болгый-болгый каршыларына ашыкты. Ә колагында калган, бердәнбер кызының «эти-и—и»—дип өзгәләнеп кычкырган тавышы күңелендәге бар борчуларын юып ташладымыный... Ерактан күрүе начарланудан, инде аралары шактый якынайса да, үзләрен күреп бетермәде әле ул. Ниһаять, Маһирә йөгереп барып:

—Этием, үлепләр сагындым мин сезне, дип этисен кочаклап алды. Локман кызының күз яшьләрен күреп:

—Чү әле, кызым, чү, нигә инде бу күз яшьләре? Кирәкмә-әс, син алай елак кыз түгелиең бит... Нишләптер жаның тыныч түгел, ахры?

—Юк, юк, эти, бары да әйбәт. Ә әнием кайда, ул ник килмәде? Әллә авырып киттеме?

—Әниең кунаклар белән өйдә калды.

—Нинди кунаклар, кемнәр?

—Анысын өйгә кайткач үзең күрерсең, кызым. Ий, синең белән мәшәләнеп күрми дә торам икән... Нурислам да килгән ич. Әссәламүгәләйкүм, егетләр. Әйбәт кенә кайттыгызмы, тынычлыкмы?

—Вәгаләйкүм-әссәлам, Локман абзый. Аллаһының биргәненә шөкер. Сезгә авылдан бик күп сәламнәр алып килдек. Җиеңга җибәргән бүләкләрегез өчен авыл халкы бик рәхмәтле калды. Калганын Нургали бәйнә-бәйнә үзе сөйләр,—дип сүзен тәмамлады Нурислам.

—Ну, кияү балакай, синең хәлләр ничек? Монда без сездән башка үткән ике атнаны уздыра алмый изаланып беттек. Әйдәгез, калганын юлда сөйләшербез. Вокзал артында атлар көтә.—Шул чак яңа хәбәр көтүдән

түземлеге төкәнгән Нурислам кыер-кыймас кына:

—Локман абзый, мин бүген үземнен элеккеге фатирыма китим. Моннан әллә ни ерак та түгел, юлы да бик жайлы. Калганын иртәгә күрешеп сөйләшербез, Аллаһы боерса. Килгән көе монда бераз булырмын әле,—дип бүгенгә хушлашырга булды. Әмма Локман житди генә:

—Нурислам туган, безгә кайтыйк әле. Сина әйтәсе сүзләр дә бар,—диде.

—Үз итеп чакыруыгызга рәхмәт яусын. Сезгә мәшәкать ясап борчып йөрисем килми. Үз юлым белән китим әле мин. Мине анда көтәләр булыр,—диде Нурислам. Нургали дә, үзе сүз башлап сорашырга кыймыйча, сабыр гына кайнатасыннан хәбәр көтте. Чөнки авылга киткәндә ул аңа Зөмәрәнен Нурисламнан бала көтүен һәм анын тиздән туарга тиешлеген дә сөйләгән иде. Аларга ярдәм кулы сузарга кирәк булыр дип тә кисәткән иде. Локман ул чакта:

—Нургали, барын да аңладым, борчылма. Ни булса да без монда бит әле. Зәйнәп апаң да ярдәмен кызганмас. Ә син берүк Маһирәне саклый күр. Монысы безнен гозеребез. Сиңа ышанып кына жибәрәбез. Ә менә Зөмәрә ханымнын хәле турында искәртеп бик дөрес эшләдең. Тыныч бул,—дигән иде бит.

Ниһаять, Локман әле берсе дә көтмәгән коточкыч авыр хәбәрне кичекмичә, тизрәк ирештерү кирәклеген аңлап:

—Нурислам, үзенне анда көтәләрдер дип уйласаң да, кызганыч, сине өзелеп көткән кеше анда юк шул инде. Үзе артыннан терекөмештәй тере, үзе атаганча, бөркеттәй улын, күз нурын калдырып, әле кичә генә гүр иясе булды. Авыр туфрагы жинел булсын. Кырыс язмыштыр инде, бары бер генә көнгә соңга калдын шул, Нурислам, бары бер көнгә...

Локманнын соңгы жөмләләре Нурисламга әллә барып житмәде, әллә ул аларны бөтенләй ишетмәдедәме:

—Локман абзый, малай кайда, малай?—дип кычкырып жибәргәнен сизми дә калды.

—Сабыр, туганым, сабыр... шөкер, малай исән-имин, ышанычлы кулда. Минем сезгә әйтәсе килгән сүзләрем—гүзәл Ана яраткан кешесен өзелеп сагына да, көтә дә, хәтта аны бер күрер өчен генә дә гомерен дә жәлләмәгән, гажәеп көчле мәрхүмә—Зөмәрә ханым турындае әле. Һай, көтеп тә карады инде үзенне... Сине соңгы мәртәбә булса да бер күрергә, күнелендә саклаган иң кадерле соңгы сүзләрен, васыятьләрен әйтеп калдырырга, Раббым, ничек тә насыйп итәр әле дигән өмете илаһи көч бирде булса кирәк аңа. Инде соңгы сулышын алды, китте, күзләрен генә йомдырасы калды дигәндә дә, ничә мәртәбә аңына килеп, «улым, бөркетем кайда? Әтисе килеп житмәдеме әле?» дип безне генә түгел, табибларны да таң калдырган ул.

Зөмәрәнең үләр алдыннан кичергән иң авыр вакытлары турында, инде гомеренең соңгы минутларында да анын котылгысыз үлем белән ничек көч табып көрәшкәнен ишетү берсен дә тетрәндерми калдырмагандыр. Әмма ир-ат—ир-ат инде, бик сиздермәделәр кебек. Маһирә дә аларга карап күз яшьләрен никадәр яшерергә тырышса да булдыра алмады. Ә шулай да үзендә көч табып, болай диде:

—Әтием, син баланы ышанычлы кулда дидең. Ә кайда, кем кулында икәнен никтер әйтмисен.

Нәкъ шушы ук сорауны кабат бирергә кыймый чак түзеп торган Нурислам, Маһирәгә сүзен тәмамларга да бирмичә: «Локман абзый, зинһар гафу ит, чыннан да, кайда ул малай, кем кулында? Мин хәзер үк шунда китәрием»,—дип, кабалана ук башлады.

—Юк инде, агайне, синен үзенне генә жибәреп булмас, без дә шунда

кайтасы бит,—дип ярым шаяртып алгач: «Бездә ул малай, Зәйнәп апагыз янында. И ул малайның терелеген күрсәгезме, искитмәле! Булам дип тупырдап тора. Инде көләргә дә маташа. Шул хәтле мәхәббәтле булып туса да туар икән...»—диде Локман.

Бу хәбәрдән соң Маһирәне, әйтерсең лә, алыштырдылар. Тыныч кына утыра да алмый: әле әтисен кочаклый, әле Нургалиенең куенына сыенып, аның колагына нидер пышылдарга тотына. Нурисламны да күз уныннан ычкындырмый...

Кайтып житүгә бөтенесен калдырып, очар коштай булып өйгә атылды Маһирә. Ишек ачылып китүгә, утлар йотып көтеп алган әнисе кызының әйтеп бетергесез шат чыраен, нур бөркеп торган күзләрен күреп сөенде һәм:
—Аллага шөкер! Әлхәмдүлиллаһ, шатланып күрешүләрне дә безләргә насыйп әйләдең! И, Раббым, моннан соң да рәхмәтеңнән ташлама! Барыбызны алдагы көннәрдә дә Хозыр Ильяс канаты астында йөртсәңие!—дип догасын кылды.

Берсен-берсе өзелеп сагынган ана белән кыз кочаклашып күрештеләр.

—Әнием, бала сезнең бүлмәдәме? Бик тә күрәсем килә.

—Күрерсең, балам, күрерсең. Иллә дә мәхәббәтле малай, йоклый әле ул. Әнә әтиләрең дә керә бугай. Бар син тиз генә юынып ал.

—Безнең белән Нурислам да килде бит әле, әни...

—Ничек, ни йомыш белән? Әтиең үзе чакырмагандыр ич?

—Юктыр... Нурисламны күргәч, үзе дә аптырап калды әле ул,—дип җаваплады да, юыну бүлмәсенә ашыкты Маһирә.

Зәйнәп ниндидер бер эчке дулкынлану белән Нургалидән бигрәк, Нурисламның керүен көтте. Нишләп йөри? Нинди максат белән килде икән ул? Әллә Зөмәрәсе белән яшерен элемтәдә булып, барын да белеп килүеме? Юк... ничек инде?... Мөмкин түгел бит бу. Әлеге шикләнүләрем: «Курыкканга куш, коерыгы белән биш» кебегрәк килеп чыгадыр. Тик шулай да сабыйның язмышын хәл итүдә, ата кеше буларак, соңгы сүзне, һәрхәлдә, Нурислам әйтәчәк. Өстәвенә мәрхүмәнең васыяте... Зөмәрәнең җан авазы белән әйткән соңгы сүзләрен ирексездән исенә төшерде ул:

—Бөркетемне әтисе кулына тапшырырсыз. Ул үзе хәл итсен. Әгәр баланы үзенә ала алмаса, аны да гаепләп булмый. Сезнең дә Нурисламга ихтирамлы булып калуыгызны телим. Аның бик яраткан үз гаиләсе бар. Хатыны—Саҗидәсенең дә сәламәтлеге шәптән түгел. Авыл җирендә гайбәте дә чүпрәсе уңган камырдай кабара. Нурисламны да авыр хәлгә куясым килми. Мин аңа болай да мең бәхил. Ул миңа гомерлек хыялым—Ана булу бәхетен бирде. Хәтта туачак баламның карынымда чакта ук хәрәкәт итүен тоюдан күпме рәхәт мизгелләр кичердем. Өч кенә көн булса да күкрәк сөтем белән баламны имезү ләззәтен дә татыдым, бик шөкер! Чыннан да, бөркетемнең авылга кайту мөмкинлеге тумаса, шул вакытта гына, фәкать әтисенең ризалыгы белән, аның язмышын нәкъ үзегез теләгәнчә хәл итүне сезгә тапшырам, Зәйнәп апа. Мин сезне беренче күрүемнән үк нарасыем өчен Раббымның рәхмәте белән җибәрелгән фәрештәләрдер дип кабул иттем. Локман абый белән сезнең кулларда улымның ким-хур булмаячагына ышанып, тыныч җан белән китәм. Безнең өчен кылган изгелекләрегезнең әҗере меңе белән үзегезгә кайтсын. Аллаһының рәхмәтләре яусын сезгә! Тагын бер гозерем: алай-болай баланы сорап үз әнием килә калса, зинһар, бирә күрмәгез. Ул анда кадерсез, бик кадерсез булачак. Үземне зиначы, баламны зина калдыгы диде. Үзегез беләсез, чакыра торып бәхилләшергә дә килмәде бит ул. Мин аңа бәхил һәм үзенә бәхиллегемне биреп китүем турында җиткерә алсагыз бик риза булырыем.

Бер карасаң, әнине бик каты гаепләп тә булмый шикелле. Ул һәр гаиләнең

никахлы булуын һәм һәр баланың фәкать никахлы ата-анадан гына туууын таныды. Үз балаларыннан һәм нәсел-нәсәбәбезнең һәр әгъзасыннан да шуны катгый таләп итте. Мин аның бары бер ягын—хатын-кыз буларак та, бигрәк ана буларак, үз балаларына үтә кырыс, хәтта әйтерием, миһербансыз булуын берничек тә аңлый алмадым. Ә әтиебез киресенчә—ачык чырайлы, йомшак күңелле, бик тә юмарт, әүлия кебек кеше иде. Тик, нишләптер, сәламәтлеккә генә туя алмады. Алты кыз, өч ир баласын калдырып, 40 яшендә гүр иясе булды. Әтигә карап, бу йортта бер каты куллы кеше булырга тиештер бит инде, дигән уеннан әниебез торган саен мәҗбүри кырысланa баргандыр, бәлки. Без барыбыз да әнидән куркып үстек. Хәтта әти дә курка иде шикелле.

Мәрхүмәнең соңгы сүзләрен хәтерендә яңартканнан соң, Зәйнәпнең уенда янә Нурисламга ияреп бала язмышы калыкты. Чыннан да, һич көтмәгәндә Ташкентка килеп җитүенеңниндидер бер сәбәбе булырга тиештер. Алай-болай, «малайны үзем белән алып китәргә килдем «—дисә, ни әйтергә... Өстәвенә, ничек итсә-итеп, алып китә калса... Нишләрмен?.. Йә, Раббым, ярдәм ит! Рәхмәтеңнән ташлама!

Кыска гына вакыт эчендә бу сабыйга шулкадәр ияләшермен дип кем уйлаган? И, Ходаем, бу ияләнү бер дә болай гына булмаган икән ләбаса. Бердәнбер кызының Нургали белән никахлашкан көненнән башлап, ниһаять оныклы да булырбыз дип инде менә ничә еллар хыялланып йөргән Зәйнәп бу сабыйны гел үз оныгына булган хисләр белән кабул иткән түгелме соң? Бу инде гади ияләнүдән бик ерак.

Моннан бер ел элек, зур тикшерүләр үткәннән соң, Маһирәнең балага уза алмаячагын хәбәр иткән мөһерле кәгазь Зәйнәпне тәмам аяктан ега язган иде. Әйе, Маһирәне тапканнан соң үзенә дә, һич онытасы юк, шундыерак хәлне белдергәннәр иде. Ул вакытта Локман белән икәүләшеп, күпме борчылдылар алар, гәрчә бер кыз балалары булса да. Ә кызларына кем уйлаган бөтенләй баласыз калу язмышы килер дип... Карале, Аллаһының рәхмәте—шушы гөнаһсыз сабый Маһирә өчен борчылуыбызны да онытдыра башлаган түгелме соң? Чү! Сабыем чакыра бугай?.. Әйе, хәзер, балам, хәзер,—дип, Зәйнәп эчке бүлмәгә ашыкты. Бүлмә ишеген ачып җибәрүгә, бала күтәреп торган Маһирәне һәм аның сабыйга текәлгән шатлык тулы мөлдерәмә күзләрен, илаһи нурлы йөзен күреп аһ итте.

—Сөбхәаналла, сөбхәаналла, балакайларым! Күзләрем тимәсен,—дип,тиз генә керфекләренә эленгән күз яшен күлмәгенең җиңе белән сөрткәләп куйды.

—Әни, асты юешләнгән, тизрәк алыштырыйк, әнә ничек борчыла. Ирләр кергәнче тәртипкә кертик без моны. Әтиләр нигәдер озакладылар.

—Сез барында ук төзи башлаган ике катлы йортны эшләтеп бетерде әтиең. Барлык җиһазларын да урнаштырдылар. Көзге эшләр беткәч, Нургалинең авылдан гаиләсен әти әнисе белән шунда күчерербез ди. Көзләргә кадәр шунда сезне яшәтергә уйлый. Бик матур килеп чыкты ул йорт. Бүген үк шунда кунарсыз, Аллаһы боерса. Нургалиләргә шул йортны күрсәтеп, уйлары,планнары белән таныштырып йөри.

—Белмим шул, әни. Киявегез ни дияр бит әле. Аның үз авылында үзебез өчен ике катлы йорт булдырып, беренче катында зур кибет ачып, шунда яшисе килә шикелле. Әти-әнисе дә шулай тели булса кирәк. Авылны ташлап китә торганнардан түгел алар. Ташкентка да кунак булып килсәләр килерләр, әмма яшәү өчен түгел. Авыл үземә дә бик ошады. Урманнарга, суларга бай. Кешеләре дә бик ачыклар, тырышлар...

—Көндәшең—Газзәбану турында бер сүз дә әйтмисең әле... Минем бөтен борчылганым шул булды. Ә син бик тыныч күренәсең, шөкер...

—И, әни, сиңа сөйлисе сүзләрем... И-и аларны сөйләп кенә бетерерлекме соң... Биләүләрен чишеп, астын корыткач, тагын йоклап китте җанкисәгем.

Урынына салыйм әле, тегеләр керә бугай...

—Чыбылдыгын капла тизрәк! Йоклаган балага карарга ярамый. Әле кырыгы да тулмаган бит,—дип бүлмә ишеген ябып ук куйды Зәйнәп.

—Кызым, син ирләрне аш өенә алып кит. Анда бары да әзер. Хәзергә мин монда калыйм. Пешекчеләргә әйт, башта гел үзебезчә пешереп чәй чыгарсыннар.

Бик вакытлы чыкты Мәһирә. Ирләр юынып, чистарынып, башта баланы күрмәкче булып алгы бүлмәгә килеп тә керделәр. Мәһирә аларны шунда ук туктатып, әнисе кушканча аш өенә алып китмәкче булды. Егетләрнең дә үз сүзләре сүз, бигрәк тә Нурислам белән Нургали:

—Күзнең кырые белән генә, янына ук бармыйча, ерактан гына карарбыз, һич уянмаячак, хәтта без карап алганны сизмәячәк тә ул,—дип ялвара ук башладылар. Ниһаять, Локман үзем катнашмасам булмас, ахры, дигәндәй, бармагы белән генә тышкы ишеккә күрсәтте дә, кул изәп, алып чыгып китте егетләрне.

—Әйттем бит мин сезгә, бу йортта Зәйнәп апагыз сүзе закон. Вакыты житкәч үзем күрсәтермен дигәнме—дигән. Күрсәтер Алла боерса, сабыр булыйк! Монда сезнең түгел, минем карыным ачып бетте инде. Сез кайтышка дип ниләр генә пешертмәде әниегез,—дип алдан житәкләшеп атлаган кызы белән кияве уртасына кереп:

—И сагындым мин сезне, балалар! Берничек тә анлатып булмый торган әллә нинди сагыну белән сагындым. Хәерлегә булсын,—диде дә, чыланган керфекләрен сыпыргалап алды.

Табын мул иде. Пешекчеләр дә бик тырышты. Мәһирә белән Нургали берсен-берсе бүлә-бүлә авыл хәлләрен сөйләделәр. Хафиз белән Тәскирәнең дә күнелле мәзәкләре искә алынды, көлештеләр. Тик Нурислам гына ачылып китә алмады. Зөмәрәсе турында тагы нидер ишетәсе килеп микән, бөтен игътибары, уйчан карашлары Локманга юнәлгән иде. Нурисламның эчке халәтен шактый күптәннән сизенеп утырган хужа болай дип сүз башлады:

—Хәзер мин сезгә мәрхүмә Зөмәрә ханым турында үтә дә гыйбрәтле бер кыйсса сөйләрием.

—Сөйләгез, зинһар сөйләгез, Локман абзый. Сездән башка миңа аны тагын кем сөйләр?

—Ялгышасын, Нурислам, ялгышасын. Бар ул кеше. Зәкия исемле бик акыллы Казан кызы ул. Зөмәрә ханымда фатирда торып, аны сонгы сулышына кадәр караган, тәрбия кылган бала. Телебезне дә ул өйрәткән аңа. Зәйнәп апаң белән мин үзбәкчә әйбәт кенә сөйләшсәк тә, ул безнең белән гел татарча сөйләшергә тырышты. Ярдәмче дә, остаз да һәм иң ышанычлы сердәш тә булыр өчен кеше нинди сыйфатларга ия булырга тиеш булса, менә шул яшь кенә кызда—барысы да бар. Анын сиңа сөйләр сүзе дә күптер... үзенә генә тапшырасы кайбер әйберләре дә бар кебек.

—Аны бүген үк күреп булмас микән, Локман абзый?

—И, сабырсыз да инде үзе. Нишләп булмасын, булыр. Әйтсәм-әйтим инде, ул да бездә. Ә сөйлисе кыйссаны Зәйнәп белән икебезгә Зөмәрәнең табиблары сөйләде. Бичараның карынында игезәкләр булган икән. Тик вакытында белә алмаганнар. Әллә игътибарсызлык, әллә икенчесенең йөрәге зәгыйфьрәк эшләгәнме, кем белсен... Инде тәмам билгеле булгач, мәрхүмәбезгә көмәненнән котылдыру чарасын тәкъдим итәләр. Кая ул... Ишетергә дә теләмәгән. Менә шуннан соң тапкан хәлдә аңа табибларның ярдәм итә алмаячагын ачыктан-ачык әйтергә мәжбүр булалар. Шунда ул «балаларның берсен генә булса да исән калдыра алырсызмы?»—дип сораган. Кире жавап ишеткәч, үзенең беркайчан да бу чарага риза булмаячагын

әйтеп, хәтта, кульъязма да язып биргән. «Сез үзегезне аңлы рәвештә үлемгә дучар итүегезне аңламыйсыз, ахры»—дип әйтеп карыйлар аңа. Ә ул барысын да гаҗәпләндереп: «Фани дөньяда минем дәвамым—балам, аннан соң баламның балалары кала икән—бу җирдә минем яшәвемнең дәвамы түгелмени? Аларда минем каным, минем җаным сакланачак. Сез аңлаган һәм мина юраган үлемне—үзем өчен үлем дип санамыйм. Сезгә, ак халатлы фәрештәләремә, Раббым кушып, баламның берсен генә булса да исән саклап кала алырсыз дип ышанам. Гомерем буе бер нәрсәдән—бакыйлыгымда да ялгыз калудан куркып яшәдем. Тормыштагы ялгызлык үтә дә китә ул. Анысы вакытлы гына. Бакыйлыкка ана булып күчү—ул Аллаһы Тәгалә хозурына изге бурычыңны үтәп килү дигән сүз. Димәк, син ялгыз түгел, үзенә дога бирүчене калдыра алгансың. Әнием мине «зиначы» дисә дә, мин Раббымнан гөнаһларымны ярлыка дип сорамыйм. Үзен җәзасын бир, дим, барына да риза. Тик туачак баламны дөм ятим итә күрмә. Аңа хәерле озын гомер бир, рәхмәтләреңнән ташлама берүк, дип, һәр намазым артыннан дога кылам. Сез дә мине аңларга тырышып, ярдәмле булсагызые,—дигән. Карагыз әле, каян килгән бу хатынга шул кадәр зур акыл, сабырлык, түземлек. Күрер күзгә гади генә бер үзбәк хатыны. Мәгълүматы да—бары укый-яза белүдән әллә ни артмаган.

Шул вакыт пешекчеләрнең берсе хуҗаның колагына шыпырт кына нидер әйтә башлавы белән: «Егетләр, әйдәгез, безне Исламетдин галиҗәнапләре көтә икән ләбаса. Киләселәре килсә килеп, күрәселәре килсә күреп калсыннар, йоклап китсәм, Зәйнәп апам берегезне дә кертмәс. Йоклаганда мине беркемгә дә күрсәтми ул, дип бик килешле генә шаяртып алды Локман. Пешекчеләргә рәхмәтләрен белдереп, ашка дога кыла башлауга: «Без монда киләбез бит әле»—дип, ашка догасын да бирмичә, Нургалиен ашыктыра башлады Маһирә.

—Ипләп, кызым, ипләп. Нурисламга юл бир. Нургали белән сез болай да өлгерерсез, монда каласы кешеләр.

Бала үз караватында йокыга китәр-китмәс кенә оеп ята. Иреннәре белән җимеп тә куйгандай була. Нурислам аны күрү белән:

—И-и, Зәйнәп апа, мин гадәттәгечә ак биләүгә биләгән малайны күрәм дип керәм тагы. Ә сез аны тәмам егет ясагансыз түгелме соң?

—Менә шулай, әттәгенәсе, биләүдә түзеп ята торган егет түгел шул без. Аяк-куллары белән чәбәләнә-чәбәләнә тәмам туарылып бетмичә йоклап та китә алмый ул. Тикмәгә генә «терекөмешем минем» дип сөйми торгандыр Локман абыйсы да. Шулкадәр тере булса да булыр икән: башта ничек итсә-итә, кулларын чыгара. Битен-күзен тырмамасын тагы дип әнә чүпрәк бияләй кидерәбез үзенә. Зәкия апасы: «тумас борын «боксер» да булдың»,—дип сөя. Якынрак кил, Нурислам, якынрак... Сине күзли кебек... Әнисе шикелле «Бөркетем, син кайда?» дип дәш әле. Зәкия апасы аңа гел шулай дәшә. Ярата ул аны, әллә әнисе дип кабул итә инде.

Нурисламның балага иелүе булды, гаҗәеп хәл, хәтта моны могҗиза дими ни дисең?

Башта күзен зур итеп ачып Нурисламга текәлде. Шул чак Зәйнәпнең урыннан кузгалмыйча гына, «Бөркетем, син кайда?»—дип тавыш бирүе малайны алыштырып куйгандай итте: әле куллары, әле аяклары белән ашыга-ашыга әллә нинди хәрәкәтләр ясый башламасынмы! «ы, гы»лар диеп, аякларын тераш арт санын да күтәрткәләп ала башлады.

—Һай, җаным, кулыма алыыем, Зәйнәп апа, мөмкинме?

—Ал, җаным, ал. Әнә үзе дә сиңа ыргыла, сиңа барасы килгәне әллә каян күренеп тора. Янында ничә кеше басып торабыз, беребездә дә эше юк, күзе фәкать синдә генә бит. Монарчы әле беребезгә дә болай кыланганы

булмады. И, сабыем, күзләребез тимәсен! Сөбханалла, Үзең саклый күр!

Могжизаның икенчесен—Нурисламның сабыен үз кулына алганнан соң күрделәр. Бу көнне мәрхүмә турында нинди генә кызганыч хәбәрләр ишетмәсен, Нурислам күз яшьләрен күрсәтмәде. Ирләрчә кабул итте шикелле. Әмма кулындагы тыныч кына яткан баласына иелеп, мөлдерәмә күзләреннән тәгәрәп төшкән яшьләрен күрсәтмәскә дә тырышып карады... булдыра алмады...

Дилбегәне янә үз кулына алырга туры килде Локманга. Башкаларны әкрен генә алып чыгып китте. Анда үзен көтеп утырган Зәкияне күргәч, Локманны, әйтерсең лә, алыштырып куйдылар. «Кешенеке кештәктә» дигәндәй, бу минутларда Нурислам өчен борчылуларның гел кирәге юк кебек тоелды аңа.

—Йә, кызым, булдымы? Мулла абзыеңның үзен күрдеңме? Ризамы, нәрсә диде?

—Әйе, Локман абый, бары да үзегез дигәнчә булды: ризалыгын да бирде, кичке сигезгә килеп җитәрмен, ике яктан да шаһитләре булсын, диде.

—Һай, рәхмәт төшкере, инде Маһирә апаларың белән дә таныш бул,—дип Зәкиянең аркасыннан сөеп куйды. Киявенә серле генә итеп күз кысарга да онытмады. Ә кияү дигәне Маһирәсенә күз ташлап, сүзнең никах турында икәнен сиздерү өчен: «Сөенечләр уртак булсын»,—дип елмайды. Маһирәсе күптән инде барын да аңлап, ни арада Нургалие сөйләп, ни арада әтисе чарасын да күреп өлгергәннәренә сокланып, күңеленнән рәхмәттә калды. Бары бер Зәйнәп кенә берни дә аңламады. Чөнки ул авылда булган хәлләрнең берсен дә белми иде әле. Инде барын да ишетеп, белгәннән соң: «шаһитләрне кияү ягыннан Нурисламны, Маһирә ягыннан Зәкияне әзерлик. Никахны аш өендә үткәрербез. Пешекчеләр белән Маһирә сөйләшсен». Нурислам белән сөйләшүне Локманга тапшырды. «Зөмәрәнең калдырган хатын бүген түгел, иртәгә бирү мәслихәт булыр. Аның күңеле болай да тулып ашкандыр инде»,—диде Зәйнәп.

—Һай, карчыгым, исән генә була күр! Шушы кыска гына вакыт эчендә барыбызны да үз урныбызга куеп, нинди зур эш башкардың. Гомерем буе шушы уңганлыгыңа, зур акыл белән йортыбызны алып бара алуыңа сокланып яшәдем. Рәхмәт, карчыгым, хәзер бераз ял итеп ал. Садыйк хәзрәт килгәнче үзенне дә тәртипкә китерергә тырыш. Соңгы вакытта көннәр буе бала белән бераз таушалып та киттең...

Нурислам кулларында яткан баласына карап, кыймылдарга да курыккандай, һаман басып тора. Локманның кергәнен дә сизмәде бугай, борылып карамады. Локман:

—Синең белән киңәшеп аласы бар,—дигәч, сабыйны үз урынына салып, алгы бүлмәгә чыктылар. Хуҗаның сүз башлавы белән:

—Бер дә борчылмагыз, бу никах авылда ук яңартылырга тиешие,—диде Нурислам.

—Ә ни сәбәпле үтәлмәде соң ул?

—Шактый вакыт Газзәбануга әйтергә кыймый йөрде Нургали. Башта җыен үтсен дип, аннары әби-бабай авылы Ташлыярга кайтып килик дип көн арты көн үтте. Ә Маһирәгә кайткан көнне үк әйтергә мәҗбүр булды. Никахны яңартуны үз өстенә алган Фарук хәзрәтнең дә үз хәле хәл. Аңа никах уку, балаларга исем кушу, мәчеттә вәгазь уку, җомга намазлары уздыру тыелган. Монда никахны Зариф абыйлар гаиләсе өчен дип яңа төзелгән йортыгызда укытсагыз дөресрәк булыр. Зариф абыйлар ата-баба нигезен беркайчан да ташлап китә торган кешеләр түгел. Тормышлары да Аллага шөкер.

—Менә шул-шул, туганым. Әллә Локман абыең туган авылын үзе бик теләп, тиктомалдан гына ташлап киткән дип уйлыйсыңмы? Рәсәй дәүләтендә татарга беркайчан да юньле караш булмады. Йә ул аны кычкыртып

чукындырырга тотына, йә ул аның эшкә унганлыгын, чыдамлылыгын вә түземлеген, өстәвенә, буйсынучан холкын вә акча яратканын да белеп, бик еракларга, иң авыр эшләргә җибәрә. Шулай итеп, күпме татарларыбыз туган җирләреннән, милләтеннән аерылып, чит җирләрдә кала килә. Алдагы көннәрдә безгә дә Ташкенттан да ераккарак китәргә туры килмәгәе әле... Ходаем үзе сакламаса...—Локманның соңгы һич көтелмәгән сүзләреннән соң ни уйларга да белмәгән Нурислам:

—Локман абзый, пажалый, мин малайны үзем белән алып китәрмен. Зәйнәп апа белән ничек тә ярдәм итә алсагыз, мәңге онытмасыем,—диде.

—Син һаман ашыгасың, якташ. Иртәгә сөйләшербез, киңәшербез... Сиңа әле Зәкия белән дә сөйләшергә кирәк. Зөмәрәнең сиңа язган хаты да бар. Аны да иртәгә, тынычлана төшкәчрәк уку мәслихәт булыр дип уйлаштык Зәйнәп апаң белән.

—Ул хат, бәлки, мине киресенчә тынычландыра алыр... Ир баласын күргәннән соң ирләрнең кайсы гына тыныч кала алыр икән?.. Белмим, житмәсә, ул үзенә тач охшаган булып та туса тагын... Сабыйның аркасында нәкъ минеке төсле миңенә кадәр бар бит, Локман абзый. Үкенечкә генә туган булса ни хәл итәрсең... Аллам сакласын!

### «Нургали бәгърем, сөенче!»

Кунакларны озатканга нәкъ бер атна дигәндә, Газзәбану үзенең авырлы икәнен белде. Шунда ук, бөтен эшен ташлап, Нургалиенә хат язарга утырды.

«Нургали бәгърем, сөенче, сөенче, сөенче!!!

Аллаһының биргәненә шөкер, безнең теләкләребез, бигрәк тә синекедер, кабул булган бит, ничек сөенмисең! Барыбыз да исән-сау. Шушы бер атна эчендә башкарган эшләребезне күрсәң, ничек шатланырыең, җаным. Сезнең кайтышыгызга барын да эшләп бетерәсебез килә. Бу матур мәшәкатьләр юксыну-сагышларыбызны да җиңеләйтә төште.

Сезне озатканнан соң без бөтенләй югалып калдык бит. Житмәсә, Хафизымның: «Әтием нигә генә китте инде ул, безне калдырып?—дип күз яшьләре белән жылап кайтып керүләре өзде үзәк багырьләребезне. Ни сабыр әткәйнең дә бу кадәр күңелсезләнгәнен күргәнем юкые әле. «Бу юлы нишләптер бик авырдан китте балакаем. Күз яшьләренә буылып: «Әти, азга гына булса да Хафизымны җибәр минем белән. Нурислам киткәндә бергә үзем озатырмын»,—диде. Әгәр бу минутларда әтисенең муенынннан кысып кочаклаган сабыем: «Мин әтидән калмыйм»,—дисә, берни эшли алмаган булырыем. Ә ул: «Әти җаным, мине әнием көтә бит. Мин дә китсәм, әни нишләл? Син үзең тизләк кайт, яме»,—дип миңа атылды. Үзе юл буе жылап кайтты»,—дип сөйләгәч, әнкәй бөтенләй урынга ук егылды. Минем ни хәлдә калганымны үзең дә күреп киттең. Ярый әле, әткәйнең үтенечен тыңлап, минекеләр бер атнага бездә калырга риза булдылар. Ирләр син алып калдырган агачлардан бура бурарга тотындылар, яңа жылы абзар өчен. Атна ахырында икесе Мәкәрҗә ярминкәсенә, синең киңәшең белән, нәселле яшь ат алырга дип киттеләр... Беләсеңме, нинди матур ат алып кайттылар. Әле ат булып ук житлекмәгән, алмачуар яшь айгыр. Атны күргәч, Хафизның сөенгәннәрен әйтеп, язып бетерерлек түгел. Маңгаендагы кечкенә генә яңа туган ай сымак кашкасына күрсәтеп, «Кашка» дип исем кушыйк әле,—диде. Барыбыз да куанып риза булдык. Әткәй аны атка якынрак китерде дә:

—Улым, ничек уйлыйсың? Нигә без ерак бабаң белән бу атны сайладык икән? Атыбыз бәләкәй башлы, дуга муенлы, бәкәлләре озын... «Чаптар»ыбызга охшамаган име,—диде.

—Бабай, «Чаптал» калтайды, чабышка да балганы юк. Ә монысы

киләсе җыенга чабышкы булсын. Мәхмүт абыйга кушсаң, ул өйләтә инде аны,—димәсенме малаең.

—И, улкаем, мин синнән нәкъ шушы җавапны көткән дә идем. Маладис! Акыллы малай шул син. Кайсыбызга гына охшап тугансыңдыр?

—Ялуллин, Ялуллин бит мин!

Бабайлар бик канәгатьләнеп, рәхәтләнеп көлештеләр.

И, Нургалием, шунда син дә булсаң, ничек горурланырыең. Маһирә дә яратып карап торыр иде әле,—дип уйлап, сезне көннәр, атналар буе күз алларымда йөрттем.

Ул да булмады, әткәй ерак бабайга атны тотып торырга дип йөгәнне бирде, Хафизны күтәреп алып, атның биленә атландырды да болай диде:

—Әйе, улым, бу атны мин күбрәк синең өчен алдым. Ходай кушып, берничә елдан синең шушы ат өстендә мәйданга беренче булып килеп кергәнеңне күрергә насыйп әйләсә иде безләргә! Ә син хәзер ашыкмыйча гына, кычкырып, «Бисмилла»ны укырсың. Аннан соң атның муеныннан кочаклап, шуышыбрак, мин сиңа булышырмын, аның уңъяк колагына «Кашка» дип өч тапкыр әйт. Бу аңа исем кушу була. Синең үзеңнең дә колагыңа мулла абзый «Хафиз» дип, менә шулай исем кушканые.

—Ә мин аны ишетмәдем бит, бабай,—диде ул бик аптырап.

Без тагы елмаешып куйдык.

Ике бабайның ярдәме белән атыбызга исем дә кушылды. Сөбханалла, ат үзен бик тыныч тотты. Чыгымлап китмәгәе дип куркыбрак торганыем, атларның холкын белеп бетереп булмый бит. Соңыннан ул Хафизга таба муенын борып, мин ишеттем, рәхмәт, дигән сыман аска таба башын игәләп куйды. Бала аны нәкъ шулай аңлады да, янә бер куанды.

—Бабай, Чаптал кыелсытмас микән Кашканы?

—Борчылма, улым. Аларның икесенең дә үз өйләре бар. «Кашка»га өйнең яңасын, зурысын бирәбез. Аңа күп хәрәкәтләнергә кирәк булыр. Мәхмүт абыеңны чакырырсың әле, су коендырырга бергә алып төшәрсез. Болында бергә йөгертеп тә алырсыз. Бераз ял иткәч, бәлкем, үзем дә төшәрмен,—диде бабасы.

Менә шулай, Нургалием. Тагын бер яңалык—Гыйззелбәнат апай мине үзе белән йөртә башлады. Яшьтән өйрәнергә кирәк ди. Арысам да, бик теләп барам. Дөньяга яңа туып килгән баланы кулыма алганда бөтен дөньяң онытыла икән. Ике-өч сәгатькә генә булса да, сагышларымнан аерылып торам. Иртәгә әтиләрне Ташлыярга озатабыз. Берәр айга Бибиҗамал әбине алып кайтып тәрбияләрбез дип торабыз. Әнкәй бик бетереште, әллә нинди сагыну белән, сабырлыгын җуеп сагына үзеңне.

Нургали, хатларыңны минем кук озын итеп яз. Онытылып укырлык булсын, яме. Маһирәгә, Зәйнәп апага, Локман абыйга барыбыздан да сәлам тапшыр. Нурислам кайчан кайтырга җыена икән? Аның артыннан да хат җибәрә күр. Саҗидә бик борчыла. Анда эшкә калуын бер дә теләми.

Тагын бер хәбәр—мәчет янына ниндидер такталар китергәннәр. Мәктәпне төзеп бетергәнче балаларны шунда укытырга җыеналар дип сөйлиләр. Намаз укый торган зур залны бүлгәләмәкче булалар ди. Фарук хәзрәт балаларга белем бирү, укыту өчен булса ярый әле, камсамуллар өчен төрле кәмит ясау ниятләре белән йөрсәләр, Раббым Үзе сакласын. Мәчетне көфер почмагына әйләндерергә батырчылык итә калсалар, җир анабыз күтәрә алмас аны. Аларның һәрберсе Аллаһы Тәгаләнең иң авыр җәзасына дучар булачак, дигән. Авыл халкы борчыла...

Нургали, эшләрегезне тизрәк бетереп, кайту ягын карагыз инде. Маһирәңә әйт, балалар, яшьләр аны сагыналар. Һәр йортта диярлек ул калдырган җырларны җырлыйлар. Гармунчы Сабирҗан да аларны

кызлардан өйрәнеп беткән инде. Һәр кичне көтү кайтканда урам якка чыгып, үзләренен капка төбендәге эскәмиядән сиптерә генә шул көйләрне. Аларның өйләре биектәрәк бит. Безнен капка төбенә чыгып утырсаң, күренеп тә тора ул. Әнкәй аны һәр көнне көтеп ала. Кичке һавада гармуннан агылган моннын үтә тәэсирле янгырашы сиңа бик таныш. Бөтен авыл илаһи монга күмелә. Сөт тулы мул имчәкләрен көчкә күтәреп, алпан-тилпән кайтып килүче сыерлар да шушы мон эчендә әкрен генә атлыйлар. Гаҗәп бит, алар да әллә уйнаучының үзенә, әллә шушы илаһи моңның сихри янгырашына үз мөнәсәбәтләрен төрле ысуллар белән белдерергә тырышалар кебек. Кайсыларының кыска-кыска гына мөгрәп куюлары, кайсыларының «өзәсен бит үзәк бәгырьләремне» дигәндәй, ачыргаланып сузып кычкырып җибәрүләре—безнен ише сагышка сарылганнарны менә шундый уйларга саладыр да инде...

Гармунын уйнап кына утырса бер хәл. Кайбер җырларны, бигрәк тә, син яратып җырлый торганнарын, җырлый да бит әле ул. Читтән бер карап кына торсаңые син әнкәйнен «Ал Зәйнәбем»не тыңлаганын.

Күз тияр дип йөзләренә
Туйганчы карамадым

дигәнен ишетүе була, «туйганчы карый да алмадым шул» ди дә, сыгылыплар гына төшә. Аннары туктаусыз күз яшьләре... Элек алай түгелие бит ул. Бу кайтуыгыздан соң бик нык үзгәрде әнкәй. Күзенен яшьсез чаклары бик сирәк була. Син аның үзенә генә атап бер хат җибәр әле. Жылы итеп яз, бел аны... Ничек сагынуларыңны, бала вакытындагы синен өчен борчылуларын, сине яратып пешергән ризыкларын, аларны сөенеп сиңа ашатуларын... и өйрәтеп утырган булам инде... Үзең менә дигән итеп язарсың әле, боерган булса. Синен ул хатың әнкәй йөрәгенә бәһаләп бетергесез дәва булачак, Нургали.

И, язасы тагын бер хәбәрем калган икән... Сез киткән көнне Мәхмүтләргә Казанда әтиләрен җирләгән туганы Гөлсем апа кайткан. Аның бик кечкенә Кәримә исемле кызы да бар икән. Безгә дә килеп киттеләр. Бик ошатып калдык без аларны. Аның сине күрәсе килгән булган. Ташкентта яшәүче мәрхәмәтле Кари әкә дигән кеше Гөлсем апаларга кайткалап йөри икән. Ул Нургалине дә, Локманны да бик яхшы беләм дигән. Нургали кайтуга миңа хәбәр итегез диде. Бәлки әле кайтышлый ук үзе безгә кереп чыгар, без Казан вокзалына бик якын торабыз, Тихвинский урамы, 77 нче йортта, диде. Нургали, ул кешенен синен үзенә генә әйтәсе сүзе бар, ахры, дип уйладык без.

Карале, Нургали, Нурислам артыннан Хафизына үзеннеке төсле киемнәрне алып җибәрегез әле. Маһирәгә үлчәүләрен бирдем. Теге вакытта ялгышып алып кайтканыгыз бик кечкенә булды бит, ул аны кия алмады. Сез аны кемгәдер бирергә теләгәч, мин, тупасрак килеп чыкты бугай, хәтерлисеңдер, «Юк, кайткан җирендә калсын әле» дип Маһирәнен кулыннан тартып алганыем. Менә кем өчен калдырганмын икән... Бүген мин аларны алып, туйганчы карап сөендем. Инде бик ләззәтләнеп пардан киенгән өч лачынымны күз алларымда йөртәм. Менә шундый матур хыялларым ялгыз төннәремә ямь биргәндәй була. Үзенә ошаган исемне сайла да, миңа язып җибәр, яме, бәгърем. Сау бул, түземсезләнеп хатыңны көтәм. Озын итеп яз, бел аны! Сагынуларым бниһая, мөмкин түгел аңлату.

Сәлам белән, Газзәбануың.

2 июль, 1924 ел.»

***

Сажиданең: «Йомышларын йомышлап бетерүгә, кайтып кына килсәе, и Раббем, рәхмәтеңнән ташлама»,— дип бер өзлексез ялварулары кабул булган, күрәсең. Нурисламының кайту хәбәрен ишеткәч, шатлыгыннан нишләргә белмәде. Мондый чакта Зариф абый белән кинәшләшү—иң дөресе булыр дип Сажидә су буеннан гына күршесенә ашыкты.

—Зариф абый җаным, берсекөнгә Нурисламыбыз кайтып төшә икән. Каршы алырга үземә кушкан хәбәрен житкерделәр бит.

—Котлыйм, күрше. Бик һәйбәт. Эшкә калмыйча бик дөрес эшләгән. Кызы белән яраткан, тугры хатынын акчадан өстен күреп, сезне сагынып кайта. Бәрәкалла, мәшалла! Акча килә дә китә, бергәлеккә ни житә димәсләрие аны, күрше. Әнә, бер дә ерак барасы юк, Газзәбануыбыз монда тилмерә, ул Нургалиемнең безнең белән соңгы хушлашкан чагын күз алдыма гына китерсәм дә, йөрәгем пәрә-пәрә килә. Поезд инде бар көченә кычкыртып жибәрде, йә, Хода, пуфылдый да башлады. Ә ул һаман улы белән мине кочагыннан ычкындыра алмый, күзләреннән аккан яшьләре әле дә күз алдымда... Шунда Маһирәнең: «Нургали, каласың бит, йөгер тизрәк» дип, ачыргаланып кычкырган тавышыннан һушына килде, балакаем. Өлгерде тагы, шөкер. Мин булсам, валлаһи дип әйтәм, өлгерә алмый идем. И, балакайлар, әле сезнең иң матур да, көчле дә чагыгыз. Бергәлекнең сәгатен түгел, минутларын да әрәм итмәгез!!!

—Рәхмәтләр яусын. Зариф абый. Сезгә дә минем шикелле шатланып Нургалине каршы алырга насыйп булсын.—Нурисламны каршыларга бергә барсак вакытыгыз булыр микән? Шул турыда сөйләшергә дип керүем,—диде Сажидә.

—И, күрше, вакытны булмаса да табарбыз, Аллаһы боерса. Бу бит безнең уртак сөенечебез. Нурислам аркылы безнекеләрнең дә хат-хәбәрләре булмый калмас. Ә син борчылма, Сажидә, мин үземнең «Чаптар»ны жигәрмен.

—Нишләптер сезнекеләр күренми, берәр жары киттеләр мәллә?

—Мәхмүт белән Мәфрүзә, Хафиз белән Тәскирә аларга ияреп Газзәбану Кашканы су коендырырга, аннары болында йөгертербез дип киткәннәрие.

—И, Зариф абый, үз шатлыгым белән онытып да жибәргәнмен. Тәскирәм әйткәние бит югыйсә.

Акыл иясе күршесенең гыйбрәтле кинәшләреннән соң Нурисламына булган шик-шөбһәләре турында сөйләп тормады Сажидә, унайсызланды. Газзәбануы булса эчен бушатмый калмасые анысы... Туктале, бөтен серемне сыйдыра торган Гыйззелбәнат апа белән сөйләшеп чыгыйм дип кергән иде дә, ул да каядыр киткән. Тәскирәм дә юк, ичмаса, биләмдә йөри. Әтисенең кайтасын да белми. Янында уйнарга Хафизы булса, аңа шул житкән. «Әниемә кирәгем чыкмады микән дип тә уйлый белми, ваемсыз»,—дип кызына да үпкәләп куйды. Аннары бик урынлы гына үзен дә шелтәләп алды. Ирем кайтышка ул яраткан ризыклар пешерү турында уйланасы, хәстәрләнәсе урынга әллә ниләр уйлап йөрим шунда, жүләр баш...

Нурисламның иң яратып ашаган ризыгы тутырган тавык. Бер тавыгым күкәйләрен каядыр качырып салып, кыртлап йөри башлаганые. Шуны суйдырып, жиде-сигез йомырка белән тутырырмын, боерган булса. Шулпага бүгеннән үк токмачларымны кисеп киптереп куярга кирәк. Мул гына итеп камыр ризыклары да пешерермен. Күршеләребез белән бергәләп бәйрәм ясарбыз, исән-имин генә кайта күрсен, жаным. Тормышның бөтен яме фәкать Нурислам белән... Ул өйдә булмагач, малларыма кадәр боеккан шикелле күренәләр. Үземне әйткән дә юк инде... Тавыкларыма хәтле электәгечә жырламый хәзер. Ә мин үз-үземне борчып, юкны бар итеп, көнләшеп йөргән булам бит әле.

Ниһаять, күнеле тынычланып, дәртләнеп эшкә тотынды Сажидә. Изеп

куйган коймагына бер-ике кашык көнбагыш мае салып, берничә йомырка сытып, әзрәк кенә чүпрәсен дә өстәп, ишәйтеп куйды. Жырлый-жырлый самавырын да куеп жибәрде.

Сагынам, бәгърем, бик сагынам.
Сагынам сине көн саен.
Һәр кич саен күккә карап,
Эзлим йолдызлар саен.

Тиз генә тавык-чебешләрен дә ризыкландырып керде. Сыерын савар өчен бар кирәк-яракны әзерләп куйды. Очып кына йөри Сажидән. Аягы жиргә дә тими диярсең... Сыерына онын, көрпәсен бергә туглап, тозын да салып бер чиләк витаминлы суын да әзерләде. Коймагына күз салса, сөбханалла, кабарып менгән, пешерә башламасаң, ташый бит бу хәзер.

Гөжелдәтеп кенә пешереп тә куйды. Һай, камырының унганлыгы, коймагының тәмлелеге... Күрер күзгә—авызыңнан сулар китерерлек, ашый башласаң телләреңне йотарлык булган. Чәйнәп тә торасы юк, шул кадәр йомшаклар, авызда эреп кенә китәләр. Аллага шөкер, сыерыбыздан да бик уңдык, ул сөте белән каймагыннан желек тәмнәре килә диярсең... Коймакларны зур жамыягына салып, өстен каплап учак янынарак куйды. Маен табада эретеп, коймакларым өстенә сибәрмен дә, маена манчып ашарга кушармын. Нурисламым шулай ашарга ярата.

Ул да булмады, Тәскирәнең гаять шат тавышы:

—Әни, әти кайтамыный? Жалиф абый әйтте, дөлешме?

—Дөрес, кызым, дөрес. Бар, матурым, тиз генә кендек әбиең белән Газзәбану апаеңны кайнар коймак белән чәй эчәргә чакыр. Тиз керегез, әни көтә диген, кызым, яме.

—Ә Хафижны?

—Чакыр, жаным, Хафижыңны да чакыр, коймакларым күп, иллә дә тәмлеләр...

Шау-гөр килеп, шатланышып килеп тә керде күршеләр.

—Үзебез дә кермәкчеиек әле, шатлыгың котлы булсын, шатлык арты шатлык тулсын йортыңа, ахирәткәем. Әткәй әйткән бу хәбәргә әнкәй белән безнең куанганны күрсәңие син... Синнән битәр куангандыздыр, мөгаен. Нургалием янынннан кайта бит... жаным. Әткәй бүген ике рам кәрәзне, әле иртәрәк булса да, аертып карады, Нурислам кайтышына дип. Менә монысын сиңа чәй эчеп тотарга бирде,—дип, Газзәбану бер литрлы пыяла банкада гажәеп хуш исле яшь балны өстәлгә куйды.

—Минем дә кучтәнәчем бал,—дип Хафиз матур гына тәлинкәгә салынган кәрәзле балны Тәскирәгә сузды. Гыйззелбәнат та үз сүзен әйтергә ашыкты:

—Нурисламның кайту хәбәре йөрәкләребезгә сары май булып ятты. Икесе берьюлы китеп баргач, бик ямансу булды. Эшкә калмавы белән бигрәк куандырды. Аннан соң, Сажидә, син үзең дә акыллы киңәш бирдең Нурисламга. Акчаң түгел, син үзең кирәк безгә, дидең. Исән-сау кайтып житсен дә, тигезлек белән гел бергә булыгыз. Әйдәгез, минем кучтәнәчемнән дә авыз итегез,—дип бер жамыяк тулы кош телен өстәлгә куйды Гыйззелбәнат. Бик канәгать, шат утырдылар күршеләр, сөйләштеләр, сыйландылар. Яңа яшь бал белән тәмләп чәй эчтеләр. Иң мөһиме—Нурислам кайтышка эшләнәсе эшләрне үзара бүлешеп тә куйдылар.

***

Локманның: «безгә моннан да ераккарак китәргә туры килмәгәе әле» дигән шомлы сүзләреннән соң, малайны монда калдырып булмас дип

уйлады Нурислам. Маһирәнең дә балага чат ябышуы, әнисенең аны һаман һуплап торуы да—нык шикләндерә башлады. Күп уйланды ул; бәлки, бу сабый, Раббымның рәхмәте белән, минем өчен бүләктер... Мәгәр алай булмаса, шулкадәр үземә охшап туар идемени ул? Аркасындагы миненә кадәр, башкасын әйткән дә юк инде... Миңа тартылуын гына кара син аның... Зөмәрәнең тилмереп язган васыятен үтәп, баламның мәрхүм әнисе рухын шат кылу—минем изге бурычым түгелмени? Ниһаять, ни генә булмасын, Аллаһыма вә Зөмәрәгә чиксез рәхмәтләрем белән, баламны үзем тәрбияләп үстерергә тиеш дигән ныклы фикергә килде Нурислам. Нургали эштән кайтып керүгә, аны ишегалдында ук каршылап, күңелендәгесен ачып салды.

—Мин сине аңлыйм, дускай. Борчылма, ярдәм итәрбез. Озата кайтырга Зәкияне җибәрербез. Үзеңә генә кыен булыр диюем.

—Рәхмәт, Нургали. Зәкия эшкә урнашып йөри түгелме соң?

—Әйе, Локман абый аны савыт-саба кибетенә тәгаенләп тора.

—Карале, кияү балакай, нинди Локман абый булсын инде ул сиңа?

—Кызык кына син, Нурислам. Ничек мин аңа бабай дип әйтә алыйм ди,йә?

—Әткәй диген. Олы кешенең күңеле булыр. Маһирәң кайтып керү белән әткәй, әнкәй дип әйтә башлады. Әле дә әткәй, әнкәй дип сагынып искә ала.

—Ярый, дускай, килештек. Син киткәнче үк шулай дәшә башлармын. Ничек кабул итәр бит әле. Әнә, үзе дә кайтып килә бугай.

## Ир бала кайта авылга

Нурисламны каршылау өчен стансыга вакытыннан шактый алда килеп җиттеләр Зарифлар. Яшь бала күтәргән чибәр генә хатын-кызны ияртеп, үзенә аллы-артлы зур сумкалар аскан Нурисламны күргәч, коелып инде Сәҗидә.

—Нигә мине чакырткан ул? Шикләнүләрем тикмәгә генә булмаган икән. Менә ни өчен чамасыз ашкынып киткән ул Ташкинына. Моңарчы бар кызганганым Газзәбану булды. Кем уйлаган, үземне ахирәтемнекеннән дә авыррак язмыш көтәдер дип... Зариф абый җаным, юк, аягымны да атлый алмыйм...

—Акылыңны җуйма, сабыр бул, күз яшьләреңне, зинһар, күрсәтмә. Мин син фаразлаганча ук булыр дип уйламыйм, күршекәем, сынатма,—дип Зариф үгетләп караса да, баскан урынында каккан казыктай катты да калды Сәҗидә.

Ул арада Нурисламнар үзләре килеп җитте.

—Читтә болай балавыз сыгып торганчы: «Ничек итеп исән-сау апкайтып җиткерә алдың бу кечкенәне дип сорарыең»,—диде Нурислам, Зәкия кулындагы балага ымлап. Аңа каршы, ачуы кабара гына барган Сәҗидәсе турсаеп:—Анасы янында ич... дип, үтә төксе җавап бирде.

Хатынын тынычландырырга теләп, кочагына да алмакчы булды Нурислам, кая ул...

—Җаһилләнмә, берегезгә дә ышанмыйм,—дип кырт кисте Сәҗидә.

—И, җаныем, мин сиңа үзең хыялланып көткән, төшләреңә кереп ымсындырган малайны апкайтам дип сөенгәнием тагы... Хәерле булсын. Ни булса да, хәзер безгә ашыгырга кирәк. Йокыдан уянуга ашарга сорый башлый ул. Гыйззелбәнат апайның кәҗәсе исәнме?

—Исән, үзе дә, кәҗәсе дә исәннәр. Анда алар сезне көтеп мәш киләләрдер инде... диде Зариф һәм бер-бер артлы үз сорауларын да бирде.

—Күрше, безнекеләрдән хат-хәбәрләр алып кайта алдыңмы? Ни хәлләрдә калдылар? Ерак сәфәрләренә китмәделәрме әле?—дип, Зариф та сүзне икенчерәк юнәлешкә бору ягын да карады.

—Бары да Аллага шөкер! Калганын юлда сөйләшербез,—дип Нурислам ашыктыра төште.

Кузгалдылар.

Хатынын җәһәт кенә күтәреп алып тарантаска утыртты һәм әйтеп тә тормыйча баланы аның алдына салды. Зәкия алар янына утырды. Сажидә әкрен генә Зәкиягә борылды:

—Бу баланың әнисе кайда соң? Нишләп ул Нурислам кулында?

—Сажидә апа, миңа бер ни дә мәгълүм түгел. Нурислам абый үзе сөйләр әле. Мине озын юлда ярдәмче булырсың дип Локман абыйлар җибәрде. Казанда әнием белән дә күрешермен дип, шатланып риза булдым.

—Һай, жаным, уяна бугай,—дип Сажидә каушап калды.

—Үзем алыйм әле. Ул миңа ияләнгән шикелле инде. Сезне күргәч, йә җылап җибәрер. Нурислам абыйны бик ярата,—дип Зәкия баланы үз кулына алды. Һәм битенә япкан юка батист җәймәне ача төште. Сажидә кырыйдан гына булса да күз төшерми калалмады. Чыннан да, сабый уянып килә. Күзләрен зур итеп ачып Зәкиягә текәлде. Менә шунда гаҗәп хәл... Зәкиянең: «Бөркетем, син кайда? « дип дәшүе булды, нарасый шулкадәр матур итеп елмаеп, юка юрганы эчендә бөтен гәүдәсе белән әллә нинди хәрәкәтләр ясый башламасынмы... Сажидә баладан күзен дә ала алмыйча, әле Нурисламга, әле балага карый-карый өнсез калды. Нидер әйтергә дә теле кебек, әмма теле әйләнми.

—Нурислам, бу нарасый синең үзеңнеке бит, дөресме дип тә сорамыйм. Аны кем генә күрсә дә шулай диячәк. Әнисе кайда, нигә бала синең кулда? Синнән дөресен генә әйткән җавап көтәм,—дип ниһаять, телгә килде Сажидә.

—Бу дөньяда юк инде ул, Сажидә. Аннан икебезгә дә атап язган соңгы хатлары, үлеме алдыннан язган васыятнәмәсе һәм үзе «Бөркетем» дип йөрткән шушы улы калды,—дип җаваплады Нурислам.

—Иннә лиләйһи вә иннә иләйһи раҗигун,—дип, Зариф белән Сажидә мәрхүмәгә дога юлладылар.

—Соңгы соравым—кем иде ул «Бөркет»нең әнисе? Зөмәрә исемле түгелме? Берничә мәртәбә синең әллә төш аралаш саташып дип әйтимме, шул исемне әйткәнеңне ишеткәләдем бит мин. Соңгылары Нургалиләр кайткан көннәрдәме шикелле хәтеремдә. Шулмы? Әйтергә теләмәсәң, үз иркең Нурислам, үпкәләмим,—дип, Сажидә мөлдерәмә күзләре белән әле иренә әле балага бакты.

—Әйе, Сажидә, ул шул син сизенгән Зөмәрә иде. Урыны җәннәттә булсын. Синең алда аның бер гөнаһысы да юк. Синең үлем көтеп яткан көннәреңдә Тәскирәм белән синең өчен иң кайгырткан кешеләрнең дә берсе ул булды. Һәр намазы артыннан сиңа исәнлек сорап дога юллаучы да ул булды. Хәтта минем исемнән акча, посылкалар салуын да монда кайткач кына белдем бит. Билгеле, мин аны сиңа теләсәм дә әйтә алмадым. Беркайчан да миннән фатир хакы да алмады ул. Гел, синең авылда балаң, авыру хатының, сыерыгыз да юк, акчаңны җыя бар, ачлыктан соң тормышыңны рәтләрлек булсын, минем үз табышым үземнең киләчәгем өчен җитәрлек дип торды. Әле, балам кем кулында гына тәрбияләнсә дә, аның үз өлеше дә булырга тиеш дип, аның өчен дә акча калдырган. Алсам да аптырадым, алмасам да, Зәкиябез шаһит. Миннән соң фатирына шушы кызны яздырып, ул аңа үз баласы кебек караган. Зәкия дә маладис, ул Зөмәрә апасының сердәшенә дә, безнең телгә өйрәтүче остазына да, авыру

көннәрендә тәрбиячесенә дә, ягъни шушы бала тугач, аның өчен дә бөтен көчен куйган җанга әйләнгән. Локман абзый, Зәйнәп апалар белән бергә Зөмәрәне гүргә индерүче дә ул булган. Ә мин өлгерә алмадым шул. Зәкия хәзер безнең гаиләбезнең, бигрәк тә улымның иң якын кешесе булачак, Аллаһы боерса. Кем белгән, Сәҗидә, һәйбәтләп тәрбияләп үстерә алсак бу егетне, үзебезнең картлыгыбызда иң өметле тәрбиячебез булыр, Аллаһының рәхмәте белән.

Чыннан да, һәр кешенең язмышы үзе бер гыйбрәтле тарих. Кем уйлаган шушы егет киләчәктә Сәҗидәнең генә түгел, Газзәбануның да бердәнбер игелек иясенә әйләнер дип.

Баланың юл буе бик тыныч һәм шулай озак йоклавы Зәкияне гаҗәпләндерми калмады. Аеруча сабыйның бер уянып, күзенә карап, әнисе әйтә торган сүзне дә ишеткәч, ничек куанганын күрсәтеп кабат йоклап китүе... Инде Нурисламның Зөмәрә турындагы искиткеч матур истәлекләрен сөйләгәндә, барысы да ихтыярсыз балага күз салгалап алдылар. Ә, ул тәмләп, изрәп йоклый... йоклый гынамы?.. Ничек матур итеп елмайгалап та ала бит әле... Шунда Зариф Зәкиянең бик аптырап утырган халәтен күреп, шыпыртлап кына болай диде:

—Барын да аңлап, тоеп ята ул, балакаем. Әнкәсен әти кешенең шулай матур итеп, ихлас искә алуына, иң мөһиме, гадел искә алуына һәр елмаюы белән рәхмәтен белдерүе дип аңларга кирәк. Зәкия кызым, син дә шулай аңларга телисең шикелле, әмма ышанасың килми, очраклык кынадыр дип уйлыйсың бугай. Тик бу—сабый күңеленең никадәр сизгер булуын исбатлаган бер мисал гына әле. Сабый күңеленә яманын да, яхшысын да белдереп тора торган үз фәрештәләре бар...

—Ий, Зариф абый, минем күңелемдәгенең барын да кайдан белдегез сез?

—Син үзең дә шул гөнаһсыз сабыйлар өммәтендә икәнсең бит, бала. Рәхмәт Нурисламга, әгәр тагын бер улым булган булса, сине үз киленем итәр өчен ниләр генә эшләмәсием мин... Һай, җәмәгать, ир бала белән ата күңеле арасында ниләр ятканын, аларны ниләр бәйләгәнен белмисез шул. Карагыз әле, бүген тургайларның сайраулары да бөтенләй башкача бит. Кичә төне буе талгын гына яуган янгырдан соң табигать үзе дә яңадан туган күк... Авылыбызга яңа туган гөнаһсыз сабый—ир бала кайта. Нурислам күршемнең улы кайта. Нургалием белән сизгән идек без аның монда кайтасын... Менә ул ата белән ир баланың уртак күңеле...

Сайрый тургай, сайрый тургай.
Баласын җуйган бугай,
Баласын җуйган тургайдай
Ник монаям мин болай...

дип, Зариф үзенең үтә дә моңлы тавышы белән әкрен генә җырлап та куйды. Сабый исә йоклый, булачак әнисе кулында изрәп йоклый бирә...

Авылга килеп җиткәндә генә уянды ул. Зәкия аны тиз генә үз кулына алып, астын корытты. Нурислам бозлы сумкадагы сөтле шешәне куенында җылытып, тәмен татып карады. Зәкия үзе тикшермичә аны балага бирергә ашыкмады. Сабыйның бернидә эше юк, аңа тизрәк ашарга булсын. Урамны янгыратып кычкырып җылавын белә әнә. Нурислам, Сәҗидәсенә елмаеп кына карап:

—Менә, әнисе, без шундый инде... Ашамсак малай без,—дип, улы белән ничек горурлануын белдермәк булды.—Булышырга Тәскирәбез бар, минем дә тәҗрибәм җитәрлек хәзер. Борчылма, яме. Җан биргәнгә җүн бирә дип, Ходайның рәхмәте белән, тәки апкайта алдым бит малайны. Кеше сүзе булмый

калмас... Тик мин сина ышанам, Сажидә, сынатмассың дип уйлыйм.

—И, Нурислам, мин сине яшь хатының баласы-ние белән алып кайта икән, Нургалине дә уздырган, кеше күзенә ничек күренербез дип хурлануымнан нишләргә белмәдем. Баланы күргә мәлҗерәп төшкәнемне үзең дә күрден бит. Нишлим соң, үзем сине шулай куандыра алмагач...

—Кая минем, Бөркетем,—дип Зәкиянең дәшүенә, жылавыннан туктаган сабыйга, сөтле шешә бик вакытлы булды.

Капка төбендә инде күптәннән кайтканнарын көтеп йөргән Тәскирә белән Хафиз бәбине күреп шаккаттылар, ни әйтергә дә белмәделәр. Тәскирә әтисенә атылды, Хафиз өйгә, әнисе янына ашыкты. Баланы өйгә Зәкия апасы алып керде. Нургилиләр җибәргән иләмсез зур, бикләнә торган сумканы тарантаста калдырып, Зариф та үзләренә ашыкты. Газзәбану Нургалиләрдән килгән әйберләрнең тарантаста икәнен белүгә, балага да карап тормады, Хафизны житәкләде дә, бакча башыннан гына үзләренә йөгерде. Зур сумка өйдә иде инде. Каенанасы сумканы ничек тә ача алмаганына гажизләнде:

—Синең белән мина язган хатлары шушында, диде Зариф. Ача гына алмыйм бит...

—Хәзер, әнкәй, хәзер, жаным,—дип, Газзәбану элгәре сумканы кочагына алды.

—Әни, ач инде тизләк, әнә, әби ничек көтә. Мин дә...

Ниһаять, хатлар, хатлар, тагын әллә ниләр...

—Әнкәй жаным, менә монысы сина,—дип, калын гына конвертны каенанасына сузды Газзәбану.

—Үзең генә укып бирсәнче, балакаем, бу арада күзем дә начарланды, күп жылаганныкыдыр инде.

—Һай, жаным, башта үземнекенә күз йөртеп кенә алыйм да... И, рәхмәт төшкере, хатымны алган икән, хатыма каршы жавап хаты бу, әнкәй. Малай була калса «Харис» дип кушарбыз дигән, и сөенгән, и сөенгән, әнкәй... Зөлкамал жылап ук жибәрде... Хафизның анда-монда эше юк—ашыга-ашыга мышнап сумка бушата. Зариф керә-керешкә бу матур манзараны күреп, аларны бүлдермәс өчен бусагадан узарга да кыймады. Жанына илаһи рәхәтлек табып, ләззәтләнеп күзәтүен дәвам итте. «И, Нургали балакаем, менә хәзер шушы дүрт бөртек газизләреннең ничек шатлаганнарын үзең күреп тора алсаң—нишләриең икән»? Ихтыярсыз туган әлеге уеннан Зарифның үз керфекләре дә чыланмый калалмады. Үзенә язылган хаттагы бераз борчулырак хәбәрләрне, бигрәк тә Нурислам аркылы ишеткәннәрен бу бәхетле жаннарга хәзер ничек әйтмәк кирәк?.. Йә, Раббем, бир сабырлык...

Кинәт Хафизның:

—Калагыз әле мина, әбәү, бабай, син дә мондамыный?—дигән тавышына күтәрелеп карасалар—Әтием төсле булдыммы?—дип, Хафиз каршыларына ук килеп басты. Өстендә ябык якалы озын кара казаки, чалбары белән пар. Башында тирәнрәк эчле кара бәрхет түбәтәй, аягында читек- кәвеш.

—Сөбханалла, гел кечкенә Нургалием булгансың бит, улым! Ни арада табып, ни арада киенеп өлгерден?—дип әнисе аны әйләндерә-әйләндерә карады. Битенең үбелмәгән жире калды микән...

—Мин күреп тордым аның ничек киенгәнен, маладис бит ул минем улым. Берегезгә дә ялынып тормады,—дип бабасы да мактап куйды үзен.

Ул да булмады:

—Күршеләр, сезне көтәбез. Зөлкамал апай, син дә калма.Улың яныннан кайткан кунак кызыбыз да сезне көтә,—дип Нурислам да кереп житте. Шунда Хафизны күреп:—И, котлы булсын, Хафиз. Шушы киемнәреннән

әтиең төсле булып кер, яме. Тәмам егет булгансың, Тәскирән шаккатсын әле,—дип, Хафизны күтәреп алып, чыгып ук китте Нурислам.

Кайтып керүгә Нурислам, чормадан Тәскирәнен сиртмәсе белән тал бишеген алып төште. Аларны чистартып, кояшта җилләтеп, элеккеге урынына элеп тә куйды. Сәҗидәсе бишек эченә йомшак урын-җирен әзерләде. Бишекне өстән үк урап ябып куя торган юка каплавычын сандыгыннан эзләп тапты, хәсиятленең хәсиятле инде. Тәскирәгә кирәге беткәч, юып, каклап төреп сандыгына салган булган. Сандык исләрен бетерәсе килеп, ишегалдының кояшлы җирендә җилләтергә дә өлгерде. Баланы юындыруны Гыйззелбәнат бик теләп үз өстенә алды. Таң белән ягылган мунчаны башта тикшереп, кирәк- яракның барын да әзерләп бетергәннән соң гына алып керде сабыйны. Суны тәмам сагынган икән бичара. Канатларын җилпегән кош сыман, шундый тизлек белән чупырдый башлап, ни тәҗрибәле Гыйззелбәнатны хәтта каушатып та җибәрде. «Һай, жаным, кулымнан төшеп китәсең бит инде... Сөбханалла, әкренрәк кылан, балакаем. Күрмисеңмени, мине дә жепбөртексез иттең бит»,—дип назлап дәшкән бу тавышны да шулкадәр үз итте сабый, чыркылдап ук җибәрде. Аяклары белән тагы да көчлерәк тибенә башлады. Чыркылдый-чыркылдый чәбәләнә бит, жаным. Нурлар чәчеп торган чем кара күзләре белән берөзлексез үзе Гыйззелбәнатны күзәтә. Әйтерсең лә, чиксез шатланып, аңа рәхмәтләрен белдерә. Әйдә, балакаем, житте, юындыра башлыйм үзеңне, әнә бот араларың да кызарып киткән, дип гаҗәеп хуш исле «Гөлжиһан» сабыны белән юындырды ул аны. «Озаграк тордылар, ни хәлләре бар икән?» дип, нәкъ кирәк вакытта Сәҗидә килеп керде. Су эчендә мен рәхәттә яткан шат чырайлы баланы күрү белән, Сөбханалла, күзем тимәсен дип сокланды. Күршесе коендырырга дип әзерләп куйган суны Сәҗидәгә сибәргә кушты. Үзе шул вакытта теләк теләп, баланы җәймә белән төреп алды.

Суы сарыксын, егетебез калыксын,
Таза булсын, сау булсын
Тормышы да бай булсын.

Аллаһының рәхмәтендә
Озын гомерле булсын!
Аны үстергән ата-анага
Игелекле жан булсын!

Шунда Сәҗидәгә малайның мул гына хәзинәсенә ымлап:

—Хәтерлисеңме Нурисламның үзенә үгез бозау күтәреп кергән төшенне? Менә ул синең төшең. Табигатьтә без белмәгән, без анламаган әллә ниләр бар ул...—диде Гыйззелбәнат.

—Гыйззелбәнат апай жаным, бу баланың да кендек әбисе син булган күк булды бит әле. Тәскирәмне дә синең шушы теләкләрең белән коендырган идек.

—Мин дә шуны уйладым. Теге елны бер-бер артлы Газзәбану белән икегез арасында кендек әбисе булып йөргәннәрем исемә төште. Бу юлы да, Аллаһы боерса, тагын сигез айдан Газзәбану нарасыен исән имин кабул итәргә язсын. Карале, Сәҗидә, әгәр бик тырышсак, синең имчәкләреңә сөт тә төшәчәк, менә күрерсең... Күкрәк бизләреңә массаж ясарбыз, баланың үзеннән дә суырттырырга тырышырбыз. Тормышта андый очраклар бар ул.

—Ай-һай, белмим, буш имине суырып торыр микән ул. Нурислам аны бик зирәк, ушлы малай ди. Буш сускины суырып та карамаган, теле белән этеп кенә төшерә ди.

—Кендек әбисе дә төшеп калганнардан түгел, әллә нинди тәҗрибәләре

бардыр әле, име, балакаем,—дип Гыйззелбәнат кулында йоклап киткән сабыйны, бисмилласын әйтеп, бишегенә салды.

Түбәсе күккә тигән Нурислам ишегалдынын буеннан буена ике рәт итеп кер бавы сузды. Юлда җыйналган бала чүпрәкләрен барын да юып, элеп тә куйды Сажидә. Бала чүпрәкләре белән тулган ишегалдыннан да мәхәббәтле урын тагы кайда булырга мөмкин, дип уйлады. Бу аның күптәнге күтәп алган, әмма тормышка ашмас хыялы иде шул.

Газзәбанулар кергәндә бала йокыда иде. Кырыгы да тулмаган, йоклап яткан балага карарга ярамаганны бары да белә. Шуңадыр инде бишек тирәсенә баручы булмады. Балалар күзенә чалынмагач, Газзәбану:

—Кара, безнен Хафиз монда түгелмени? Тәскирәсе дә күренми,—диде.

—Ә-ә-ә, алар Зәкия апалары белән Гыйззелбәнат апаларда, бәбигә мәми пешерәләр,—диде Сажидә.—Әйдә, утырыша башлагыз, алар да кереп җитәр.

Өстәлдә ниләр генә юк... Уртага каплап куелган табакны ачып җибәрүгә, сап-сары тутырган тавыкны күреп, Нурислам көлеп үк җибәрде.

—Вәйт, әнисе, маладис! Белә бит ул минем нәрсә яратканны. Кая пычак, бүлеп куйим әле. Шул кадәр оста пешерелгән, шартламаган да, чатнамаган да. Барыгызга да рәхмәт, күршеләр, безнең хатыннарга җитәме соң!..

—Тутырган тавыкны без дә ким яратмыйбыз үзе,—дип көлдереп куйды Зариф. Чыр-чу килеп, Зәкия апаларын җитәкләп, балалар да кереп җитте. Зарифныкылар гаҗәеп матур киенгән Тәскирәне күргәч, аһ иттеләр. Балалар икесе дә бүген гадәти генә киемнәрдән түгел иде шул. Шәһәрнен аристократ балалары гына кия торган киемнәр, икесенә дә Маһирә апалары бүләге дип аңлатты Нурислам. Балаларны яна киемнәре белән котлап, Хафизга тавыкнын ботын, Тәскирәгә канатын бирде. Зәкиягә дә, очасы кыз дип, канат эләкте. Ашны чыгарырга Газзәбану булышты. Маһирә турында сүз кузгалгач, Газзәбану ана рәхмәтен әйтеп болай диде:

—Безгә дә хат язган, әнкәй белән Бибиҗамал әбигә кәҗә мамыгыннан бәйләнгән зур шәл, әткәйгә каракүлдән тегелгән түгәрәк бүрек, минем туачак нәниемә күп бүләкләр, үземә авырлы вакытымда кияр өчен үзбәкчә бөреп тегелгән киң күлмәк җибәргән.

Безне нык гаҗәпләндергәне— үзенә Бибиҗамал әби сөйләгән Гөлҗәүһәр белән Мөхәммәтнур тарихын китап шикелле итеп язып җибәргәне булды. Тышына «Фаҗигаи мәхәббәт» язмышына багышланган кыйссаи хикәят. Көек авылынын атаклы кендек әбисе, 97 яшьлек Бибиҗамал әби авызыннан дип язылган һәм Бибиҗамал әбинен үзенә тапшырырга кушкан. Үзеннән сон кемгә тапшырасы килсә дә—үз ихтыярында диелгән. Бездән әбкәйнен үзенә укып бирүебезне сораган, үз күзләре күрми бит. Бер данәсен үзбәк теленә күчереп яздым дигән. Үземдә укучы яшьләребез чиратлашып, бар дөньяларын онытып, шаккатып укыйлар дигән.

Бу сүзләрне исе китеп тынлап утырган Гыйззелбәнат уйга калды. «Ай, Ходаем, Маһирә монысын сина җибәргәние дип Нурислам мина да бер төргәк бирде бит. Мин аны өстәлдә генә калдырдым бугай. Карап алырга арасы да тар булды шул. Алай-болай, минем сөйләгәннәремне дә язып җибәрмәде микән? Үзен сакла берүк! Монарчы әле йортымны басымчак итүче булмады булуын. Аерым бер хөрмәт белән карадылар, шөкер. Бала-чага кызыксынса гына инде... туктале, тиз генә барлап, сандыгыма салып керсәм, җаным тыныч булыр»,—дип уйлап, өенә чыгып керү ягын карады.

Табын янындагылар барсы да бик канәгать, Газзәбануыбызга исә бигрәк мач килде.

—Бу арада үземнен дә тутырган тавыкка нәфсем барые, пешергән вакытта

ук авызыма сулар килде. Шулпасыннан бөтен өйгә таралган хуш исләрен иснәп туялмадым мин анын,—дип сөйли-сөйли, иллә дә тәмләп ашавын белә. Шуңа куанган каенанасы күп уйлап тормады, үзенә алган өлешләрен дә шыпырт кына килененә таба шудырды. Зариф читтә каламы сон:

—Аша, балакаем аша, әгәр нәфсең бар икән, синең өчен иртәгә үк бер тавыкны тутырырбыз, боерган булса,—диде.

«Их, шушында Нургалием дә булса ничек куанып, горурланып утырырыем. Янында Маһирәсе утырса да риза булырыем, әллә ни көнләшмәсием дә шикелле.

Никахларын яңарттылар микән? Нурислам белми калмас, сорарга кирәк әле. Нишләптер, икесенең берсе авылга кайту турында ник бер сүз язсыннар, ләм-мим... Бүген үк хатымны языйм да, Зәкия артыннан җибәрим»,—дип уйлап куйды Газзәбану.

Зөлкамал юк-юкта бишеккә караштыргалап ала. Анын бала белән кызыксынганы, аны күрәсе килгәне әллә каян сизелеп тора.

—Тиз генә уянмас әле ул. Ничәмә көннәр юлда су коену күрмәгән баланы парлы мунчада юындырып чыгару бигрәк әйбәт булды. Селкенми дә йоклый, балакаем,—диде Нурислам.

—Карале, Нурислам, дүкәмитләре бармы соң анын? Ташкинда яздырганнармы? Исем-мазары куелганмы?—дип, сорауларын тезеп китте Зөлкамал.

—Бары да тәртиптә, Зөлкамал апай. Туу таныклыгы бар. Ташкент мулласы кушкан исеме—Исламгали, әтисе—Нурислам Һадиев дип язылган. Туган көне—10 июнь, 1924 ел, Ташкент шәһәрендә диелгән.

—Сөбханалла, сөбханалла, исән-имин генә үссен инде. Бәхете белән кайткан җан булсын! Бу яңа йортына төкле аягы белән кайтсын. Ата-анасына да көтелмәгән бәхет алып кайтсын, амин!—диде дә Зөлкамал, тиешле догасын да кылды. «Әнисенең исеме язылганмы?» дип сорамакчы булган иде дә, сабырлыгы җиңде. Анысы миңа нигә кирәк, үзләре беләләрдер дип уйлады. Монда да, шушы көннәрдә үк, Фарук мулладан Коръән укытып, анын белән дә киңәш-табыш итешеп алырга кирәк булыр, дип, киңәшен бирде.

Ташкент күчтәнәчләре һәм Сажидә пешергән чәй ризыклары белән тәмләп чәй эчкәннән сон, сый-хөрмәткә дога кылдырды Зариф. Хуҗаларның рөхсәте белән Зәкияне үзебезгә алып чыгарыек, диде.

—Зариф абый, рәхмәт инде. Нургали абый да кунарга Газзәбану апаң янына керерсең дигәние. Мин тиз генә мунча кереп чыгыйм. Аннары Тәскирә озатып куяр үземне,—диде Зәкия.

—И, җаным, мунча үзебездә дә әзер. Туры шунда китәрбез. Нургали абыең үземне тәгәрәтә-тәгәрәтә чапкан шикелле, сине дә тәгәрәтеп чабыйм әле. Безнең мунчамы... Зәкия, искитмәле әйбәт. Анда аталы-уллы, әткәй белән Нургалием кулы шул, эзләсәң дә, бер килешмәгән җирен тапмассың.

Озак булдылар алар мунчада. Ниләр генә сорашмады Газзәбану. Әмма күңеленә беркайчан да тынычлык бирмәгән никах турындагы сорауны, бик теләсә дә, бирергә кыймады. Үз-үземне кимсетү булыр бу дип уйлады булса кирәк. Зәкия япь-яшь булса да, бик сак, сабыр кыз булып чыкты. Күбрәк Зөмәрә апасы турында сөйләргә тырышты. Шулай да, әллә уйлап җиткермичәрәкме, Маһирәнең Исламгалине үзенә бик тә ияләндерәсе килгәне турында «И, үз итәргә тырышып та карадылар инде бу сабыйны Маһирә апа белән әнисе» дип ычкындырды. Газзәбануның: «Читләрнекен асат кына үз итәргә аларга бир инде»...—дип корырак кына әйтеп куюы Зәкияне куырып китерде, ни диярgә дә белмәде. Үз хатасыннан ике бите комачтай кызарды бичаранын.

Төне буе ут сүнмәде Зарифларда. Зәкия иртәгә Казанга китәргә тиешлеген

әйтүгә, Газзәбану Нургалиенә хат язарга кереште.

—Хет бер генә көнгә калсаные, улыбыз янышнан кайткан, бик кадерле кеше бит син безгә, балакаем,—дип Зөлкамал өзгәләнә үк башлады.

—Апа җаным, минем дә әнием тилмереп көтәдер. Бер генә кич булса да үз өебездә дә кунасым килә. Локман абзый да, зинһар тоткарлана күрмә дигәние.

—Карагыз әле, өченче көн Мәхмүт «Казанга җыенам, Гөлсем апай чакырткан» дип сөйләнгәние. Китеп өлгермәгән булса, Зәкиябезгә дә иптәш булып бергә китсәләр, менәтерә шәп булырые,—диде Зариф.

—Өйдә ул, өйдә... Сажидәләргә керер алдыннан гына күрдем мин аны. Картым, җәһәт кенә үзен кереп сөйләшеп чыкмыйсыңмы соң?—дип Зөлкамал Зарифны Мәхмүтләргә кертеп җибәрде. Шул арада әйләнеп тә чыкты Зариф.

—Булды, балакаем. Иртәгә үзе дә китәргә җыенган булган. Стансыга үзем илтә барам дигәнием, кая ул, Мәфрүзәсе белән икәүләшеп каршы төштеләр. Үзем илтәм генә дип тора бит Мәфрүзә. Бигрәк уңган бала инде, җаным. Газимҗаныбыз гына күрмәде, мәрхүм. Иртә белән сәгать сигез тулганда кузгалырбыз, кунак кызыгызны үзебез кереп алырбыз диде Мәхмүт, рәхмәт төшкере. Кайчан кайтасын сораганыем, «Төгәнысын гына әйтәлмыйм. Иртәгә Гөлсем апайның кунагы Кари әкәне каршылагач, әти янына зиратка барып кайтам. Берсекөннәрсез дә кайтып булмас»,—диде.

—Иртәгә Мәхмүттән сораштырырмын әле. Зөмәрә апай күршесе Кари әкә түгел микән ул. Әгәр ул булса, миңа да күрергә кирәк аны,—диде Зәкия.

—Бәлкем, шулдыр. Гөлсем безгә килгәндә Нургалине дә, Локманны да яхшы белә ул дигәние.

—Алайса, шул инде, Зариф абый. Зөмәрә апайны җирләгәндә ин зур ярдәмче Кари әкә булды. Чыннан да, шул Кари әкә булса, Нургали абыйларның хәлен белә дә белә инде ул.

—Нинди хәлне?—дип әсәренде Газзәбану.

—Юк, киттеләр микән ерак сәфәрләренә дип кенә әйтүемие,—дип котыла алды Зәкия.

### Шомлы хәбәр

Мәхмүтне дүрт күз белән көткәндәй көтте Зариф. Зәкияне озатуга, янә Нурислам белән дә икәүдән-икәү генә сөйләшеп чыкты. «Син үзенне ул кадәр бетермәле, Зариф абый, көтик Мәхмүтне. Син мине барын да әйтеп житкерми дип уйлыйсың, ахры. Безне озатырга Нургали үзе дә кайтмакчые. Аны көтеп утырганда ашыгып кына бер кибетчебез килде дә: «Кибеткә ниндидер ике кеше килде, хуҗаларыбыз белән булгахтерны да дәшеп, кабинетта ниләрдер сөйләштеләр. Аннан безне һәм барлык хезмәткәрләрне, үзебез чакыргач килерсез дип тараттылар. Кибетне бикләп, пломба салдылар. Аннан безнекеләрнең өчесен дә ияртеп каядыр киттеләр. Без аларны икенче кибетләребезгә баралар булса кирәк дип уйладык. Бу хәбәрне ишеткәч, Зәйнәп апа агарып китте. Йөрәген тотып кәнәфигә килеп утырды. Мин дә бу хәлендә әнине ташлап китә алмыйм, сез үзегез генә кузгалырсыз инде, атлар көтә»,—диде Маһирә. Ә бездән соң, иртәгесен, Локман абзый белән Нургали Кытайга юл тотарга тиешләрие. Менә, ничә сөйләсәм дә, Зариф абый, шул инде, артыгы да, киме дә юк. Тулке Зөлкамал апай белән Газзәбану белә күрмәсен. Минем тирәдәгеләр берсе дә белми. Бәлки әле хәлләр без уйлаганча ук начар да түгелдер. Үзбәкләрдә үзгәрешләр дәүләт күләмендә көтелә

булса кирәк. Мин эшләгән кибеттә үзбәк сатучылар, нишләптер, мине бик якын итteләр. Бу юлы очрашкач, менә нәрсәләр ишеттем әле мин алардан. «Оҗмахларга тин үз дәүләтебезне ысысысыр дигән капкорсак урыслар йотырга маташа икән. Ә безнең хөкемәт башындагы үзбәкләр әллә ялгышалар, әллә сатылалармы, «ризалык биреп яталар икән. Халык каршы. Урыс килсә талавын белә инде ул. Оҗмахка кызыгалар, эшләргә яратмыйлар. Башында «шумел камыш» белән генә әллә кая барып булмый шул. Ярар, урыс урыс инде ул. Күпләргә мәгълүм, холкы белән дә, эше белән дә, ашы белән дә дигәндәй... Ә менә татарларыбыз, үз мөселман татарларыбыз ни күрсәтте сон? Ачлыктан күпмегезне саклап калган татарларыбыз, әйтергә дә оят, хәрби бригада булып килеп, күпме үзбәкләребезнең канын койдылар. Ә күпмесенең җанын кыйдылар. Басмачылар имеш... Үзбәк халкы хәзер мондый татарларны рәнҗеп искә ала. Син гафу ит безне, Нурислам туган, татар халкының мондый юлга үз иреге белән басмасына ышанабыз. Күп вакытта хакимнәр үзләре бутый халык башын»,—дип сөйләделәр.

Ни генә булмасын, тормыш бара, ә алданиләр күрәселәребезне анык кына әйтә алмавыбыз һәм борчылуларыбыз, чорына күрә, бик табигый, Зариф абый..

—Ярый, күрше, шулай да яхшыга өметләник әле. Малаебыз ни хәл сон? Биетәме? Төнлә ничек йоклады? Сажидә тынычланып беттеме инде?

—И, Зариф абый, ничек алып кайттым әле, Ходайның рәхмәте. Сөенеп бетә алмыйбыз. Шундый җанлы тормыш хәзер бездә. Барыбызны да биетә, ничек кенә биетә әле... Сажидә дә бик маладис, малай өчен нишләргә белми. Бүген төнлә бераз борчылгалап алды үзе, һава алыштырадыр, мөгаен. Тәскирәне бик ярата, карап кына тора. Күрмиерәк торса, эзләнә үк башлый.

—Авыл савитына, Фатыйхның үзенә бар. Исламгалиебезне монда теркәргә кирәк хәзер. Малаең өчен җир өлеше алырсың, Аллаһы боерса. Карале, Нурислам, борчуларым белән әйтергә дә онытып торам, кортларың да бик тырышлар булып чыкты. Син югында ике мәртәбә карап алдым. Әйбәт ташыйлар балны. Мин кортлар караганда безгә дә кер. Үзенә өйрәнергә кирәк хәзер.

Кинәт Хафиз шәрран ярып кычкырып килеп керде.

—Бабай, син кайда? Чапталны җигик әле. Әни белән Бибиҗамал әбине алмага балабыз... Кузлада кучел үзем булам.

—Эш кешесе бит ул минем улым. Бабасы шикелле теләсә кайда ләчтит сатып йөрми. Әйдә, улым, әниең көтәдер безне.

—Ләчтитеңне ничә тәңкәгә сатасың, бабай? Өйдә генә сат син аны... Әбидә акча бер букча—дип, үз сүзеннән үзе рәхәтләнеп көлде Хафиз. Бабасы көлүдә Хафизны да уздырды.—И, улым, кечкенә Нургалием бит син минем... Син булмасаң нишләрием?

—Тиле җыеп күн эшләлиең, бабай.

—Ул күн белән нишләрбез?

—Кәнфит итеп тешләлбез.

—Тешең төшсә нишләрсең?

—Бабай булдым диялмен,

—Тәки син җиндең, улым. Җинүчегә ни тиеш?

—Җинүчегәме? Ни сораса шул тиеш. Беләсеңме бабай, мин нәрсә солалыем?

—Нәрсә генә сорасаң да, мин бирергә тиеш булам бит, улым.

—Мине «Кашка»га атландылып, үзебезнең улам буйлап алып баласың, килештекме?

—Бир бишне, улым!

—Мә, бабай, ун булсын, кулым шифалы булсын!

—Минем өчен синең кулдан да шифалы кул бу дөньяда юктыр ул, балакаем.

—Ләхмәт, бабакаем!

Боларның «тел уены» сокланып тыңлап торган Газзәбану:

—И, әткәй, сина күпме генә рәхмәтләр укысам да аз булыр. Ничек шулай оста итеп өйрәтә аласың син? Гел кечкенә әртис булып бара бит, әй... Их, әтисе дә күрсә, минем шикелле тыңлап та торса, икегезне дә кочаклап, нинди генә матур сүзләр әйтмәсие. Мәле, улым, бүләк киемнәреңне киеп, нәкъ әтиең төсле булып утыр әле кузлага, дип, каенатасы янында горур басып торган улына карап сокланып туя алмады Газзәбану.

Бабасы белән сүз алышуда җиңүче булып танылу Хафизны шулкадәр сөендерде ки, нишләрен белмәде сабый. Өстәвенә әнисе дә мактап җибәргәч, очар коштай булып Чаптар янына атылды.

—Хәзел без синең белән улам буйлап очып кына балылбыз. Бибиҗамал әбине очылтып кына монда апкайтылбыз. Аңладыңмы? Ә мин хәзел әти төсле итеп киенәм,—дип, әнисе кулыннан киемнәрне алып мунчага йөгерде. Мунчаның алгы ягыннан:

—Бабай, дугага кыңгылау куй, яме. Әбекәй белнәсә күлми бит ул. Кыңгылау тавышына сөенеп килел. Кызык булыл.

—Ярар, ярар, балакаем. Җиңүчеңең һәр сүзе минем өчен закон. Күз генә тимәсен инде сиңа. Бигрәкләр дә зирәк булып чыктың бит әле син, улым!

—Бабай, миңа башка күз киләкми, ике күзем булгач...—дип көлеп тә куйды тегесе.

Ат та җигелеп бетте, ялт итеп елмаеп егет тә килеп чыкты. Үзенә үлчәп тегелгәндәй чем кара казаки чалбардан, казаки астында кайтарма якалы ап-ак күлмәк, аягында, шулай ук кара төстәге йомшак күн читек-кәвеш, башында кара бәрхет түбәтәй... Күз тутырып карарга да оялырлык гаҗәеп зыялы, затлы кечкенә чын шәкерт диярсең...

Бабасының, билгеле инде, «Сөбханалла» дип кат-кат әйтелгән сүзләр тезмәсе астында тулып ташырдай мөлдерәмә күзләр... И, Раббым, ошбу сабыеңны бәхеткәйләреннән мәхрүм итә күрмә, ятимлек хәсрәтләрен берүк бирә күрмә, яман күзләрдән Үзең сакла! Әйтерсең лә, малкай да шундый ук ярлыкау белән сабыйга текәлгән. Үзенең ифрат ягымлы гөрелтеләре аша тышкы кыяфәте белән яшь хуҗасына нык охшаган Хафизга нидер аңлатырга тели кебек. Сагына «Чаптар», бик сагына шул Нургалине.

—Туктале, бабай, Чаптарга ипи апчыгып каптылыйм әле. Әбинең теше үтмәгән кибән башы калганые,—дип Хафиз йөгереп кенә кибән башы ипине алып та чыкты. Ул да булмады, өстен-башын алышып, чулпыларын чыңлатып, үзе белән кояшны да ияртеп Газзәбану да чыкты. Әллә Газзәбануның шулай бәйрәмчә матур булып чыгуына куанып-мы, әллә Хафизның тәмле ипи белән сыйлавына рәхмәтен белдерепме, шундый итеп кешнәп җибәрде Чаптар, урамны гына түгел, бөтен авылны яңгыраткандыр, мөгаен.

—Кызык бит ул безнең Хафиз. Әни, толымнарына көмеш чулпылалыңны так, пажалысты ди генә бит. Күзе күрмәгән Биби әбигә күнелле булыл ди. «Пажалысты»сын кемнән өйрәнгән дигәнием, Фәми абый гел шулай әйтә ди. Үзенә ошаган сүзләрне отарга гына тора, җаныкаем. Хафиз кушкач, менә шул чулпылар аркасында тоткарландым да инде. Аннан соң әнкәй дә чыгып җитмәсме диебрәк уйлаганыем.

—Эшләрем күп булса да, мин дә сезне чыгарып җибәрмичә тәки

кузгала алмый торам. Әле кайчан гына, сезне Ташлыяр җыенына озаткан чакларыбыз күз алдыма килде дә... Тагын күзләр мөлдерәмә...

—И, әткәй, әйтмә инде. Төштә күргән шикелле генә калды инде ул көннәр... Сез, әнкәй белән икегез, бигрәк өзгәләнәсез. Әнкәй өчен курка да башладым инде. Күзгә күренеп бетерешә. Сөйләштереп тә булмый, тамагына да рәтләп ашамый. Юкса Нургали бик кистереп әйтте бит. Маһирә кайтса да, кайтмаса да, урып-җыю башланганчы кайтып җитәм. Сездән башка яши алмыйм мин хәзер, диде бит. Бу юлы мин алай ук сабырсызланмыйм үзе. Әллә карынымдагы балам да шулай кушамы?.. Сез дә бирешмәсәгезие. Әнкәйне Казанга алып барып, берәр духтырга күрсәтеп кайта алсаң начар булмасые. Гыйззелбанат апай да шулай ди.

—Рәхмәт, кызым, әле дә ярый сез бар. Әниегез өчен үзем дә борчылам, шушы арада берәр чарасын күрми булмас дип йөри идем. Раббыбыз рәхмәтеннән ташламасын инде. Кара, кучерыбыз кая китте соң әле?

—Тәскирәне дә чакырам—дигәние. Әнә чыгып килә. —Нәрсә, улым, Тәскирә кирәме?

—Юк ла-а, анын бәбие бал бит хәзел. Исламгали кайткач, чичти әллә кем булды ул,—дип, Хафиз үпкәсен дә сиздерде.

—Бик куалама, улым, яме,—дип Зариф озатып калды үзләрен.

Бибиҗамал әби үзен зурлап алмага килгән Газзәбану белән улы Хафизга багышлап озаклап дога кылды.

—Бибиҗамал әби, без сине үзебездә берәр ай тәрбия кылырбыз дип уйлаштык. Әнкәй белән бер-берегезгә иптәш булып, сөйләшеп йөрерсез, бергә намазлар укырсыз. Сезнең чөкердәшеп утыруыгыз безгә дә күнелле булыр, Аллаһы боерса.

—И, рәхмәт төшкерләре, болай булгач, алышырга кием-салымнарымны да алыйк инде,—дип үзе белгән урыннарыннан алып, аларны бер төенгә салды. Газзәбану гаҗәпләнеп вә сокланып карчыкның һәр хәрәкәтен күзәтеп утырды.

—И, Бибиҗамал әби, син үз өеңдә күзле кешеләрдән болайрак йөрисең әле, сөбханалла. Синең китәнеңне кайсы күршеңә әйтик? Җәмилә сина бик еш йөри бугай. Аңа әйтеп чыгыймммы соң?

—Бик һәйбәт булыр. Мин өйдә югында да күз-колак булып йөрсение, әйт үзенә, яме,—дип, үзе өй иясенә догасын биреп, өстәлендә бер чокыр су белән бер телем ипи калдырды. Әгузе-бисмилласын әйтеп, аларны тастымал белән каплап та куйды. Газзәбану Җәмиләне өендә туры китерүенә сөенде. Бигрәк акыллы кыз бу Җәмилә, кем бәхетенә үсәдер гүзәлкәй, дип, бүген янә сокланды ул аңа. Үзен озатышырга дип кергән Җәмиләнең тавышын ишетүгә карчык иллә дә сөенеп:

—Җәмилә, балакаем, мин китәм инде. Өемә, һәрвакыттагыча, күз-колак булырсың, яме. «Актәпи»емне дә үз ихтыярыңа калдырам. Аны да рәхмәтеңнән ташлама, яме, балакаем,—диде.

—Ярар, әбекәй, барысын да эшләрмен. Әмма син киткәч күңелсез була бездә. Алай бик озакларга тырышма инде. Сиңа җырласы бер җырым бар, өйрәнеп тә бетердем, тик җырлап күрсәтергә өлгерә алмый калдым.

—Ниндиерәк җыр ул, исеме ничек?

—Әйтми торам әле, сиңа ошый торган моңлы, озын көйле борынгы җыр. Ишетәсең килсә тизрәк кайтырсың, әбекәй.

—Карале, Җәмилә, иртәгә өйлә намазыннан соң безгә кил әле. Без әбиләр белән бергәләп бәлеш пешерербез. Син күрергә тиешле шаккатырлык бер китап бар бездә. Җиренә җиткереп укый беләсең син, Хафиз да бик ярата синең укуыңны. Әбкәебезгә бу кыйссаны үзең укып тынлатсаң, ул тагы да

озак яшәр, Аллаһы боерса. Үзе бер тарих булып...

—Нинди китап ул, Газзәбану апа, исеме ничек?

—Ә-ә-ә, мин дә әйтми торыйм әле. Үзең килгәч, күрерсен дә, укырсың да,—диде ул.

Кузлада утырган Хафиз янында бер көтү бала-чага. Сөйләшәләр, көлешәләр, табышмаклар әйтешәләр. Шул арада бер-берсе белән үчекләшеп тә алалар. Хафиз ястык астына куйган ярты ипие барлыгын хәтерләп, тиз генә аны алды да бүлгәләргә кереште. Житкәне кадәр малайларга таратты да «Чаптар»ны сыйларга кушты. И куанышты инде малайлар. Чеметеп-чеметеп кенә үзләре дә кабып карады. Тәмле... Тешләмәс микән дип куркып тору да юк. Һәрберсе үз өлеше белән «аткайны куандырдым әле» дип уйлап Хафизга рәхмәт укыдылар.

Хафиз, әниләренең килгәнен күреп, үзе тиз генә кузлага күчте, малайлар чебешләр кеби читкә сибелделәр. Жәмилә Бибижамал әбине иплап кенә тарантаска утыртышты. Шунда Жәмилә Хафизны күреп дәште: «Абау жаным, Хафиз энем, синме бу? Танымаслык, кызлар күзе төшерлек егет булгансың тәмам, Мәшалла! Шул кадәр Нургали абыйга охшарсың икән, киемнәрең белән дә. Бик бай, укымышлы кешеләр генә кия торган мондый киемнәрне мин малай-шалайларга да тегәләр дип уйламый идем.

—Кем малай-шалай, минме?—дип, Хафиз Жәмиләгә усал гына карап куйды да, көр тавыш белән: «Әйдә, малкай, на-а»—диюенә, Чаптар дәртләнеп кузгалып китте. Жәмиләнең «Хафиз, гафу ит, энем. Мин сиңа әйтмәдем бит ул сүзләрне»,—дигәне ишетерлек булмады. Дугадагы кыңгыраунын зеңгелдәп чыңлаган тавышын ишетүдән таң калды Бибижамал. «Бала Хафиз үз әтисенең кендек әбисен, 97 яшьлек карчыкны кыңгыраулы атларда гына йөртер әле дисәләр, үзем дә ышанмаган булырыем, Әлхәмдулиллаһ, чиксез шөкер! Мине шушылай куандыруыгызнын әжере үзегезгә мене белән кайтсын, йә Раббем!—диде ул.

Карчыкнын иң зур сөенечләре әле Зарифларның өендә көткән икән. Кунагының жилкәсенә, Маһирә жибәргән дип, бүләк шәлне салды Зөлкамал.

—Бу нинди искитмәле, гажәеп шәл? Үземнең Хак Тәгаләм биргән озын гомеремдә шактый шәлләр күрдем, шөкер. Әмма мондыйны бәйләгәнем югые әле,—диде ул.—Үзе бик йомшак, бөтен арка-билләремне каплап алырлык зур да икән әле... Бүләк жибәрүченең үз гомере дә озын, бәхете зур булсын!

Башыннан ук та бөркәнеп карады.—Һай жаным, башымны, гәүдәмне генә түгел, бөтен жанымны дәвалый торган хәзинә бит бу. Мондый шәл башка юктыр ул, дөньясында да.

—Ул, әбекәй, кәжә мамыгыннан, кулдан бәйләнгән шәл. Әнкәйгә дә, икегезгә пардан жибәргән.

—Газзәбану балакаем, хәтерең калмасын. Бу бүләкнең мәгънәсен бик тирән дип аңлыйм мин. Маһирә Нургалигә булган мәхәббәтенең никадәр тирән булуын безгә дә аңлатырга теләгән шикелле тоела миңа. Беренчедән—яраткан кешесен дөньяга тудырган газиз ана. Икенчесе—аны исән-сау саклап, үз куллары белән кабул иткән кендек әбисе.

—Әткәйгә каракүлдән тегелгән бик затлы түгәрәк бүрек тә жибәргән әле,—дип өстәде Газзәбану.

—Менә, күрәсеңме, балакаем, өчебезгә дә баш киемнәре... Өчесенең дә башлары исән булсын дигән уедыр, мөгаен. Бик тирән уйлый торган бала булып чыкты түгелме соң Маһирә дигәнебез.

—Кем ничек юрый бит әле анысын. Әйе, юрау өчен дә киң күңелле

кеше булу кирәктер,—диде Газзәбану.

—И, әбекәй генәм, әле аның сиңа гына багышлап җибәргән икенче бүләген күрсәң, белмим нишләрсең икән?

—Йә, Хода, тагы ни уйлап тапкан? Зарыктырмыйча әйтсәгезие тизрәк...

—Сезгә гаҗәеп китап ясап җибәргән ул. Иң кызганычы—сезнең аны күрә алмавыгыз. Тышына язылганын укып бирәм:

«Фаҗигаи мәхәббәт» Кыйсса.

«Гөлҗәүһәр белән Мөхәммәтнур» язмышларына багышлана.Көек авылының атаклы кендек әбисе, 97 яшьлек Бибиҗамал әби авызыннан.

Язып алучы: Маһирә Яруллина.

Шундый ук бер китабын үзбәкчәгә әйләндереп язган. Монысын үзенә тапшырырга кушкан, бездән укып бирүебезне сораган. Соныннан кемгә калдырырга теләсә—үз ихтыярында дип язган. Менә, әбекәй, бу амәнәтен дә үзегезгә тапшырам,—дип Газзәбану китапны аның кулларына салды.

—Бу кадәресен үк һич көтмәгәнием,—диде Бибиҗамал. Китапны элгәре куллары белән назлап кат-кат сыйпады, битләренә куйды, яңакларына да куеп алды. Аннары йөрәге янында тотты бераз. Сукыр күзләреннән саркып кына чыккан бер тамчы яшь керфекләренә эленеп калды. Ул аларга кагылмады. Моңарчы сүзсез генә утырган Зөлкамал болай диде.

—Укып чыктым мин бу тылсымлы китапны. Ул тарихны ишеткәнем барые барын. Ләкин мондый тетрәндергеч итеп сөйләгән кешене белмим. Син, әбекәй, күзең күргәндә китапларны күп укыгансың, ахры. Шаккатып, онытылып укыдым мин аны. Гел чын язучы язган төсле булган бу.

***

Мәхмүтне каршыларга үзе килде Зариф. Поезд әле туктап бетмәс борын ук ачык ишектән күренеп киткән Мәхмүтне тыны белән суырып алырдай булды. Күрештеләр.

—Мәфрүзә килмәдемени? Нишләп олы кешене—сине җибәрде ул?

—Бик киләсеие, үзем риза булмадым. Син Мәхмүтең яраткан ризыкларыңны пешерә тор, кайткач, бергәләп чәй эчәрбез дигәч кенә, —көчкә калдырдым мин аны. Аннан... ни бит... Мәхмүт энем, үзең белән генә тынычлап сөйләшәсем килде. Төнне үткәрә алмыйча да иза чиктем. Таңы да ата алмый азапланды, минем шикелле. Туктале, мәйтәм, чыккан көе үз игеннәребезгә дә күз салырмын дип, өйдәгеләрнең берсенә дә сиздермичә генә чыгып киттем. Таңны юлда каршыладым.—Зариф кузгалып китүгә никтер тыела алмыйча сөйләде дә сөйләде.—Без бит туа-тумыштан авыл балалары. Әллә нинди сихри төсләргә кереп, алсуланып таң атуларын кай урыннардан гына күрмәдек. Бүген дә, Алланың рәхмәте, онытылып күзәттем, беренче тапкыр күрәммени.... Башта астан, бик ерактан кеби нурларын гына сузгалап, ялындырып кына кояш үзе дә күренә башлады. Күктәге ае да югалып өлгермәгәние. Миңа бүген Аебыз барча тереклек хуҗасы галиҗәнаб Кояшка болай дип әйтә сыман тоелды: «Чыксаң чык инде, нигә шулкадәр ялындырып көттерәсең? Мондый тонykланган, мескен хәлемдә инсаннарыма бик үк күренәсем килми шул. Иң матур, нурлы вә тулы чакларымда да алар миңа карап, күбрәк моңланырга, узган гомерләрен, яшьлекләрен өзелеп сагынырга хирыслар. Ә мәхәббәт шәрәбеннән исергән гашыйк җаннар миңа карап хыял дингезләрендә парлы аккошлардай йөзәләр дә йөзәләр. Әле минем, беләсең килсә, бик серле булып, яңа туып кына килгән төннәрем дә була бит. Менә шул чакта, янә миңа карап, яше вә карты сине дә, мине дә дөньяга яраткан бердәнбер Раббыбызга ялвара башлый.

Яшьрәкләре:

Ай күрдем аман белән,
Авызым тулсын иман белән.
Бу аем да үтсә иде
Бәхет тулы көннәр белән,

—дисә,
Өлкәннәре:

Ай күрдем аман белән,
Авызым тулсын иман белән.
Шушы айларда вафат булсам,
Үткәр, Ходам, иман белән,

—ди.

Ә беләсең микән син, Кояш, күпме шагыйрьләр мина карап шигырь вә җырлар яза? Әйе, менә шулай дип әйтә сыман тоелды мина Ай.

Җыр дигәннән, халыкның үзе чыгарган берсеннән-берсе моңлы җырлары вә шаян такмаклары, минем кодам әйтмешли, да чурты... Бүген шуларның берсен дөнья бәһасе, мәрхүм дустым Газимҗанны—әтиенне сагынып җырлыйм әле.

Ай яктысы якты дисен, көн яктысы күк түгел.
Башка дуслар да юк түгел, ләкин синен күк түгел.

И, язмыш диген инде, ул да ачлыктан шешенеп беткән хәлендә дә бер Ходаена ялынды. Гомер сорап дисенме, юк, һич юк... Без китергән ризыкны да кабарга теләмәде. Ачлыгына бирешмәсием әле, сагыш бетерә мине. Тизрәк карчыгым янәшәсенә илтсение ул мине, диде. Ач үлемнән алып калалсак та, сагышына дәва бирә алмадык. Ахыр чиктә, сезне өйләндереп йортына ямь бирергә өметләнде. Шушы мәшәкатьләрне өстенә алып, сукыр эчәгең шартлаганда да түзеп йөр әле син... Бала өчен ата-ана шулай инде ул, ни хәл итәсең... Менә сине дә борчып алдым, гафу ит. Урыны җәннәттә булсын. Кабере читтә калса да, үз теләгенә иреште, әниең белән барыбер бергә ул. Сезнең өчен дә рухы шаттыр, иншалла. Без ана догада... Раббыбыз кабул итә күрсен!

—Рәхмәт, Зариф абый. Әтине шулай сагынып искә алуына Аллаһының рәхмәтләре яусын. Кичә Гөлсем апай белән зиярат кылдык үзен. Мәчеткә дә сәдака илттек, шөкер.

—Мәхмүт туган, сизәсең микән берни дә сорашмыйча, башта әкият сатып, Хафизым әйтмешли «ләчтит» сатып, мәзәк сөйләп кайтуымның сәбәпләрен?

—Мин бик рәхәтләнеп тыңлап кайттым әле, Зариф абый. Нинди сәбәпләр эзләп тормадым. Юкка гына «Кышкар» мәдрәсәсендә укымагансыңдыр. Нишләп син, Зариф абый, дин юлыннан китмәдең икән?

—Ул мәдрәсәдә бары бер генә ел укып калдым шул. Кинәт кенә әни авырып китте дә, укуны туктатырга туры килде. Аннары шул калудан калынды инде. Бер генә ел укысам да, ул мәдрәсә шактый күпне бирде мина.

Менә нәрсә, балакаем, күрешү белән Нургалием турында сорашмавымның сәбәбе бер генә. Күнелсез хәбәрләрне ишетүемнең ничек тә вакытын сузу... Сорашмыйча да булмый. Кайттымы Кари әкә дигән кеше? Зәкия дә күрдеме аны? Ниһаять, нинди хәбәрләр бар, Мәхмүтҗан?

—Менә хәзер аңладым. Чыннан да, Зәкиягә бик таныш кеше булып чыкты ул.

—Мәхмүт, син миңа, зинһар, ничек бар, шулай сөйлә. Мин беразын болай да ишетеп, җанымны кая куярга белми йөрим. Чын дөреслекне, ничек кенә авыр булмасын, мин ишетергә, белергә тиеш.

—Әйе, Зариф абый, ничек кенә әйтергә инде дип борчылып кайта идем үзем дә. Хәзер мин синә нәкъ, үзең сораганча, ничек бар, шулай сөйләргә тырышырмын.

Кибетләрен ачмаганнар әле. Аларны дәүләтнеке итәчәкләр дигән сүзләр йөри ди. Бик зур хосусый милекләрне, дәүләтнеке итү өчен, хуҗаларыннан тартып ала башлаганнар икән. Локман абыйларның кайда икәнлеген беркем дә белми диде. «Алар бит икесе дә, килешүләре буенча, Кытайга товар алырга барырга тиешләр иде, шунда киткәннәрдер», дип кенә җавап биргәннәр. Кари әкә белешкән, икесе дә шул чыгып китүдән, өйгә кайтмаганнар. Өйдәгеләргә бер җирдән дә, бер хәбәр дә килмәгән диде. Гомумән, хәбәрсез югалганнар булып чыга... Маһирә апалар зур борчуда. Әнисе урын өстендә, сырхап ук киткән диде. Аларга хәзергә хат язмасыннар, иң яхшысы Зәкия белән Гөлсем апай аркылы элемтәдә булырлар диде. Менә сиңа җиткерәсе бөтен хәбәр шушы, Зариф абый.

—И, Ходаем, малларын гына түгел, инде башларын да ашадылар микәнни? Шулайрак килеп чыга түгелме соң, Мәхмүт? Маһирәләр дә кызганыч, күпме мөлкәтләре яна, Локманнан башка ничек яшәр алар?

Иң булдыклы, иң сәләтле, татарларны күрәлмауның тагын бер чарасы түгел микән әле бу? Йә булмаса, «басмачылар» дип аталган үзбәкләрне тар-мар итәргә җибәрелгән татар хәрбиләренең залимлекләре өчен үзбәкләр тарафыннан үч алуның бер төре түгел микән? Урыс безне, татарларны, гомер-гомергә күрәлмады. Әле безне үзбәкләр сыйдырае, анда Локман шикелле татарлар шактый дигәние Нургали абыең да. Тикмәгә генә «моннан да ераккарак китәргә туры килмәгәе әле» димәгән икән Нурисламга. Менә Локманның шул сүзләреннән соң баласын тизрәк алып китү ягын караган да инде Нурислам.

Ә безгә нишләргә хәзер, нишләргә?.. Карап торган берд әнбер улымны бары егерме ике яшендә югалта калсак, ничек түзәр бу йөрәк? Зөлкамалым болай да бөтенләй бетерешә бит инде. «Төшемә керде» ди дә, өзелепләр китә. Төшен дә сөйләми үзе. Кем-кем, Ана йөрәге сизгән булып чыга бит, Мәхмүт җаным. Без дә китсәк, ике бала белән Газзәбануыбыз нишләр?

—Мәхмүт, зиреклеккә җитеп киләбез, беразга туктыйк әле шунда. Нургалиемнең иң яраткан аланында туйганчы, эчемне бушатканчы бер тәгәрәп җыламасам, үземнекеләргә күренер хәлем калмас шикелле.

—Әйе, әйе, Зариф абый, дөрес әйтәсең. Анда җиләс тә, һавасы да бөтенләй башка. Агачлар арасында күләгәдә әзрәк ял итеп алсаң начар булмас. Агарып та киттең... Төшәргә булышыйммы?

—Юк, юк, энем, үзем төшәм. Шөкер, үтте шикелле...

—Ни булды, Зариф абый? Менә шушында чирәмгә ятып тор әле,—дип тиз генә баш астына үзенең пинҗәген салды Мәхмүт.

—Бая нидер йөрәгемне бик каты авырттырып чәнчеп куйды. Менә шул хәлемне алды да инде. Бер дә болай булганы югые әле, хәерлегә булсын...

—Мәхмүт, тарантас башында бер шешә булыр. Шуңа тутырып, мондагы чишмәдән су алып кил әле. Ул чишмәне беләсеңме?

—Беләм, беләм, якын гына ул. Ә син тыныч кына ятып тор, Зариф абый,—дип Мәхмүт атлый-йөгерә китеп барды.

Зариф суны башта йотлыга-йотлыга эчте, калганы белән битен-кулын

юды да, иркен итеп сулыш аларга тырышып, киерелеп куйды.

—Рәхмәт сина, агайне, тәки хәл керттен үземә. Инде кузгалсак та була. Шулай да юлга тагын бер шешә су алыйк әле. Бу чишмәнен суы үзенә бер төрле тәмле. Салкынлыгын кара син анын, шифалыгын әйткән дә юк инде. Бүген көннен артык эссе, бөркү булуы да ярамады бугай. Шундый итеп китереп кысты йөрәк дигәнен, ычкынам икән дип торам, котым очты.

—Сиздем мин аны, Зариф абый, үзем дә куркып калдым, тагын әзрәк ятып тормыйсынмы сон?

—Өйдә минекеләр дә, синен Мәфрүзән дә көтәдер. Иплап кенә кузгалып карыйк әле.

Зарифнын капкадан кергән тавышын ишетүгә өйдәгеләр атылышып чыктылар. Бибиҗамал карчык та, өйдә генә көтеп аласы түгел, таягын җиккән дә, баскыч төбенә чыгып баскан. Ин алда Зөлкамал:

—Җә, әтисе, Мәхмүт кайттымы? Нинди хәбәрләр алып кайтты? Кари әкә дигән кеше килгәнме? Нургалиемнән нинди хәбәр бар?—диде.

—И, хатыннар, жанкисәкләрем, сез мине чәй эчерү, тәмле ризыклар белән сыйлау турында уйламыйсыз да, ахры. Тан атканчы чыгып киткән кеше бит мин. Баш командирыбыз кайда сон, күренми?

—Әткәй жаным, самавырыбыз кайнап тора, бәлеш мичтә, баш командир «Кашка» белән бакча артындагы чирәмлектә. Хәбәрләрен безне сөендерерлек булса, кулларыбызда күтәреп алып керербез үзенне,—дип кабалана ук башлады Газзәбану.

—Тынычланыгыз, зинһар, бары да Аллага шөкер. Нургалиләр Кытайларына киткәннәр. Озаграк торырга туры килсә, борчылмасыннар, үзебез хәбәр итәрбез, көтсеннәр дигән. Көтәрбез боерган булса! Өч елдан артык көткәнне берничә аена гына түзмәскә, име, карчык...—дип әйтеп кенә өлгерде, кинәт йөрәгенен кыса башлаганын тойды. Ничек тә сиздермәскә инде. Әнә бит ничек куаныштылар.

Ниһаять, бу сөенечле хәбәрдән Зөлкамалнын да күзләре нурланып, битләре алсуланып китте. Зариф та берни булмагандай шаяртып куйды:

—Йә, килен балакай, өстәл янына кайсыгыз күтәреп кертә инде мине? Бары да дәррәү көлеп җибәрделәр.

—Әлбәттә, үзем күтәрәм. Килен балакаен болай да бер Яруллинны күтәреп йөри. Икенче дәү Яруллинны гомерем буе күтәреп йөрергә дә риза мин, үзем күтәрәмгә калмасам, Аллам сакласын.

Ул да булмады, тирә-юньне нурга күмеп Җәмилә килеп керде. Аны тиз генә Хафизны алмага җибәрделәр. Бабасын күреп малай куанса да, анысын сиздермәде. Ә иртәдән бирле үзенен үпкәләп йөрүен әйтми калалмады. Һәрвакыттагыча бабайнын кочагына да атылмады.

—Бабай, үзен тан тишегеннән китеп балгансын, мина әйтмичә. Минем баласы килгәнне белден ич. Ялал, ялал диден ич. Мәхмүт абый кайттымы? «Кашкай» көтә. Бүген бигләк эссе, су коенасы килә анын, алал белән минем дә.

—И-и, улым, үпкәләмә инде, гафу ит. Шулайрак килеп чыкты шул. Үзем нишләптер йоклый алмадым. Сине төн уртасында уятырга жәлләдем. Бар, Мәхмүт абыйларынны чакырып чык хәзер. Әнә, әниен мичтән бәлеш тә чыгара, икесе дә керсеннәр.—Малай бик шатланып риза булды. Бабасына булган үпкәсе дә, әйтерсен лә, жилгә очты.—Мәфрүзә апана чәй эчәргә үзем керермен дигәнием дә, сезнен янга ашыктым.

Җәмиләнен Хафиз белән бергә керәсе килеп, торып басуга:

—Юк, үзем генә керәм. Малай-шалай белән йөлмә,—дип, ярым көлеп, шундый итеп сыйпады Җәмиләгә, барысын да шаккатырды. «Бабай, бәлешнен авызын ачмый тор, яме» дип тә кисәтә бит әле.

—Биш яше дә тулмаган бала шулай үзенә ошамаган нәрсәләрне күнеленә салып куяр дип кем уйлаган, үскәч, кем булыр икән безнең Хафиз?—дип, соклануын белдерде Газзәбану.

—Балалармы? Бала күңеле кадәр нечкә күңел ул, зурларда ай-һай... Менә ни өчен балалар белән бик сак булырга кирәк,—диде Зариф.

—Безнең әткәй бик яхшы укытучы булырые дип күп вакыт уйлап куям мин. Бик масаеп кына китмәсен инде Хафизыбыз,—диде әнисе.

Гомер аккан сулар кебек... дигәндәй, көннәре дә гаҗәеп тиз үтә тора. Көннәре генәме, никадәр сагыш, кадерленне тилмереп көтү газаплары белән булса да, айлары да берсен-берсе куа диярсең. Инде урып-җыю эшләре дә тәмамланып килә. Тик Нургалидән генә бер хәбәр дә юк.

Көннәрнең кояшлы, коры торуы аркасында ашлыкның бер граммы да югалмады. Уңыш искиткеч мул булды. Газзәбануыбыз да күзгә күренеп тулыланып килә. Ул тагы да матурайды, аның һәр хәрәкәте, кайда гына булмасын үз-үзен тотуы, елмаеп сөйләшүләре илаһи бер гүзәллек белән төрелеп бара. Хатын-кызлар аны күреп һәрберсе үзенчә соклана. «Карале, Газзәбану бу корсагын тагы да матур күтәрә, әле Нургалие дә янында булса... гел очып кына йөрерие...» диештеләр. Хатыннар сөйли инде ул, берсе: «Бер көнне Фатыйх Газзәбануны очратып, аннан күзен дә алалмыйча, Хәнифкә сөйли икән; корсагы да бар диләр, бер баласы янында, икенчесе карынында дигәндәй. Кайнеш белән нинди зур хуҗалыкта яши, башы эштән чыкмыйдыр, әле кендек әбисе булырга да өйрәнеп йөри диме тагы... Гаҗәп бит, ә, үзе һаман чибәрләнә, нурлана гына бара... Тагын күзалдымнан китмәс инде дип әйтә, ди. Хәниф, җәлләп тә куйдым Фатыйхны. «Барыбер сиңа булмый бит инде ул. Тот та өйлән, сиңа любой кыз килә бит, йөрмә болай, булмастайга күзенне кыздырып»,—дип әйттем әле дип сөйләгән, ди.

***

Беркөнне ашыгып кына Нурислам килеп керде. Зарифның атларга башак әзерләгәнен белгәч, бигрәк әйбәт дип, абзарга таба атлый-йөгерде.

—Зариф абый, менә хәзер генә Җәмиләнең тагын бер хаты килде. Үзенең хаты эчендә сезгә дигәне дә бар. Менә ул хат,—диде.

Кинәт кенә әйтелгән бу хәбәрдән Зариф каушабрак калды:

—Үзең укыгансыңдыр инде...—дип, курку катыш сорап куйды. Кулларын алъяпкыч итәгенә сөрткәләп, әгүзе-бисмилласын укыды да:

—Җүнле хәбәр бир, Ходаем,—дип, ниһаять, хатны кулына алып, эчтән генә укый башлады. Хат кыска язылган. Әмма язган кадәресе бары да күңелгә ятышлы.—Матур яза, укымышлының укымышлы инде. Әйдә, тагын бер кат кычкырып укыйм әле:

«Хөрмәтле вә гыйззәтле, газизләрдән газизем әткәй илә әнкәй!

Сезгә сагынып, бик сагынып сәлам язам. Шулай ук Газзәбану белән Хафиз сөйдергеч бөтиемә дә сәламнәремне ирештерсәгезие. Безнең хәлләр һаман да шул бер көе, билгесез. Әниемнең сәламәтлеге бик какшады. Биргән дәваларыбызның да ярдәме аз. Үзем эшләп торам әле, биргәненә шөкер!

Әткәй, сезнең арагызда үткән, җаным вә күңелемне баеткан матур, әкияти көннәремнең һәр сәгатен генә түгел, минутларын да сагынып яшим. Миңа күрсәткән ихлас хөрмәтләрегез һәм мине үз балагыздай кабул итеп алуыгыз өчен рәхмәтләрем чиксез сезгә. Сезләрнең—барчагызның да, Аллаһы Тәгаләнең һәр даим рәхмәтендә булуын телибез. Әткәй, ни генә булса да, өмет белән яшәргә язсае. Өметебезне югалтмыйк әле. Әнкәйне сакларгарак тырышыгыз инде, төшләремә борчылып кергәли башлады. Хафизга иптәшкә, Ходай кушып, тагын

бер сабый туса, әнкәйнен ярдәме аеруча кирәк булачак. Без анын бик бәхетле әби булуын телибез! Газзәбануга жинеллек, сабырлык бирсен Раббем. Амин!

Әткәй, борчый димәсәгез, сезгә бер гозерем бар. Жәмиләне безгә килергә үгетләп карагыз әле. Без чакырганда әнисе Зөләйхә апа риза булмаганые. Икесе бергә бөтенләйгә килсәләр, безгә бигрәк тә яхшы булырые. Бүлмәләр дә, урын-жир дә житәрлек. Зөләйхә апага да эш табылыр. Ул баланы укытып, кеше итә алсам, Аллаһым каршында бер саваплы эшем булырые дип уйлыйм.

Ярый, хушыгыз, таза-сау яшәгез. Мин жибәргән юл белән, хәлләрегезне белдереп, жавап яза алсагыз бик шатланырыек.

Бибижамал әбекәй белән Гыйззелбәнат апага да сәлам жибәрәм».

—Менә шулай, күрше, әллә ни сөенерлек хәбәрләр булмаса да, ике арабызда элемтәнен ялгануы бик һәйбәт. Рәхмәт Зәкиягә, сина язылган хатында ниләр бар сон, Нурислам?

—Эшкә урнашасы кибетендә, Маһирәнен кинәше белән, бөтенләй күренмәгән. Кибет дәүләтнеке булып эшли башлаган. Сатучыларнын күбесе яна кешеләр икән, Зәкия элеккеге эшләгән тегү әртилендә эшли башлаган. Зөмәрә йортында ялгыз яшәп ята икән. Ышанычлы гына, үз якларыбыздан килгән берәр кыз булса, бик теләп фатирга кертерием дип язган. Кари әкә ана Маһирәләрдә бик күренеп йөрергә кушмаган. Маһирә үзе дә шундыйрак фикердә бугай. Шулайрак анладым. Исламгалине бик сорашкан Маһирә. Сажидәнен күкрәгенә сөт төшеп, баланы үзе имезә башлаганын белгәч, исе-акылы китеп: «Бәхетне бирим дисә, бирә бит ул Ходай, Үзе теләгән кешесенә учлап та, колачлап та бирә»,—дигән. Инде ул бәхетне кире алам дисә, анысы да Үз иркендә...—дип жылап та алды Маһирә апа,—дип язган.

Барын да сабыр гына тынлаган Зариф авыр сулап: «Әйе, Зөлкамал апан белән без дә кызганабыз аны. Ичмаса, бала тапкан булса, баласы белән юанырые. Инде анасы да ташлап китсә, нишләр ул, Маһирә? Әле без монда барыбыз бергә дигәндәй, борчуларны да, дөнья мәшәкатьләрен дә бергә күтәрәбез, шөкер Ходайга. Ялгызлыктан Үзен сакла...»

Нурисламны озаткач, өйгә ашыкты Зариф.

—Газзәбану кызым, Маһирәдән хат бар.

—И, рәхмәт төшкере, иренем кычытканые аны, хат укырга булган икән? Үзен укыдынмы әле, әткәй?

—Укыдым, кызым, укыдым. Әнкәен дә ишетсение, кайда сон үзе? Күренми.

—Келәттә Коръән укый ул. Өйдә бик бөркү бит. Әйдә, әткәй, хатны да шунда гына укыйк әле.

Хатны Газзәбану укыды. Хатнын башыннан ахырына кадәр, тагын акты Зөлкамалнын күз яшьләре. Каян килә диген син аларны... бертуктаусыз...

—Тагын бер кат, ашыкмыйча гына укы әле, кызым,—диде Зариф.

Тагын укыды Газзәбану.

—Мин үзем абзарда ике кат укыдым. Менә тагын ике кат тынладым, әмма Нургалиемнен үз хатларына, үз сүзләрен ишетүгә сусаганым басылмады.

Маһирәнен Жәмиләне әнисе белән бергә үзләренә чакыруын өчесе дә хупладылар. Өйлә намазыннан сон Маһирәгә бөтен яналыкларны әйтеп бик жылы хат яздылар. Зөләйха белән сөйләшеп, китәргә риза булган тәкъдирдә, барлык юл мәшәкатьләренә үзебез ярдәм итәрбез дип яздылар. Шунда Хафиз: «Кунак апайга миннән дә сәлам языгыз, үзе мина сәлам әйткән ич,—диде.—Сөйделгеч бөтие дигәне ошамады, аны бәбигә генә әйтәләл,—дип иренен турсайтып куйды.

## Соңгы күрешү

Сентябрьнең соңгы көннәре. Бу елның көзе дә, назлы җәеннән аерылырга теләмичә, үзенекен итә. Әбиләр чуагы әле киләсе айда да дәвам итәр диләр. Вакытын белеп кенә җылы яңгыры явып китә. Искән җилләре дә җылы, җанга рәхәт. Йорт саен диярлек амбары, келәтләре тулы ашлык. Тик Нургалидән генә бер хәбәр дә юк... Маллар көтүдә. Тегермән елгасы тулы ап-ак казлар йөзә. Көекнең аның казлары да һәммәсе диярлек ак төстә, көрәннәре бик сирәк. Һәр хуҗаның казлары үз тамгаларын йөртә. Ә тамга төсләрен санап та бетерерлек түгел. Ишле булып йөзгән чакларында, озаграк карап торсаң, үзе бер могҗиза. Әйтерсең лә, каз «болытлары» өстенә кемдер төрле-төрле чәчкәләр сипкән. Ә казларның һәрберсе, сыртындагы чәчкәсен югалтмаска тырышып, чума-чума йөзәләр, шаярышалар... Шунысы гаҗәп, казларның һәр аерым гаиләсе читләрне үзләренә якын җибәрмәс өчен ниләр генә кыланмыйлар... Чынлап торып усалланалар хәтта. Ә үрдәкләр тирән елга кирәк дип сайланып йөрмиләр. Аларга өйгә якынрак инеш тә җитә. Бераз чумгалап, чайканып алуга, янә бүксәләрен тутырганчы ашарга кире өйгә кайтасы бар бит. Үрдәкләрнең бу гадәтләрен Хафизга әбисе болай аңлаткан. Алар бүксәләре тулганчы ашыйлар-ашыйлар да, алпан-тилпән килеп, тезелеп, су буена китәләр. Шунда берсе «бак-бак, без ашадыкмы соң әле?» дип сорый ди. Калганнары уянып киткәндәй булып, «бак-бак-бак, «юк-юк-юк» дип бакылдашып, ашаган җирләренә кире борылып менәләр ди. Хафиз бик ошаткан әбисенең бу әкиятен. «Менә шуңа күлә симез бит алал, әби, иеме?» дип көлгән дә көлгән.

Мондый матур көннәргә Кашка да бик шат, юырткалап йөрүдән куш аяклап чабуга күчә. Бабасының Хафизны атландырганына да канәгать. Төрлечә итеп кешнәргә ярата. Инде Хафиз кулыннан тәмле-тәмле күчтәнәчләр дә эләксә, малайның битләрен дә ялап ала.

Бөтен җирдә көзге матурлык. Көннәр җылы, кояшлы булып торса да, табигать үзенекен итә. Агачлар саргайган яфракларын салмак кына коялар. Бу табигый үзгәреш агачның үзенә дә, коелып барган яфракларына да ниндидер моңсулык бирә кебек, хәсрәтле вә сагышлы кешеләргә бигрәк тә...

Менә шундый матур иртәләрнең берсендә төшендә Нургалиен күреп уянып китте Газзәбану. «Ник уяндым соң?..» дип ачыргаланып җылап та җибәрде. Бу үзәк өзгеч тавышны ишетеп:

—Балам, ни булды, ник җылыйсың?—дип Зариф атылып керде.

—Әткәй җаным, Нургалине төшемдә күрдем. Ул каядыр китәргә бик ашыга икән. Үзе миңа таба кулларын суза. Сүзе юк, ә мин аны сүзсез дә аңлыйм шикелле. «Әйдә минем белән, бергә китик», дип әйтә төсле. Ә мин шатланып, хәзер-хәзер дип аңа таба ашыгам икән. Инде кулларыбыз тоташа дигәндә генә уянып кына киттем бит. Ник уяндым мин, әткәй? Никләргә генә уяндым соң? Кичтән тилмерепләр сораганыем үзеннән. Ичмаса, бүген төшемә генә кереп булса да миңа күрен, зинһар, дип. Ишеткән бит җанкисәгем, ишеткән. Ә мин уянганыма үкенеп җылыйм, әткәй. Үзе юк та юк инде. Төшләремдә генә булса да бер күреп калсам, йөрәгемә аз булса да ял булыре дип ни теләдем. Их, әткәй, аның матурлыкларын күрсәң... Син югыең шул анда... Шул затлы киемнәреннән, бөтен җире ялт иткән... Ул да шулкадәр сагынган... Сүз белән әйтмәсә дә, әллә каян күренә.

Гел елмаеп кына, якты нурлар сибеп тора торган Нургалием үтә моңсу, сагышлы моңсу гына түгел, әллә нинди кайгы катнаш моң иде аңарда. Ә үзе каядыр ашыга да...

—Ярый, кызым, тынычлан инде. Үз карынында йөрткән нәни Нургалиебезне саклау да синең өстеңдә бит. Сез хәзер икегез бер җан. Үзең ничек борчылсаң, аны да шундый хәлгә куям дип уйла. Үпкәләтмәскә

тырыш син аны. Менә хәзер дә «әтиемә әйтәм, барыбер әйтәм мин сине дип ятадыр әле»,—дип, үзенә авыр булса да, Зариф шаярткан булып, киленен тынычландырырга тырышты.

Каенатасының көтмәгәндә балаларча шаяртуыннан Газзәбану хәтта көлеп җибәрде, гәрчә яшь аралаш булса да.

—Пәйгамбәрләр акылы бардыр синдә, әткәй, рәхмәт яусын. Әле дә ярый сез бар. Әнкәй белән сез булмасагыз, әллә кайчан саргаеп үлгән булырыем инде мин.

—Алай димә, балакаем, алай димә. Беребезне дә сабырлыктан мәхрүм итмәсен, Ходаем, барыбыз да исән булыйк әле...

Тынычлана төшкән Газзәбану җәһәт кенә торып, битен-күзен юды. Самавырын куеп җибәрде. «Ташкентта ни хәлләр бар икән, Маһирәгә кыска гына итеп хат языйм әле» дип килеп кенә утырды. Кинәт карынында гадәти булмаган, төртеп куйганга охшаган кыска гына бер хәрәкәт тойды ул. Нәкъ шул урынга кулын куеп тынып калды. Эчендәге үзгәрешнең кабатлануын көтеп, тирән сулыш алырга да куркып утыруын дәвам итте Газзәбану. Юк, башка кабатланмады. Туктале, нәрсә болай утырам, Гыйззелбәнат апаның аппараты бар, тынлап карасын әле дип, очардай булып остазына йөгерде. Бәхетенә, анысы өйдә туры килде.

—Беренче авазын салырга вакыты җитә нәнинең дип инде кичә үк уйлаганыем,—диде кендек әбисе, Газзәбануны күрү белән.

Тынлый башлауга көлеп үк җибәрде Гыйззелбәнат.

—Бик дөрес. Вакыты җитүгә «әнием, мина җан инде, йөрәгем дөпелди башлады» дип кулы белән сиңа төртеп хәбәр иткән ул. Менә шулай, күрше, февральнең 22-23 көннәрендә туарга тиеш, бирсен Ходаем,—дип сөендерде ул үзенең шәкертен.

—Кичә Мәфрүзәдә булдым. Анарда да шул ук хәл. Бик куаныштылар. Бүген үз вакытың белән барып кайт син аның янына, аппаратны ал. Башта үз колакларыңны сына. Аннары шушы атнада, Аллаһы боерса, Гыйззениса килене Сания бәбиләргә тиеш. Бергә барырбыз. Тудыруы катлаулырак булырга мөмкин. Аллага тапшырдык. Баласы аркылы ята. Көн дә тикшереп торырга туры килә.

—Чыккан көе Саҗидәгә кереп чыгыйк әле, бергәләп. Сөенечемне аның белән дә бүлешәсем килә, ахирәтем бит. Бу арада гына керә дә алмадым. Аның үзенең койрыгы бозга катты инде, Саҗидәне әйтәм. Әле үзе генәме, Тәскирәсенең дә кулын бәйләде.

Килеп керсәләр, Саҗидә бик ләззәтләнеп бала имезеп утыра.

—Күз генә тия күрмәсен үзегезгә,—дип соклануларын белдерделәр. Газзәбану якынрак килеп:

—Кая, сөте киләме?—дип дәшүе булды, бала имчәгеннән аерылып матур итеп елмайды да, ике кулын суза-суза Газзәбануга барасы килүен күрсәтте.

—Карале, җаным, ниләр генә кыланмый! Ничек алмыйсың инде сине?—дип, Газзәбану аны кулларына алды.

—Менә шундый биләмче егет без. Кемне күрсә ятсынуны да белми, барам гына дип тора. Атасы да шакката инде.

—Нишләп ятсынмасын, безне үз кешеләре икәнен сизгәнгә күрә генә шулай итә. Күрдек без аның төрле чагын, зиһенле малай ул,—диде Гыйззелбәнат.

—Анысы шулай инде. Авылда кем генә күрми калды икән аны, ай-һай... Бәби ашы китерүне сылтау итеп, эте дә, бете дә калмады инде. Ошамаганраклары булса, шунда ук акырып җылый башлый. Дөрес, балаларның барысын да үз итә,—дип сөйләп китте Саҗидә.

—Ахирәткәем, февраль ахырындарак Исламгалиеңә иптәшкә минем дә бәбием туачак, белеп торыгыз. Кендек әбиебез шулай ди. Нургалиең дә төшенә шуңа сөенеп кергән, ди.

—И-и, хәерле сәгатьтә, җаным. Шатлык өстенә шатлык булып, ярабби, Нургалиең дә кайтып житсә ие,—дип ахирәте өчен шатлануын белдерде Сажидә.

***

22 февраль, 1925 ел. Кышның инде соңгы көннәре булса да, ул әле тиз генә бирешергә теләми кебек. Иртәдән бирле тын гына йомшак кар ява.

Көн кичкә авышканда Газзәбану кәефсезләнә башлады. Килененең һәр хәрәкәтен үзалдына тынгысызланып күзәтеп йөргән Зөлкамал каушап ук китте.

—Балакаем, баядан бирле күзәтәм үзенне.. Тулгаклыйсың түгелме соң син? Теге бүлмәдә урын әзерләдем, син шунда кереп ятсаңые хәзер. Үзең керә аласыңмы, әллә булышыйммы?

—Рәхмәт яусын, әнкәй. Безнең эшләр шулайрак бугай шул... Нишләптер кызулый ук башлады бит әле бу... Әткәй Хафизны Нурисламнарга алып керсен. Сажидәне монда җибәрсеннәр. Гыйззелбәнат апай да...—Калган сүзен әйтеп бетерә алмыйча, эчен тотып, эчке бүлмәгә юнәлде. Зөлкамал чөйдән бишмәтен генә эләктерде дә, чыгып та йөгерде. Шул арада бисмилласын әйтеп, Раббысына җинеллек сорап ялвара, шунда ук: «И, балакаем, булса да булыр икән түземлек, кайлардан килә икән бу балага шул кадәр сабырлык, рәхмәтеңнән ташлама, бер Аллам!»—дип капканы ачуга, бөтен кирәк-яракны алган Гыйззелбәнат үзе пәйда булды.

—Зөлкамал, үзем дә керергә дип торадырыем. Күрәм, син агарып та киткәнсең, зинһар тынычлан, ашыкма, бераз туктап, тын ал. Ә мин йөгердем, яме.

Гыйззелбәнат кереп җиткәндә, Сажидә шунда иде инде.

—Йә, нихәлләр? Мин аны ястү намазы алдыннан, йә шул намаз вакытында табар дип чамалаганыем. Әле ике сәгать элек кенә караганыем бит,—дип, Газзәбану янына килде.—Ашыгасы иттеңмени, җаным? Кая, карыйк әле...

—Әнкәй кайда? Мин ашыкмыйм... ма-лай-дыр ул, па-жа-лый... ай... һай, җаным...

Ул арада кендек әбисе барын да тикшереп, үзе дә тынычланып, Газзәбануны да үтә куркып, каушап калган халәтеннән чыгара алды.

—Бер дә куркырлык урын юк. Бары да тәртиптә. Әле эшем кыргандай, шабыр тиргә баткансың. Өстәвенә каенанасы өчен борчылып ята бит әле. Әнә, әнкәең дә өйдә, сиңа баладан котылгач сыйларга дип тәмле әйберләр пешерә. Ә син хәзер хәл җыярга тырыш, сулыш алуыңны тәртипкә китер. Кабаланма. Үзең кендек әбисе булырга җыенасың. Бу синең практик эшең инде, сынатма. Бәһаңне төшермә, җаным, көчеңне тупла... Сажидә, син салкын суга чылаткан тастымал белән тирләрен сөртеп ал, алмашка тагын шундый бер сөлге әзерлә, кирәк булачак әле...

—Ай, а-а-й, билемне үтәләй кисә би-и-ит...

—Түз, җаным, түз. Алда кирәк, бик кирәк булачак көчеңне әрәм итмә.

—Бик авырта бит, үтерепләр авырта-а-а...

—Кемнеке авыртмый?

—Сезнеке авыртмый шул, уф-ф...

—И, җаным, синеке шикелле генә түгел, әллә нинди авыртуларына да «әһ» тә итми түзәрием. Ходаем миңа бу бәхетле авыртуларны бирмәде шул. Әллә кызганды, әллә кылган гөнаһларым...—Калганын әйтеп бетерә алмады.

Шунда ул «хәлиткеч» вакытның килеп житкәнен күрде.

—Ай, жаным, үләм ич, үлә-ә-әм...

—Нинди үлү ди ул, булмаганны, көчән, тагын, тагын, вәйт, рәхмәт төшкере! Шунда ул якыная барган балага: «Әйдә, матурым, әйдә, жаным, әниен бик көтә бит.—Әнисе, тагын бер бик чирәшеп көчәнеп жибәрсән, «минем дә тавышымны ишетерсен», диясе килә бит нарасыеннын... капкара чәчен күрәм, монда озак тору бик куркыныч, тын ала алмаячак.

Ә Газзәбануыбыз кендек әбисен ишетми дә кебек. Коточкыч көчле авыртудан күзен дә ачалмый.

—Зөлкамал, Сажидә, икегез ике яктан бераз күтәрә төшегез, сезгә аркаланып каты итеп бер көчәнеп жибәрүе кирәк, ай, бик кирәк... Газзә, ишетәсенме мине, тырыш, жаным... Ниһаять, ишетте Газзәбану, нәкъ кендек әбисе кушканча тырышты... Менә шунда сабыйнын бөтен өйне янгыратып жылап жибәрүе, «Әнием, ач күзенне, күр мине, минем дә сине күрәсем килә»,—дип жылыйдыр кебек тоелды ана, әмма никтер күзен ача алмады. Кендек әбисенен: «Сөбханалла, сөбханалла, тупырдап, булам дип торган егет бит бу. Төкле аягын белән, балакаем»,—дигәне колагына чагылып киткәндәй булды. Әмма ачык кына итеп берни дә ишетмәде. Ул йоклый иде. Бу бик кыска вакытлы гажәеп тирән йокы аны икенче сихри дөньясына, Нургалиле дөньясына алып китте. Газзәбану аннан беркая китәргә теләмәде. Ул ана Харисын күрсәтә. Ә Нургалие икесен бергә кысып кочаклаган, икесен дә үбә. Нидер әйтергә тели кебек. Газзәбанунын аны бик тынлыйсы килә. Читтән кемдер дәшә, дәшә.

—Кечкенә Нургалиемне алып кайттын бит, жаным. Койган да куйган Нургалием бит. Мин тапкан Нургалием дә нәкъ менә шушындый матур малай иде. Ач, балам, күзенне, Аллаһы Тәгаләнен рәхмәтедер бу безләргә...

«Нургали» исеме кабатлана торгач, сискәнеп китте Газзәбану. Газиздән газиз бу исем Газзәбанунын зиһененә яшендәй бәреп керде. Татлы йокысыннан уянып киткәндәй:

—Кая Нургали, әле генә мондае бит ул... Исән булмаса, нәкъ көннәрен туры китереп, безнен янда йөрерием? Сабыема жан ингән көнне инде. Менә аны тапкан көнемдә дә безнен янда бит ул. Үзе еракта булса да, күнеле белән барын да белеп тора. Ничек исән булмасын ди!!! Моннан сон да Үзен сакла Ходаем! Сабыйларым хакына Нургалиемнән аерма мине, и газиз Раббем,—диде.

Кендек әбисе анын каршына килеп:

—Менә ул, синен кечкенә Нургалиен,—дип Газзәбануны мөмкин кадәр тынычландырырга тырышып, баланы күрсәтте. Шунда жылап басып торган каенанасын күреп алды Газзәбану:

—Әнкәй, нигә жылыйсын? Жылама, әнкәй. Аллага шөкер, үзем дә, Харисым да исән-сау. Нургали белән дә күрештек. И-и, күрсәгезие сөенгәннәрен... Минем дә хәлем әйбәт. Харисымны имезергә дә вакыттыр инде?.. Нургали бик теләгәние шул анын ир бала булуын,—дип каенанасынын яшьле күзләренә текәлде һәм кемнедер эзләгәндәй як-ягына да карап алды.

—Ир бала гынамы сон, ул бит беткәнче Нургали. Рәхмәт, кызым. Болай булгач, аны күрергә әтисе ничек кайтмасын ди. Кайтыр, Аллаһы боерса. Харис дип исемне дә үзе бирде бит, жаным... Йоклый әле ул. Уянуга имезерсен, әмма үзен тәмам тынычланып бетмичә торып имезергә ашыкма әле, кызым...

Шулай итеп, Газзәбанунын тагын гел әтисенә охшаган икенче улы да дөньяга килде. Һәм шушы йортка күпме шатлык, күпме горурлык алып килде ул. Зөлкамалнын чыраена алсу төс керде. Һәр ризыкнын тәмен белеп, әпититләп ашый башлады. Зарифнын да эшләре гөрләп барды. Кашка да чын чабышкы аты булып, жыеннарда һәр елны беренчелекне яулый торды. Газзәбану да

Гыйззелбәнат ярдәмендә тәҗрибәле «кендек әбисе»нә әйләнде. Никадәр авыр булса да, инде Нургалинең башка кайта алмаячагына да ышана башладылар кебек. Шулай да, өметсез шайтан дигәндәй, һәрберсе үзенчә, хыял катнаш көтү белән яшәде. Газзәбанунын бар юанычы, өметләре Хафиз белән Харис булды. Нинди генә бәхетләр юрамады ул аларга. Ләкин үзенә шул көтелгән бәхетләрнең берсен генә булса да күрү насыйп булмаган икән. Авырлык илә югалтуларны бихисап күп күрсәм дә, Раббем мине ташламады, сабыр канатларымны сындырмады. Һәрвакыт авыл халкына кирәклеген белеп һәм аның зур хөрмәтен күреп яшәвен—ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан үзенә җибәрелгән бүләк дип санады. Изге хезмәтендә остазына һәм үз кыйбласына тугры калды.

Илгә килгән сугыш афәтләре һәм сугыштан соңгы ачлык, хәерчелек елларында бик авыр хәлгә калган чакларым да булмады түгел, булды. Түздем, күп түздем. Һәрнәрсәнең соңгы чиге булган кебек, түземлек дигәннәре дә мәңгелек түгел икән.—Газзәбану уй-хатирәләргә чумды.—Түземлегем тәмам төкәнгәч, бичарага-ничара дигәндәй, бер көнне көндәшем Маһирәгә тоттым да хат яздым. Хатымда яшәүдән тәмам гарык булганымны, улларым белән Нургалине сагынуларымны, үземнең дә алар янына китәргә ашкынуларымны бәйнә-бәйнә тездем дә тездем. «Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән бәгырь кисәкләрем янына синнән алда миңа китү насыйп булса, доганнан калдырма, бәхил бул! Ә мин сиңа бәхил, Маһирә...»—дип тә язып куйдым бит әле... Ике дә уйлап тормыйча, хатымны салып та җибәрдем. Җибәрүен җибәрдем... Ә соңыннан үзем үкенеп бетә алмадым. Көндәшемнең: «Әллә ычкынып бара инде бу хатын»,—дип уйлавыннан шикләнеп, тәмам пошаманга төштем бит.

И-и, Ходайның бирмеш көне диген, ай ярымнан Маһирәдән хат килеп төшмәсенме! Укыдым да шаклар каттым. Ул да минем төсле үк ялгызлыктан җанын кая куярга белмичә иза чигә икән. Ул да, бигрәк тә әнисен җирләгәннән соң, Нургалинең теге дөньяга үзе янына чакыртып алуын гына көтеп ята икән. Аның бу җөмләсе мине сискәндереп җибәрде. Без Нургалине исәндер әле дип яшәгәндә, ул аны теге дөньяда итеп күрә. Ул безгә караганда хәбәрдаррак булып чыга бит, нидер белә. Ә нигә безгә җиткерми? Миңа кайгы ярамас дип уйлавыннанмы?.. Нургалием бит әле минем хәләл ирем генә түгел, тач үзенә охшап туган алтын алмалар кук улларымның газиз әтиләре ләбаса.

Шулай булгач, Нургалигә минем хакым зуррак икәнне аңламаслык томана түгел бит ул, укымышлы хатын. Шулай да кызганып та куйдым үзен, Маһирәне әйтәм. Әнисеннән башка үзенә бәрәңге де пешереп ашый алмаган килеш ничек көн итмәк кирәк? Уйладым-уйладым да, үзебезгә кайтырга чакырып тагын бер хат язып салдым. Юатырга тырыштым, кемгә дә газиз ананны югалту бик авыр. Маһирәнең авылга кайтуын үзем өчен дә теләгәнием. Ничек тә бергә-бергә җиңелрәк булыр кебек тоелды. Мәктәптә балаларны урысчага укытыр, скрипкә уйнарга өйрәтер, ә мин өй эшләрен карармын, аз булса да акчасы да килер, дип уйлаганмындыр инде. Мәктәп директоры да риза булганые. Тик нишләптер, никадәр генә көтсәм дә, җавап хаты да килмәде, үзе дә кайтмады.

Ике айдан Маһирәнең вафат булганын ишеткәч, югалыплар киттем. Күрше Нурисламның малае—Исламгали Ташкинга баргач, аның бер дә көтмәгәндә, авырмый-нитми генә дөнья куйганын ишетеп кайтты. Бу хәбәрдән соң көне буе күземнән яшь китмәде. Никадәр көнләшсәм дә, әле ул исән чакта, уртак сагыш белән янып-көеп яшәүчеләр бу дөньяда икәү булганбыз бит. «Инде мине Маһирәсез дә калдырдыңмыни, Ходаем, дип еладым да еладым, ул көнне гөнаһлы булып, хәтта намазларымны да укый алмадым. Аның төне дә төн генә булдымы соң? Йокы юк та юк инде... Тоташ газапларда узган гомер

юлым, хәсрәтле көннәрем бер-бер артлы күз алдымнан үттеләр дә үттеләр. Маһирәнең бу юлы да миннән бәхетлерәк булуыннан янә көнләшеп куйдым. Нәкъ менә шул вакытта ишек белән мич арасыгының алгы ягында бер шәүлә күренгәндәй булды. Нургалием, имеш... Йокламыйм да шикелле үзе. Шулай да ана күңелемдә йөрткән бөтен үпкә сүзләремне әйтеп калырга кирәк, белеп торсын дип уйлыйм. «И, Нургали жаным, синең рухың түгәрәкләнгәндер инде, Маһирән белән янадан кавышкансың икән. Уларың да янында. Ә мин һаман сездән еракта, каңгырып йөргән ялгыз каз хәлендә. Исән чагында да мине сары сагышларга салып яшәдең бит, жаным... «Газзә түзәр әле, түзем бит ул»,—дисеңдер инде. Түземлегем төкәнеп, югары оч Сылубикә төсле үземә кул салсам нишләрсең? Юк-юк, Аллаһым үзе сакласын! Тьфү-тьфү, әйттем исә кайттым... Син бит Сылубикәне дә авылда иң сабыр хатын дия идең. Аның да сабыр савыты тулып ашкандыр, жанашым. Иренең сугышта үлгән хәбәре авылда иң беренче ана килде. Авыл халкы бик жәлләде үзен. Кемнәрдер мордар киткәннәрне зиратка кертергә ярамас дисәләр дә, каенанасы янына илтеп жирләделәр. Күмгән чакта халык, бернигә дә карамыйча, тол солдаткага тиешле ихтирамны күрсәтергә тырышты.

И, Нургали бәгърем, сары сагыш, ачы хәсрәтләрең белән бергә юанычларың да биргән идең бирүен... Тач үзенә охшаган—сөйдергеч бөтиләре—малайларың өчен, үзең дә беләсеңдер, рәхмәт тә укып яшәдем мин сиңа. Аллаһы Тәгалә разый булсын! Тик соңыннан, әллә күпсенден инде, йөрәгемне суырып алгандай, аларны да үз янына тарттың... Синең соңгы бүләгең диеп сөеп үстергән Харисымны гына булса да янымда калдырган булсаң.,—дип әйтеп кенә өлгердем, күз алдымда торган теге кара шәүлә, тора-бара гел Нургали төсенә кереп, өйнең теләсә кайсы почмагында пәйда була башлады. Күземне кая төшерсәм ул шунда, ап-ачык күрәм. Йөзе болай тыныч шикелле үзе, елмаеп та куйгандай итә, әмма күзләрендәге монсулык бихисап, әйтеп бетергесез. Бер-беребезгә карап туялмаган гашыйклар күк күпме шулай басып торганбыздыр, әйтә алмыйм. Миндә куркуның әсәре дә калмады. Әллә шуны Нургалием дә сиздеме, телгә килде генә бит, жаныкаем, Ходайның рәхмәте... «Мина да ди, Маһирәгә дә ди, рәнжемә, ул—минем өчен өзелергә торган бары бер кыл гына иде, ди. Яратканым син генә булдың, ди бит жаныкаем. Безнең янга килергә ашыкма, синең үз дөньяң бар. Анда син күпләр өчен әле бик кирәкле кеше! Ата-бабамнардан калган нигезебезне дә саклый күр!—ди. Моннан соң да, ди, тәмле ризыкларыңнан бүгенге шикелле мәхрүм итмә безне, димәсенме тагын, үзе инде, үзе, тавышы да үзенеке... Тик мина караганда кыяфәте белән күпкә яшь, матур... Бөтенләй әллә нишләп киттем, ни дияргә дә белмим, баскан жиремдә каттым да калдым. Ә ул миннән нидер көткәндәй карап тик тора. Телемне әйләндереп ник бер сүз әйтә алыйм... Шулай да күңелем белән: «И, Раббем, ичмаса бер генә сүз булса да әйтеп калыйм үзенә»,—дип, Раббемнан тел ачкычы сорап ялварам, өзгәләнәм... Ниһаять, ниндидер көчләр бар вөжүдемне кысып торган тимердәй кыршаудан ычкындырып жибәрмәсенме; «Нургали бәгърем, күпме көттем мин бу очрашуны... Жылы сүзләрең өчен рәхмәт. Намазларымны да бүген укый алмадым шул, Ходаем үзе ярлыкасын инде. Син дә гафу ит, бәгърем, сезне дә бүген догаларымнан мәхрүм иттем шул. Кем уйлаган, барың да белеп ятасыз икән бит... Синнән бер генә нәрсә үтенәм: алып кит мине бүген үзең белән, калдырма монда газаплар илендә»,—дидем дә, ике кулымны жәеп Нургалигә таба атылдым. Тик шунда ике арабызда куе томан барлыкка килде һәм Нургалием шул томан эчендә калып юкка чыкты. Ни булды бу: әллә өнем, әллә төшем, әллә саташуым—тәки аңлый алмадым.

Бисмилламны әйтеп әкрен генә торып утырдым. Аннан «Аятел көрси» сүрәсен укып, бишле лампамны кабызып куйдым да, өемнең һәр почмагына

күз салдым. Нургалием инде башка күренмәде. Җәһәт кенә тәһарәтемне алып, укылмый калган намазларымны укыдым. Барлык әрвахларым өчен, инде көндәшем Маһирәне дә өстәп озаклап дога кылдым. Нихәл итәсең, аның үлемен дә авыр кичердем. Менә шул көннән башлап аны да догамнан калдырганым юк. Ходаем кабул кылсын, Нургалиемнең рухы шат булсын! Шөкер, үземнең дә күңелем тынычланып китте, тик колагымның карурмандай шаулап торуы, нигәдер, көчәя төште. Кәрәчинем бетсә бетәр дип утны сүндермичә генә урыныма барып яттым. Йокысыз үткән бу төнем дә хәтеремдә мәңге онытылмаслык булып уелып калды.

22 февраль, төн. 1950 ел.

Йә, Хода, 22 февраль—Харис улымның туган көне бит бу.

Исән булса бүген аңа 25 яшь тулырые. Ә ул бары 19 яшендә, үзенең туган көнендә һәлак булган. Өзелеп сөйгән яры калды. Сөембикә исемле, мәхәббәт алиһәсе диярлек кыз. Харисымның үлеменә ышанмыйча, һаман көтә.

Үзем дә, әлеге төнемә кадәр, кайда гына булса да, исәндер әле дип, Нургалиемне 26 ел буе көттем. Менә бүген мин аның инде күптән җир куенында ятуына, ниһаять, ышандым, үзенең ярдәме белән.

Беренче улым—Хафизым 1939 елны армиягә алынды. Көнбатыш чик буенда хезмәт итте. Аның да 21 яшендә, 1942 елны «Хәбәрсез югалды» дип язылган хәбәр кәгазе килде, Нургалием дә 1924 елның җәендә, бары 22 яшендә бер хәбәрсез югалганые. 1929 елны әткәйне кулга алдылар. Мулла абзыйны кулга алудан һәм мәчет манарасын кистерүдән саклап калырга тырышып, яклап чыкканы өчен. Фарук мулла белән икесен дә Себергә җибәргәннәр дигән ярым-йорты хәбәрдән башка берни дә билгеле түгел. Шушы иң якыннарым—ике улым, ирем вә каенатамның җәсәде кайларда ятадыр, әле һаман билгесез. Әткәй өчен хәсрәтләнүдән, йөрәге күтәрә алмыйча, шул ук елны, әнкәй дә гүр иясе булды. 45-47 яшьләрендә генә ие бит әле алар да. Шулай итеп, берүзем, япа-ялгыз калдым. Терәк күршебез вә якын дустыбыз Нурислам сугышның беренче көненнән ахырына кадәр катнашып, 1945 елның 2 маенда һәлак булды. Ярый әле улы—Исламгали исән кайтты. Мәрхүмә Зөмәрә Саҗидә ахирәтем бәхетенә тапкан икән бу игелекле баланы. Калган гомеремдә ул мине дә ярдәменнән ташламады.

Нинди матур гөрләп барган тормышыбыз 20 ел эчендә пыран-заран килде дә бетте... Инде колхозыбыз да күтәрәмгә калган хайван кук... Эшче куллар җитми. Сугышка алынган ир-егетләребезнең күбесе сугыш кырында ятып калды. Кире әйләнеп кайтканнарының да хәлләре ташка үлчим, кайсы аяксыз, кайсы кулсыз дигәндәй. Авыл халкына терәк булырдай Хәнифләр, Фатыйхлар, укытучыларыбыз Габдрахман, Борһан, Зәки абыйлар кайта алмадылар шул... Алда тормыш рәтләнер әле дигән өмете дә юк бит аның. Сугыштан исән кайткан Мәхмүт белән Исламгали дә Донбасс шахталарына китсәк кенә, бәлки, гаиләләребезне саклап кала алырбыз дип сөйләшкәли башладылар. Хөкүмәтнең налогларын да... Аларны түләп кенә бетерерлекме соң? Үзем дә налоглардан котылыр өчен исән калган алмагачларымны җылый-җылый кистем. Әткәйдән калган ике баш умартамны калхузга тапшырдым, әткәй төсе итеп бик саклыйсым килсә дә... Ә заемнарын, ач калсаң каласың инде, барыбер түләтәләр... Түләми генә кара...

Сугышта ирләрен югалткан үткенрәк яшь хатыннар да, читтә яшәүче туганнарына сыенып, ничек тә авылдан китү ягын карыйлар. Яшәүнең бер кызыгы да калмады. Данлы җыеннары, пар атларда кунак төшерүләре, гашыйкларны кавыштырган кичке уеннары белән гөр килеп яшәгән авылның яме күзгә күренеп җуела бара. Искереп туза барган йортлар, җимерелә башлаган каралты-кура кемнең генә күңелен күтәрсен?..

Үзем хәзергә остазым Гыйззелбәнат ападан үзләштергән һөнәрем белән,

үз авылым һәм тирә-юнь авыл кешеләренә хезмәт күрсәтеп, аларның хөрмәтен тоеп яшәп ятам. Алдагысын Алла белә дигәндәй, тагы ниләр күрәсе бардыр... Улларым белән Нургалием төшләремә сирәк кенә керсәләр дә, алар миңа көч бирәләр, ни генә эшләсәм дә янәшәмдә йөриләр, күнелемне күтәрәләр. Ә менә Мәһирә көндәшемне нишләптер ешрак күрәм. Начар да күрмим, әмма бик моңсу, һәрвакыт ялгыз итеп күрәм мин аны... Кызганып та куям үзен...

Гомерем буе бер нәрсәгә аптырап яшәдем. Әбием әйтергә яраткан «Ил бирмәк кан бирмәк, ир бирмәк жан бирмәк» дигән мәкаль, әйтерсең лә, гел минем өчен генә туган...

Сөлектәй улларым ил өчен сугышта башларын салдылар. Үлеп яраткан ирем белән дә бары бер ел да ике атна яшәп калдым. Мәһирә белән кушылмыйча, Нурислам шикелле ил өчен сугышта батырларча һәлак булган булса да, кимендә 21-25 ел бергә бәхетле, бик бәхетле яшәгән булыр идек. Нишләмәк кирәк... Мирхәйдәр Фәйзинең гүзәл Галиябануы жырлаганча— «Ходай насыйп итмәде»...

Бер көнне, һич көтмәгәндә, Ташкенттан Зәкия кайтып төште. Бертуган өч абыйсы да сугышта һәлак булган. Ялгыз калган авыру әнисен үзе янына алып китәргә дип кайткан. Миңа көндәшем Мәһирәнең аманәте белән соңгы язган хатын алып кайткан. Аманәт дигәне «Гюзялбанат кыйссасы» дигән үзе язган китабы булып чыкты. Гыйззелбәнат апайның үлгәнен ишеткәч, миңа тапшыру өчен дип Зәкиягә биргән. Зәкиянең сөйләве буенча, аманәтен тапшыргач, көндәшем үзе дә бары берничә көннән гүр иясе булган. Китапны укып өнсез калдым. Менә кемдә булган ул илаһи түземлек вә сабырлык. Үзенең коточкыч язмышы турында кемгә-кемгә, хәтта яраткан шәкертенә дә ник бер сүз әйтсен... Мәһирәгә сөйләгән, берсен дә яшермәгән...

Үзе үләре алдыннан хәле авырайганны сизеп, ахры, шул йөзеген, йөзегенә пар алкасын (анысын үзе алган булса кирәк) миңа бүләк итте. «Төсем итеп ки, сакларга тырыш. Берләнбер үтенечем—доганнан калдырма, үзем белән бергә әти-әниемне дә»,—диде. Шунысын да өстәде әле: «Доганны кылганда бу истәлекләремне ки, аларга орынгалап та ал, онытма, яме,—диде бит әле, жан кисәгем. Менә ни өчен ул миңа һәрвакыт: «Газзәбану акыллым, шөкер итеп яшә, Ходай биргән язмышыңа тел-теш тидерә күрмә. Сиңа килгән хәсрәт ялгыз хәсрәт түгел, ил белән килгән хәсрәт. Әнә күрше авылыбызда гына бит газиздән газизләрен—ирен вә берсе артыннан берсен сигез улын сугышта югалткан Мәрьямбикәне күз алдыңа китер»,—дияр иде сагышларымнан жылый-сыкрый башласам.

И, кадерле остазым, ачлыктан интеккән чакларымда, әллә берсен генә булса да сатыйм микән дип уйлап куйган чакларым булгалады, әмма күнелем тартмады. Менә хәзер барын да аңладым. Синең күнелең изге булган, рухың шаттыр дип ышанам. Күпме гомер бирер Раббем, соңгы сулышыма кадәр мин сиңа догада булырмын, нәкъ үзең теләгәнчә... Бер Раббем кабул итсен!!!

Тәмам.

*2001—2008 еллар.*
*Казан.*



Рашат
Низами

## МЕҢӘР ЯФРАК—УРМАН КҮЗЛӘРЕ...

### Яшәү тамыры

**Әй син, Вакыт!**
**Күзләр җибәрдем дә**
**Җәйне кудым, диеп алданма...**
**Кышны кичеп чыккан бөреләргә**
**Яфрак җебе килеп ялгана.**

**Болын. Урман.**
**Җирдә—чәчәк туе.**
**Юкәләрдән татлы бал тама.**
**Яшәрсен дип, Җирнең күкрәгенә**
**Яңгыр җебе килеп ялгана.**

**Ак мендәрдә ап-ак сабый бала,**
**Ике бите—гүя тулган ай.**
**Буыннардан буыннарга күчеп,**
**Гомер җебе шулай ялгана.**

**...Хыял күкләрендә йолдыз яна,**
**Ямь биреп тә, яшәр гамь биреп.**
**Бу дөньяда—таулар гына түгел,**
**Хәтта... үләннәр дә мәңгелек!**

### Туй

**Кыз һәм егет мәхәббәте—**
**Урал тавы чаклыдыр.**
**Кәләшнең ак пәрәнҗәсе**
**Күз тиюдән саклыйдыр.**

Рашат НИЗАМИ (1950) — *шагыйрь, прозаик, публицист; «Йолдыз яңгыры», «Кызыл җәй», «Җыр һәм мылтык» исемле (композитор Ф. Яруллин турында) һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Урам буйлап әллә атлар,
Әллә туй үзе чаба?
Тел шартлатып кала ирләр:
«Килен чибәр, ничава!»

Гармун өсләренә менеп
Биеште стаканнар.
Теләкләр, шампан шәрабе
Ташыды тустаганнан.

Хисләр дә ташый, түгелә
Җиде йолдыз чатына,—
Җырга һәм тостка уралып,
Табын таган атына...

Ниләр посып ята икән
Кызның мендәр астында?
Кыштырдый ефәк чыбылдык...
Атла, егет, тартынма!

Офыкта таң көлемсери,
Туй табыны бушаган.
..........................................
Дөнья бүген яшь парларның
Хөҗрәсенә охшаган!

## Урман күзләре

Урманыма керсәм, эреп китәм:
Анда—шатлык, бәхет, сәгадәт!
Учак ягам...
Бик борынгы бабамнардан
Каныбызга сеңгән бу гадәт.

Яшел урман—гигант һәйкәл бит ул,
Буыннардан күчә буынга.
Менә мин дә кыйсса языйм әле
Үзебезнең урман турында.

Җиләкләре—бала-чага өчен,
Печән дисәк, безгә—ирләргә;
Пакус арты пакус каезлыйбыз
Бата-чума кара тирләргә.

Елан күзен күрдем...
Ә чынлыкта
Күрдем кебек урман күзләрен.
Тере урман җырын аңлатырга
Каян табыйм шигъри сүзләрем?

Яшь куаклар, яшь наратлар үсә
Ромашкалар белән янәшә.
Бер-берсенә алар, туганнарча:
«Исәнме?»—дип сөеп эндәшә.

Чикерткәләр, ярый, бик тә юаш,
Черки-кигәвеннәр бик усал:

Тешләшәләр—
Ял итәргә диеп
Пакус өсләренә син аусаң.

Калкып-балкып чыга чүмәләләр—
Туган якның нәни вулканы.
Чалгы узып киткән сызмаларда
Ишетелә
Үлән тамырлары типкәне.

Чишмәләрне инде әйткән дә юк,
Меңәр яфрак—урман күзләре.
Каен тузларында—кемнең шулай
Ап-ак кына әйтер сүзләре?..

## Әй, сеңел!..

Айкады күңелне бу сурәт:
Кырауга эләккән сиреньдәй,—
Нәрсәдер пышылдый, ялвара
Мәсхәрә ителгән иреннәр...

Ак-кара буталган. Кайда соң
Язларны китергән җыр назы?
Жавапсыз мәхәббәт—әйтерсең,
Юлыннан адашкан кыр казы.

Яз иртә килде, дип кайчакны
Агачта бөреләр алдана,—
Таллыкта зирекләр чугыннан
Сут түгел, кәүсәри кан тама.

Тамырлар туфракта чагында
Кояшка тартылмас кайсы гөл?
Өметсез уйлардан өскәрәк
Башыңны күтәр син, әй сеңел!

Төзәлер күңелең ярасы,
Адаша күрмә син юлыңнан.
Күр әнә: күк читен тешләгән
Бәйгегә чыгасы колыннар...

## Кырда—казлар өне

Өзеп кызыл тәпиләре белән
Камылдагы пәрәвезләрне,
Теләченең ялан кырларына
Кыр-казлары килеп тезләнде..

Берәү... өчәү... бишәү... Әллә ничәү!
Саный китсәң, ике йөзләп бар.
Шушы казлар белән күтәрел дә,
Романтика нурын эзләп бар.

Мәрмәр сынлы чибәр киек казлар!
Хушлашырга диеп килгәнсез.

Никадәрле азат кошлар бит сез—
Богауларсыз, бәйсез, йөгәнсез.

Күпме әнә бала үстергәнсез,
Сыгылмаслык булсын канатлар.
Очар юлың буталмасын дисәң,—
Йолдызларга, айга карап бар.

Кыйгак-кыйгак! Кырда—казлар өне,
Моңсу булып китә күңелгә.
Сәйдәш белән Бах моңнары гүя
Туган кырларыма түгелгән...

Кошлар китеп бара җылы якка,
Кышлар килеп ята котыптан.
Ник өзелеп калдың, каурый каләм,
Ак җилпәзәң, ахры, тутыккан...

## Эзләп киләм...

Әй, аңларга телим йолдыз нурын,
Җирнең мәңге яшел үләнен.
Зур сораулар белән җитәкләшеп,
Дөнья серен эзләп киләмен.

Җирдә, күктә талгын бер тамаша;
Күрегезче, вакыт фасыллары
Берәм-берәм ничек алмаша...
Кояш—галәм президенты булыр иде
Кем икәнен үзенең аңласа.

Тик мәңгелек микән Кояш шары?
Яна торгач, хәтта учак та,
Муенынннан көлгә бата-бата
Сүнеп кала шулай бер чакта.

Җирне бүлеп, дөрес эшли микән
Картадагы меридианнар?
Ни өчен дип, нәрсә хакы өчен
Уяна да дулый вулканнар...

Чын-чынлап та кеше—кешеме соң:
Әллә инде ерткыч, хайванмы?
Күргәнегез бардыр—бомбалардан
Шәһәр тикле шәһәр ауганны.

Динозавр күптән үлеп беткән,
Ә бөҗәкләр һаман исәннәр.
Дарвин бабай безгә ярлык таккан—
Без маймылдан чыккан исәрләр.
(Күп сөйләшсәң, башны кисәрләр).

Дөнья серен эзләп киләм шулай.
Тик куркыта мине бер нәрсә:
Соңгы сүзен әйтеп, әзер бул, дип
Күкләр миңа хәбәр җибәрсә...

***

Бала чакта битне юдым
Иртәнге чыклар белән.
Чирәмдә «әбәк» уйнадым
Шаян чыпчыклар белән.

Үсмер чагым... Битләремне
Юдым чишмә суында.
Беренче мәхәббәт тәмен
Татыдым нәкъ шушында.

Егет булгач, битне юдым
Диңгез сулары белән.
Тугыз баллы дулкыннарның
Холкын мин яхшы беләм.

Күккә аштым—һәр күзәнәк
Һәм җаным белән гүләп!
Бөтен тәнемне юдым мин
Йолдыз сулары белән...

Шулкадәрле хәтәр нәрсә
Бу тормыш дигәннәре...
Бер кылда эленеп тора
«Мин яшим»...—дигәннәрең.

Үлемнән һич курыкмыймын,
Язмыш бит ул—уйдырма.
Әй, дөнья!
Тик беркайчан йөзләремне
Кан белән юындырма...

## Көзгә таба

Сыек томан...
Тынлык. Коймалардан
Ташып чыккан көзнең кодрәте:
Сыгылмалы авыр ботакларда—
Алма туе, алма сурәте!

Нидидер кош чукып-чукып киткән
Бакчадагы чияләремне.
Көзгә таба җимнәр җитми кала...
Аңлыйм, кошчык, аңлыйм хәлеңне.

Йолдызларның күчешен кабатлыймы:
Күктә—кошлар «мириадасы».
...Хәтер учмаларын,
Көлтә-көлтә итеп,
Төйни бүген адәм баласы.

Сентябрьнең салкын йолдызлары
Күктә яшәп ята тулышып,
Моңсу томан эчләреннән бүген
Тоям алмаларның сулышын.

Сагышларым, сары тасма булып,
Маңгаема минем уралган.
Ә шулай да, әнә, «Сөенче!»—дип,
Шатлыкларым чаба иң алдан!

Сулыйм. Яшим.
Көзгә кереп барам.
Миндә—хисләр мириадасы.
Учак исе килә болыннардан...
Учакларның
Кабыныр әле тагын яңасы!



Суфиян
Поварисов

# УТЛЫ ДУГА КЫҢГЫРАВЫ

РОМАН-ХАТИРӘДӘН ӨЗЕК

***

Көне буе тасырдап торган канлы фронт яланы кинәт тынып калды. Дары исе сеңгән тын кич. Солдатлар, сират күперен чыкканда тәмугка төшеп китүдән котылып калгак әрвахлар кебек шатланып, иркен тын алып куйды. Эссе кояш, сугыш уты ялкыны аларның йөзләрен бакырга әйләндереп, эчәк-бавырларын тәмам корытып бетерде. Өзлексез аккан тир гимнастеркаларны манма итте, аларга чаңтузан кунып, дары исе сеңеп, каткан каешка әйләндерде. Менә хәзер киселгән агач кебек кинәт аварга да, шаңкытылган балык кебек исәнгерәп, тирән йокыга чумарга иде. Юк шул. Юк. Их, ир-узаманнар! Башта акыл булмаса, аякның беркайчан да ял итмәячәген һаман аңлап бетермиләр. Энгер-меңгер куерып, янә йолдызлар калыккач, инде тәгәрәшеп оерга торганда, тагы да күченергә команда булды. Яугирләрнең берише, бигрәк тә олы яшьтәгеләр, инде сукраныргa-сүгенергә сүз тапмый башлады. Әллә ниләр әйтеп ташладылар:

—Ата каз урынына һаман бер жирдә таптанабыз...

—Машина белән жилдерәчәк немецны шулай ку инде...

—Ишәкне дә бу тиклем жикмиләр...

—Жуков белми микәнни шушыны?

Җеп өзәрлек тә хәле калмаган, күзләре тәмам гарешкә терәлгән мескен солдат хәзер инде, авыр коралларны күтәрү түгел, кыл да кыймылдата алмас кебек. Шулай да, бер кузгалгач, әкренләп хәрәкәт ителә, каторгада эшләгән ристаннар кебек, өнсез-тынсыз дигәндәй, күтәренеп, сүгенә-сүгенә атлый бирәләр.

Бүген хәтта Әхсән-Чыңгызхан да, «Мулла бабай» да, башка яугирләр дә солдатларга әллә ни рухи көч бирә алмады. Харисов аларның да эчәк-бавырлары суырылып, кикрикләре шактый шиңеп барганлыкны аңлады. Ничек кенә булмасын, күтәренеп-ташынып, кояш нурларын яңа ут позициясендә каршыладылар.

---

Суфиян ПОВАРИСОВ (1924) – *язучы, галим, филология фәннәре докторы; күпсанлы фәнни хезмәтләр һәм әдәби әсәрләр авторы. Уфада яши.*

***

Шушы көнне 4691нче миномет полкы командиры майор Чернявскийны артиллерия башлыгы генерал-майор Полуэктов чакыртып алды.

—Син тагы да солдатларны ишәк урынына җигеп, алардан төне буе хәрби техника ташыткансың, оятсызлык бу, кешедән көлүнең иң яман формасы, әгәр моны фронт командующие генерал Конев, йә Ставка вәкиле маршал Жуков белеп калса, икебезне дә жан җиребездән асып куячаклар,—дип ярсыды Полуэктов.

—Башка чара юк, иптәш генерал,—дип акланды майор.

—Бар. Мин табам.

—Тынлыйм, иптәш генерал.

—Әгәр солдатларыңның тагы да бер тапкыр ерак җиргә шулай күтәренеп күченүләрен ишетсәм, майор погоның белән хушлашасың. Менә сиңа бирәгәйле чара.

Майорның ялбыр кашлары җимерелеп төште. Генерал алдында башкача акланып маташуның хәсияте юклыкны тәмам аңлады ул. Шуңа күрә анык, конкрет җавап бирергә булды:

—Бу хәл башкача кабатланмас, иптәш генерал!

Полуэктов аз гына йомшый төште. Хәтта эчке кичереш белән, генерал икәнлеген онытып сөйләүгә күчте:

—Кешедән күпме көләргә мөмкин, майор! Хәер, бу безнең каныбызга сеңгән. Сугышка чаклы да кешене дуңгыз баласы урынына күрмәдек. Рәсәй, әйтерсең, адәми затны шаңкылдатып җәзалау урыны. Плаха. Фашистлар да болай кыланмый лабаса. Ташытыр ул сиңа 360 килограмм авырлыгындагы минометны биш-алты километрга күтәртеп. Алар солдат кадерен безгә карганда яхшырак белә. Шушы хәлне ишетсәләр, алар бездән егылып, эчләре катып, буылып-буылып көләчәкләр. Болай да «хәерчеләр» дип мыскыл итәләр. Бөтен җир йөзенә таралган бу «данлыбыз». Бөлде ил. Барыбыз да бөкре биллегә әверелеп беттек. Ярый ла сугыштан соң үзебезнең кем икәнлегебезне күрсәтә алсак, һаман шулай эттән хәерче булып яшәмәсәк...

Генералдан аерылгач, машинасы белән полкка җилдергәндә дә, соңыннан да үзе хакында нык, кат-кат, йодрыгы белән маңгаен төя-төя уйланды майор. Генерал аның погонына кизәнә. Шул чиккә җиттеме ул? Кайда сөренде? Таутөмәндә тиешле машинаның дүрттән бер өлешен генә бирделәр. Шулай булгач, аның ни гаебе бар? Фронтта машиналарның сафтан чыгуы табигый хәл. Моңа полк командиры гаепleme? Янган машиналар урынына яңаларын китерергә тиешләр. Китерде ди сиңа. Шиш. Тот капчыгыңны. Генерал үзе ачыктан-ачык әйтә, дөрес әйтә: ил көрчегенә килеп терәлде. Фронтка машиналарны гына түгел, корчаңгы алашаларга тиклем җибәреп бетерделәр.

Батырлык, ирлек, горурлык мәсьәләсенә килгәндә, ул әле һич тә майор погонын бирү чигенә килеп җитмәгән. Беренче көнне үк ут эченә иң тәүдә үзе кереп китте. Разведчиклар белән бөтен алгы ут позицияләрен айкап-байкап йөрде. Дошман пулясы башындагы фуражкасын очырып алып китте. Аның курку белмәс командир икәнлеге бөтен полкка мәгълүм булды.

Юк аның гаебе, аслан юк. Сөттән ак, судан пакь ул. Тик... Ялгыз карга яңгыр яудырмас, ялгыз батыр ул кайтармас ди бит. Үзеңнең батыр йөрәкле булуың гына җитә микән монда? Кешелеклелек ягың гына да полктагы гөнаһларны каплый алмаска мөмкин. Бөтен яугирләрне үзең кебек әйбәт кеше итеп тәрбияләргә кирәк, һәр солдат «һайт» дигәндә «тайт» дип торсын. Тыныч тормышта да шулай бит. Кешенең үзе яхшы булганы гына җитми, ул эшнең асылына, җаена төшенеп, дөрес житәкчелек итсен; кояш орбитада

Жир һәм башка планеталарны ияртеп тулпардай томырылган кебек, үз артыннан башкаларны әйдәп алга ыргылсын. Эче яхшылык гәүһәре белән тулы булса да, өстәл артында бохар песиедәй йокыга моң булып утырса, инициатива дилбегәсен ике кулына шакырдатып урап алалмаса, эше, кем әйтмешли, дуңгыздан бер кыл кебек кенә икән, андый житәкче—ташка үлчим генә инде.

Иң башта үзенне-үзен танып-белергә тиеш икәнсең. Әгәр шуна ирешә алмасаң, тырнак арасыннан кер эзләгән кебек йөрмә инде син, туганкай!

Аннары фикер җепләрен генералга табан сузды майор. Полуэктов белән күптән таныш ул. Генералга—илле яшьләр чамасы. Әмма гаскәри кыяфәт, житез хәрәкәт аны әле бик яшь күрсәтә. Үзе ул нык таләпчән. Вакыты белән артык усал да була белә. Шулай да чаманы онытмый. «Яхшы усал» дигән кушамат аңа шуның өчен сылангандыр, бәлки. Бу аның кешелеклелегенә бәйле. «Яман усал» дигән бәя тагылса, ай-һай-һай, бәсең китә дә китә инде: ул бер килеп берексә, аннан соң пычак белән дә кырып ташлап булмый. Кыскасы, дегет чиләге урынына артыннан тагылып тик йөри.

Генерал кешелекле генә түгел, кечелекле дә була белә. Әле менә майор алдында, үзенең генерал икәнлеген онытып, бөтенләй кечерәеп, аны бертуганы кебек күреп сөйләшергә керешге. Аз гына вакыт эчендә, сөйләмен бөтен ил кайгы-сагышы белән бәйләп, йөрәккәенне әрнетер-әчендерер чиккә житкереп, күңелендәге бозны да эретерлек итеп сөйләп китте дә барды. Майор погонына кизәнүе дә дөрес шул. Комнан аркан ишә, балтадан аш пешерә белә торган солдатлар алдында нигә жебеп төште соң әле ул? Машинага өмет баглау жилсез көннән давыл көтү кебек кенә хәзер. Ә нигә әле атка күчмәскә? «Курск дугасы» бар. «Курск аты» да табылыр.

***

Унөченче июль көнне бөтен фронт буенча башланган һөжүм уңышсыз килеп чыккач, безнекеләргә ярсу йөрәкләрен янә берни тиклем тынычландырырга, әйткәндәй, тәкъдиргә баш иеп, өзелер чиккә житеп тартылган нерв кылларын бераз йомшартырга туры килде. Исхаковның бөтен офицерлар алдында полк командирына һичбернинди икеләнүләргә юл куймыйча, нықышып, чатнатып әйткән сүзләре бер-ике көн эчендә чын хакыйкатькә әйләнде дә куйды. Әкияттәге кебек бу. Әллә жир тишегеннән алалар, әллә күктән тартып төшерәләр. Әллә күзгә күренми торган сихерле дөньядан суырып чыгаралар. Атсыз татар—канатсыз, дигәннәре чын икән. «Ат» сүзе чыккач, күпләр канатланып очып китә язды. Ике көн дигәндә әллә ничә жигүле ат пәйда булды. Олы яшьтәгеләрне—Шәвәли абзый, Муллаян абзый кебекләрне ездовой итеп куйдылар. Яна урынга инде ат белән күчелде.

Дөрес, хәзергә барысы да ал да гөл түгел иде әле. Йә камыт, йә дуга, йә ыңгырчак житешми. Әмма солдат барыбер бер жаен тапмыйча калмый. Әлбәттә, четерекле яклары әйтеп бетергесез: әгәр миномет өчен бәләкәй генә бер өй китереп утыртырлык окоп казылса, ат һәм арбаларга инде зур йорт сыйдырырлык итеп чокырга кирәк. Моны ездовой берүзе генә булдыра алмый. Аңа бөтен яугирләр ярдәм итәргә тиеш. Шулай булса да, бу эш солдатның бер чиләк тирен түктерә.

Яңа ут позициясендә хәрби эшләр түгәрәкләнгәч, һәр солдат үз эше белән мәшгуль булды. Сәлим иртәгә сугышка керәбез дип Гөлжамал апасына хат язып жибәргән иде. Сугыш утына керү—үлемгә бару дигән сүз. Шуны уйлап, апасы хафаланып ятмасын. Ул үлмәячәк. Яшәячәк. Чирле апасын тынычландыру, борчымау өчен алдашу юлына басты хәтта. Монда даими рәвештә ут казанында кайнаганлыкны, ике көн эчендә яртı полк кырылып

беткәнлекне, жир шартлап ярылыр чиккә житкәнче сугышуларны әйтмәде, пехота өчен генә авыр, минометчыларга бер кыенлык та булмауны аңлатты, исән-имин йөреп кайтачагы турында язды. Бу хатында Мәрьям исемен мәгәр телгә дә алмады.

Фронтта авылдаш белән очрашудан да зур шатлык юктыр. Шушы хакта шатлана-шатлана язмакчы иде ул. Әмма Мәхмүт, Сәлимнен кәгазь-каләм тотып йөргәнен күргәч, очрашу турында ләм-мим сүз әйтмәскә кушты. Моның нинди яшерен сере бардыр, ул турыда Ходай үзе генә белә. Гомумән, Мәхмүт авылдан киткәннән бирле бер хат та язмаган. Нигә? Ни өчен? Бу тиклем таштай каты бәгырьлелек каян килә? Ә Мәхмүт моны үзе егетлеккә санап йөри икән. Ул, имеш, кайбер ир-егетләр кебек, хатын-кызларга охшап жебеп йөрми; аныңча, сагыну мәмәй авызларга гына хас.

Бу сүзләрне ишетеп артына егылып китә язды нечкә күнелле Сәлим:

—Ялгышасың, Мәхмүт, алай ярамый, тилмертмә әтиенне, әниенне, яз,—дип карады Сәлим.

Ләкин тегесе авызын гына очлайтты:

—Хатка җавап килгәнче бер ай вакыт үтәчәк, әллә син шушы ут йомгагында тагы да берәр атна йөрермен дип өметләнәсенме?

—Алай төшенкелеккә бирелмә, Мәхмүт, кемдер исән калырга тиеш бит...

—«Утлы дуга» диләр моны. Барыбыз да көеп, янып, чәнчелеп бетәчәкбез...

Бу сүзләрне ишеткәч, Сәлим эсселе-суыклы булып китте. Шуңа күрә башкача сүз куертып маташырга уйламады да.

Бүген фронтта да, табигатьтә дә бер үзгәреш тә юк дип әйтергә мөмкин. Кояш һаман шулай, җирдәге дәһшәтне күрүдән йөзен сыткан сыман, курка-курка гына пәйда булды офыкта. Ул башта күтәрелергәме-юкмы, үзегезнең юньсезлегегез белән йөземә кара якмассызмы дигәндәй, утлы күзләрен мөлдерәтеп, озак кына карап торды. Ләкин, җирдәге фаҗигагә күпме генә рәнҗемәсен, үз вазифасын һәркөн төгәл үтәп бара. Ул кешеләр кебек ахмаклана белми.

Солдатлар, ял итеп, шәхси эшләреннән аерылгач, әкренләп, Мулла бабай тирәсенә жыела башлады. Ул илле ишеген ачкан кеше. 1895 елда туган. 1915 елда өйләнеп, егерме яшендә үзаллы дөнья көтә башлый. Дөмәй мәдрәсәсендә укып, әтисе юлыннан китә ул—мулла була. Утызынчы елларда кулга алып, остабикәсе һәм сигез баласы белән Себергә сөрәләр. Тайга урманнарында дүрт баласы, хатыны үлә. Утыз бишенче елны туган авылына кире кайта. Икенчегә өйләнә. Тавык кетәге зурлыгы өй әтмәлләп ала. Колхозга кереп, ат урынына эшли башлый. Җир сөрә, урып-жыю вакытында лобогрейкага утыра, кыш көне машина белән ашлык суктыра. Ләкин 1937 елны аны тагын кулга алалар. Яшь хатыны, бер яшьлек сабые, бөтен авыл халкы аны елап озатып кала. Сугыш башланыр алдыннан ул Уфа төрмәсенә килеп эләгә. Төрмәдән чыгарып, шушы полкка китереп сылыйлар. Хәзер беренче хатыныннан калган дүрт малае да фронтта. 1917 елгысы—очучы. Мәскәү янында барган каты сугышларда ук, таран ясап, бер немец самолетын бәреп төшерә. Ул инде хәзер дошманның уннан артык «корыч кошын» яндырган. Советлар Союзы Герое исеме биргәннәр. 1919 елгысы—полковник. Нииндидер полк белән командалык итә. 1921 елгысы рота командиры икән. 1923 елгысы—Ерак Көнчыгышта хезмәт итә. Болары белән ата кеше үзен бик бәхетле дип исәпли. Тик икенче хатыныннан туган сабые вакытсыз дөньядан китә, яшь хатын икенче иргә тормышка чыга.

Нурмөхәммәт абзый—Мулла бабай—кайгы казанында нык кайнаган кеше булса да, үзен болай ару тота. Әзрәк аксабрак йөри ул. Производствода

эшләгәндә уң аягын таш баскан. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, бервакыт сул кулы да сына. Бу чирләрне дә ул чын ир-егетләрчә үткәрә. Төрмәдән чыгарып, фронтка җибәрү өчен тикшергәндә, боларны әйтми. Аның өчен хәзер авылына янә иген үстерергә арестант булып түгел, фронтовик-җинүче сыйфатында кайту хәерлерәк. Аталык дәрәҗәсе дә бар бит әле. Шундый батыр улларың алдында йөзен кызарырлык булмасын. Ул солдатларны төрле мәрәкә-көләмәч сөйләп тә көлдерә, вакыты белән дин дөньясына да алып кереп китә, нык, түземле, чыдам булырга өнди. Һәр әңгәмәдә нинди дер бер яңалык чокып чыгармыйча калмый. Әле дә менә әлеге бәләкәй өй китереп утыртырлык окопта солдатлар, сандугачлардай тезелешеп утырып, аның авызына карап каттылар:

—Йә, Мулла бабай, ялындырып маташма!

—Чиш тизрәк сүз капчыгынны!

—Арытты сугышып...

—Көлдер безне...

Ләкин хәзергә Мулла бабайның көләмәч-мәрәкәләрен, дөнья хәлләре турында сөйләячәк кыйммәтле сүзләрен тыңларга насыйп булмады. Әнә, әкрен генә атлап, үз дәрәҗәсенең түбән татып, мин минме икән, мин кем икән дигән кыяфәт белән, комиссар үзе килә. Ул, форсат табып, бөтен подразделениеләрне бер урап чыгарга ярата. Солдатларны батыр, тәртипле, күндәм булырга өнди. Тышы аның һәрвакыт ялтырап тора. Аягындагы хром итеге көзгә кебек. Нинди генә авыр вакыт булмасын, өс-башына, итекләренә тузан төшермәскә, солдатлар арасында үзен үрнәк итеп күрсәтергә тырыша. Сүзләре йомшак. Ефәк белән бер. Иң каты бәгырьле хатын-кызны да эретерлек.

Солдатлар аны аяк өсте басып каршы алды. Ул, гәүдәсен бөгелдереп-сыгылдырып, сүзсез генә, кулы белән ымлап, утырырга кушты. Комиссарның йөзе шат иде. Күзләренә тиклем елмаеп тора. Әнә, мин кем, үрнәк алыгыз, телебез генә түгел, кулыбыз да эшли, танк яндырган кеше мин, дигәндәй тота ул үзен. Таутөмәндә, Яңа Очкылда чакта иң башта ашау мәсьәләсен сорашкан була торган иде. Моның күз буяр өчен икәнлеген иң ахмак солдат та аңлап ала. Кешенең эчендә ач бүреләр улый. Моны ул яхшы белә. Ә нигә, ачу китереп, үзенне фәрештә итеп күрсәтергә теләп, сорашып йөрергә ди? Сүздән аркан ишеп булмаган кебек, сүз белән тамак та туймый. Фронтта бу мәсьәлә хәл ителде, билгеле. Иртәгәсе көнгә мең кешегә дип азык-төлек алалар икән, ул көнне кичкә чаклы аларның яртысы да калмый. Солдат тегеннән дә йолка, моннан да таба. Ана ирек кенә бир. Шулай да комиссар, сүз башлап җибәрү өчендер, бәлки, тамак мәсьәләсен бүген дә искә алды:

—Ну... как... хватает?..

Бер сорауга әллә ун җавап яңгырады:

—Артып кала...

—Тук бүре белән бербез...

—Кикереп йөрибез...

Комиссар көлеп куйды. Солдатларның шаян сүзләре ошый аңа. Шуннан ул алда торган көчле давыл хакында сөйләүгә күчте. Бу давыл тарихи вакыйга булачак, имеш. Безнең бу утлы шардан тиз генә ычкынып, житез генә һөҗүмгә күчүебез хәерле, янәсе.

Моны, билгеле, хәзер һәр солдат үз аягындагы ботинкасы, башындагы пилоткасы кебек яхшы белә. Чөнки бу ут шарында әйләнеп-тулганып сугышуның бер фәтвәсе дә юк. Бу инде солдатлар өчен яңалык түгел.

Комиссар моны үзе дә сизде. Солдатларның һәр сүзне элекке кебек йотып барырга ашыкмаганлыкларын аңлады. Шуннан ул патриотик

тойгылар дөньясына кереп китте. Сугышка бәйле булган күп кенә тарихи вакыйгалар турында сөйләп:

—Бөек рус халкын җинәрлек көч юк дөньяда,—дип бетерде сүзен. Шуннан соң, бераз тын торгач, һәрвакыттагыча:

—Сораулар бармы?—диде.

Солдатлар, тылда чактагыча әллә ни әдәплелек саклап тормыйча, кул да күтәрмичә, бер-бер артлы сорау яудырырга кереште. Әхсән-Чыңгызхан:

—Ә башкортлар нindirәк халыкка керә, бөеккәме, түбәнгәме?

Ташкент егете Шәрип:

—Ә үзбәкләр?

Казан егете Әхмәт:

—Татарлар?..

Чуаш егете Николай:

—Чуашлар?..

Төрекмән, хакас, абхаз һәм башка милләт егетләре дә шул ук сорауны бирде. Полкта—егерме җиде милләт вәкиле. Шатлык та, кайгы да—барысы да уртак. Бер кабым ризыкны икегә бүлеп ашарга әзер торалар. Бер төргән тәмәкене унар кеше җыйнаулашып тарта. Һәрберсенең солдат капчыгында дары исе сеңеп беткән кул яссылыгы зурлыгындагы дәфтәрендә кырыклап полкташ-яудашының адресы бар. Болары, сугыштан соң исән-имин туган якларга кайткач, бер-берсе белән хат алышу өчен. Фронт дуслыгы—бөек дуслык! Аны язып та, сөйләп тә аңлатып бетереп булмый. Кайберәүләр, бигрәк тә сугышта кат-кат булган өлкән абзыйлар, бу дулкынны хәтта туганлык хисеннән, ата-анага карата булган кайнар тойгыдан да өстенрәк куялар. Бу һич тә туган-тумача, кардәш-ыру, ата-ананы кимсетү җәһәтеннән түгел. Аларның барысы да үз урынында. Аларның исем-җисемнәре һәркем йөрәгендә көчле давыллар куптарып ыргыта алмас дәрәҗәдә тамырланган. Ә инде фронт дуслыгы төшенчәсе бу тамырдан үсеп чыккан кәүсәгә килеп кушылып, яфрак булып ярды, күрәсең.

Шашкинның тылда чакта да даими рәвештә «бөек рус халкы» дип сөйләве башка милләт кешеләренең саруын кайната торган иде. Таутөмәндә чакта бервакыт шундый чагыштыру белән эш итте хәтта. Әйтик, вак балыкны чуртан йота. Ә чуртан үзе акула өчен бик тәмле ризык. Халыклар да шулай, янәсе. Вак халыкларны эресе йота. Эреләр тагы да эрерәкләр арасында йотыла. Аннан соң эреләр иң эреләр канаты астына җыелып сытылып бетә. Бу әлеге коммунизм чорында милләтләрнең бер-берсенә якынаю, бер-берсенә телләре керешү, ''Бөек» милләтнең җиңеп чыгу сәясәтен аңлату чарасы иде. Шушы төшенчәләрне сагыз урынына чәйнәп, кызыл сүзләрне борчак урынына чәчеп, Шашкин үзен политик яктан тотанаклы, тирән белемле, аңлы офицер итеп танытты. Тик менә әле төрле милләт вәкилләренең аның өчен куеннарына елан асраулары гына күңелсез хәл. Тылда песи кебек йөргән солдатларның да сугышта телләре ачыла башлады. Шуңа күрә монда шәйләп сөйләшү тиешлекне аңлады ул. Ничек кенә булмасын, җавап бирергә кирәк.

—«Бөек рус халкы» эчендә мин башка милләтләрнең барын да күз уңында тотам,—диде ул.

Бу җавап, билгеле, солдатларны канәгатьләндермәде. Чөнки әлеге эре балыкның вак балыкны йотуы кебек иде бу. Шуннан соң, җиңелеп калмау, сүзен өскә чыгару өчен, икенче төрлерәк нәтиҗә ясарга булды Шашкин:

—Без барыбыз да рус җирен фашизмнан азат итү өчен көрәшәбез. Монда укытучы-математик Рәхимов, фән кешесе философ Нигъмәтуллин, инженер Иванов һәм башка абруйлы шәхесләр дә бар иде. Аларның һәрберсе гаҗәеп үзенчәлекле, зыялы зат. Рәхимов солдат капчыгында математика

китабын йөртә. Мәктәптә сугыш чыгар алдыннан бер мәсьәләне чишә алмаган да китабын шуңа калдырмаган. Аз гына форсат табылса, шул мәсьәләсенә тотына. Ләкин һаман чишә алмый. Нигъмәтуллин тарих, философия фәннәрен су урынына эчә. Инженер Иванов нефть эшкәртү турында сөйләргә тотына.

Мәгълүматлы булсалар да, боларда солдатка хас гаскәри кыяфәт юк. Озын буйлы Рәхимов телеграф баганасын хәтерләтеп тора. Бөкрерәк Нигъмәтуллин аю шикелле лап-лоп басып йөри. Бер күзе кылый Иванов тотлыгып сөйләшә. Аларны хәтта «раз», «два»га солдатларча басарга да юньләп өйрәтә алмадылар. Расчет командиры яки төбәүче итеп тә куя алмадылар. Ә инде бәхәскә шәпләр. Әле дә менә Шашкин сүзләренә чыраен сытып:

—Әллә бөтен Советлар Союзы «рус жире» дип кенә аталамы?—дип сорады «философ» Нигъмәтуллин.

Шашкин ык-мык итте, арт чүмечен кашып алды, шулай да бирешмәскә тырышты:

—Чит илдә дә: «рус жире , «рус солдаты» дип сөйлиләр бит.

Бу җавап солдатларны отыры котыртып кына җибәрде:

—Мулла бабай аңлатсын әле моны,—диештеләр.

Мулла бабай башта, Шашкинны авыр хәлдә калдырмыйм дигәндәй, ялындырыбрак торды. Аннан соң, солдатлар бик үтенеп сорагач, тамак кырып, җай гына сөйләп китте. Бу җирләрдә ерак чал тарихта шумерлар, скифлар яшәгән. Безнең эраның дүртенче гасырында исә герман кабиләләре—готлар килеп оялый. Аларны дүртенче гасыр азакларында—нәкъ шушы урыннарда һуннар (төркиләр) кысрыклый. 375 елда һуннар Днепр аръягына чыгып, анда немецларны тар-мар итеп ташлыйлар. Шуннан соң төрки-һуннар Көнбатыш Европага табан юл тоталар. Атилла җитәкчелегендәге гаскәр хәзерге Венгрия, Германия, Франция дәүләтләре урнашкан җирләрне үтеп, Рум (Рим) шәһәренә юнәлә. Атилла гаскәрендәге 100 мең яугир Румны һәм Христосны яклап килгән 900 мең яугире булган гаскәрне тар-мар итә. 375-454 елларда Арал диңгезе, көньяк Урал таулары, хәзер «утлы дуга» дип аталган урыннар. Днепр буйлары, бөтен Көнбатыш Европа һун-төрки канаты астында яшәгән. Атилла гаскәрендә төркиләрдән тыш славяннар, угырлар да булган. Соңгылары, билгеле, ярдәмче көч сыманрак йөргәннәр... Мулла бабай сөйләде дә сөйләде...

***

Мулла бабай белән тагы да бер мәртәбә сөйләшеп карарга булды Харисов. Тик сүз җебенең очын таба алмыйча җәфа чикте ул. Ни дип әйтергә? Ни зыяны бар соң аның? Әлеге кара тап турында аз гына да борчылмый Харисов. Аны Мулла бабай язмышы борчый. Шашкинга һич ышанмый ул. Югарыдагыларга барып әллә нинди гайбәтләр сөйләсә, бу изге күңелле кешенең башына җитәргә дә күп сорамаслар. Азмени адәм башын ашауны чебен үтерү урынына да күрмәгән мүк йөрәкле бәндәләр?

Мулла бабай башта авыл мәдрәсәсендә укый. Аны ташлап, Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә килә. Монда татар, башкорт, казакъ, үзбәк, төрекмән һәм башка милләт егетләре була. Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Сәйфи Кудаш, Шәехзадә Бабич, Хәсән Туфан кебек каләм осталары укый. Галимҗан Ибраһимовның дәресләрен тыңлау, Сәйфи Кудаш, Шәехзадә Бабич, Хәсән Туфаннар белән аралашу, дус булу, төрле әдәби түгәрәкләрдә бергә кайнашу аны шактый мәгълүматлы, мәдәни, киң аң даирәле шәхес итеп өлгертә.

Боларның барын да белә лейтенант. Чөнки Мулла бабайның сөйләгәне

бар. Әнә ни өчен аның язмышы нык уйланырга мәҗбүр итә лейтенантны. Ул аны үз янына чакырып, читкәрәк алып китте.

—Мин аңлыйм, Мулла бабай, яхшы күңелле кеше син, тик... Шашкин кебекләр алдында теленне тешләү хәерлерәк... Мин моны һич тә командир буларак әйтмим... Якын күреп, үз итеп.

Мулла бабай яхшы күңелле, эчкерсез кеше булса да, аның киреләнә торган галәмәте дә юк түгел. Әмма үзе моны һич тә холык-фигылендә булган кара як дип исәпләми. Киресенчә, иманыма тугрылыклымын, тәкъдиремә хилафлык китермим, теләсә нинди искән җилгә тал чыбыгыдай бөгелеп-сыгылып тормыйм дип уйлый, солдат итеп түгел, олы кешегә санап, хөрмәтләп сөйләшүе, биргән киңәше өчен рәхмәт әйтте дә:

—Мин бит теләсә кем йолыккалый торган ангыра тавык түгелмен, иптәш лейтенант, таш капчык та, сугыш уты да каныма сеңгән иманымны корыта алмас,—диде.

Тагы да нидер әйтмәкче булган иде, лейтенант аны башкача тыңларга теләмәде, бу юлы инде якын мөнәсәбәттән команда бирү тонына күчеп әйтте:

—Китәргә мөмкин...

Лейтенант монда үзенең берни тиклем җинелүен дә сизде. Тылда чакта алдында тораташтай басып, бер сүз әйтергә куркып торалар иде. Хәзер исә, бер туган абыең урынына күреп сөйләшүгә кучкач, әнә ничек һаваланып китте. Әйтерсең, Харисов аны тавык йонын йолыккан кебек теткәләр өчен чакырган. Әйтерсең, аның иманын суырып алып, икенче берәү кулына китереп тоттыра, йә булмаса—усал җил-давылга туздыра.

Ачуы килсә дә, күңеле белән Мулла бабайны зурлау ягында булды лейтенант. Кеше үз иманына тугрылыклы. Алдамый. Ялганламый. Ык-мык итми. Турысын күзең чәчрәп чыгарлык итеп әйтә. Бу инде—шәхес! Тик андыйларга яшәве авыр шул. Утыз җиденче елларда ялагайлар, әләкчеләр, икейөзлеләр әнә шундый шәхесләрнең иманына көл сиптеләр. Тарих сәхифәләренә кара кан белән язылып калачак бу пычрак күренешләр әллә һәр адымда үлем көткән шушы ут эчендә дә дәвам итәрме?

***

Комиссар киткәч, солдатлар үз эшләре белән шөгыльләнергә кереште: берсе хат яза, икенчесе тәмәке көйрәтә, өченчесе гимнастеркасына ак яка тегә...

Бу өч тәүлектә, гәрчә тын алырга вакыт булмаса да, ут эчендә кайнашып торсалар да, Сәлим бөтенләй үзгәреп китте: үзен хәзер начар хис итми—бизгәк дигән юньсез чир аннан мәңгелеккә качты. Ул, чирле чебеш, горур әтәчкә әйләнеп бара хәзер. Әлеге танк мәсьәләсе ул теләгәнчә хәл ителде. Аңа данның тамчысы да кирәкми.

Яндырылган танкны комиссар батырлыгы итеп күрсәткәнгә, бу хакта гәзиттә мәкалә басылып чыкканга шатланып йөри Сәлим. Мондый макталуны ул барыбер күтәрә алмас иде. Кызарып, җир тишегенә кереп китәрдәй булыр иде. Чамаң ничек булса, бүрегеңне шулай ки ди, үзенне чамалап тоту хәерлерәк.

Тик Мәхмүтнең генә чамасын аңлый алмый ул. Кимсетелгән бәпкә кебек, һаман читтә-миттә генә йөри. Әлеге әңгәмә вакытында да, авызын турсайтып, бер як кырыйда бәлтерәп утыра бирде. Сәлимнең исә өзлексез сөйләшәсе, фикер алышасы килә. Әгәр кыз мәсьәләсендә ул җиңүче икән, хәзер инде үпкәләвенне бер пот үпкә ашап та бетереп булмас: тешеңне кыс, уртыңны чәйнә, йөрәк ярсуын сиздермә—түз; Мәрьям унлаган хатына бер җавап та язмаган икән, «яратам» дип алдавы көн кебек ачык. Сәбәпсез чебен дә канатын какмый, хат язмавының сәбәбе бар икән шул.

—Әйдә әле, Мәхмүт, сөйләшик, нигә бер дә илекмисең, монда барысы да үз кеше,—дип барды ул авылдашы янына.

Мәхмүт авызын турсайтты да:

—Үз кеше... тюремщиклар... Мулла... һм... тагы да әллә кемнәр... Җыен шалапай...

—Алай димә, Мәхмүт, бу—кеше язмышы, төрмәдә аларның нахакка, бер дә юкка утырганнары да бар...

—Һм... әйттең сүз... төрмәгә кешене бер дә юкка утырттылар ди...

—Без күп нәрсәне анламыйбыз әле...

—Монда җан кайгысы...

—Анысы шулай. Ләкин төрле язмышлы кешеләр белән бергә булу... Менә үзең белерсең әле... күнегерсең...

—Һм... күнегерсең... Шушы уттан исән чыгуыңа син әле һаман ышанып йөрисеңмени?

—Белмим. Ул хакта уйлаган юк. Минем өчен барыбер...

—Ничек барыбер булсын ди... Үләсең киләмени?..

—Куй? Мәхмүт, башка нәрсә турында сөйләшик...

—Йә, нәрсә турында сөйләшик соң?..

—Без авылдашлар, яшьтәшләр бит.

—Әллә Мәрьямне тартып алганга ачуың киләме?

—Анысы мәхәббәт эше инде...

—Теге кичәдән соң син Мәрьямне киткәнче күрмәдеңмени?

—Юк.

—Ә без икенче көнне бергә булдык. Аулакта. Мин теләгемә ирештем. Ул көтәргә сүз бирде.

Сәлим эсселе-суыклы булып китте. Шулай да кичерешләрен сиздермәскә, үзен кулга алырга, кешелеклелеген җуймаска тырышты:

—Котлыйм, Мәхмүт, син бәхетле, Мәрьям яхшы кыз, сакла үзеңне аның өчен,—дип «дустының» кулын кысты.

***

Бәхет! Кемгә кайчан, ни рәвешле килә ул? Күбәләктәй җилпенепме? Тулпардай ярсыпмы? Кояштай елмаепмы? Сайраганда сандугач узар, очканда карлыгач узар, диләр бит. «Истәлек дәфтәре» алышып, сандугачтай сайрашып йөргәндә—узган иде, үзен бик бәхетле санаган иде Сәлим. Очып китү белән карлыгач алга уктай атылды. Бәхетне шушы мәхәббәт бизмәненә салып үлчәргәме? Мәрьям язган «Истәлек дәфтәре»н юлга алды ул. Солдат капчыгының төбендә «мәхәббәт кодрәте» булып йөри. Ач вакытларда да, үлеп арыганда да, Алкин лагерында суыктан туңганда да «Истәлек дәфтәре» яшәүгә рухи көч бирде. Бәләкәй генә бу капчык эчендә гүя Мәрьям елмаеп утыра. Шуны кочакласа, Мәрьямен куенына алгандай тоела. Мең кат укыгандыр инде аны. Һәр хәрефе, һәр сүзе күнел түренә йотылган. Үзенчә «Мәхәббәт дәфтәре» дип атады аны Сәлим. Шул «Мәхәббәт дәфтәре»н хәзер үк ерткалап ыргытачак ул. Юк, утта яндырырга кирәк. Менә шушында, чит җирдә, барысы да аяк астында тапталып калсын. Чәнчелеп китсен. Бу хакта уйлап, күңелне беркайчан да күбәләкләндермәскә. Вәссәлам!

Ул йөгерә-атлый барды да, окоптагы солдат капчыгын алып, тиз-тиз чишәргә кереште. Борылмаска тырышса да, куллары калтырап тора иде аның. Менә ул дәфтәр. «Истәлек дәфтәре». «Мәхәббәт дәфтәре». Ялган дәфтәр. Ялган хисләр. Ялганга төренгән «йөрәк сүзләре». Барысы да ялган. Бөтен дөнья ялганга корылган. Барысы да алдаша. Алдый. Алдана. Сата. Сатыла. Ул, чалбар кесәсеннән шырпы алып, кабызып җибәрде. Хуш, яшьлек истәлеге! Хуш, мәхәббәт ядкаре! Әмма дәфтәр янмады. Тукта! Ни

өчен? Суланганмы әллә? Нигә ут капмый? Тагы сызды шырпыны, тагы, тагы... Менә хикмәт. Шырпы үзе үк янмый башлады. Йә сынып китә, йә кабына да сүнә. Әллә кулы калтыраганга шулаймы? Әллә, мәхәббәте, күренмичә генә, күбәләктәй очып йөриме? Шул сүндерәме? Әллә Мәрьямнең мәхәббәте монда очып килгәнме? Ут эченә. Тукта! Нәкъ шулай икән ләбаса. «Ялгышасың, Сәлим!», «Мин сине яратам!», «Нык яратам!», «Җиңеп кайт!», «Көтәм!» кебек сүзләр назлады колак барабанын. Юк, колак барабанын назлап кына калмыйча, йөрәк капкачын бәреп ачып, бөтен тәненә, кан тамырларына йөгерде Мәрьям илаһилыгыннан килгән бу назлы сүзләр сихере.

Нәрсә бу? Чынбарлыкмы? Хыялыйлыкмы? Әллә саташамы соң? Мулла бабайның теге... икенче дөнья турында сөйләгәннәре чынмы? Әллә шуның галәмәтеме бу? Мулла бабай, шул дөнья кешеләре белән сөйләшеп, очрашып торуы турында әйтә. Тик алар изге, гөнаһсыз, саф күңелле кеше белән генә эш итә ди бит. Мулла бабай—шундыйларның берсе. Ул шул тиклем күп авырлыклар, кимсетүләр, гаделсезлекләр күргән, ләкин олы йөрәкле, саф күңелле, намуслы булып калган, кешелеклелек сыйфатын бөек тоткан, кайгыларга бирешмәгән.

Сәлим үзе кем? Мулла бабай кебек нык була алырмы? Әле нинди гөнаһлар эшләп өлгерде ул? Бармы? Күпме? Әллә санап та бетергесезме? Бөтенләй юктыр, бәлки. Берәүне дә рәнҗетмәде. Урлашмады. Олыларны хөрмәт итә белде. Их, Мулла бабай кебек, ул да күңелен теге дөнья кешеләре күңеле белән бәйли алса икән! Аларга барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирер иде. Бу дөнья кешеләренә йөрәк капкачын тулысынча ачып булмый шул. Кереп оялый да корт урынына кимерә дә башлый. Иң изге хисләрең белән шаяра.

***

Фашистлар һөҗүмгә бүген дә бөтен фронт буенча күчте. Көрәш, башка көннәрдәге кебек, һәр җирдә дә тигез генә бармады. Немец бер төбәктән ерып китсә, безнекеләр аның арт ягыннан төшә башлый. Мондый очракта, чолганышта калудан куркып, алар артка чигенә. Урыны-урыны белән безнекеләрдә дә шундый ук хәл килеп чыга. Бәреп кереп китәләр дә, ятьмәгә эләккән балыклар шикелле, үзләренең камауга килеп эләккәннәрен сизмичә дә калалар. Вакыт-вакыт йодрыклашу, тешләшү чигенә дә барып җитәләр. Дошманның һөҗүмгә җыйнаган көче әнә шулай әкренләп-әкренләп кими бара.

«Самавырчыларның алты батареясе—алты урында. Бүген авырлык бастырыгы күбрәк бишенче, алтынчы батарея урынына төште. Алларындагы пехота чигенгәч, боларга тагы да фрицлар белән якалашырга, хәтта танкларга каршы көрәшергә туры килде. Беренче батареяда мәгәр андый хәл булмады бүген. Иртән, бөтен дөнья дөбер-шатыр килә башлаганда да, аларда тыныч иде әле. Дөрес, ялкау гына очып килгән снарядлар якында гына урык-сурык килеп ярылырга тора. Монсы инде солдат өчен гадәти хәл. Снаряд очып килгән тавышка солдат колагын куйса, аның кайсы тирәдәрәк ярылуын да шәйләп ала: йә килеп җитмәячәк, йә узып китәчәк. Ә инде аның «бәхетенә» килүен сизеп алса, йомран кебек, тиз генә окобына чума.

Мондый хәл—җирнең снаряд, мина, бомба ярылуыннан тетрәнүе—Сәлим белән Мәхмүтнең сөйләшеп туктаган вакытында ук башланды. Әмма дошман снарядлары, ара-тирә ярылып торсалар да, беркемгә дә әнә очы зурлыгы да зыян китермәде бүген. Батареяга да, ни өчендер, залп белән атарга команда күп булмады. Тик беренче расчетка гына тынгы бирмәделәр. Бер чәпне алгач, аттырдылар да аттырдылар. Аның нинди чәп икәнлеген сиңа берәү дә әйтми. Моны күзәтү пунктындагы комбат кына белә. Сәлим уйлавынча, комбат бүген юлга аттырды. Атулар бер урында кабатланса, ул

юл булып чыга. Аннан машиналар, транспортерлар үтеп тора. Берсе күренү белән, комбат атарга тиз генә команда бирә.

Кояш төшкелеккә җиткәндә, кыр кухнясы килде. Аны бер машина йөртә, һәр батареяга—бер кухня. Аның ике тәгәрмәче машинаныкы зурлыгында. Казан—иманеч зур. Пешерүче Галиев ашны озын саплы чүмече белән җитез генә өләшә дә китеп тә бара. Чөнки ана монда озак торырга ярамый. Ана командирлар да рөхсәт итми: пешерүче дә, әлеге иманеч зур аш казаны да, бу казанны сөйрәп йөртүче машина да, аның шоферы да күз карасыдай кадерле.

Төш вакытында Җир-Ананың үкереп елавы бертиклем тынып торды. Немецлар да, бәлки, тамак ялгарга утырганнардыр. Алар—төгәл халык. Вакытында эшләп, вакытында ял итеп, вакытында күнел ачып яши торган бәндәләр. Ә менә бөтен дөнья халкын вакытсыз мазасызлаулары—акылга сыйгысыз.

Ничек кенә булмасын., безнекеләр, бу ут кулчасыннан тизрәк котылып, алга ыргылуны яхшырак күрә. Тегермән тик торса, ташы ярылыр, дигән борынгылар. Бу ут эчендә берәүнең дә әйләнми торган тегермән ташы буласы килми.

Бүген, төштән соң, барысы да тынып калды. Кисәү сабың кыска булса, кулың көяр ди. Гитлерчылар куллары көюдән туктап калдылар, күрәсең.

Солдатлар тагы да бер иркен тын алып куйды. Ә инде күзәтү пунктыннан комбатның телефон аша беренче расчет төбәүчесе сержант Пирмөхәммәтовка тагы да рәхмәт белдерергә кушуы бөтен батарея өчен шатлыклы хәл булды. Беренче расчет аткан мина бүген дошманның ике хәрби транспортерын, өч машинасын, егермеләп солдатын сафтан чыгарган.

Сәлимне башта лейтенант Харисов белән кече лейтенант Тарасов килеп котлады. Солдатлар күтәреп үк чөйделәр хәтта. Уймин, һаман шул тупас гәүдәсен уйнаклатып, мактанып йөрде:

—Вот... понимаешь... что значит... моя забота... Я воспитал его... Я научил...—дип мыгырданды.

Үзбәк егете Шәрип, чуаш егете Николай, төрекмән егете Нурмөхәммәт, мулла бабай, тагы да әллә кемнәр аның кулын кысты. Һәрберсе нindiдер җылы сүз әйтергә тырышты:

—Менә сина «чирле чебеш»...

—Юаштан юан чыга...

—Күрсәтер әле ул...

—Таутөмәндә дә шәп аткан иде бит...

—Моны юганда шәп булыр иде дә...

Сәлим җавапсыз калмады:

—Ә мин сезне бәрәнге белән сыйлыйм,—диде дә чиләк алып йөгерде.

***

Түгәрәк ясап, бәрәнге ашап утырганда, уң яктан бер кызның үтеп китүе күренде. Ул солдат киемендә. Кызлар монда сирәк очрый. Әгәр күренсә, солдатлар «рама», «воздух», «шрапнель»...—тагы да әллә ниләр әйтеп, кычкырып калалар. Бу юлы алай дип әйтмәделәр. Чөнки сүзне кече лейтенант Тарасов башлады:

—Әйдә, безнең белән бәрәнге ашарга,—дип кычкырды.

Кыз артык кыю булып чыкты, күрәсең:

—Ә син килеп ал,—дип җибәрмәсенме.

Тарасов нишләргә дә белми аптырап калды. Солдатлар:

—Барыгыз...

—Котә бит...

—Алып кил монда...—диешкәч, сикереп торып, китеп тә барды.

Алар әллә кайчангы танышлар кебек күрештеләр. Солдатлар, бәрәңге турында бөтенләй онытып, күзләрен тозландырып, тын да алмыйча, аларга карап катты. Алар озак сөйләшмәде. Бер-берсенең күзләренә карашып, кулларын тотыштылар да аерылыштылар.

Әйләнеп килгәндә, кече лейтенант бөтенләй башка төс алган иде: ул, әйтерсең, мәңгелек бәхет кошын эләктергән—шат, елмая, күзләре нур чәчә. Ул ярсып-ярсып кызны мактарга керешә. Күзләре, имеш, зәңгәр һава төсле, иреннәре—пешеп тулышкан чия, карашлары серле, ягымлы, кыскасы, дөньяның бер чибәре инде. Бер күрешүдә гашыйк булганнар, янәсе. Бу дөньяга бер-берсе өчен туганнар.

—Һи, сезнең белән сөйләшеп тә тормады бит ул, ятчә урынына тып-тып басып китте дә барды,—диде бер солдат.

—Без күз карашлары белән аңлаштык, сүзләргә урын юк монда,—диде кече лейтенант.

—Ә ул очып киткән мәхәббәт белән нишләмәкче буласыз?

—Очмас, ул штабка ашыга, ниндидер хәрби задание белән, бер сәгатьтән кире кайтачагын әйтте. Вообщем... беренче мәхәббәт өчен,—диде дә кече лейтенант, бәрәңге кабып җибәрде.

## XV

Унбишенче июльдә дә көн дә була торган хәл кабатланды. Кызарып кояш чыкты. Алсу-кызгылт нурларын фронт кырына сипте. Иртән ике яктан да юньле атыш булмады.

Ә кече лейтенантның тәүге мәхәббәте килмәде. Кичә дә. Бүген дә. Тарасов бөтенләй башка кешегә әверелде. Ул, бәлки, кичерешен башкаларга сиздермәскә тырышадыр. Ләкин аның үз-үзен кая куярга белмичә йөрүе, үзен-үзе өзгәләп ташлар чиккә җитүе, теге очрашкан урынга барып-барып килүе, авыр тын алуы... барысын да хәлне аңлатып тора. Хәзер инде аны берәү дә шаяртмый. Киресенчә, һәркем теге Чибәркәйнең тизрәк килүен, кече лейтенантның янган йөрәге басылуын тели.

Монда бит төрле кешеләр бар. Берәү дүрт бала белән калган яшь хатынын сагына. Икенчесе өйләнгәч бер ай торып кына китеп барган. Өченчесе менә иртәгә ЗАГСка барам дигәндә генә сугыш чыккан. Көтешергә вәгъдә бирешеп аерылышканнар да күп. Кыскасы, мәхәббәт һәркем өчен кадерле, кыйммәт, көрәшкә дәрт бирүче бөек көч. Шуңа күрә кече лейтенантның кичереше уртак кайгыга әйләнеп китте. Ул балалар йортында тәрбияләнеп үскән. Ата-ана назы татымаган. Моны һәркем яхшы белә. Фронтка киткәнче берниндн кыз белән дә йөрмәгән. Боларның барысын да сөйләгән иде ул. Бәлки, үзенә лаеклы пар таба алмагандыр. Кече лейтенантның егетләр солтаны икәнлеге бер карауда ук аңлашыла. Чибәр. Очкын чәчеп торган күзләр. Зифа буй. Өзелеп торган бил. Кыскасы, теләсә нинди матур кызны бер карауда гашыйк итәрлек егет ул.

Сәлим үзен кече лейтенант урынына куеп карады. Аның кебек була аламы ул, юкмы? Мәхәббәт аның йөрәгенә дә шулай көчле тәэсир итәме? Әллә аның йөрәге менә шушындагы ут шары кебек кайнар түгелме? Котып бозы салкыны бармы? Әллә ул мәхәббәтнең ни икәнлеген аңлап та бетермиме?

Әлбәттә, бу уйлар баштан яшен тизлегендә үтеп китә. Уйлар давылына кереп адаша торган урын түгел бу. Аңа ирек тә бирмиләр. Тагы да атарга команда булды. Тагы да җирдә дә, күктә дә көчле алыш башланды. Дошман тагы да контрһөҗүмгә күчте. Фашист козгыннары, тезелеп-тезелеп килеп, батарея өстенә бомба коярга керешә. Солдатлар, окопларга сеңеп, тагы да Җир-Ананы кочаклап яттылар. Шөкер, кешеләргә зыян килмәде. Тик

атлар окобына гына бер бомба туп-туры төшкән иде. Малкайлар да, арбалар да күккә очкан.

Монсы яна мәшәкать тудырды. Ярлының икмәге бар—тозы юк, тозы бар—икмәге юк дигәндәй, миномет бар—аны ташырга арба юк, арба бар—ат юк. Алар дошман бомбага тоткан вакытта харап булып бетте. Кичкә табан безнекеләр, дошманның контрһөҗүмен кире кагып, үзләре бер тиклем алга китте. «Самавырчы»ларга да ут позициясен алыштырырга кушылды. Солдатларга төне буе бөтен хәрби техниканы күтәреп ташырга туры килде. Иртәнгә полкка тагы да артиллерия башлыгы генерал-майор Полуэктов килеп житте.

—Сез бит солдатларны ишәк урынына жигеп, моннан соң хәрби техниканы күтәреп ташытмаска сүз биргән идегез, нигә вәгъдәгезне бозасыз?—дип жикеренде генерал.

—Ул немец самолетларын бомба ташларга мин үзем чакырып китермәдем бит, иптәш генерал-майор,—дип акланмакчы булды полк командиры.

Бу жавап ачудан шартлап ярылыр чиккә житкән генералны котыртып кына жибәрде. Билгеле, күркә урынына кабаруда да, шартлап ярылуда да, соңгы чиктә үзен-үзе чагып үтергән чаян кебек кылануда да бер хәсият тә юк. Генерал салкын кан белән анлату юлына басты:

—Алтынны табу гына житми, аны эшкәртә белергә дә кирәк, майор. Немецларның артиллеристлар, минометчылар өстенә һәрвакыт бомба коеп торганлыгын беләсез, ә атларны ут позициясе янында тотасыз икән. Ездовойлар эше нидән гыйбарәт? Шуннан: ул хәрби коралларны китереп куйды яңа урынга, бушаттыгыз; атыш вакытында тормасыннар алар якында. Китсеннәр дә барсыннар артка табан, өч-дүрт чакрым ераклыкка; атларын карасыннар, ашатсыннар, эчертсеннәр, тәрбияләсеннәр; кирәк булганда, чакырдың алдың...

—Моннан соң сез кушканча булачак, иптәш генерал-майор!

Сезгә барысын да чәйнәп каптырырга кирәк, майор, инициатива дилбегәсен кулыгызга алмасагыз, лейтенант званиесенә төшереп, мин сезне взвод командиры итеп куячакмын. Югарыдан түбәнгә төшү бик жиңел ул, ә менә югарыга күтәрелү...

—Так точно, иптәш генерал...

—Кыланма, майор, кирәкми. Полк белән командалык итү—землянкада хатын-кыз белән сөешеп яту түгел ул...

Генералның бу сүзләре майорның йөрәгенә тагы да хәнҗәр белән китереп кадагандай тәэсир итте. Артиллерия башлыгы китеп баргач та озак кына акылына килә алмыйча торды ул. Погонына теге вакытта да кизәнгән иде. Бүген дә лейтенант дәрәҗәсенә төшерәчәкне искәртте. Ә бит, төптәнрәк уйласаң, дөрес әйтә. Чынлап та, атларны ут позициясе янында тотарга ярыймы соң? Шуны гына уйларлык та баш юкмыни соң анда? Шушы вак мәсьәлә буенча батарея командирлары, башкалар фикер йөртә алмыймы? Күбесе авылдан килгән, ат белән эш итеп күзләре чыккан крестьян баласы бит юкса. Барысына да полк командиры гаепле имеш. Хәтта полк комиссары капитан Соколовның үлеме өчен дә аны жавапка тарттырырга маташалар бит.

Анысы болай булды. Ике ГАЗ машинасы белән алар корпус штабына киттеләр. Беренчесендә—шофер Сафин, икенчесендә—Мәүлиев. Сафин янында—полк командиры. Мәүлиев янында—Соколов. Әржәдә полк радисты Фарукша Жиһаншин, полк командирының адъютанты Дуля, разведчиклар, элемтәчеләр, телефончылар, берничә офицер бар иде.

Кайтканда полк командиры туры юлдан Рогозинка авылы аша китәргә кушты Сафинга. Авылга якынлашып килгәндә,юл буендагы солдатлар:

—Куда вы?... Вернитесь...

—Там немцы...—дип кычкырып калдылар.

Иртән генә ул авылны безнекеләр алган иде. Солдатлар шаярта дип уйлады командир. Әрҗәдәгеләр дә шул фикердә иде. Корпуста алган хәрби заданиене тизрәк подразделениеләргә җиткерергә кирәк! Машинаны шуңа нык куарга кушты майор. Пәри арбасы урынына чапты машина. Тәгәрмәчләре тигән урынга тия, тимәгән урынга—юк. Аңсыз күбәләк ут ялкынына шәйләми барып эләккәндәй, болар да турыдан-туры ут авызына барып каба язды. Баксаң, Рогозинка авылы янә немецлар кулына күчкән булып чыкты. Моны фрицлар пулеметтан көчле ут ачкач кына белделәр. Әгәр немец моны эшләмәсә, ике машина тулы кеше полк командиры белән бергә әсирлеккә төшәсе.

Ә төшкәннәре булды. Немецлар капитан Соколовны, ике лейтенант һәм берничә солдатны эләктереп алдылар. Адъютант Дуля, өч офицер, берничә солдат җирдә мәңгелеккә күзләрен йомды. Полк командиры үзе дә чак кына эләкми калды. Бер пуля хәтта аның фуражка козырегын тишеп чыкты. Бу бәладән ул үзе, шофер Сафин, радист Җиһаншин, тагы берничә солдат кына котылып кала алды.

Икенче көнне Рогозинка тагы да безнекеләр кулына күчте. Капитан Соколовның үле гәүдәсен бер курадан таптылар. Ул, күрәсең, берниндн дә серне ачмаган, тез чүкмәгән. Фашистлар аны нык җәзалаганнар: ике күзен чокып алып, күкрәгенә кызган тимер басканнар, тәнен штык белән телгәләп бетергәннәр...

Шулай итеп, командирның бер акылсыз адымы күпме кешенең башына җитте. Ябык йөз, эчкә баткан яңаклар беркайчан да полк командирының күз алдыннан китмәячәк. «Син харап иттең мине, кибәк баш, таш йөрәк»,—дип рәнҗеш яудырып торачак. Акылсыз кыюлык фаҗигасе...

***

16 июль. Табигатьтә һаман әле бер үзгәреш тә юк. Шул ук алсу таң. Кояшның шул ук уттай кызарып чыгуы. Яугирләр тормышы да—бертөрле. Яңа урынга күчү. Яңа окоплар казу. Төне буе керфек тә какмау. Барысы да җиренә җиткерелгәч, таң алдыннан черем итеп алу.

Балыкчы күлен мактый, көнлекче көнен мактый дигәндәй, урыны да яхшы туры килде бүген, көне дә матур. Ут позициясе алдында—артык текә булмаган калкулык. Анда—яңа гына үсеп килгән яшь агачлар. Дөрес, алар да, бахыркайлар, сугыш фаҗигасен шактый нык татырга өлгергәннәр: тирә-якларында бомба һәм снарядлар ярылуыннан хасил булган чокыр-чакырлар; яфраклары көеп беткән, һәр нәрсә монда зур афәт булуы турында сөйләп тора. Шулай да урынны яманлап булмый. Уң якка табан тар гына сукмак китә. Бераз баргач—әрәмәлек. Анда бәләкәй генә—тургай тезен күмәрлек кенә—инеш. Андагы зирек, тал агачлары да сугыш ялкыныннан көеп беткәннәр. Әмма инеш, бу фаҗигадән тизрәк котылыйм дигәндәй, ага бирә. Су солдат өчен аеруча кадерле. Форсат табылса, рәхәтләнеп бер юынып аласың; чәй кайнатырга, бәрәңге пешерергә дә була.

Бүген дә, кичәге кебек, иртә бик матур да, тыныч та булды. Лейтенант Харисов, минометларны тикшереп чыккач, бер урынга барып, хат язарга утырды. Тик кече лейтенант Тарасовның гына йөзе бүгенге кояшлы көнгә һич тә охшамаган. Башка вакытта, берәр мәзәк сөйләп булса да, солдатларның күңелен күтәреп китәргә ярата иде ул. Ә бүген балтасы суга төшкән кешедәй йөри бирә. Яугирләр белә моның сәбәбен: теге чибәркәй килмәде. Бу хакта солдатлар төрлечә фикер йөртте:

—Дурак безнең кече лейтенант...

—Ниндидер тишекле бер тиен өчен...
—Тапкан вакытын...
—Мәхәббәт бит ул, егетләр!..
—Әйе, анын өчен ут ни, чурт ни...
—Бәлки, ул кыз бомба астына...
—Тфү, яратмыйм начарга юраучыларны...
—Соң, сугыш бит ул, жанкисәккәем...

Ат әйләнеп, казыгын табар, су әйләнеп,юлыгын табар, кыз әйләнеп, егетен табар ди. Теге чибәркәй кояш биш-алты дилбегә чамасы күтәрелгәндә килеп чыкмасынмы: әллә күктән төште, әллә жир астыннан калыкты. Беренче миномет окобында көйрәтеп утыралар иде. Килде дә басты окоп читенә. Фәрештәдер бу. Адәми заттан түгелдер. Ул буе, ул көләч йөзе, ул чибәрлеге. Әйтерсең, дөньядагы иң матур чәчәкне өзеп алды да Ходай Тәгалә, боларның окоп читенә китерде дә кадады. Солдат киеме ничек килешә үзенә! Аякта көзгедәй ялтырап торган хром итек. Өзелергә торган нечкә бил. Күпереп торган чәч өстендәге пилоткасы менә-менә очып китәр кебек. Әмма ул селкенми дә, шултиклем ипле утыра, гүя кызның ихтыярына нык буйсынып тора.

—Кече лейтенант Тарасов кирәк иде,—диде ул, ягымлы күз карашлары белән солдатларның әле берсен, әле икенчесен коендырып.

—Алар икенче батареяга киткәннәр иде бит әле...

—Ала-а-й... Ярый... гафу итегез...—Кыз, кырт борылып, китә үк башлады.

Аның юлын Иргалин бүлде:

—Аз гына көтегез. Кече лейтенант сезнең өчен...
—Минем вакытым бик тар шул...
—Икенче батарея моннан ярты чакрым гына, хәзер барып әйтәм...
—Юк, юк, кирәкми, кичкә табан үзем тагы сугылырмын.
—Күчеп китсәк?
—Табармын.
—Уй, әнә киләләр, лейтенант Харисов белән.

—Рәхмәт сезгә! Гафу итегез!—диде дә аларга каршы юл тотты кыз. Ул киткәч, солдатлар янә телгә килде:

—Ну, чибәр, әй...
—Балкашыкка сал да йот.
—И-и-х!.. Миңа булса...
—Сагызак бу. Үзе эзләп йөри.
—Тфү, тел синдә...
—Мәхәббәт бөтен ваклыклардан бөек. Вәт.
—Яратсаң, сагызак кына түгел, укра булырсың.
—Ха-ха-ха...

Кыз йөгерә-атлый барды тегеләр каршысына. Барып житкәч, Харисов алардан аерылып китте. Солдатлар, күзләрен талдырып, бу икәүнең култыклашып әкрен генә атлавына сокланып карап торды, һәркем эчтән генә кече лейтенантка зур бәхет теләде. Мәхәббәт бәхете! Мәңгелек бәхет! Кем белә: шушы ут эчендәге мәхәббәт—иң изге мәхәббәттер, бәлки.

Моның шулай икәнлеген аларның икесенең дә чырайлары ук әйтеп тора иде. Окоп янынннан үтеп киткәндә икесенең дә шатлыктан балкыган йөзләре күренеп калды. Хәтта ике якта да атыш тавышлары да ишетелми бүген. Шушы мәхәббәт хакына Аллаһы Тәгалә ике якның да кулын тотып торамы әллә?

Менә алар әлеге инеш янынннан сузылган сукмакка барып житте. Кулларын тотышып, бер-берсенә карашып калдылар. Чү! Их, фриц!

Ләгънәт төшкере! Аз гына сабыр итсәң ни булган соң инде? Күпме мәхәббәт чылбырын өздең син. Хәзер боларныкына да кыжрыйсыңмы? Жир йоткыры нәрсәкәйләр. Тагы да ут ачтылар. Бер-бер артлы снарядлар килеп ярыла башлады. Кече лейтенант, кызны җитәкләп, окопларга табан йөгерде. Ләкин аларның юлын очып килеп ярылган снаряд бүлде. Икенче снаряд аларның артында ярылды. Кече лейтенант, кызны яшен тизлегендә җиргә егып, аны гәүдәсе белән каплады. Тагы да берничә снаряд килеп ярылды да барысы да кинәт туктап калды. Контрһөҗүмгә күчкәндә болай булмый. Ату сәгатьләр буена сузыла. Берничә снарядны немец «төшереп» алганда да җибәрүчән. Яки ана пушкасын сынап карарга кирәк була. Моның шулай икәнлеген һәр солдат аңлады. Тик... тегеләр... икеседәме?.. Нигә тормыйлар?..

Йөгереп барсалар, кече лейтенант үлем белән көрәшеп ята иде. Бер снаряд ярчыгы аның маңгаена тигән. Икенчесе муенын өзеп чыгара язган. Күп тә үтмәде, зәңгәр һавага соңгы мәртәбә карап, кече лейтенант җан бирде. Аны шунда җирләделәр. Кыз, кабер өстен озак кына сыпырыштырып утыргач, китеп барды.

Бер уйласаң, күз ачып йомган арада булган мәхәббәт бу. Икенче яктан карасаң, мәңгелек мәхәббәт! Ләйлә—Мәҗнүн, Таһир Зөһрә, Йосыф Зөләйха мәхәббәтләре бар. Күпме газаплар, кичерешләр, авырлыклар аша килгән мәхәббәт алар! Болар Җиргә, Күк йөзенә, Кешеләр күңеленә мәңгелеккә язылып калган илаһи мәхәббәтләр! Ә бу мәхәббәт? Ул да мәңгелек! Җиргә, Күк йөзенә, кешеләр күңеленә язылып кала торган мәхәббәт!

Сугыш, ачлык, йокысыз төннәр—берсе дә җиңел түгел. Әмма фронтта иң авыры—кеше җирләү. Өч-дүрт тәүлек эчендә генә дә күпме яугир корбан булды. Берлинга барып җиткәнче һаман шулай адым саен кеше күмеп йөрерләрме алар?

Тарасовның үлеменә һәр солдат үзенчә бәя бирде:

—Ялгышты кече лейтенант...

—Бер кыска итәк өчен...

—Аңламыйсыз. Егетлек күрсәтте...

—Мәхәббәт бит ул...

—Тфү!—дип төкеренде Мәхмүт, Сәлим белән бер сөйләшкәндә,—арагызда адәм рәтле бер кеше бар дисәм, ул да алабарман булып чыкты.—Сәлим эндәшмәде. Ул бөтенләй башкача уйлый иде. Әгәр, әйтик, Мәрьям шундый хәлгә тарыса, Мәхмүт аны гәүдәсе белән каплап коткармас иде микәнни? Шундый кыска мәхәббәт өчен гомер бирү—бу бит чын егет эше! Бу олы йөрәклелек, батырлык, кешелеклелек! Мәрьям алдында үзен чын кеше итеп күрсәтү өчен теләсә нинди авырлыкка барырга әзер тора Сәлим. Кирәк икән, үлемгә дә. Чын мәхәббәткә лаек икәнлегеңне күрсәтү—егет өчен иң зур горурлык ул!

***

Ике яктан да ут давылы бер-берсенә килеп бәрелеп кенә тора. Бәрелә дә шартлый. Бу шартлауда меңләгән кешеләрнең гомерләре өзелә. Шул гына. Бары шул гына. Гитлер армиясе һаман көнчыгышка ыргыла. Безнекеләрнең сукыр тычкан кебек җир куенында сеңеп ятуларына аптырый ул: моны, билгеле, үз файдасына юрый—дошман гаскәрләренең каешы тәмам бушады, контрһөҗүм ясар рәтләре юк дип уйлый, хәзер, дуганы сындырып, Мәскәүгә йолдыздай атылу өчен иң кулай вакыт, һәркөн шулай дип теш ыржайта җирән хәшәрәтләр. Шулай уйлап, давылдай кубып, ут төкерә-төкерә, җир куенында яткан «сукыр тычканнарны» изеп китәргә килә. Бу «сукыр тычканнар», җир куеныннан дәррәү күтәрелеп, ут күзле арысланга әвереләләр дә, тешләрен ыржайтып, каршы алалар тегеләрне. Айгыр малга

ни житә, йөри белгән кешегә, туган илгә ни житә, кадерен белгән кешегә ди. Туган жирнең һәр карышы кадерле. Аны хәзер берәүнең дә ерткычлардан тапатасы килми. Бер йортка ике бикәнең тавыгы да сыймас ди. Нишләп әле бер жирдә ике дошман илнең жан ияләре сыешып яшәргә тиеш?

Бу хакта уйламыйдыр фашист. Уйласа, баш ватса, сөмсез сыер кебек, үләсен белмичә, яман канлы борынын сузып маташмас иде. Бүген тагы да көне буе маза бирмәде. Көрәш бөтен фронт сызыгы буенча барды. Ләкин ике яктан килеп кушылган утлы давыл бер-берсе эченә кереп югала торды. Ике яктан да алга китеш булмады. Жир-Ана күкрәге тагы да корбаннар белән түшәлде. Корбаннар беренче батареяда да шактый күп булды. Тагы да көне буе аттылар. «Самавыр» торбасы ут кебек кызды. Көне буе эссе кояш көйдерде. Солдат гимнастеркасы манма су булды. Ана дары исе, тузан сеңгән. Бүген дә төнлә ял итәргә ирек бирмәде фриц. Әҗәленә жилкенә, күрәсең. Атты да атты. Атакага күчеп маташты бугай. «Сукыр тычканнар» төндә, окопларына сенеп, тирән йокыга чумганнар дип уйлаганнардыр инде.

Максатлары төндә тапап, изеп, сытып китү булган.

Монсы бер хәл әле. Ин үкенечлесе—икенче миномётнын ярылуы. Күбрәк беренче расчет атты. Аннан соң берәм-берәм атарга да команда булды. Әллә ничә тапкыр бөтен батарея залп белән дә атты. Әнә шул залп белән атканда, икенче миномётның минасы ачылмый калган. Моның сәбәпләре күп була ала: йә мина дискыга килеп терәлмәгән, йә төзәүче шнурны минаның капсюлена тиярлек итеп тартмаган...

Төн караңгы иде. Чөнки сәгать берләрдә болытлатып жибәрде. Икенче миномёт үзе генә атса, көбәктән чыккан утны күрерләр иде. Ә инде бөтен батарея залп белән аткач, берәү дә шәйләми калган: минаның атылмаганын белмиләр.

Залптан соң янә берәм-берәм атуга күчтеләр. Менә беренче миномёт очырды минасын. Мина көбәктән чыгып киткәндә ут көлтәсе бөркелә, жир тетрәгәнен хәтерләткән иманеч көчле тавыш янгырый. Шуннан соң икенче миномётка атарга команда булды. Сәлим йөгереп алар янына барды. Нигә бардымы? Моны ул үзе дә белми. Нindидер инстинкт китерде инде әллә? Атканда аларның плитәләре ничек тора икән, көбәк нык дерелдәмиме—шуны күзәтергәдер, бәлки. Менә ул окоп читенә барып басты. Менә коручы минаны көбәккә салды. Менә төзәүче Баранов, йөгереп барып, шнурны тартып жибәрде. Менә миномёт... ярылып та китте. Монда инде ут көлтәсе генә түгел, зур ут шары хасил булды, һәр мина—уналты кило. Ике мина—утыз ике кило. Алар 360 килолы миномётны он-талкан иттеләр.

Атарга команданы Харисов ерактан, алтынчы миномёт яныннан биреп тора иде. Бу көчле шартлауга башкалар да, Харисов та әллә ни игътибар итмәгән. Хәер, әзме-күпме вакыт эчендә колаклар көчле шартлау ишетүгә күнегеп беткән инде. Харисов аткан вакытта нindидер «саташкан» снаряд килеп төшеп ярылган дип уйлаган. Берәү дә килмәгәч, Сәлим Харисов янына йөгерде:

—Икенче миномёт ярылды, иптәш лейтенант!

—Булмас ла...

—Үзем шунда идем...

Килеп карасалар—миномёт та юк, расчет та юк. Мина ташучы бер молдован егете генә исән калган иде. Ул да нык яраланган. Аны кыр госпитаtable озаттылар. Уннан артык яугир һәлак булган иде.

Мондый вакытта сәбәп эзләүчән булалар. Ни өчен ярылган миномёт? Кем гаепле? Жил исми, яфрак та селкенми дигәндәй, сәбәпсез берни дә булмый, билгеле. Мәрхүмнәрне гаепләү килешми. Шулай да монда төп гаеп—төзәүче Барановта, мөгаен, Таутөмәндә чакта ук аны «алабарман» дип

йөрттеләр. Хәтта «разгильдяй» дигән сүзне дә ишетергә туры килә иде аңа. Яхшылап каешын буып, пилоткасын да дөрес кия белми иде ул. Ачулануга, сүгенүгә дә, тиргәүгә дә беркайчан да исе китмәде. Җаваплылык тойгысы, кешелеклелек сыйфаты да анда чамалы гына иде. Белеме булган өчен генә аны төзәүче итеп куйдылар. Хәзер инде ялгышканлыкларын аңладылар. Ләкин—соң. Үзе дә харап булды, уннан артык кешенең дә башына житте, бахыр.

Төлке алып киткән тавык өчен чүл бүресен каргаган кебек, бер гамьсез солдат кылган дуамаллык кәсафәте ахыр чиктә тагы да полк командиры башына төшә: дүрт-биш көн эчендә алты миномет ыгыз шартлады, Берлинга барып житкәнче берсе дә калмаячак, полкны таркатырга кирәк, дип жанга тияләр.

Әгәр кешенең ике колагына берьюлы ике кеше сөйләсә, ул берсенекен дә аңламыйча калырга мөмкин. Фронтта, тылдагы кебек, шулай ит тә болай ит дип адым саен бармак белән төртеп күрсәтүләр булмаячак, һәр командир үзе белеп эш итәргә тиеш, диләр иде. Ләкин һич тә алай булып чыкмады. Полк командирының бер колагына бишенче армия командующие генерал-лейтенант Жадов өрә, икенчесенә—армиянең артиллериясе белән командалык итүче генерал-майор Полуэктов. Миномет ярылган саен, алтын югалткан кеше кебек куркып, полкка бу ике генерал да ярсып килеп житә. Алар инде һәр подразделениегә барып тормый. Тәртип юк, оешканлык та юк, солдатларны бер нәрсәгә дә өйрәтмәгәнсез, жебегәннәр, камыр кебекләр, дип сүгеп китәләр. Әгәр полк минометы кебек катлаулы техниканы өйрәнү өчен нибары ике ай бирелү, егерменче апрельдә инде Таутөмән станциясеннән төялеп китү, солдатларның йә бик яшь, йә бик карт, кайсыларының төрмәдән алынган булуларын әйтсәң, тыңларга да теләмиләр: юк-бар сәбәпләр табып маташу иң булдыксыз командир эше дип кенә ябалар авызыңны...

***

Дошман контрһөҗүмне бишенче июль көнне башлаган иде. Нык башлады. Каты башлады. Ул хәтта психологик атакага күчте. Бер төркем самолет бомбаларны борчак урынына коеп китсә, икенче төркем очып килеп, әллә нинди тимер-томыр, мичкә, рельска охшаш нәрсәләр ыргытып жанга тия. Алар мең-миллион аждаһа ажгырган тавышлар чыгара-чыгара коела жиргә. Әлеге мичкәләр ут шарына әверелә. Кеше үтерү, кеше куркыту өчен ни генә эшләми бу фриц.

Безнекеләр вакытлыча чигенергә мәҗбүр булды. Әлеге һава пәриләре «хейкелләр», «костыйльләр», «юнкерслар», жир аждаһалары «тигрлар», «пантералар»дан куркып түгел, ә бәлки төп көчне саклап калу өчен. Бу чигенүне дошман чынга алды, гел шулай булыр дип уйлады. Башларын артык нык алга сузганнар иде, безнекеләр аларның маңгайларына китереп бәрде. Ә хәзер, ныклы контрһөҗүм ясап, бу ут шарыннан чыгып ычкыну өчен, немецларны башта әнә шул бишенче июльдә һөҗүм башлаган урыннарына китереп кысрыкларга кирәк. Бу, билгеле, жиңел эш түгел. Чөнки аларның арттагы обороналары әллә ничә жирдә. Алардагы тирән окоплар, траншеяләр, пулемет оялары, блиндажлар, землянкалар кат-кат тимер-бетон белән ябылган хәтта. Боларны снаряд та, мина да жимерә алмаска мөмкин. Бомба килеп төшсә, актарып ыргыта, әлбәттә. Маршал Жуков боларның барысын да искә алды. Давай, давай, тизрәк, һөҗүмгә күчегез дип кыстамаска булды ул. Әүвәл әкренләп дошманны әнә шул быел башлаган урынына китереп терәргә, аннан соң, бөтен көчне туплап, сыртларын бик нык каезларга да, тәвәккәлләп, көнбатышка юл тотарга.

Маршалның бу планы барлык подразделениеләргә житкерелде, һөжүм башлану көне унжиденче июль.

«Самавырчылар» өчен бу көн бик шәптән булмады, әлбәттә. Дөрес, атлар, арбалар, бричкалар һаман табылып тора. Тик барлы-юклы машиналарны йөртер өчен ягулык юк: «Әни, ярма булса, ботка пешерер идек, май юк»,— дип әйтте ди бер бахыр бала ачлык елны. Шунын кебек булды инде бу.

Беренче батареяның хәле тагын да мөшкелрәк иде. Көндез кече лейтенантны, төнлә икенче расчет яугирләрен жирләү барысын да тетрәндерде. Дөрес, кеше күмү табигый бер хәлгә әйләнеп киткән иде инде. Беренче көнне йомшак күнелләләрнең керфек очларында яшь бөртекләре күренгәләде. Аннан соң күңелләр таш кебек катты. Кеше күмү—бәрәңге күмү белән бер. Күпләре әле күмелү бәхетенә дә ирешмиләр. Чөнки каты бәрелеш вакытында бу мөмкин түгел. Эссе көнне кеше дөньяга сасы ис таратып ята. Дөрес, жир өстендә берәү дә калмый, күпмедер вакыттан барысы да жирләнә. Моның белән шөгыльләнүче махсус кешеләр бар. Әмма, күпме генә таш күнелле булырга тырышма, фронтташ дустан аерылудан да авыр кайгы юктыр. Беренче расчет белән икенче расчет бигрәк дуслашып беткән иде. Бертуганнар кебек. Хәтта тапканнарын бергә бүлеп ашый башладылар. Расчет командиры Бөре шәһәреннән иде. Кешелекле, сабыр холыклы, тәртипле иде. Тик төзәүчесен генә тәрбияли алмады. Бөкресе кабердә генә төзәлер инде мәрхүмкәйнен. Уннан артык кешене бер чокырга сузып салдылар да, күмделәр дә куйдылар. Бар иде расчет—хәзер юк инде. Бар иде кешеләр—хәзер юклар инде.

Иртән, унжиденче июль көнне, һөжүмгә күчәсе билгеле булгач, төнлә тагы да юньләп йокламадылар. Комбатлар күзәтү пунктыннан үз батареяларына минометларны, миналарны яхшылап тазартырга, ут позициясендә идеал тәртип булдырырга, солдатларны ял иттерергә боердылар. Болар взвод командирларына житкерелде. Алар алда торган житди бурычны расчет командирларына әйттеләр. Бушка әйләнгән тегермән ташы тиз ярыла дип сөйләнә иде һаман бер урында таптанганны килештермәгән солдатлар. Димәк, бушка, файдасызга әйләнү вакытлары үтте, хәзер алга, фәкать алга барасы...

Бу көнне дә кояш уттай янып килеп чыкты. Нурларын ике якка да тигез сипте. Фани дөньяда кояштан да гаделе юктыр. Ул кешеләрне дуска, дошманга аермый. Кайчан бөтен цивилизация шушы житди мәсьәләне аңлау дәрәжәсенә күтәрелер икән? Кая инде аңлау. Башта, каныгызны тагы да калтыратыйк әле дигәндәй, фашистлар ут ачты. Ярты сәгатьтән артык окоп тирәләрендә снаряд, миналар ярылып торды. Аннан соң һава козгыннары килеп, бомба яудырып киттеләр. Танклар һөжүмгә күчте. Димәк, янә аларның контрһөжүме башланды. Нишләргә? Килгәннәрен көтеп торыргамы? Юк инде: көн дә берүк төрле кәмит ялкытты. Бу һаман шул тегермән ташының бушка әйләнүе белән бер. Әмма безнекеләрнең тегермән ташы шәп әйләнде бүген. Он түгел, ут чыгып торды аннан. Немецлар күтәрелү белән тотынмасыннармы болар атарга. Дөньяны ут чолгады. Бу ут эчендә кояш үзе дә кечерәеп, югалып калды хәтта. Ату сәгать буена сузылды. «Катюша»лар уйнаганда жир тетрәп торды. Аның снарядлары ярылганда ике планета бер-берсенә килеп бәрелгәндәй тоела. Моның тавышы ун чакрым жиргә дә коточкыч булып ишетелә. Күккә күксел төтен катыш ут шары күтәрелә. Безнең самолетлар да бүген, меңләгән күк пәриләре үкергән тавыш чыгарып, очып-очып киләләр дә өсләренә бомбаларны борчак урынына коя бирәләр. Танклар да, горур арысланнарны хәтерләтеп, алга ыргылдылар. 469нчы миномет полкы ярдәм иткән 95нче подразделение кузгалды һөжүмгә, көчле «ура!» тавышлары башкаларны

да алга дәртләндерде. Бу инде безнекеләр өчен чын мәгънәсендә һөҗүмгә көчү иде. Командирлар, солдатлар арасында төрле шатлыклы сүзләр яңгырады:

—Буа ерылды...

—Ут шары шартлады...

—Дуга сынды...

Артиллерия һәм минометлар атышын генерал-майор Полуэктов ныклап күзәтергә булды. Бүгенге һөҗүм әле киләчәк зур һөҗүм өчен репетиция кебек кенә. Тышкы яктан караганда, барысы да әзер сыман тоелса да, һәр подразделениедә китек-митек яклар менләгән. Маршал Жуков аларның барысын да белеп бетерми. Әмма зур контрһөҗүмгә көчүгә әзер түгел икәнлекне аңлый. Артиллерияне сугыш Алласы диләр. Әгәр ул Алла икән, безнең җәяүлеләр күтәрелгәндә иманеч көчле ут ачкан дошман пулеметын тиз генә тар-мар итеп ташларга тиеш. Тик барысы да син уйлаганча ал да гөл түгел шул монда. Бер биеклектәге пулемет тәки баш күтәрергә ирек бирми бит.

Сугыш картинасын бүген 5нче армия командующие генерал-лейтенант Жадов, армиянең артиллерия командующие генерал-майор Полуэктов бергә карап тордылар. Алар, билгеле, фронт чылбырының төрле урыннарында булалар. Барысын да күрергә, тикшерергә, анализларга кирәк. Бүген алар 95нче укчы дивизия һәм аларга ярдәм итүче артиллеристлар, минометчылар хәрәкәтен күзәтергә уйлады. Алар янында 469нчы минометчылар полкы командиры да бар иде. Тик артиллеристлар да, минометчылар да генералларны шатландыра алмады. Безнең пехота күтәрелү белән, дошманның бер пулеметы амбразурадан ут чәчәргә тотына. Безнекеләр ятарга мәҗбүр була. Шуннан әллә ничә тапкыр артиллериягә атарга команда бирелә. Аталар. Теге амбразура янында бихисап снаряд ярыла. Бу вакытта атмый дошман. Шуннан соң безнекеләр: «Тончыктырдык моны!»—дип уйлый. Хәйләкәр пулеметчы булды бу. Безнекеләр баш күтәргәч тә тиз генә атмый әле. Бу вакытта күзәтүче командирларның шатлыгы кырга сыймый. Ләкин ул дөмекмәгән дә, чәнчелмәгән дә—тагы да чәчә утларын. Безнекеләр чабылган печән урынына түшәлә. Болай булса, биеклекне алганчы берсе дә калмый кырылып бетәчәк. Генераллар сүгенергә тотына:

—Тфү... сугыш Алласы, имеш...

—Сугыш черкиләре болар...

—Көч инде монда контрһөҗүмгә...

—Мондый сукыр чебеннәр белән...

—Бөтен җирдә дә амбразура каплаучы Матросов юк шул...

Шуннан «сүзне» минометчыларга бирәләр. 469нчы миномет полкының беренче расчеты башта чәпне алырга тиеш була. Чәп алынгач, йә батарея, йә бөтен полк белән атачаклар.

Чәпне бу юлы да өч мина белән алу бәхетенә ирешә Сәлим. Бу өч мина чәпнең үзенә үк тимәсә дә, янында ярылырга тиеш. Ә бу юлы беренчесе—унда, икенчесе—сулда, өченчесе нәкъ дошман пулеметының өстенә төшеп ярылды. Хәзер инде Александр Матросов та, артиллеристлар да, минометчыларның полк белән атулары да кирәкми. Безнең пехота, дәррәү күтәрелеп, атакага ташланды, немецларны окопларыннан бәреп чыгарды.

Чәпкә туп-туры төшерү өчен 120дән артык мина атарга кирәк. Ә менә бүген өченче мина ук төшеп ярылды. Генерал-майор Полуэктовның әйтүенчә, мондый хәл фронтта әле беренче тапкыр икән. Генерал полк командиры Чернявскийның кулын кысты:

—Котлыйм! Бу төзәүчене сакларга кирәк. Андыйлар сирәк була. Бүген үк «Батырлык өчен» медале белән бүләкләгез,—диде. Ул гына да түгел, Сәлим

ясаган сынау атуы буенча башта беренче батарея, аннан соң дивизион, бөтен полк атты хәтта, качып барган фрицларның тетмәсе нык тетелгән. Полк дошманның ике йөздән артык солдатын, әллә күпме ут позициясен, хәрби техникасын кыранлата. Пехота командирлары соныннан бу минометчыларга зур рәхмәт әйтте. Мәгәр Башкорт полкы бер бирсә берәгәйле бирә икән, дип сөйләделәр.

Кичен, атыш тавышлары тынып, юлга әзерләнеп торганда, машинасы белән полк командиры үзе килеп чыкты. Кояш баеп, эңгер-меңгер төшә башлаган иде инде. Батарея яугирләрен бер җиргә җыйды да, Сәлимгә рәхмәт белдереп, медаль белән бүләкләнәчәген әйтеп китте.

***

Фронтта хәбәрче-корреспондентлар йөреп кенә тора. Алар алгы сызыкта да, ажгырып танклар килгәндә дә, өстән бомба яуганда да яугирлар арасында булырга тырыша. Чөнки шунсыз, барысын да үз күзең белән күрмәсәң, яхшы мәкалә дә, сурәтләмә дә, очерк та язу мөмкин түгел.

Сәлим аткан мина, дошман пулеметын чәнчелдергәч, нәтиҗәдә пехота алга киткәч, икенче көнне иртүк, унсигезенче июльдә, янә бер хәбәрче килеп чыкты. Өлкән лейтенант. Кырык яшьләр чамасы булыр үзенә. Болай бик җитди, ачык йөзле, мөлаем кеше. Сәлим белән сөйләшә башлаган иде, күзәтү пунктыннан атарга команда булды. Башта аның минометы гына атты. Аннан соң залп белән дә озаттылар миналарны дошман ягына. Бөтен батарея бергә атарга команда булса, почмак үлчәгеч һәм прицелны дөрес куйгач, һәр төзәүче бер генә сүз белән җавап бирә: «Готово!» Шуннан соң взвод командиры уң кулын күтәрә дә, төшергәндә «Огонь!» ди.

«Готово!»ны Сәлим иң алдан кычкыра. Кайбер чакта, төзәүчеләр әле ыгы-зыгы, тыз-быз килгәндә, взвод командиры йөгереп килеп карап та китә: ай-һай, бигрәк тиз кычкырды, алты адым атлаганчы, алтмыш тапкыр артына кара диләр бит, ашыгуы түгелме бу, янәсе. Барысы да әзер. Тиешенчә икәнлеген белгәч, зур канәгатьлек белдереп, китеп бара.

Бәлки, кичәге уңышы тагы да ныграк канатландырып җибәргәндер, бүген ул бигрәк тә җитез кыйланды. Төнлә яна урынга күчү дә әллә ни йончытмады шикелле. Киресенчә, иртүк тагы да атасы килеп куйды хәтта. Коручы алай-болай салкынлык күрсәтсә, мәрәли башласа, ана да ярдәм итте. Минаны көбәккә аның өчен үзе салып җибәргән чаклары да булды. Минага артык заряд кидерелгән булса, аның берсен алып ташларга кушмады, бу эшне дә яшен тизлегендә үзе башкарды. Бер кулы белән тау ега, икенче кулы белән йолдыз тота бит бу, дип уйлады хәбәрче.

Ату шактый озакка барды. Әйтмәсәләр дә, ни өчен күп атканлык билгеле, әлбәттә: кичә утлы чукмар белән көне буе тукмагач, төне буе эчеп-исереп, иртән ыңгырашып яткан алкаш сыман, алар бүген баш күтәрә алмый, һөҗүм итәргә куркалар; безнең пехота, түш белән җир ярып, һаман алга бара; хәзер инде, тау башына менгәндә алҗып егылган кеше кебек, артка борылу килешми.

Ату беразга тукталгач, хәбәрче янә Сәлим янына килде. Башта ул кичәге оста атуның—өч мина белән ут ноктасын алуның сәбәбен сорады.

Сәлим ни дип җавап бирергә дә белми аптырады. Чөнки монда взвод командиры Харисов та, расчет командиры Уймин да, башкалар да бар иде. Хәтта бер як читтә һаман шулай кыерсытылган ятим бәпкә кебек басып торган Мәхмүт тә якынрак килде. Ә ул Сәлимнең мәргәннәрчә атуын кичәдән бирле очраклы хәл дип уйлап йөри иде. Аныңча, шултиклем баһадир яугирләр арасында «өтек» Сәлимнең кояш булып балкырга торуы һич тә акыл казанына сыя торган хәл түгел. Монда тормышның

ачысын-төчесен татыган, утта янмый, суда батмый торган кешеләр күп. Кояш йөзен тизәк пычрата алмаган кебек, бер тиенгә тормас сүзен белән берәүнең алтын фикерен каралтып булмый. Шуңа күрә эндәшмәүне хуп күрде Мәхмүт. Тешен кысып, уртын чәйнәп тик йөрде. Айга сикерергә ажгырган ахмак кебек кыланырга үз авылың Күккүз кешеләре юк монда. Аз гына кабарынганыңны сизсәләр, кикригеңне тиз шиндерәләр. Сәлим кичәге унышы хакында:

—Случайно...—дип, бер сүз белән генә әйтеп куйды. Әйтте әйтүен, әмма шуның белән ул авылдашы алдында үзен дә, батареяны да, полкны да юкка чыгарды. Чөнки аның белән батарея да, дивизион да, полк та горурланып өлгергән иде инде.

Аның бу җавабын Мәхмүттән башка берәү дә яратмады. Кемдер:

—Он обманывает,—дип кычкырды.

Лейтенант Харисов исә башкачарак әйтте:

—Он у нас очень скромный...

Бу сүзне ишеткәч, хәбәрче яңа уенчык тапкан бала урынына шатланды. Ул инде байтак сугыш каһарманнары белән очрашкан, күпләр турында язып чыккан кеше. Бәгъзе берәүләр, ялган батырлык алу өчен, аның алдында яшен ташы булып тәгәрәргә әзер тора. Әмма Сәлим батырлыгының алай түгел икәнлеген аңлады ул. Батыр булсаң йөрәктән, көчле булсан—беләктән, дип тә әйтәләр бит. Менә бу төзәүченең йөрәгендә дә,беләгендә дә берниндидә гаярьлек галәмәте сизелми. Киресенчә, ул оялып, кызарып тора, мактаганны яратмый. Димәк, батырлыгы—зиһенендә, күңелендә, бөтен кан йөрешендә. Гәзиткә сурәтләмә-фәлән язса, шушы мәсьәләгә ныграк игътибар итәргә кирәктер, бәлки.

Башкалар алдында сөйләргә оялганлыгын аңлагач, хәбәрче Харисовка, Уйминга аларның икесен генә калдыруларын үтенде. Алар киткәч, хәбәрче озак кына сүз башлый алмыйча торды. Язу өчен кешенең күңеленә, йөрәгенә керә белергә, бөтен үткән тормыш сәхифәләрен актарырга, ул сәхифәләрдәге ак һәм кара тамгаларны күрергә, шулардан чыгып, әйткәндәй, уптым илаһи бәя бирергә кирәк. Бер нәрсә дә сәбәпсез башкарылмый бу дөньяда: яхшысы да, яманы да. Сәбәпсез сәнәк тә урыныннан кузгалмый. Шуңа күрә авылы, районы, әти-әнисе, туган-тумачасы, кардәш-ыруыннан ук сораша башлады хәбәрче.

—Сез каушамагыз, мине әллә кайчангы танышыгыз кебек күрегез; үзебезчә, гади итеп сөйләшик...—диде ул татарчалатып.

Сәлим хәбәрченең үз кеше булуына бик тә сөенде. Ни сораса, шуңа төгәл җавап биреп торды. Тормыш хәлләрен әнәсеннән җебенә тиклем сөйләп чыккач, сүз хәрби эшкә күчте. Сәлим тылда өйрәнү вакытында да оста ату сәнгатен күрсәткән. Монда ут эчендә—бу сәнгатьлелекне янә үстереп җибәргән. Хикмәт нидә, моңа ничек ирешкән ул? Мәсьәләнең тышкы ягыннанрак башлады сүзне Сәлим. Иң әүвәл окопны яхшы казырга кирәк, диде. Дөрес, бу—бик авыр, мәшәкатьле, күп көч сорый торган эш. Чөнки ике озын аягын дөя кебек ике якка аерып, көбәген дә дөя муены кебек сузып торган, плитәсе зур түгәрәк өстәлне хәтерләткән 360 килограммлы миномет өчен галәмәт зур окоп кирәк. Чөнки төзәүче, коручы, мина ташучы бер-берсенә бәрелешә башласа, рәтле ату килеп чыкмый. Почмак үлчәгеч, прицелга атарга әзер итеп куелган икән, аякларга, плитәләргә, көбәккә чебен канаты да тиярга тиеш түгел. Ә иренеп казылган тар окопта чебен канаты гына түгел, солдатның кулы да, аягы да, башка җире дә тиеп китә. Көбәк төбәлгән урыныннан бер миллиметр гына кузгалсын, чәпкә барып җиткәнче мина йөз метр чамасы авышлык ясарга мөмкин. Кайберәүләр, иренеп, миномет окобыннан ике якка китә торган траншеяне бик тар,

сай казый. Ә бит аларда миналар саклана. Ату вакытында ташучылар берберсенә орынып-бәрелеп түгел, иркен йөрергә тиеш. Ярый, әле хәзергә көндез—кояш, төнлә ай нурларын коя. Ә бит янгыр, кар яуса, ул миналар, аларнын зарядлары чыланып бетә. Андый чакта мина йә атылмаска, атылса да тиешле урынга барып төшмәскә мөмкин. Янгырда ул траншеяләр баткакка әйләнеп бетәчәк. Шуна күрә тирән казып, өстен ябарга кирәк. Миналар күп вакыт тутыккан хәлдә килә. Аларны яхшылап тазартырга кирәк. Тутык минаны көбәккә салу бик куркыныч. Ул дискка хәтле төшеп житмәскә мөмкин. Төшеп житсә дә, ул минанын, көбәктән жинел чыгып китмәгәнлектән, чәпкә барып житмичә ярылуы ихтимал. Дискка барып житмәсә, минометнын ярылу, шартлау куркынычы да бар. Чөнки залп белән атканда игътибарсыз төзәүче минанын атылганын сизмичә дә калырга мөмкин. Шуннан, белмичә икенче минаны жибәрсә, миномет һәм бөтен расчет харап була да куя. Күп минометлар полкта шушы сәбәптән шартлады.

Минаны «кыяр» дип йөртәләр. Берни тиклем охшашлык бар, әлбәттә. Иң очында—мембрана. Ул күз алмасы зурлыгында гына. Ап-ак. Көмештәй елтырап тора. Очканда яфракка гына бәрелсә дә, мина ярыла. Шул күз алмасыннан очлы мина юанaя бара-бара да аннан соң тигез йомрыга әйләнә. Койрыкка табан ул янә нечкәрә башлый. Шул нечкәрәйгән урынга заряд бәйлиләр. Ул ап-ак крәндилне хәтерләтеп тора. Бу крәндил ап-ак марля белән төренгән. Марля эчендә—дары. Иң койрыкта—стабилизатор, очканда минага дөрес юнәлеш бирүче. Зарядка чык зурлыгындагы бер тамчы су да тияргә тиеш түгел. Бу—бер. Икенчедән, ул «крәндилне» почмак үлчәгеч, прицел куелышын, минанын атылу троекториясын искә алып бәйли белергә кирәк. Бик якынга булса—берәү, икәү дә житә; ара ераклашкан саен анын санын арттыра баралар. Бу, билгеле, ату вакытында яшен тизлегендә эшләнә. Монда мәсьәләне секундлар хәл итә.

Минометның тышкы ягы да, эчке ягы да һәрвакыт көзгедәй ялтырап торырга тиеш. Оста жигелмәгән ат ярсып чапмаган шикелле, пычрак минометтан атылган мина да һавада житез очмый. Атканнан соң көбәкнең эчен даими рәвештә тазарта барырга кирәк. Анын махсус эшләнгән озын саплы пумаласы бар. Пумалага күп ял итәргә ирек бирергә ярамый. Ә инде озаграк атмый торачагы билгеле булса, бөтен минометны жинелчә генә майлап кую хәерле. Тик ату алдыннан көбәктәге майны әлеге пумала белән тиз генә сөртгереп ташларга кирәк. Түгәрәк өстәл зурлыгындагы 150 килолы плитәнең дә «холкы» көйсез баланыкы белән бер. Аны көйләү бигрәк тә мөһим. Чөнки көбәк ана беркетелә. Жир йомшак булса, атканда плитә аска китә, әгәр дә каты икән—сикерә. Тегесе дә, монысы да яман. Шуна күрә плитәнең дөрес утырышын төзәүче даими күзәтеп торырга тиеш.

Ә инде ату сәнгатенең эчке ягына, Сәлим уйлавынча, почмак үлчәгеч һәм прицел белән эш итү керә. Уставта төзәү ноктасы ут позициясенең алдыннан алырга киңәш ителгән. Тылда чакта ул шулай эшләнде дә. Алга—йөз яки йөз метр ераклыкка—дүрт-биш метр озынлыгындагы казык кадап куела. Күзәтү пунктыннан команда бирелгәч, төзәүче прицелдагы ярыкны шул колгага (төзәү ноктасына) яраклаштырырга тиеш. Яки төзәү ноктасы ярыкның уртасына туры килә. Бу вакытта почмак үлчәгечтәге терекөмеш тә урта сызык өстенә килеп житәргә тиеш. Төзәүче шундый төгәллек күрсәтеп, «готово!» дип кычкыргач кына атарга команда була. Бу вакытта төзәүчедән тизлек, салкын канлылык, түземлелек һәм зур жаваплылык таләп ителә. Шуларга охшаш мәшәкатьләрнең тузан бөртеге кадәресе генә житмәсә дә, төзәүче оттыра, минасы тиешле жиргә төшми.

Ләкин уставта каралган дип төзәү ноктасын бер генә тапкыр да алдан алмады

әле Сәлим. Чөнки, аның уйлавынча, төзәү ноктасын, уставта каралганча, бер йөз, ике йөз метр гына түгел, ә бәлки аннан да ераграк алу хәерле. Ә монда кайбер урында илле метр белән канәгатьләнергә туры килә: син чокырдасың, алдында—үр. Шуңа күрә, гәрчә мәшәкатьлерәк булса да, ату вакытында бер алга, бер артка борылып эш итәргә туры килсә дә, төзәү ноктасын арттан алуга җитми. Җил тегермәне икәнлеген беләм дә ул, суы кайда соң монын дип әйтте ди берәү. Төбәү ноктасын арттан алырга кирәклекне беләсең дә бит, кайда соң ул? Аны кем сиңа утыртып куйган ди әле? Берәр агач үсеп утырды ди. Төзәүчегә аның көбәге кирәк. Ботаклар, яфраклар көбәкне күрсәтми—каплап алган. Күренсә дә, әгәр юан булса, ул барыбер ярамый. Төзәү ноктасы казык юанлыгы чамасында гына булырга тиеш: караганда ул прицелнын әлеге ярыгына сыеп бетсен. Шуңа күрә, бер казык табып алып, Сәлим аны үзе белән йөртә. Машина белән булганда җайлырак иде, әлбәттә әрҗәгә сузасың да саласың. Атка калгач—кыенрак. Шулай да ату сәнгатенең әлеге эчке үзенчәлеген, аның «җанын», «кан агышын» тәшкил иткән бер колгага бричкада да урын табыла. Килеп җитү белән, окоплар казылып миномет урнаштырылгач, Сәлим, кулына шул колганы һәм көрәкне тотып, тизрәк артка йөгерә. Аны бер метр чамасы казып утырта. Казык төз булырга тиеш. Җил чыгып, аз гына чайкалса да, ул әлеге прицелдагы ярыкка янә туры килми. Бу вакытта атып җибәрсәң, синең минаң тагы да «сөткә китте» дигән сүз.

Сәлим өлкән лейтенантның хәбәрче икәнлеген дә онытты хәтта. Сөйләде дә сөйләде.

—Хәзер шуларны кыскача гына язып бирегез инде,—диде өлкән лейтенант.

Сәлим тиз генә ризалашмады. Озак кына уйлап торгач:

—Мин русча яза белмим шул,—диде.

—Соң, татарча яз, русчага үзем аударырмын...

—Ул нигә кирәк?

—Синең осталыкны башка төзәүчеләргә җиткерер өчен кирәк.

—Бу әллә ничек бит әле...

—Бер дә әллә ничек түгел, сержант, күрәм: син артык тыйнаксың. Әтиенә охшагансың.

Сәлим тертләп китте:

—Сез минем әтиемне беләсезмени?

—Беләм, һәм бик яхшы беләм. Әтиең, әниең мине Гражданнар сугышы вакытында үлемнән коткарганнар иде.

—Ә-ә-ә, аңладым: сез безне Себергә җибәртмәгәнсез.

—Әйе. Син ул чагында бала гына идең әле.

—Әнием безгә соңыннан барысын да сөйләп бирде. Әмма безнең аркада сезнең үзегезне утыртканнар бит.

—Булды инде. Еллары шулай иде. Ләкин сезнең аркада гына түгел. Моны үзеңә ала күрмә берүк. Мин артык озак утырмадым. Биш ел гына. Аннан соң язучылык эшенә керештем. Төрмәдә күргәннәрне яздым. «Корбаннар» дигән романымны язып та бетердем—сугыш та чыкты. Ә фронтта менә журналистика эшенә керештем. Гәзит чыгарабыз. «Ватан өчен» дигән. Синең мәкаләне шунда бирәчәкмен.

—Мин яза алмам, абый, гафу итегез. Килешми.

—Әллә хат та яза белмисеңме?

—Ансын булдырабыз ла ул. Монда картрак абзыйларга да мин язып бирәм.

—Хат язу да иҗади эш, энем.

—Көндәлек тә язам ла ул... Шигырьләр дә...

—Көндәлек? Шигырь?

—Әйе. Үзем өчен генә инде.

—Карарга мөмкиндер бит?

—Әле рәтләп язып булмый. Вакыт юк.

—Шулай да...

—Сез аны танымассыз да... китап битенә... теләсә нинди кәгазьгә язылган... Дәфтәр юк бит...

—Корреспондентның күзе бөркетнеке белән бер ул, энем.

—Ярар соң, алайса...

Сәлим, йөгереп барып, солдат капчыгының төбендә гәзиткә төрелеп яткан кәгазьләрен алып килде. Алар белән бергә Мәрьям язган «Истәлек дәфтәре» дә эләккән. «Солдат дәфтәре»н кыенсынып, ояла-ояла гына сузды ул хәбәрчегә. «Хатасы күптер инде, без бит жиденчене латин графикасы белән тәмамладык, ә хәзер урыс хәрефләре белән язарга туры килә»,—дигән сүзләрне әйтте. Өлкән лейтенант Сәлимнең аркасыннан кагып куйды:

—Бу авырлыкны мин дә кичерәм, туганкаем: 1929 елда гарәптән—латинга, 1939 елны латиннан урысныкына күчәргә туры килде. Без күчү белән артык нык шаярабыз, ахры. Уйлап-нитеп тору юк—күчәбез. Ә менә дөресме ул, түгелме—уйланмыйбыз. Төлке—койрыгы, түрә боерыгы белән алдый,—дигәндәй, койрык белән дә, боерык белән дә алдыйлар...

Шулай диде дә як-ягына каранып алды хәбәрче: безнен сөйләшүне ишетмиләрме, янәсе. Менә ул, шик-шөбһәләреннән арынып, «Солдат дәфтәре» сәхифәләре эченә чумды. Дөрес, үзе әйткәнчә, хәреф хаталары шактый. Ул, бәлки, ашыгып язудан да киләдер. Ә менә укый башлагач, һич тә аерылып китәсе килми.

«1942 ел. 29 август. Алкин лагерына килеп төштек. Безне бер землянкага китереп тутырдылар. Дынгычлап. Базга бәрәңге тутырган кебек. Землянканың тәрәзәсе-фәләне юк. Жир идән. Талдан читән итеп үргән нәрсәне сике итеп җәйгәнәр. Ул ике катлы. Монда хәтта көндез дә караңгы. Әллә нинди сасы ис килә. Авызынны ачсаң, тузан бөркелеп керә. Без, егерме дүртенче елгылар, бер авылдан утыз өч егет киттек. Алкинда унөчебез бергә туры килдек. Монда авылдашларым Рәис, Мәхмүт, Мирзагали һәм башкалар бар. Мәхмүт башта ук сүгенергә тотынды. «Юньле хужа мондый землянкага дунгызын да япмый»,—ди. Ул, председатель малае булгач, балда-майда йөзде шул. Бөтен нәрсәгә төкереп карарга өйрәнде. Кеше башыннан йөрде. Ә минем өчен бу землянка алтын сарай. Авылда яшәгән землянкабыз артык тәбәнәк, кысан иде. Башны күтәрим дисәң, түбә сайгакка тия. Борылыйм дисәң, кабырга стенага бәрелә. Гөлжамал апа монда яшәмәсә, үпкә чире алмас иде. Ярый әле мин бирешмәдем. Бизгәк, зәңгелә, эч китү кебек вак-төяк чирләр белән генә котылдым. Ә бу Алкин землянкасы минем өчен ничава әле».

«1942 ел. 12 сентябрь. Безне Чишмә районындагы бер колхозга ун көнгә дип җибәрделәр. Беренче көнне үк бик каты эшләдек. Авыл кызлары, рәхмәт яусын аларга, клубта безнең өчен вечер ясадылар. Мондый вакытта үләргә яткан егет тә сикереп торыр. Без, телне эттәй салындырып, эштән бик арып кайтсак та, взвод командиры Харисовтан клубка барырга рөхсәт сорадык. Ана да зур рәхмәт! Каршы килмәде. Әмма ул бездән бик каты көлде:

—Соң, шундый кием белән кызлар янына клубка баралармы инде...

Киемнәр шәптән түгел иде шул. Сөйләүләре буенча, безгә фронтта үлгән кешеләрдән салдырып алган гимнастерка, чалбарларны биргәннәр. Булыр да. Алардан дары исе, кан исе, тир исе килеп тора. Аякта тишек ботинка. Тезгә тиклем обмотка уралган. Анысы да ничава иде әле. Әллә авыл кызлары солдатның кем икәнлеген белмиме? Ак күлмәк, кара чалбар, матур пинжәк киеп, форсить итеп йөрергә тиешме алар? Тик авылдашым

Рәис белән минем гимнастерка аркасы умырылып, асылынып төшкән иде. Тегик, йә ямыйк дигән идек, энә белән жеп тә таба алмадык. Әгәр салам эскерте эчендә бер энә бар, эзләп алыгыз шуны, дисәләр, валлаһи менә, шәп-шәрә килеш калып булса да, шул эскерткә чумыр идек. Сугыш, күрәсең, безне энә белән җептән дә мәхрүм итеп өлгергән.

Шулай да безнең ач карын, ярсып типкән яшь йөрәк, йомарлаган май шикелле авыл кызларын күрергә ашкынган күңел катып беткән, тишек-тошык, ертык-мыртык гимнастеркалардан өстенрәк булып чыкты. Бер ташландык, иске чабата киндерәсен кисеп алдык та, кылны кырыкка бүлгән кебек, киндерәне сүтеп, шуннан җеп ясап, без белән тишкәләп, чатнатып ямадык та куйдык. Рәхәтләнеп биедек Рәис белән. Күргәннәрдер. Көлгәннәрдер. Әйдә, көлә бирсеннәр. Гөнаһыбыз кимер».

«1942 ел. 26 сентябрь. Безне кухняга «кара эшче» итеп җибәрделәр. Анда, күк кабагы ачылгандай, һәр солдат шатланып бара. Акмаса да, тама дигәндәй, анысын чәлдереп, монсын чеметкәләп, ач солдат рәхәтләнеп бер тамагын туйдыра. Әлбәттә, эт эченә майлы аш ярамаган кебек, бәгъзе берәүләр «юртак ат» җигеп кайта, землянка белән әбрәкәй арасында килән сара. Бу юлы Мәхмүт тә шунда булды. Повар күрмәгәндә дуңгыз маен чәлдергән дә тотынган ач песи урынына комсызланып ашарга. Аннан соң бер котелок ашны ялт иттергән. Шуннан, теге май эчтә кайный башлагач, бер кәрешкә суны да түнкәреп куйган. Бер заман моның эче, унлаган бака бакылдаган тавыш чыгарып, богыр-богыр килә башлаган. Ул «бака тавышларын» хәтта без ишетеп тордык. Шуннан Мәхмүт «уф» дип эчен тотты да ике ботын кысты. Шул арада сасы ис чыкты. Ул астына җибәргәнен үзе дә сизмичә калды».

«1942 ел. 28 сентябрь. Безне иртәнге аштан соң стройга тезделәр. Бу беренче тапкыр гына түгел. Тезәләр дә, сине энә күзеннән үткәрердәй итеп, тикшереп карыйлар: буй-сының, килеш-килбәтең, төс-битең, күкрәк киңлегең, үз-үзеңне тотышың нинди барысын да «һә» дигәнче, икенче төрле әйтсәк, күз карашы белән бәялиләр. Врачка күрсәтеп, бөтен тишекләрне тикшертеп торуның кирәге юктыр, күрәсең. Шулай карап чыгып, илле кешене бервакыт Ерак Көнчыгышка, диңгез флотына җибәрмәкче булдылар. Алар арасында мин дә бар идем. Дөрес, буй ягыннан мактанырлык түгелмен. Шулай да «кәтүкләр», «бүтәкәләр», «кәрләләр» гаскәренә кермим. Бер майор күкрәккә егылып китәрлек итеп сукты да, күзләремә бөркет карашы белән озак кына карап торды, «пойдет» диде аннан соң. Мәхмүт минем янда тора иде. Ул, үзен озын күрсәтү өчен, аяк очына басып тора икән. Теге озын буйлы, юан майор көрәктәй кулы белән башын сыккан иде, үкчәсе җиргә тию генә түгел, тезләре бөгелеп егылып китә язды, бер үк вакытта «пырт» иткән тавыш та ишетелеп калды. Майор да, башкалар да, бөтен строй, хор белән дигәндәй, шаркылдап көлеп җибәрде.

Бер атна чамасы көттек, ләкин, нишләптер, җибәрмәделәр. Шуннан соң кемне кая кую мәрәкәсе башланды. Без, Рәис, Мәхмүт, мин, 82 миллиметрлы миномет батальонына эләктек. Шулай итеп, авылдашлардан—утыз өч яшьтәштән—өчәү генә тырпаеп калдык Алкинда. Бу стройга Рәис белән икәү генә эләктек. Мәхмүтне, эченнән каннар китә башлагач, лазаретка салдылар. Безне хәзер, күренеклерәкләрне сайлап, хәрби училищега укырга җибәрәләр, имеш. Бу юлы да әлеге озын, юан, көрәк куллы майор килгән иде. Тыныч вакытта училище ике еллык икән. Ә хәзер—сугыш вакытында—шул ике еллык программаны алты айда үтәргә тиешбез. Училищены тәмамлагач, башта кече лейтенант званиесе бирәчәкләр. Аннан соң—лейтенант, өлкән лейтенант, капитан, майор, подполковник, полковник. Кайберләребез исә генерал, маршал дәрәҗәсенә җитәргә тиешбез. «Һәр солдат кесәсендә генерал погоны йөртергә тиеш»,—дигән Суворов.

Шул хакта сөйләде майор. Тырышып укырга, сынатмаска кушты. Бодай арасына ялгыш килеп эләккән кырлык кебекләрне алмадылар. Мин, күрәсең, бодайга тартым булганмындыр—алдылар. Шулай да чын бодай түгел икәнлегемне дә аңладым. Чөнки әлеге майор күзгә дә тишәрдәй итеп карый, көрәк кулы белән башны да сугып ала, сул бармагы белән иякне дә югары күтәртеп куя; сизәм: кырлык белән бодай арасындаракмын. Шулай да кырлыклар сафына басасым килми. Бодайның да төрлесе бар бит: вагы, эресе, уртачасы, һич югында вак бодай сыманрак итеп булса да бәяләсен иде майор дип уйлыйм, һич кенә дә кырлык кырында киселәсем килми. Рәхмәт майорга! Рәхимле булды—мине бодайлар сафына бастырды.

Тик Рәис кенә эшне харап итте. Әлеге тышкы кыяфәт, буй-сын, килеш-килбәт сыналып беткәч, белемеңне дә сорыйлар. Училищега элек дүрт класс белем белән дә алганнар. Ә хәзер җидене тәмамламаганнар кабул ителми. Рәиснең алты гына иде шул. Монда, билгеле, берәүнең дә кесәсендә документ юк. Кем ничек әйтә, шуна ышаналар. Рәис буй-сыны, үз-үзен тотышы, килеш-килбәте буенча ярамаслык түгел. Тик бер класс җитми. Ә белеме белән ул бездән күпкә уздырып җибәрә. Русчаны су урынына эчә. Алар бервакыт читкә киткәннәр иде. Сугыш чыккач, әйләнеп кайттылар. Рәискә, нишләптер, ТБУМ (тулы булмаган урта мәктәп) тәмамларга насыйп булмаган. Азмы-күпме дуслашып өлгергән якташларыбыз да, мин дә аңа «җиде классны тәмамладым» дип әйтергә куштык. «Юк инде, кыстамагыз, гомер буе алдашмаганны...» дип маташты ул башта, ә инде без бик нык үгетләгәч, «эш кәгазьдәмени соң», «монда сине этем дә белми», «аерылышмыйк» дигән сүзләрне кат-кат әйткәч, «ярый инде, җиндегез», диде. Ләкин сорагач, барыбер алты класс кына тәмамлавын әйтте. Шулай итеп, утыз өч авылдаштан берүзем торып калдым. Мин, билгеле, моны бик авыр кичердем. Төрлечә фараз итәм үзем. Менә без, утыз өч торна булып, очып барабыз. Бер ук тигәч, утыз икесе очып китте, ә мин каты яраланып, егылып төштем. Яки киресенчә: мин очып киттем, тегеләр каядыр юк булды. Минем өчен, әлбәттә, тегесе дә, монсы да күңел сызлатырлык иде».

«1942 ел. 10 октябрь. Менә мин тагы да Алкинның дуңгыз абзарыннан кайтыш землянкасында. Училищега дип Стәрлетамакка алып барганнар иде. Әмма укырга булган кайнар теләк, кинәт дөрләп тиз генә сүнгән салам ялкыны кебек, сүрелде дә куйды. Сәбәпсез сәгать тә сукмый дигәндәй, моның да сәбәбе юк түгел.

Безне Стәрлегә лейтенант Харисов алып барды. Җәяү. Ике тәүлек атладык. Юл буендагы берәр авылга кереп черем итеп алабыз да тагы да китәбез. Әле ишеп яңгыр, әле ябалаклап-ябалаклап юеш кар ява. Лычма су булабыз. Энә очы белән төртеп табарлык та коры җир калмый. Туктап ял итәр идең дә, аяктан егардай итеп, сөякләргә чаклы үтеп искән җил һич ирек бирми. Туктасак, бер минут эчендә, бизгәк тоткан кеше кебек, калтыранырга тотынабыз. Тешләр тешкә тими хәтта. Моны сизгән лейтенант Харисов «шаго-о-м марш» дигән команданы тагы да бирергә ашыга. Ярый әле тишек-тошык, кырык ямауны шинель биргәннәр иде. Әмма ул да киндер белән бер. Җил тотмый. Өстән ишелеп төшәргә тора. Монсы бер хәл. Монда мин генә түгел. Батыр солдатка ун дошман бер булып күренә дигәндәй, түземле солдатка ун авырлык та чепуха. Уртак авырлык сизелми ул. Лейтенант Харисов иң алдан атлый. Ул үзен бик җитди, горур тота. Үзәкләргә үтеп искән бу каты җил, койма яңгыр, юеш кар, әйтерсең, аның өчен берни түгел. Аның өстенә гүя ябалак-ябалак карлар түгел, япма-япма чәчәкләр ява. Аның үз-үзен шулай чын ир-егетләрчә тотуы солдатларга борын салындырырга һич тә ирек бирми. Вакыт-вакыт ул җыр башлый. Солдатлар моны күтәреп ала. Җыр кайгыны да, авырлыкны да, бөтен күңелсезлекне куа бит ул.

Лейтенант стройны бозмаска, һаман дөрес атлатырга тырыша; еш-еш кына «эр-р-эс, два, эр-р-эс, два»ларны әйтеп ала. Безнең аяклар аның музыкаль тавышы ритмына буйсынып атлый. Тик минә рифмасы гына вакыт-вакыт буталып куя. Монсына күбрәк мин гаепле. Чөнки башы убыр авызы сыман ачылган ботинкамның үкчәсендә тырпаеп торган бер кадак бар. Авылда чүкеп карагач, беткән иде кебек. Юлга чыккач, ходай суккыры нәрсәкәй, тагы да баш күтәрде. Туктаган арада калын киез-фәлән салыр иден—каян табасың ди аны? Сатып алырга да юк. Бер туктаганда, аптырагач, сизелмәслек итеп, шинельнең арт яктагы ерык урынын кисеп алдым. Бөкләп салгач, ару гына кебек иде. Ләкин бара-бара теге ләгънәт төшкере кадак минем олтан аша тагы да борын төртә. Җитмәсә, ботинка кысып җанга тия. Бер олыныкын, бер кечeнекен тот ди. Ботинкасын башта зурысын биргәннәр иде ризалашмадым. Их, шул зур ботинка булса, кышкылыкка дип өйдән алып килгән җылы оегымны киеп, чолгау урап җибәрер идем дә рәхәтләнеп атлар идем. Хәзер үкенүдән файда юк—терсәкне тешләп булмый.

Минем сул аяк тәмам эштән чыкканда, Стәрлегә барып җитәргә егерме чакрым калган иде әле. Хәлемне лейтенант та, башкалар да белә. Шуңа күрә иң арттан барырга рөхсәт иттеләр. Үземчә, аксамаска тырышам, уртымны чәйнәп, тешемне кысып түзәм. Барып җиту белән ботинкамны салып карасам, бөтен үкчәм кара канга баткан.

Билгеле, мине барысы да җәлли, тик ярдәм генә итә алмыйлар. Шулай да Әхсән әмәлен тиз тапты. Безне ниндидер озын барак янына китереп туктатканнар иде. Монда хәрби комиссариат икән. Шунда, имеш, бездән имтихан да алырга тиешләр. Анда санинструкторлар, хәрби врачлар да бар икән. Бер санинструкторны алып килеп аягымны яхшылап бәйләтте дә Әхсән:

—Хәзер имтиханга керәбез,—диде.

Тәнем эсселе-суыклы булып китте. Нинди имтихан ди тагы? Нигә бу хакта Алкинда әйтмәгәннәр?

—Минем һич тә командир буласым килми, Әхсән дус, Алкинда чакта «белемем биш класс» дип әйтәсем калган, лутчы тизрәк фронтка китәсе иде,—дидем.

—Мин дә шулай уйлыйм, Сәлим дус,—диде ул.—Бер дә командир буласы килми, лутчы тизрәк фронтка китик.

—Ә моннан җибәрмәсәләр?..

—Җибәрми чаралары юк. Икәү бергә керербез. Минем хәйләне күрерсең..

Имтихан дигәннәре бер дә куркыныч түгел икән лә. Стенага эленгән картадан тегесен, монсын күрсәтергә кушалар. Әхсән-Чыңгызхан бер нәрсә дә белмәгәнгә салышты. Шуннан аны «дундук» дип чыгарып җибәрделәр. Мин дә дустымның «маһирлыгын» кабатладым. Мәскәүне күрсәтергә кушканнар иде, аны Сахалиннан эзләп маташтым. «Дундук» дигән мөһер миңа да сугылды.

Башка «бодайлар» торып калды. Без, ике «кырлык», лейтенантка ияреп, Алкинга кайтып киттек. Харисов безнең дуамаллыкны аңлаган, әлбәттә.

—Шәп уйлап тапкансыз, молодцы, аңлыйм: фронтка китәргә ярсыйсыз, ну и что же, начар түгел, сезнең кебек солдатлар белән миңа да күңеллерәк булыр,—диде».

«1942 ел. 26 декабрь. Бүген дә тургайлар очкан җирдән тунып төшә торган суык. Төшке аштан соң безне кинәт кенә стройга тезделәр. Һич тә басып торыр әмәл юк. Суык битне, колакны, борын очын чеметә. Җитмәсә, «равняйсь», «смирно» командасы бирәләр. Әллә аякның шакырдап тунганын белмиләрме? Бер иблис солдат качкан булган икән. Шуны тотып алып килгәннәр. Хәзер полк алдында атачаклар. Тавык мие эчкән нәрсәкәй дин

син аны. Качып кайда ятмак кирәк? Әниеннең базындамы? Һәр килгән авырлыктан өркеп, барыбыз да шәрә шайтан шикелле кача башласак, илне кем саклар? Иленне саклау әтиенне, әниенне, туган-тумачаларыңны, дусишләреңне, сөйгән ярларыңны саклау, дип аңлаткан иде жиденче класста укыганда тарих укытучысы Мансур абзый.

Ә бу тавык баш кешеләрчә үлә дә белмәде, ичмасам. Бөрешкән. Беткән. Суга манчып алган песи баласы кебек калтыранып тора. Тфү! Адәм мәсхәрәсе. Син инде, рас «качкын» исемен алгансың икән, һич югында, менә мин кем дип, тыштан гына булса да үлем алдында кукраеп тор. Ә ул, мылтык төзәгәч, елап жибәрде дә жиргә ауды. Тфү! Эт баласы урынына да күрмичә аттылар».

«1942 ел. 27 декабрь. Бүген шатлык һәм кайгы, көтелгән һәм көтелмәгән кунак кебек, икесе берьюлы килде. Өйдән посылка алдым. Сохари. Үпкә чиренә юлыккан апамның бу сохарины нинди авыр юллар белән тапканлыгын яхшы аңлыйм. Мин бит хатларымны беркайчан да зарланып язмадым. Миномет батальонында хезмәт итүем, полк мәктәбендә укуым хакында әйттем. Алдакчының алды ертылыр ди. Стәрлетамакта алдашу һич тә безнең файдага булмады, һаман шул Алкинның ач авызыннан котыла алмыйбыз. Безне 82 миллиметрлы минометны өйрәнә торган полк мәктәбенә китереп сыладылар. Аны тәмамлагач, Таутөмәнгә жибәреп, яңа оешырга тиешле полкта расчет командиры булачакбыз, имеш. Училище тәмамласак, йолдыз тага идек, ә хәзер—шпал. Язмыштан узмыш юк, күрәсең, бездән бәләкәй генә командир ясамакчы булалар.

Кемнәрнеңдер әйтүенчә, полк мәктәбендә курсантларны яхшырак тукландырырга тиешләр. Әмма командирлар, старшиналар, азык-төлек белән тәэмин итүчеләр кикергәнгә генә жан саклап йөри мескен курсант. Ачлыктан ачы кайгы юк дигәне дөрес икән. Кайберәүләр моны бигрәк авыр кичерә. Менә, бу инде гадәти хәлдер дип күнеккән кешегә, барысы да барыбер кебек. «Бик яхшы хезмәт итәм, әйбәт ашаталар, минем өчен кайгырма, апа, үзеңне кара, сәламәтләнергә тырыш»,—дип яздым хатларны. Әмма бөтенләй эшне Мәхмүт харап итте. Хатларын елый-елый яза икән. Шуннан әтисе тотынмасынмы монда азык ташырга. Бервакыт ул Алкинда булып кайткач, Гөлжамал апам безнең хәлләрне сорашырга барган. «Нык ачлык анда, солдатлар, мескеннәр, аякларын көчкә өстерәп йөриләр»,— дигән жавап ишеткән. Шуннан апам миңа: «Нигә дөресен әйтмисең, ачлыктан бик кыйналасыз икән»,—дип язды. «Без бит полк мәктәбендә укыйбыз, командир булырга, шуңа күрә безне яхшы ашаталар»,—дип жавап яздым инде. Тик апам үз авызыннан өзеп посылка жибәргән миңа.

Сигез кило чамасы бу сохари, ай күрде, кояш алды, дигәндәй, «һә» дигәнче юк булды. Землянкадаш курсантлар, посылканы ачканда ук, хужасы жим чыгаргач ябырылган үрдәк балаларыдай, минем янга ашыга-ашыга килеп тезләнделәр. Кемгә күпме эләккәндер—белмим. Мәгәр зуррак өлеш үземә тиде. Моның кире ягын белсәм, ашамаган булыр идем, әлбәттә. Чөнки кичкә табан эч китә башлады. Монда врач та аптырады. Халык та, медицина да эч киткәндә сохари ашарга киңәш итә. Ә минем юньсез эчкә кергән сохарилар шунда ук бака булып бакылдарга тотынды. Ике икең дүрт булган кебек гап-гади бер хакыйкать икән бу: Безнең эч ачлыктан шултиклем береккән, сасы балык башына, туңган бәрәңге, черегән кәбестә шулпасына шултиклем күнеккән, эт корсагына сары май килешми дигәндәй, безнең эч затлы ашны хәзер бөтенләй ятсына башлаган икән».

«1943 ел. 23 февраль. Таутөмән. Салкыннан һаман әле жирләр чатнап ярыла, тәрәзәләр боз белән карыш ката, сыер мөгезләре сына. Бүген 469нчы полк формалашкан көн. Алкинда полк мәктәбе тәмамлап килгәч, монда безне расчет командиры итеп куймакчылар иде. Ләкин нигәдер

алай килеп чыкмады. Мин, сержант—төзәүче. Монсы шәп. Башта үзен зур тоткан—соңыннан хур булган. Команда бирә белмәсәң, адәм көлкесенә калуың көн кебек ачык. Ә инде төзәүче буларак сынатмаячакмын. Ходайга шөкер, үзем уйлаганча килеп чыкты. Шуңа күрә бик шатмын. Ә инде кече сержант Йомагужин Әхсән-Чыңгызханны хәзергә мина ташучы итеп кенә куйдылар. Тартай теленнән таба, диләр бит, аның теле озынрак. Тәртәгә типкән ат кебек, хәрби уставлар кысасында да үзен яманрак тота; кулыннан килсә, аларны менә бүген типкәләп, җимереп, челпәрәмә китереп бетерер иде. Бәлки, шуны уйлаганнардыр. Бозылган эшне батыр үзе төзәтә ди, ул, билгеле, киләчәктә хәрби тәртә арасына кермичә калмас.

Акыллы кеше эрелек күрсәтмәс дигәнне дә аңлыйм. Ләкин иләктән иләгәндә акыллылар аска коела, дураклар өстә тырпаеп кала. Шыр надан Уйминны безнең беренче расчетка командир итеп куйдылар. Шыр тиле «Көти» колхоз белән житәкчелек итә. Әллә бу тормыш диваналар, ахмаклар кулында булырга тиешме соң? Әллә революция шуның өчен ясалганмы? Власть пролетариат кулында булырга тиеш дигәне шушымы әллә? Әгәр ул пролетар кеше надан булса, власть башында ботка ашап, тәмәке пыскытып, аракы эчеп утырудан башканы белмәсә? Куй, нигә язам әле боларны? Зур уйлап хур булыргамы? Нинди зур уйлау? Менә галәмәт! Мина, ятим бозауга, нигә инде мондый сораулар белән баш ватарга?»

***

Кеше! Бәгъзе берсе коточкыч салкын йөзле, имәнеч усал карашлы, хәйләкәр елмаюлы була. Йөзендә иман нуры юк, диләр мондый бәндә хакында. Аның янында, хәтта, тын алуы авыр. Шундый кеше белән бер сөйләшмәс өчен мең сум бирерсең, валлаһи! Башкалар тарафыннан шултиклем нәфрәт алып яшәү үзе генә дә зур бәхетсезлектер ул.

Ә менә бу өлкән лейтенант—хәбәрче абзый—бәхетле! Йөзе нурлы, мөлаем, шәфкатьле, карашлары җылы агым кебек мәрхәмәтле, елмаюы күңелгә һич аңламаслык нindидер яшерен наз, шифа биреп тора. Ул дөреслек эзли. Үзе өчен түгел. Кешеләр өчен!..

Бу сөйләшү Сәлим өчен таң алдыннан күргән матур төш кебек булып калды. Әллә яшәү, дөнья, тормыш бөтен авырлыклары белән матурмы? Бәндәләрнең кешелеклелеккә омтылган иманы барысыннан да бөекме? Боларның барысы да яхшы кешеләр йөрәгендәме? Бертуган абыйсы гына түгел, яшәүгә, авырлыкларны җиңүгә, кешелеклелек сыйфатлары яулауга зур көч, рухи ныклык биреп торучы әтисе кебек якын күрде Сәлим бу хәбәрчене. Әйтерсең, дөньяга ул фәкать Сәлим бәхете өчен генә туган, төрмәдән биш ел эчендә Сәлим өчен генә котылып чыккан, фронтка, язучы-хәбәрче булып, Сәлим бәхете өчен генә килгән.

Хәбәрче киткәч, барысы да, анасы янына йөгерешкән кош балалары сыман, Сәлим янына ябырылды. Аңа төрле сораулар яуды:

—Нигә килгән?

—Нәрсәләр сөйләдең?

—Безне яманламадыңмы?

—Әллә орден бирәчәкләрме?

—Герой итәләр ди, тишек борын.

—Ха-ха-ха...

Сәлим ике арада булган әңгәмәнең эчтәлеген кыскача гына сөйләп бирде. Тик хәбәрченең үткән авыр язмышы, ата-анасын белүе, таныш кеше булуы хакында ләм-мим. Чөнки мондый серләрне күңел сандыгында бикләп тотарга кирәклекне яхшы аңлый ул хәзер.

Мәхмүт тавык тотарга чамалап боргаланган төлкедәй, һаман шулай

читтән генә карап йөрде—яугирләр янына килергә ашыкмады: галәмнең иге-чиге булу-булмау хакындагы фаразны бәгъзе берәүгә аңлау авыр булган кебек, Сәлимнең ут эчендәге солдатлар арасында шушындый абруй казанып өлгерүен һаман башына сыйдыра алмый әле ул. Моны ниндидер могҗиза, очраклы хәл, кояшның болыт арасыннан ялгыш күренеп китүе дип исәпли. Подумаешь, ул аткан мина пулемет өстенә туп-туры барып төшкән, бу бит очраклы гына, аңыкы да түгелдер әле, бәлки, дип фикер йөртә. Шулай да, солдатлар таралышкач, котларга килмичә булдыра алмады.

—Ну, әй, молодец булып чыктың бит тора-бара, вакытында пешереп ашамасаң, йомшак камыр да соңыннан тимердәй ката, дигән иде такмакчы Гыймазетдин абзый бер вакыт, син дә шуның ише икәнсең,—дип аның кулын кыскандай итте. Шул ук вакытта әлеге Мәрьям чиккән кульяулыкны кесәсеннән алып, җәеп күрсәтеп, кире салып куярга да онытмады.

—Бу арада Мәрьямнән хат юк әле, әй,—дип, үзенчә төшенкелеккә бирелгән булды.

Авыл такмакчысы Гыймазетдин абзый җор телле, тирән фикерле, халык чыгарган мәкаль-әйтемнәрне күп белүче кеше иде. Кирәк тапса, ул үзе дә тиз генә яңадан-яңа мәкаль-әйтемнәр уйлап чыгара белә. Җырга да, такмакка да оста. Йомшак камырның каткан тимергә әйләнүе турында да әйткәндер. Әмма аны әле менә Сәлимгә китереп сылавы күңелсез килеп чыкты. Кеше тәтәен урлап мактанып йөргән акылсыз бала кебек, Мәрьям бүләк иткән кульяулыкны һаман аның борын төбендә уйнатуы да килешсез.

Әлбәттә, бу хакта Сәлим бер сүз дә әйтми. Сабыр төбе—сары алтын дип йөри бирә. Хәер, утырып, иркенләп сөйләшергә вакыт бар мыни? Әле генә менә, нишләптер, ике яктан да дөнья җимерердәй булып котырынып атулар тукталып тора.

* * *

Хәбәрче лейтенант Харисов белән дә әллә кайчангы танышлар кебек ачык йөз белән күрешеп, ихлас күңелдән сөйләште. Аучы аучыны ерактан таный дигән кебек, алар бер-берсенең үз кеше икәнлекләрен күз карашы белән үк аңлап, күрешеп алгач, һич икеләнеп тормыйча, татарча гәпләшеп киттеләр.

Хәбәрченең минометчылар белән күп тапкыр сөйләшкәне бар. Ләкин бер генә төзәүченең дә оста ату сәнгате хакында бу тиклем аңлап, бөтен нечкәлекләрен белеп, күңел биреп сөйләгәнен ишеткәне юк иде әле. Ул хәтта бу һөнәрне чын йөрәктән яратып өлгергән кебек. Кеше карбыз түгел, ярып карамагач, эчен белеп булмый диләр. Ярып карамасаң да, аның йөзе, кыяфәте, сөйләшүе кем икәнлеген күрсәтеп тора. Су тирәнлеген таяк белән, кеше акылын тел белән үлчиләр, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Ә менә минометның теле дә юк, эчен дә ярып карап булмый. Шулай да төзәүче «ярып караган». Эченә кереп, әнә очы зурлыгы җаена тиклем тикшергән. Ул яратып, дулкынланып, мөкиббән китеп сөйли минометы хакында. Ә бит тыныч тормышта да, әллә ничә ел эшләп тә, үз һөнәренең әһеле була алмаучы, өстәл артында йокымсырап утыручы, хезмәтенең эченә керә алу түгел, тышкы ягында да куркып йөрүче ахмаклар, бюрократлар, «мин-мин» дип бугаз киереп бакыручы шалапайлар дөнья тулы. Тормыш әнә шундыйлар аркасында аксый, дөнья тәгәрмәче әнә шундыйлар аркасында акрын әйләнә, сугыш корбаннарының күплеге әнә шуларга бәйләнгән...



## Луиза Янсуар

### Дөньялыкта, фани мәңгелектә...

**1**

**Яшәү уйсулыгын иңләгәндә**
**Кай сукмактан үттек? Хәтердәме?**
**Күкләр—үткер... Никтер телә җанны**
**Әрем тәме—түрдә—бәгырьдәге...**

**Нидер калган төсле төгәлләнми—**
**Чәрдәк-чәрдәк күңел ихатасы...**
**Юраганны кабат язар өчен,**
**Бер кайтасы иде... бер айкасы**

**Хәтерләрнең кагылгысыз читен,**
**Бушанасы ялган тышаулардан...**
**...Бу гавәмнең ватык арбасыннан**
**Бардыр ләса—керсез төшә алган?!..**

**Бардыр ләса... җилгә, офыкларга,**
**Үләннәргә ятып тугарылган?..**
**Һәм сафланган... Тузан бөртеген дә**
**Сәламләгән, багып югарыга...**

**Юралганны кабат язар өчен**
**Агарасы иде сөрем-кердән...**
**...Күкләр—үткел... Үчлап хәтер йөген,**
**Үтәсе бар җанның шул үткелдән...**

**2**

**Табынма!**
**Бу Яшәү кабыгын**

Луиза ЯНСУАР—*шагыйрә; «Күзен ача умырзая», «Болан кызы», «Без җан өргән учак» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Салыр да, калыр җан ялангач...
Кайтулар булырмы яңадан?
–Бәлки, ал офыклар ялгангач?
Җир һәм Күк кушылгач бербөтен,
Җуелгач бар чикләр, кануннар...
Алданма!
Яшәүне кичкәч тә,
Адәмне әсирләр канун бар...

3

Бер тарая, бер киңәя офык...
Чиксезлеккә томырыла юллар...
Юллар тузаныннан чистарын да,
Үрләр томанына кереп югал!

Бар да фани гавәм хәтерендә
Калсын эзең, сүзең—тамырланып.
Таулар йөрәгенә ак кар ятар
Һәм куерыр Вакыт чатырманы...

Бар да үтәр, янә—кабатланыр,
Мәңъеллык төш балкышында күкрәп.
...Бер тарая, бер киңәя офык...
Һәм җан сулышыннан изри Күкләр...

4

Кемдер кагар әле ишегеңне
Дөньялыкта, фани мәңгелектә...
Һәм тамызыр йөрәгеңә зарын,
Бар сагышын—үргән көлтә-көлтә...

Иреннәрең биккә йомылгандай,
Өнсез торыр, йотып читнең гамен.
Һәм онытыр бер мәл үз газабын,
Үзәгеңдә тоеп дөнья гарен...

Кемдер атлар әле бусагаңнан,
Таң нурыдай кунар керфегеңә...
...Тоймый калма шулчак яшәү моңын
Тыйнак кына тамчы бөртегендә...

5

Мәңгелек сәфәрдән бүленгән,
Төшләрдән айныган мәлендә
Җан кайсы учакка укталыр,
Ымсынып онытылу тәменә?!

Кан кайсы туфракка ымсыныр,
Үзәкне актарып, сулкылдап?!
...Юралган Киләчәк эзенә
Бер толым нур төшә елкылдап...

Уйсудан уйсу бу гомернең
Татыннан айну юк тамчы да...
Бүзәргән офыкның ялына
Яшеннәр селтәнә—камчыдай...

Селтәнә яшәү дә, үлем дә—
Бер җанга уктала һәрберсе...
...Һәм бага һәркемнең күгеннән
Моң гына тибрәп үз Тәңресе...

## Сагыш алкасы

*Тоска—это скрипка...*
Синең сүзләр

1

Җан-күзгедә—иман сурәтеме?
Гөман—уйлар бизгәгеме әллә?
Үткәннәрдән килгән кайтаваздан
Киләчәкнең пышылдавын шәйлә!

Хәнҗәрләрме анда кисешәчәк,
Гомерләрме кыелачак кабат?
...Җавабы юк соравыңны җилләр
Учактагы уттай ала ялмап...

Болгар җәбе кайда өзелгәнен,
Киселгәнен кайда өметләрнең
Беркем белми... Йокымсырау йөрәк
Тыңлый җиде ятның үгетләрен

Һәм бертынсыз гына Күккә бага...
Тәңресенме эзли офыклардан?!
Бу уенда, ахры, безне кемдер
Сиздермичә генә отып алган...

Хәнҗәрләрнең йөзен кызартмыйча,
Иман җебен әллә кысып бәйлик?!
...Томанмы?.. Уй (?!)... пәрәвезе аша
Булыр-булмас Киләчәкне шәйлик...

2

Кабилләрдән килгән кыргый гадәт—
Канга сусау... Күкләр белән алыш...
Бу халәтнең сулкылдавык уты
Икебезгә безнең бердәй таныш...

Бу каһәрнең тамырдагы суты
Кемнәр җанын көлгә калдырмаган?!
...Тынгы тапмас әрнүле өн кайта
Бер кисәтү булып—гасырлардан...

Үзәкләргә алкаланган сагыш—
Шулмы йөртә хәнҗәр йөзе буйлап?
...Мәңгелекнең үзен даулаган җан
Биеп кенә үтәр аннан, уйнап...

Канга сусау... Һәм күзгә-күз калыш
Сөю аранында... яу кырында—
Кабилләрдән иңгән хакыйкыйлек—
Җанның меңьяшәүле бер сырында...

## Уйлама да...

Фанилыкның ачысына түзәр чаклар—
Бары кәгазь бүзләренә типчеп җанны...
Бу Күкләрнең юк хәтере...
Уйлама да
Яклар, диеп, беркөн кызып безнең хакны...

Саплам кадәр гомер барда йомгагында,
Кем яшәвен, кем бетемен сүтмәс адәм...
Ак болытлар иңсәсенә башым куям...
Азагы юк бу уенга—бер сүз: «Тәмам!»

Фанилыкның кайчысына түзәр чаклар
Затлыдан да затлы хәнҗәр айкап бары...
Бу Күкләрнең юк хәтере...
Уйлама да
Типчер, диеп, бәгыренә безнең зарны...

***

Юк, танымас безне быелгы Көз...
Нәүмизләнен түгәр сагышын
Тәрәзләргә, асфальт бәгыренә...
Яфракларның утлы каргышын
Җилгә чөяр диеп: «Йә, бигайбә!»
Кемгә кирәк үксез әрнүләр?!
Кемгә кирәк нидер исбатлаулар,
Дөньясында—үткәч кадерләр?
Тәрәзләрдән, асфальт итәгеннән
Бүлыр җыйган җанын—карышлап...
–Йә, исәнме, Көзем, таныйсыңмы?..
Мин—үземә хәзер табышмак...

***

Бер җавапсыз калган җаныбызга
Бер сораусыз гына бага дөнья...
Икебезгә уртак—ничә кыйтга!
Икебездән гали—күпме кыйбла...

Идел тып-тын җиз офыкка коя,
Айный алмый Сагыш хәмереннән.
Син өзәсең сызлап торган кылын
Бер аяусыз кемнең бәгыреннән?!

Эзләреңә һәр төн яфрак ява—
Гамьсез генә Көзгә керә калаң...
Хатлар оча җилгә, антлар яна,
Дөрләп тора җанда татлы ярац...

Икебезгә уртак—күпме кыйсса,
Һәм күпмесе әле көтә алда,—
Бер карусыз калган җаныбызга
Фал кодрәтен коеп боек таңда...



Тәлгат Галиуллин

## ИТЛЕ ПӘРӘМӘЧ

ХИКӘЯ

—Көзге яңгырлар башланганчы сәфәр чыгып, авыл һавасы сулап, дусишнең хәлен белеп, үзебезне күрсәтеп бер җилләнеп кайтыйк әле—дип, Нәкыйп симерүенә түзә алмаган кигәвен кебек, дусты Талипның теңкәсенә тиде, желегенә төште. Адәм баласы үзенә кирәккәндә моңлы да, шаян да була ала икән.

Икенде шәүләседәй озын буйлы, кыска итеп кистергән чәченә ак бәс кунган, икътисад фәннәре кандидаты Талипны нәфес корты «каршы килеп маташма, ризалаш, фани дөньясында бер тапкыр гына яшибез, форсатны ычкындырма» дип, котыртып торса да, үзе дә ышанмаган дәлилләрен китереп, карышкандай итте.

—Кайсы тарафларда безне шулай зар-интизар булып көтәләр инде? Бер әрсезенең баласы мина имтихан бирә алмагандыр әле?

—Юк ла,—диде Нәкыйп фикеренә ярдәм иткәндәй кулын болгап,—Нәрәстә районы хакимияте башлыгы Фәһим Юзликәев күптәннән чакырып интектерә. Аның күңеле үзе туып үскән кыпчак далалары шикелле киң диләр, кунакчыллыгы турында риваятьләр йөри. Аннан килеп, без аның белән Саратов партия мәктәбендә бергә укыдык. Минем дә дусларча ярдәмем ана күп тиде.

—Фикереңне ачыклабрак сөйлә,—дигән булды Талип, сүз ялгау өчен генә.

—Күп имтиханнарын минем конспектлардан файдаланып тапшырды. Кстати, ул үзе дә фән кешесе, доктор. Тик кайсы фәннәрнеке икәнен төгәен белмим. Мин аңа якын дустым, икътисад белгече, университет укытучысы белән киләм, рәхәтләнеп аралашырсыз дидем.

—Конспектлата ярдәмеңә ышанып кына ерак юлга чыгу дөрес

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938)—*язучы һәм әдәбият галиме; күпсанлы китаплар («Дәгъва», «Тәүбә», «Элмәк», «Төнге юллар», «Шигърият баскычлары» һ. б.) авторы. Казанда яши.*

булырмы икән? Булган, беткән. Аннан бит һәр нәрсәне төрлечә бәяләп була... Сабакташым «Нәкыйп Мухаметов минем дәфтәрләрдән күчереп отличниклыкта йөрде, дүрт ел буе үзен баржа тарткан бурлактай өстерәп бардым», диеберәк итеп берәр ирләр мәжлесендә ычкындырырсың дип, шаяртып, әңгәмәдәшенең нечкә кылларына кагылып, ирештереп алды. Нәкыйпнең хыял уены белән дөреслек арасындагы чикне шәйләп бетерә алмавыннан файдаланып, Талип шундый арзанлы үртәүләрдән ләззәт таба иде. Юмор хисе тумыштан кимә һәм анын һәр кешедә дә булу-булмавы күкләрдә хәл ителә, диләр. Партшколада алган белеменә, ишеткәннәренә, укыганнарына чын күңелдән ышанып яшәгән Нәкыйп өчен ул чор изге, ул биеклеккә шик белдерү Талиптан башка берәүгә дә рөхсәт ителми.

Аларның дуслык жепләре бик нык, әлегә аны өзәрлек көч тумаган иде. Танышу, якынлашу тарихыннан хәбәрдар булмаган кешеләр шөгыльләре төрле, холык-менәзләре үзгә булган бу ике ир-егетнең Әсәк белән Кесәк, хохол мәзәкчеләре Штепсель белән Тарапунькадай ахириләр булып, ни әйтешсәләр дә үпкәләүгә, рәнжүгә кадәр барып житмәүләрен аңламыйлар да, башларына да барып житми. Монысы адәм баласының килеп чыгышы кебек үк мәңгелек сер булып кала бирә. Фикерләү рәвешләре, табынган идеаллары төрле булу бер хәл. Тышкы охшашлыклары икесенең дә ике аяклы, ике куллы, бер борынлы, бер авызлы ата-ана балалары булуларыннан ары китми.

Көнбагыш сабагы мисле кояшка тартыла-тартыла артыгын үсеп киткән Талипның янында буе житәр-житмәс, конгырт күзләре кин маңгае эченә кереп оялаган, куе чәченә ак буяуның заты да эләкмәгән Нәкыйпне кечкенә дип булмый. Чөнки ул гел жиргә тартылып, буйга түгел, киңлеккә киткән, әйтерсең лә, кемдер, нәрсәдер башыннан басып торып, аңа өскә таба үсәргә ирек бирмәгән. Ашыкканда тук үрдәк кебек як-якка чайкалып йөрүенә карап торсаң Нәкыйп турында «абзый һәр адымының кадерен белеп атлый» дигәнрәк тәэсир калырга мөмкин иде. Тамакларын туйдырган һөнәрләре арасында да уртаклык юк дигән идек. Нәкыйп район дәрәжәсендәге оешмада бүлек мөдире, ягъни урта калыптагы чиновник булса, Талип—фән әһеле, укытучы, педагог. Әйтелгәнчә, бу аерма дуслыкларына хилафлык китерми. Атна-ун көн очрашмый торсалар, берсен-берсе ирләрчә сагына, ихластан юксына башлыйлар. Күрешкәндә исә, авызларын авызга куеп, аерылышырга уйламасалар да ирләреннән зарланудан тәм тапкан хатыннар кебек, сәгатьләр буе сөйләшеп утыра алалар.

Милләт балаларын якынлаштырган мәүзугъ озак еллар дәвамында жавапсыз табышмак булып кала бирде. Мәгәр ике кеше белгән сер—сер булудан туктый икән. Кемсәдер нәрсәдер ишетә, күрә, үзеннән өстәп, аны пышылдап кына күршесенең колагына ирештерә, ә тегесе «берәүгә дә ычкындырма, якын күреп сиңа гына әйтәм» дип, йомгакның очын өченче кешегә тоттыра, ниһаять, бу дуслыкның тамыры Мәдинә исемле дөнья бизәгенә барып тоташканы ачыклана. Урам сөләгәйләренең гайбәтенә ышансаң, берсенең дөньяда яшәве турында икенчесе хәбәрдар булмаган, югары уку йорты студентлары Нәкыйп белән Талип бер үк кызга бер үк вакытта гашыйк булып, сөю-сәгадәт нурларында коеналар. Алар фикеренчә: мондый чибәр, һәр яктан камил кыз жиһанда берәү генә, яшьлек дәрте калку күкрәгенә, нечкә биленә, төз аякларына сыеша алмыйча, уймактай жыйнак авызында, кайнар коймакны хәтерләткән иреннәрдә дәвамын тапкан. Һәммәсе бергә яшь-жилкенчәкләрнең башын әйләндерә, дөньяларын оныттыра.

Магнит кыры кебек үзенә тартып торган кыз тыштан жиләк кебек йомшак булса да, эче зәһәр, хисе аек акылга, исәп-хисапка корылган

булуын сөюдән күзләре тонган мәхлүклар башларына да китерә алмыйлар. Мәҗнүннәр белән аерым-аерым очрашып йөри дә кыз, икесенең дә күп балалы гаиләдән, стипендиядән башка керемнәре юклыкны, кыйммәтле бүләкләргә, рестораннарга хәлләре булмауны аңлап ала. Бар мөмкинлекләре бармак шомартып утыру, тезгә үрелү уе белән кинонын арткы рәтенә билет алуга кайтып калгач икесеннән берьюлы котылырга ниятли. Үзе шундый мәкерле фикергә килеп җиткәнме, берәрсе кинәшен кызганмаганмы, кыз гашыйклардан бер мизгелдә арыну әмәлен таба: егетләрнең икесен дә бер үк вакытка, бер үк урынга очрашуга чакыра. Берсе кулына арзанлы кыр чәчәге, икенчесе лимонад тотып, үз бәясен белеп, соңлабрак килгән кызны көтәләр. Бер үк чибәрне яратып йөрүләрен башларына да китермичә, талгын җил белән иңгән хушбуй тәме борыннарын әчетүгә, мәгъшукалары янына йөгерәләр.

Тездән югары чәчәкле күлмәк кигән, житен чәчле, аяз күктәй зәңгәр күзле, күпереп торган сөт өстен хәтерләткән ап-ак тәнле, бер күрүдә ирләрнең кыргый дәртен уята алырдай кыз бүген аеруча матур, очрашуга зур өметләр белән килгән ике дивананың күзләрен камаштырырлак, акылларын җуйдырырлык кимәлдә иде. Кыз ерактан күренүгә, берсе чәчәк бәйләмен, икенчесе татлы сулы шешәсен тотып сүнмәс-сүрелмәс мәхәббәтләрен изһар итү теләге белән сөеклеләре янына ашыгалар. «Нишләп йөри әле монда бу колга аяк астында буталып?» «Нәрсә калган бу бүтәкәгә минем кыз янында?» диешеп, егетләр бер-берсенә усал караш ташлыйлар да, мәрхәмәт көтеп, чибәркәйнең күзләренә ымсынып, нәүмизләнеп багып катып калалар. Мәдинә исә иреннән бер читенә тәкәббер вә битараф елмаю кысып чыгарып, тере сын шикелле басып тора. «А» да—юк, «Б» да чыкмый авызыннан. Чәчәкне дә алмый, суга да үрелми.

Дуамал көчләре ташып торган яшь җүләр егетләр гаепленен кем икәнен ачыкламастан, тар басмада бер-берсенә юл бирергә теләмәгән тәкәләр кебек, акаешып торалар да, Нәкыйп «кем исән кала, кыз шуңар була» дип, җан авазы чыгарып кычкыруга хисләрен йодрыкларына төйнәп, аякларын, маңгайларын ходка җибәреп, борыннарыннан шарлап кан киткәнче, шешенеп беткәнче сугышалар. Нәкыйп көндәшенең ияк астына үреләә, ике бот арасына тибәргә тырыша, Талип үз югарылыгыннан «бүтәкәнен» башын, иннәрен төя. Көндәшләр тәмам хәлдән таеп, җирдә авыр сулап ятканда, тиләләр орышын елмаеп багып торган сценарий авторы сөйгән егете алып биргән француз туфлиләре үкчәсендә зырылдап әйләнә дә: «кстати, тамаша кызык булды, рәхмәт сезгә, тик мине әти-әни хәерчеләр өчен үстермәгән, мин башканы яратам, мине артык борчымавыгызны үтенәм, чао!», дип китеп тә бара. Аякка күтәрелерлек тә көчләре калмаган, язмышларына ярык тагарак кына насыйп икәнлекне гарьләнеп, үрсәләнеп аңлаган, шул ук вакытта өсләреннән ниндидер йөкнең төшүен сизенгән, кызнын җылы тәне урынына яралар, кара тимгелләр алып, бит сыйпап калган көндәшләр борыннарыннан килгән хәләл каннарын сөртеп, тормышның әле дә дәвам итүен, кыз ташлап кына ахырзаманның җитмәвен калебләре белән сиземләп, яткан җирләреннән бер-берсенә карашып, көлешеп җибәрәләр.

Беренче булып Талип телгә килә:

—Минем әти «ике чәүкә сугышканда кара карга тук була», ди торганые. Хәзер генә бу мәкальнең мәгънәсен аңладым. Без үләксә өчен сугышкан чәүкәләр булабыз, ә сөеклебез кара карга кочагына чумды, шул кирәк без мәхлукларга.

Нәкыйп үрмәләп диярлек Талип янына килеп, киләчәк дуслыклары намәнә кулын бирә:

—Әйдә, каныбыз тамган, мәхәббәтебезне күмгән җирдә гомерлек дус

булырга ант итешик. Бер дә борчылма, безгә насыйп кызлар үсә торсын! Тулай торагыбызга кереп юынып алыйк та, үзебезне тәртипкә китереп, Маяковский клубына тансыга юл тотыйк.

Килешү янәдән каты итеп кул кысышу белән раслангач, бер-беренә карашалар да кычкырып: «Карале, ничек кызык итте безне бу кызый, бик хәйләкәр нәмәстәкәй булып чыкты шайтан, пичтән әле генә алынган итле пәрәмәч безгә тәтемәде шул, рәхәтен башкалар күрәчәк»,—кебек сүзләрне кабатлый-кабатлый сагышлары, көенү-үкенечләре, эчке моннары чыгып беткәнче, туктала алмыйча көлешәләр. Очраклы узып баручы туктап боларга карап, бармагын чигәсенә тидереп тора башлагач кына, аннарына килеп, капылт борылып тулай тораклары ягына китеп баралар.

Менә шундый монлы шартларда туа бер туганнар арасында да сирәк очрый торган көнләштерерлек, гыйбрәтле дуслык.

Икътисад фәненен нигезендә һәр шәйне шик астына ал, чагыштыр, сына кебек төшенчәләр ята, диләр. Шул юнәлешнен докторы булу турында хыялланып йөргән зат буларак, Талип янәдән булачак сәяхәтләренен бер хәвефле ягын ачыклау нияте белән яна сорау тартып чыгара:

—Безләрне кунакка чакырган адәм бергә укылган, эш беткән, узган эшкә салават димәсме икән? Димәк, җөмлә ахырына нокта куелган. Анын бергә студент булып йөргән еллары якты истәлек булып томан артында калды, Сарытау чабатасы искерде дип әйтүе мөмкин түгелме? Аннан килеп, шәһәр исемен дәгъвалап йөргән алдынгы районга килеп-китеп йөрүчеләрдән юл өзелми, диләр. Депутатлар да, халык мәнфәгатьләре турында кайгыртып, борчылып ул төбәктә еш булалар, дип ишеткән идем.

Буе тәбәнәк булса да, зур башлы, коңгырт күзе елгыр Нәкыйпне тәвәккәлләгән фикереннән, ми шәрифләрен бораулаган уеннан кире кайтаруы ифрат кыен, хәтта гайре табигый шөгыль иде. Соңгы тиенсез калыр, әмма үҗәтлеген итәр.

—Фәһим Сабирович яхшылыкны оныта торган кеше түгел. Берничә көн элек кенә үзен бер зур җыелышта очраттым. Чакыруын тагын кабатлады. Бармасак просто яхшы түгел, кешене үпкәләтербез.

Талип, матурлыгын мактаган саен күнеле йомшара барган кыз кебек, үзендә дә юлга чыгу уе өстенлек ала баруын тойды. Сарытау партшколасында янә бер кат психология фәнен укыган Нәкыйп дустынын күзләрендә, гольфстрим агымы килеп кергәндәй, җылылыкның артуын, басым ясауның файдасын сиземләп, саклабырак торткан дәлилен, уен тузын чыгарып сала.

—Без ул яклардан әйләнеп, болганып кайтудан берни югалтмыйбыз. Бердән, соңгы вакытта үзебез дә сирәк күрешәбез, дөнья мәшәкатьләре басты, сөйләшәсе сүзләр, кинәш-табыш итәсе әйберләр җыелды. Машинаның арткы утыргычында иркенләп аралашып барырбыз. Икенчедән, шашлык, бәлеш, тутырма, кызыл балык, авыл тавыгы ашап, мунча кереп, кешечә сыйланып кайтырбыз.

Үзе санап үткән ризыкларнын берсен алдавыч жим итеп сайлап, Талипның колагына үрелеп, Нәкыйп сүзенә үтә бер серлелек төсмере бирергә тырышты:

—Син, Талип, ничектер, мин үзем шашлыкның үзеннән бигрәк исен үлеп яратам. Анын шаян җил алып килгән хуш исе сихри көчкә ия, күнелләрне иләсләндереп, яшисе килүнен мәгънәсен кинәйтә. Ашый башлагач, серлелек югала. Мин үземнең бүлектә тарханга, шашлыкка чыгып керәбез дигәч, күбесе төкерекләренә буылып, көнләшеп калдылар. Юзликаев шашлыкны сарыкның кабыргасыннан, сөяге белән зур итеп ясата, ди. Гадәти кеше генә түгел шул минем сабакташ,—дип сүзен тәмамлады Нәкыйп, күнелен

иләсләндергән горурлык хисен яшерүне кирәк тапмыйча.

Талип хыялый сәрхүш дустын җиргә төшерү вакыты җиткәнне сизде.

—Синең хыялларың, абзый, бик зурдан. Өметең боз тавына килеп сөртенгән кораб кебек уалса, акланмаса нишләрсең? Куаныч куыгың буш булып чыкса. Шашлыкның исен дә исни алмыйча калсак? Японнар гомерләрен озайту чарасы итеп, әүвәл ярты сәгать ризыкның исе белән канәгать булып утырсалар да, соңыннан аны бик тәмләп ашап куялар, ди. Шунысын да бар, әле, ягулыкка түккән акчага «Буш» тавыгы аякларын сатып алып, шашлыкны үзебез ясап, син аның серле исен туйганчы иснәп, мин мескенең итен кимереп бәйрәм итсәк, арзанракка да төшәр, ышанычлырак та булыр кебек.

—Ничек инде арзанракка төшәр. Аңа күпме тәмләткеч, әзерләргә вакыт, утын кирәк. Ә юл романтикасын, яңа кешеләр белән аралашу шатлыгын кая куясың? Сиңа җирдән шуышып барырга гына булсын. Романтиканы аңламыйсың! Хакимият башлыгы итеп теләсә кемне куймыйлар, аның белән аралашу үзе ни тора! Аның һәр өлкәдән продвинутый кеше булуы турында легендалар йөри. Дөрес, үзе башлап җибәрсә, берәүгә дә сүз бирми, ди. Кунакта анысына гына түзәсең инде.

Бер-ике көннән юлга чыгарга тәвәккәлләп, кул бирешеп саубуллашкач та, Нәкыйп үзен якында гына көтеп торган машинасы янына ашыкмый. Төп мәсьәлә хәл ителгәч тә әле чалбар балагына ябышкан кырмавыктай кечерәк мәсьәләләр калган булып чыга. Нәкыйпнең янә бер үзенчәлекле сыйфатын әйтмичә булмый, ул—дәрәҗәсен төшерә торган вак саранлык. Сугыштан соңгы елларда күп балалы гаиләдә черек бәрәңге коймагы, алабута шулпасы ашап, әтисез үсү галәмәтеме, башка берәр сәбәбе бармы, өздереп әйтүе кыен. Талип «ни әйтсәң дә, Нәкыйп егет кеше инде, вакланып тормый», дип уйлап та өлгерми, тегесе мичкәле балга бер кашык дегетне тамыза да куя: әлеге дә баягы вакчыл саранлыгы калкып чыга. Талип дустының машинасына утырып китәргә ашыкмавын өстәмә бурыч куясы буладыр дип фаразлады. Бу юлы да элеккеге көндәше аның «ышанычын» аклады. Нәкыйп бәдәненнән кыскарак аякларында таптанып алды да:

—Машина олы юлга чыгарга ажгырып тора. Өр-яңа двигатель куйдык. Ягулык ягы гына кыенрак. Минфин безне бик нык кысты, көненә нибары ун литрга калдырды. Ярты юлга җитәрлек запасыбыз бар бугай. Нәрәстәгә барып җитәр өчен кимендә бак ярым ягулык кирәк. Нишләрбез икән?—дип, коңгырт күзләренә, киң маңгаена, борыны читендәге миңенә чарасызлык тудырган сипкелле моңсулык йөгертеп,—Талип ягына борылды.

Казан университеты доценты, янәсе, бәгъзенең икътисадый хәленә кереп, аны аңларга, киңәш бирергә, ярдәм кулын сузарга тиеш. Гадәттә, минем йомыш белән йөрибез, чит машина ялласаң, кыйммәткәрәк төшәр иде, бензин миннән булыр, дип, дустын «кома»дан чыгаргалаган Талип бу трит Нәкыйпнең сораулы-ялварулы карашын соры күзләренең корычтай катылыгы белән каршылады.

—Минем акча ягы такырырак шул, малай. Булганда кысылып тормаганымны беләсең. Хатын йокы бүлмәсенә кыйммәтле австрийский гарнитур алып кайткан—дип, бик тәмләп зарланып алгач,—соң, бензин мәсьәләсе бик авыр булгач, эч пошырып, кычытмаган җирне кашып, көпчәк һәм туфлиләр туздырып йөрмик! Ул тарафларда безне зар-интизар булып көтеп торучы кызлар да юк бугай. «Башкорт бәхете»ндә Исхакый күкрәкләре мул булса да, мишәр кызлары бик усал, телләренә шайтан төкергән дип язган түгелме соң?

Нәкыйп бокс уенында дошманнан саклану алымына ошатып ике кулын аркылыга куйды. Район хакимияте башлыгы белән күрешүгә каһәр суккан

бензин аркасында гына бармый калып буламы соң, тузга язмаганны.

—Юк, юк, бер килешкәч, юлга чыгабыз булгач, чыгабыз. Шундый олы кеше үзе (бу сүзгә басым ясады) чакырып торганда бармый калу һич кенә дә дөрес булмас.

Ак дымлы тешләрен ялтыратып, кеткелдәп алганнан соң, өстәп куйды.—Ягулыкны эзләп карармын. Берәр дусны кысармын. Әйткәнемчә, кара сарык кабыргасыннан ясалган шашлык искә төшкәч, авыздан сулар килә, эссе мунчасы күз алдына килеп баскач, аркалар кычыта башлый. Фәһим Сабировичка хас кунакчыллык гаҗәеп диләр. Безне дә ашатып-эчертеп, тәмам хәлдән тайдырмыйча, җибәрмәс дип уйлыйм.

Инде икенче тапкыр саубуллашкач та, Нәкыйп Талип яныннан китәргә ашыкмады. Аны нәрсәдер бимазалый, агач корты кебек җанын, миен эчтән кимерә. Борчылуының сәбәбен ачыклый алмый интеккәннән соң, зиһен капкачы ачылып киткәндәй булды. Ул үзен ни, нәрсә бораулаганны аңлады. Бөтен авырлык аның өстенә төшә түгелме соң? Глава белән ул сөйләште, машина аныкы, ягулыкны да ул табарга тиеш. Ә Талиптан нәрсә: газ биреп торган машинага кияү егете кебек колга гәүдәсен ташлый да, шуның белән вәссәләмме? Дус дигәч тә, алай ук салынырга ярамый.

Акча юк дип шомарткан була, хәчтрүш. Дуслык ул бәллүр савыт кебек, аны саклый белергә акыл кирәк. Кысмырлыгы олыгайган саен көчәя баруы сизелә. Башына шул мизгелдә күктән ингәндәй яңа фикер килде.

—Карале, Талип, без юлга чыгасы көнне бик иртә кузгалабыз: ашарга да, эчәргә дә өлгермибез. Безнең юл өстендә, чамалавымча, кафе-мазар юк, нишләрбез икән?—дип, дустын, әлеге тәкъдимне кабул итәргә әзерләгәндәй, тавышына инәлү катыш кызгандыру төсмере чыгарырга тырышты. Мәгәр икътисад белгеченең кырынганда бит уртасында пәкегә эләкми калган йоны да селкенмәде.

—Ну и что! Ачка үлмәбез әле. Аш казаныбыз ял итәр. Табыныбыз хуш килмәде бугай дип хуҗаларның кәефен бозмас өчен кунакка ашамыйчарак бару лязим (монысы узган ел Төркиядә ял итү җимеше) диләр.

—Синең хатын итле пәрәмәчне тәмле итеп пешерә, безгә юлга әзерләп җибәрмәсме икән дип кенә әйтмәкче булган идем.

Нәкыйпкә, кулын селтәп, машинасына титаклаудан башка чара калмады. Талипка сиздермәсә дә, Нәрәстәгә дәшкән сәяхәтнең нәтиҗәсе өчен Нәкыйп бик борчыла иде. Сәбәбе шул: урамда очраклы күрешкән, авыл хуҗалыгы министрлыгында эшләүче бер танышы аның күңеленә акрын гына, әмма гел кимереп торырлык корт, шул ук вакытта начар камыр кебек кабара торган шөбһә салды.

—Фәһим Сабирович хозурына барырга җыенасызмы? Хуш, хуш. Ифрат киң күңелле, шул ук вакытта кырыс, усаллана торган шәхес. Аныңниндирәк вакытына туры киләсез бит әле.

—Анысы нәрсә була инде? Без сабакташлар, партшколада бергә укыган идек,—дип мыгырданды, югалып калган Нәкыйп.

Чиновник җитди сер белгән кешедәй вәкарьлек белән генә борын очына төшкән күзлеген өскәрәк күтәреп куйгач, фикеренә ачыклык кертте.

—Үзеннән-үзе килеп чыгамы, әллә вакытын шулай шәрехләп куямы, ул атнаның һәр көнен аерым проблемага багышлый, диләр. Сүз килгән кунакларның күңелен күрү турында бара.

Берни аңламаган Нәкыйп:

—Кызык,—дип куйды. Күз алдыннан бер-бер артлы төрледән-төрле күңелле һәм шөбһәле манзаралар узды.

—Әйтик, атнаның бер көнендә ул читтән килгән кешеләрне атлары янына алып бара, һәр тулпары турында озак итеп сөйли, малкайларына шикәр, чәк-

чәк ашата. Икенче көнен бодайның яңа сортларына, арыш белән кушылган төренә, солыга, борчакка багышлый. Әлбәттә, инде кунаклары аның белән көне буена кырда йөри. Өченче бирмеш көн Германиядән, Украинадан кайткан комбайннарга, аларны чагыштырып бәяләүгә корылган булырга мөмкин. Пәнҗешәмбесе тарихка багышланып, татар халкының фаҗигале язмышы өчен сагышлану көне булгалый. Аннан соң бит әле бөеклек өянәге кабынган вакыты да, хәмергә сәлам биреп алган көннәре дә булгалый... Бәхетегезгә нинди туры килә инде. Кайсы йолдызлык астында тугансыз бит,—дип, кычкырып көлеп, Нәкыйпне кантарлы уйлары белән ялгызын калдырып, үз юлы белән китеп тә барды.

Юлга чыгасы көннәренең ямьле, матур булуына өметләнүләре дә, гозерләре дә фәрештәнең амин дигән вакытына туры килмәде. Иртә шыксыз, нурсыз иде. Кояш чыгаргамы, юкмы дип икеләнеп күк читендә, болыт астына яшеренеп, иркәләнеп ята. Әбиләр чуагы керфекләрен җиргә индерергә ашыкмый.

«Волга» машинасы ерак сәфәргә чыгуга шатлангандай, гайрәт белән көчкә табылган ягулыкны яндырып (Нәкыйпне көендереп), тыныч, төзек, калай түбәле татар, җимерек, беришесе хәрабә хәленә килгән урыс авыллары яныннан элдертүен белә. Нәрәстәгә чаклы өч йөз чакрым юлның үтелгәнен сөйләшә-аралаша, берсен-берсе чеметкәли барып, сизми дә калдылар.

Уннарга килеп җитсәк, бик шәп булыр иде дип, фараз кылулары хакка чыкты. Уйланылган вакытта кара һәм саргылт туфлиләр Нәрәстә асфальтын бәхетле иттеләр. Шәһәр исемен алуга дәгъва итүче район үзәге ишләреннән бер ягы белән дә аерылып тормый дисәң дә, зур хата булмастыр. Күзне иркәләрдәй үзенчәлекләре бер тирәгә—үзәк мәйданга сыешкан. Уң якта, утыртылган чәчәкләргә күмелеп, гавамга кайсы якка юл тотканда бәхетле буласыларын кулы белән күрсәтеп, Ленин бабалары басып тора. Акыллы кеше булгандыр, ахмакны монда тотмаслар иде. Юлбашчы сынының сул ягында матур соры төскә буялган элекке райком, хәзерге хакимият урнашкан ике катлы бина кәперәеп утыра. Иң зирәк фикерләр район халкына шуннан индерелә. Ильич һәйкәленең уң ягына, юлны аркылыга бүлеп, мәдәният сарае утыртылган. Хакимиятнең акыллы боерыкларын үтәгәннән соң, халык шунда ял итәргә, күңел ачарга агыла имди. Нәкыйпнең аларда кайгысы юк. Шәриф Камалның үзен озатырга вокзалга килгән халык алдында тотачак нотыгын кат-кат кабатлаган депутат кебек, хакимият башлыгына әйтәчәк сүзләрен Нәкыйп киченнән уйлап, шәрехләп, күңел, йөрәк дәфтәренә язып куйган иде. Юк-бар сөйләп абруй төшерү вакыты түгел.

Очрашу мизгелләрен күз алдына китерүе кыен булмады аңа. Зәңгәр күзле, аксыл чәчле, билләре төклетуранықы кебек эчкә тартылып торган, озын аяклы сәркатип кыз кунаклар килеп төшү хәбәрен хуҗасына ирештерүгә, шул мизгелдә үк, махсус көтеп торгандай, олпат гәүдәсен туры тотып, агара башлаган чәчле мәһабәт ир атылып килеп чыгар да, заманында кылган изгелекләре өчен, рәхмәт сүзләрен догадай колагына пышылдый-пышылдый, Нәкыйпне кочагына алыр, аркасыннан сөяр, бәлки, яңакларын битенә тидереп алыр, шуннан соң гына, монда тагын бер бәндә бар икән әле дигәндәй, авызын ябарга онытып торган Талипка олы учын сузар. Кабинетка керә-керешкә Нәкыйп күптән килергә әзерләнеп йөрсәк тә, тиз генә чыгып китеп булмады, ниһаять сине (бәлки, кеше алдында сезне кирәк булыр) күрү бәхетенә ирештек, яшәреп, матурланып киткәнсең, Дәүләт советы оештырган җыелышта арганрак күренгән идең кебек, күңел түреннән ургылып чыккан мөкатдәс уйларын чәй өстәле янында яисә ресторанда дәвам итәр. Анда абзагыз Юзликәевкә кабатланмыйча кына нәрсә әйтәсен белер: партшколада укыткан профессорларны үртәп, ирештереп, беришесен

мактап искә алыр, төне буена кәрт уйнап, йә хәмер чөмереп утырганнан соң, зачет-имтиханнарны унышлы гына аударып кайтуларын әйтеп көлдерер. Күз төшүгә ир-атның дәртен утка тарган дарыдай кабыза, каны кайнап, иреннәре наз бөркеп торган тулы күкрәкле җыештыручы маржага җылы мөнәсәбәтләре турында әйтү урынлы булырмы икән, дөрес аңлармы? Син арага керден дип шул хатын өчен ду тузып миннән көнләшеп тә йөрде бугай. Ә бит майлы калҗа икесенә дә тәтемәде: бөтенләй өченче кешегә—бер чанта кара уылдык, бер ящик коньяк төяп килгән калмык мужигына эләкте. Без кылтаеп, маржаны күз белән ашап йөрүдән уза алмадык. Бу хакта, бәлки, Рим сенаторлары кебек, аякны суга тыгып, җылы мунчада сыра чөмереп утырганда елмаеп искә алырмын. Талип белән мондый тормыш нечкәлекләре турында киңәш-табыш итеп булмый шул, аңа ни, арба ватылса утын, үгез үлсә ит, хатыныннан итле пәрәмәч тә пешертә алмады, өйдә юк дип алдый булыр, бичәсе көнбагыш ашап, минералка эчеп, телевизордан сериал карап утыра торгандыр әле. Чын тормыш дәресләрен партшколада гына алып була иде шул, демократия дигән нәмәстәкәйләре шундый мәдәни-сәяси үзәкләрне бетереп, начар эшләде. Хәзер әнә Рәсәй президенты әзерлекле кадрлар житешми дип зарлана. Үзенә күрә генә түгел, «коммунистлар мәктәбендә чарланган кешеләр кушканны сукырларча үтәүче роботлар, өсләренә бурыч алып, иҗади эшли белмиләр», дигән була әле, саламторхан. Бу бит Талипның үз ми казанында туган фикер түгел, көнче ташбакалар тараткан гайбәтне, суфыйлар эчтәлеген аңламыйча ятлаган дога кебек, кеше сүзен кабатлый. Бу уйлар Нәкыйпнең башында туктаусыз чуалып, килеп җиткәч кенә төгәлләнгән нәтиҗә төсен алдылар.

Мосафирлар үзәк мәйданны күпне күргән тәҗрибәле күз карашы белән инләделәр дә, бая әйткән ике катлы бина эченә кереп бөялделәр. Кабул итү бүлмәсе ишеген үтеп, өстәл артында утырган җаваплы ханымга күз салуга Нәкыйп югалып калды. Уң ягына ак, кара, кызыл телефоннар тезелгән шома өстәл янында хыялында йөрткән чибәр, мөлаем, нәзек билле кыз урынында күн тышлы кәнәфидә яшен яшәгән, киселгән урмандай сирәк чәчләрен көл төсенә буяткан, сусыл күзле ханым утыруы Нәкыйпнең күңеле сүрелүгә, кәефе кителеп төшүгә беренче сәбәп булды. Аның партшкола югарылыгындагы нәзберекле зәүкы ханымны кабул итмәде. Чакырылмаган кунаклар ягыннан иңгән кара дулкын сәркатипкә барып җиттеме, әллә инде ул мондый япанчылардан гарык булганмы, шакы-шокы итеп каты басып кергән озын вә кыска ирләргә сөзеп карады да, урыныннан кымшанмыйча гына:

—Сезгә кем кирәк?—дигән җөмләне кысып чыгарды.

—Без глава янына килдек,—диде Нәкыйп, мангаена тир бәреп чыгуын ханым ягыннан килгән итагәтсезлеккә юрап.

—Йомышыгыз нинди? Бәлки, урынбасарлары хәл итәр?—дип сусыл күз өстәлнең икенче ягыннан теркәү журналын алып, кем булуларын, каян килүләрен язып куярга җыенды.

Фәһимгә ныклап әйтәсе булыр, үзен хур итеп, ямьсезлеге генә җитмәгән, мондый илтифатсыз, тәрбиясез хатынны янында тотмасын, аның урыны гардеробта кием алып тору. Кем икәнлегебезне, нәрсә сорап килүебезне теркәп ала имеш, тузга язмаганны... Яратмасаң да, кабул итмәсәң дә, теге дөньядан килеп төшмәгәнлегеңне, ишәк түгеллегеңне аңлатырга туры килә моңа.

—Без Казаннан Фәһим Сабировичның шәхси чакыруы буенча килдек. Рәсми йомышыбыз юк.

Партшколада бергә укыганыек дип тә өстәмәкче иде дә, вакытында теленә тыю салырга өлгерде, ни өчен әле бу килбәтсез ханымга хисап

биреп торсын! Вакытында тукталып кала алуы өчен искә төшкән саен үзен кайта-кайта мактады.

—Безнең кайдан килгәнне кереп әйтүегезне сорыйбыз,—диде Нәкыйп, җитдидән кырысрак тон белән.

Ханым торырга җыенып, урынында кымшангандай булган иде, телефоннарның берсе зеңгелдәде.

—Алло! Рәсимә синме? Исәнме, ахири. Хәлләрме, ярыйсы, эш күп, бертуктаусыз кеше. Менә бүген үземә файдалы эш эшләдем: килүенчә базарга кереп өч кило яхшы кишер алдым. Бәясе дә по-божски булды. Чуашлар яшелчәне үстерә белә. Тырыш халык. Бик комсызлар да тегел. Гафу ит, Рәсимә, икенче телефон шалтырый.

—Улым, тордыңмы? Бик иртә уянгансың әле бөген!—дип, сирәк тешләрен күрсәтеп кеткелдәп алды.—Бәрәңге белән кәтлит плитәдә. Җылытып аша. Пока, улым, шеф чакыра.

Телефонын шап итеп урынына куеп, ханым имән ишек артына кереп югалды. Төп кабинеттан чыккач та, чакыру сүзен әйтергә ашыкмады. Өстәле янына кереп утырып, тулы гәүдәсен җайлаштырып куйгач кына:

—Фәһим Сабирович бик важный эш белән утыра. Бераз көтсеннәр диде.

«Көтсеннәр» сүзен Нәкыйп ифрат авыр кабул итте. Әйтерсең лә, аның башына бер чиләк салкын су тондырдылар. Талип каршында олы абруеның бер чите убылып төшкәндәй булды. Ачуы чыгудан каны кызган табадагы май кебек чытырдап кайнаса да, тынычрак булырга тырышып:

—Сез безнең каян килүебезне, кемнәр булуыбызны әйттегезме?

Төксе тавыш «хуҗа барысын да белә» дип әйткән мәлдә, үзара элемтә уты кабынды. Нәкыйпкә таныш та, ят та тавыш:

—Кунакларны утырышлар бүлмәсенә кертеп утырт. Бушагач, мин дә шунда чыгармын,—дигән әмер төшерде. Исәнмесез дә, сау булыгыз да юк.

Нәкыйп өнсез калды. Ничек аңларга инде Юзликәевнең бу кыланышын? Бүлмәсенә чакыртып алып яисә үзе имән ишекне тупсаларын каерырлык итеп ачып, йөгереп чыгып кочаклап аласы урынга, утырышлар залына озата. Язылмаган кануннар буенча сабакташлар арасында кем булсан да, рангларга бүлешү, болай ук кыйландыру кабул ителмәгән кебек иде. Аяк табаннарыннан күтәрелгән үпкә катыш рәнҗү хисен басарга тырышып, Нәкыйп хакимият башлыгының бу адымын аклау юлларын эзләде: янында Мәскәү кешесе утырмаса да, финанс оешмасыннан тикшерүчедер әле, соңгы мәлдә бюджет акчасының кая тотылуы белән бик кызыксына башладылар дип, үзен дә тынычландырырга тырышты. Партшколада иң кыен мизгелләрдә дә сабыр була белергә, язмыш басымына баш бирмәскә өйрәттеләр түгелме соң бәгъзеләрне?

Ямьсез ханым аларны коридорга алып чыгып, бөтенләй икенче якта урнашкан зур бүлмәгә алып керде. Кыл уртада олы түгәрәк өстәл тора, сул як дивар буйлап тезелгән язу өстәлләренә төрле китаплар, белешмә карталар, кубоклар тәртип белән тезелгән.

Каршылыклы хисләр ташкынын, миен бораулаган күп санлы сорауларны басарга тырышып, тәкъдим ителгән стендлар белән танышкандай иттеләр. Вакыт отыры акрын узды. Сәгатьнең башка шөгыле булмагач, көндезге уникегә үк килеп җитте. Егетләрнең ашыйсы килеп, эчәкләре түбән авыл этләредәй тавыш күтәрә башлады. Хатыннары пешергән ризыкны—Нәкыйп кәбестәле ашын, Талип итле пәрәмәчен уртлап утырасы урынга үз теләкләре белән җәһәннәм читенә килеп, ач килеш алдынгы сыер савучының нурлы йөзенә, базарда ит чабучының (анысы ничек районның алдынгылар альбомына эләккәндер, бер Алла белә) тук чыраена карап утырырга мәҗбүрләр. Рәсемнәрдән илһам алып, үзара хәзерге заман

кунакчыллыгының янарган эчтәлеге турында гәпләшүгә күчкән дуслар икенче якта стенага сыланган ишекнен тавышсыз гына ачылып, Голливуд фильмнарындагы шикелле, жир астыннан калыккандай, алларында хакимият башлыгынын басып торуын күргәч, каушап калдылар. Берсе якыннан, икенчесе жыелышларда, зәңгәр экранда күргәннәре булса да, район хужасынын мәһабәт гәүдәсенә, иллене узган булса да, житезлеген жуймаган йөрешенә сокулануларын яшерә алмадылар. Бирсә дә бирә икән Ходай яраткан колына. Сина, мина, Нәкыйп белән Талип иптәшләргә тиешле сыйфатларны бер кешедә жыеп күрсәткән. Буй-сынның килешле төзлеген, иннен кинлеген, таза муенга утыртылган чал чәчле олы башның горур тотышын, сырлары да килешеп торган мангайнын күп акыл жыярлык кинлеген, тиресенә сыеша алмыйча, икегә аерылып, алга чыгып торган иякнен эрелеген, шулар өстенә елмаюга әзер иреннәрнен кабарып торуын әйтәсенме? Кайнап торган ирлек сыйфатлары, үрчемле кан билгеләре һәр күзәнәге хәрәкәтеннән сизелеп тора. Һәммәсе искитмәле үз урынында. Шулары гына житмәгән: ипигә сылап ашардай кара жирле, тимер юллы, жир асты байлыклары хәттин ашкан, эшчән халыклы вилаятне кулына тотырганнар. Тик менә чәнечкеле яшькелт-соры күзләре генә бу гәүдә өчен кечерәк булып күренделәр Талипка. Ә Нәкыйпнен Фәһимгә нисбәтән партшкола мәхәббәте дөрләп уянып, сөякләре таралып, аңы чуалып киткәндәй булды. Житмәсә, әле шундый кеше, сабакташын танып, бөркет канатлары кебек кулларын як-якка жәеп, Нәкыйп янына үзе килеп, кочаклап алды, аннан, учын турайтып, исем-фамилиясен әйтеп, кулын Талипка сузды.

—Егетләр гафу, гафу. Бераз көттердем бугай. Эшләрнен бик тыгыз вакытына туры килдегез. Мавыгып та киткәнмен. Мин районда, бәлки, республикада яна башлангычка нигез салдым. Бер кая да эшләми, укымый торган, шаляй-валяй йөрүче, араларында хулиганнары да булган яшьүсмерләрне исәпкә алып, һәрберсен тәрбияви эш алып бару өчен район житәкчеләренә беркетеп чыктым. Үземә иң юлдан язганын сайлап алдым. Хәзер шул малай—Андрей Морозов белән бикләнеп, ике сәгатьләп сөйләшеп утырдым. Яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләр, урыннар бүлешү турында күп нәрсә белдем. Андрейга яшьләрне теннис уенына тартып кертүне тапшырдым. Кыскасы, очрашудан бик кәнагать калдым.

Нәкыйп белән Талип ирексездән күз карашлары белән алыштылар: глава бүлмәсендә үтә «важный» персона булган икән шул. Шунын белән кереш сүзен тәмамлап, хужа түгәрәк өстәл башына барып утырды, янына кулындагы бер кап сигаретын, кабызгычын куйды. Кул ишарәсе белән кунакларны янына чакырды. Хәл-әхвәл, һава торышы, юл мәшәкатьләре, районда урып-жыюнын тәмамланып килүе, ашлыкнын күпмерәк чыгуы, яңа сорт бодайда клейковинанын микдары турында кыскача гына фикер алышканнан сон, Фәһим Сабирович, әфисәр бармагын кабызып, үзенә бер нәзакатьлелек белән һавага төтен жибәреп алгач, төп темасына күчүгә зәмин әзерләде.

—Сез менә укыган кешеләр, яна танышкан иптәш икътисад фәннәре кандидаты дидегез, Нәкыйп ике югары уку йортынын башын чукыган кеше...

Үзе дә көтмәгән кыюлык белән Нәкыйп нотыкчыны бүлдерүгә жөрьәт итте.:

—Юк, дөрес түгел. Минем өч дипломым бар. Университетнын тарих факультетына кергәнче, мин Лаеш авыл хужалыгы техникумын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган идем. Партшколада бергә укыганны хәтерлисездер, Фәһим Сабирович!

Хакимият башлыгы сүзен бүлдерүчегә үгез кызылга караган кебегрәк күз ташлап алды да, Нәкыйпнең Лаеш дипломына мөкиббән китмичә, сүзен дәвам иттерде.

—Ә шулай да безнең як тарихын белмисез. Андыйлар (укы: наданнар) күпчелек. Янәсе, Нәрәстә төбәге ундырышлы җире, унган чуаш һәм мишәр халкы, күптән түгел табылган нефте белән генә атаклы. Юк, җәмәгать, бу берьяклы караш, бу яклар элек-электән югары мәдәниятле, татарның асыл егетләрен үстергән, укымышлы затлар биргән төбәк булган. Берничә ел элек кенә мин чакырган археологлар Бизләү авылы янында зиннәтле әйберләр, хатын-кызлар кулланган алтын-көмештән ясалган беләзекләр, чулпылар, ярым ай ясалган алкалар таптылар.

«Карале, бүген нинди көн соң әле, атна кич—пәнҗешәмбе ләбаса, димәк, без тарих көненә туры килгәнбез», дигән уй Нәкыйпнең миен тырнап узды. Ерак үткәнне искә алу көненең ахыры ничек тәмамлана икән? Талип озын муенын тагын да сузарак төшеп, нотыкчыны йотлыгып тыңлый.

—Бизләү элек җиде мәхәлләле, җиде мәчетле зур авыл булган. Анда зыялыларны, дин әһелләрен әзерли торган мәдрәсә гөрләп эшләгән. Утыз Имәни дә әллә үзе укыган, әллә берничә ел укыткан ди шунда. Кол Гали эзләрен дә таптылар галимнәр.

Бүлмәгә көя кебек тавышсыз-тынсыз гына кабул итү бүлмәсендә утыручы ханым кереп, хуҗасының колагына нидер пышылдады. Юзликәев сүзен бүлеп:

—Безгә янә берничә дус килгән. Алып керегез үзләрен. Алар да тыңласыннар. Чәй әзерләгез, кунакларның тамаклары кипкәндер.

Яңа мосафирлар бүлмәгә керә-керешкә үк хуҗа таныштыра да барды. Уртача буйлы, җирән сакаллысын чуаш гәзитенең баш мөхәррире Василий Прокофьев дип атаса, арттанрак кергән озын буйлы, кара тут йөзле, елгыр кара күзлесен «Тургай» журналыннан Вакыйф Исмәгыйлев дип атады.

Кунаклар белән бергә үк бүлмәдә пәйда булган көл чәчле ханым өстәлгә төсле чәшкәләрне таратып, кәгазь чәй капларын куеп, әзерләп куелган кайнар суны агыза ук башлады. Шулай ук ясалма бәдрә чәчле яшьрәк, матуррак икенче ханым поднос белән әгъла төшке аштан соң чәйгә бирелә торган өрек, каражимеш, чикләвек, балык сурәтле кечкенә печеньеләр, шикәр кебек нигъмәтләрне тезеп чыкты. Иренеп кенә, сөйләүчене тыңлый-тыңлый, чәй йотымы белән аралаштырып капкалый торган ризыклар ач карынны котырту өчен генә ярашлы иде. Роза чәчәген противогаз киеп иснәүгә тинләгән кәгазь пакетлы чәйне Талип өенә кертмәсә дә, кунак хуҗаның ишәге дип, үзен тынычландырып, ашказанын нәрсә белән булса да алдап, бүреләр улавын бастырып тору кирәк булыр дип, чәй чөмерергә кереште. Эчәкләренең актарылып-актарылып шаулап ризык сорауларын күршеләргә ишеттерү яхшы түгел дип, Нәкыйп тә кулына чәшкәсен алды. Сыекчаны күбрәк эчсәң, ашыйсы килү онытыла дип ишеткәне бар иде.

Фәһим Юзликәев тумыштан хисчән, нечкә күнелле булып үсә. Шул ук вакытта, усаллана да белә, иң явыз малайларга да баш бирми. Мәктәптә укыганда ук шанлы татар тарихына, Атилла, Кубрат хан кебек бөек шәхесләргә табынып, «ул чорда яшәп, мин Казан ханы булсам (мона шиге юк иде), үзләре әйтмешли, күрсәтер идем мин урысларга кысла оясының кайда икәнен. Соңрак туылган шул» дигән фикер аңа тынгы бирми. Вакытында үз юлыңны дөрес сайлый белмәсәң, башың белән бәреп боз ватсаң да, синнән файдалы кеше чыкмаячак дип, әтисе аны авыл хуҗалыгы институтына алып килә. «Җиһангир була алмасаң да, тамагың тук булыр» дип өсти ата кеше. Үкенми. Әмма халкы үткән тарих аны һаман да еракта гы йолдыз кебек сихерләп, үзенә тартып тора. Тарихтан

алынган мәгълүматларын, фаразларын үзендә тоту дөрес булмас дип, ул еш кына хезмәткәрләре, кунаклар алдына үз концепциясен җәеп сала торган булды. Бу юлы да килешле борыныннан төтен өерен ат дугасына охшатып түшәмгә таба озата-озата, тынлаучыларга болгар-татар тарихына кагылышлы фикерләрен ирештерүгә кереште.

—Болгарстанның башкаласы булып Болгар каласы саналса да, аның рухи һәм матди байлыгы, тирә-якны ымсындырып торган алтын-көмешләре Биләрдә, ягъни безнең яктарак сакланган. Ә укыту, белем эстәү үзәге булып Бизләү авылы икәнлекне тарихчылар исбат иттеләр инде. Өч үзәкнең дә юл аралары берүк диярлек. Идел елгасы буенда урнашкан Болгар сәүдә, алыш-биреш үзәге буларак үскән. Аны елга яисә яр буйлап килеп талап китүе дә җиңел булган. Нәкъ менә шуңа күрә байлык капчыгы вазифасын Биләр үтәгән, —дип, тәмәке төтене белән бергә авызыннан саескан очырды хакимият башлыгы.

—Кызык, кызык, яңачарак караш,—диештеләр, бер артистлы театрда статистлар һәм тамашачылар ролен үтәргә мәҗбүр булган кунаклар ачы язмышларына буйсынып. Максатлары, сәбәпләре төрле булса да, сөйләүче бүгенгесе көндә һәркайсына кирәк иде. Бер кичкә кер мичкә дип түзеп, тарих битләреннән чапкынлап үттеләр. Бу мәгълүматлар чуаш гәзитәсе хуҗасына кызыклы булса да, татар тарихын аркылыга-буйга инләгән, берише буыннарын хыялы белән тулыландырган Вакыйф өчен авыл хуҗалыгы белгеченең тарих турындагы фикерләре бәясе төшкән (Рәсәйдә еш булып торган) акча кебек арзан, капчыгы бер тиен иде. Мәгәр гозер белән килгән кеше беркайчан дөресен әйтә алмый. Үз эше өчен җаваплылык хисен тоймаган адәм генә принципиаль кеше мантиясен кия ала.

Бөтен хис-фикерләрен, мөнәсәбәтен шул шөгыленә салып, «Тургай» мөхәррире авызын зур ачып иснәде, чуаш гәзитәсе редакторы җирән сакалын сыйпап туйганнан соң, чепи күзләрен уу шөгыленә керешге.

Талип Нәкыйпнең колагына башкалар ишетмәслек кенә итеп:

—Дустың диңгез ташы кебек шомарган,—диде, хакимият башлыгының чынлап та партшколаны тәмамлаганына ышанып.

—Мин гомерем буе авыл хуҗалыгы белән мәшгуль булсам да,—дип дәвам итте сүзен Фәһим Сабирович,—татар тарихы белән кызыксынуга вакыт таптым. Мин аның бай, гайрәтле, аянычлы үткәненә гашыйк. Бездә халык мәнфәгатьләре белән яшәүче, югары кимәлле тарихчылар бармак белән генә санарлык—дип, бәя биреп узды нотыкчы галимнәргә, авыр башын өскә күтәреп, тәмәке төтенен ак түшәм ягына юнәлтеп һәм матур сүзләр табуына эчтән сөенеп. Ул—туган телен нечкәлекләре белән сизеп, теләсә нинди аудиториядә курыкмыйча, оялмыйча татар телендә сөйли алучы түрәләрнең берсе (бәлки, соңгысыдыр) иде.

Нәкыйпкә партшколада сеңгән әрсезлеге сүз агышына кысылып алырга мөмкинлек бирде.

—Сездән, Фәһим Сабирович, үткәнне тирәнтен аңлый, фәнни нигезгә сала белгән, югары белемле тарихчы чыгар иде.

Сабакташының очы күренеп торган арзанлы мактавы йөрәгенә сары май кебек сыланса да, сөйләүче үзен бүлдерүгә игътибар итмәгән булып, фикерен иркенләп җәеп салуны дәвам итте.

Диварда эленеп торган сәгать өчне суккач, хакимият башлыгы югары дәрәҗәдәге сөйләшүне башлаган кебек кинәт кенә тәмамлап та куйды.

—Ярый, егетләр, мин ашыгам, сезнең дә шәһәрне карыйсы, авыллар, мәктәпләр белән танышасы бар. Берегез дә кунарга калмыйсыз дип аңладым. Кичен күрешербез. Редакторлар бирсдә кала бугай. Сезне минем урынбасар

Вафа Садриев озата барыр. Камка авылында концерт белән укучылар көтә. Хәзерге авыл тормышы белән танышып, җилләнеп кайтыгыз әле!

Вафа Садриев дигәннәренең буе-сыны әллә кем булмаса да, җинел хәрәкәтле урта яшьләрдәге ир аралашу, сөйләшү мәсьәләләрендә хуҗасының нәкъ киресе булып чыкты, авызыннан аңлату, җавап алу кипкән каен тактасыннан тутыккан кадак суырып алу белән бер диярлек иде. Сүзчән түрә үз янына телсезләрне, озыны тәбәнәкләрне, матуры ямьсезләрне җыярга тырыша, күрәсең. Әти-әнисе исемен дә белеп кушканнар. Нәкъ Вафа инде.

Аңлатмалары телеграф өслүбенә якын.

—Монсысы спорткомплекс. Бусысы май заводы. Тегендәрәк картлар йорты. Үзегез карап килегез. Мин машина янында калам.

Нәкыйпне яңа төзелгән мәһабәт биналарда, картлар йортында намазлык өстендә утыручы Үзбәкстаннан куып кайтарылып, бәхетен туган җирендә тапкан мөлаем карчык та, йөзү бассейнының озынлыгы да артык борчымый. Ашыйсы килү дә инде интектерми. Ризыкны кабул итү вакыты узгач, ашказаны язмышына буйсына, хуҗасын артык бимазаламый икән. Тән күзәнәкләре исәнлек өчен ифрат файдалы ач торуга әзерләнә булса кирәк. Борынгы Римда гладиаторларны көненә бер тапкыр гына ашатканнар дип каядыр укыган иде. Әнә ничекләр җиңел сугышканнар, байларның күңелен күрер өчен берсен-берсе «эһ!» тә итми кадап үтергәннәр.

Дөресен әйткәндә, Нәкыйпнең кылдан нечкә, кылычтын үткен күңелен ике мәүзугъ борчый. Берсе—күп өметләр баглаган сабакташының шулай кешегә санамыйча кабул итүенең шаһиты колга Талип булып, аның алдында керсез абруена тап төшү, икенчесе—кесәдән акча чыгармыйча гына кире әйләнеп кайтырлык ягулыкны бакка салу. Бензин белән ярдәм итүен сорап Вафага мөрәҗәгать итте.

Урынбасарның гаҗәпләнүе йөзенә савылып чыкты.

—Сез ул мәсьәләне хуҗа белән хәл итмәдегезмени әле? Бу минем компетенциягә керми.

Шул ук телеграф өслүб сыртын бирүдән коткарып калды. Киләчәктә дә ул аның таянычы булачак.

Район үзәген аркылыга-буйга әйләнеп чykканнан соң, кырык чакрым ераклыкта урнашкан чын татар авылы Камка ягына элдерттеләр. Хакимият башлыгының бәясен төшерә торган, үзен пошаманга салган борчуы белән Нәкыйп янәдән Вафаның миен шакыды.

—Ни өчен Фәһим Сабирович кабул итү бүлмәсендә шундый өлкән, ямьсез ханымны тота икән? Ул бик зәвыклы, алдынгы карашлы кеше бит.

Йөртүче янында алгы рәттә утырган урынбасар бюрократик хакимиятнең яраткан алымын эшкә җигеп, әүвәл сорауны ишетмәмешкә салышты. Бу ысул тиешле нәтиҗә бирмәде. Чөнки Нәкыйпне партшколада хәзер пиар, элек «массалар белән элемтә» дип аталган предметта сөальне җавап алганчы кабатларга кирәк дип өйрәттеләр. Шул тәгълиматка турылыклы калып, кунак үзен борчыган низаг белән җаваплы кешегә кат-кат мөрәҗәгать итте.

—Үзеннән сорарга иде,—дип котылмакчы булды Вафа. Мәгәр ул беркатлы зат сорау бирүченең өч диплом иясе икәнен белми иде.

—Үзеннән дә сорарбыз,—дип вәгъдә биреп, Нәкыйп һөҗүмгә күчте.—Сез бит аның кадрлар сайлау, кую буенча ярдәмчесе. Җаваплылык сезнең өстә, бигрәк тә кешеләр белән эшли торган урыннарга тәкъдим иткәндә,—дип, Ленин хезмәтләреннән өзекләр әйтеп, Вафаны тәмам почмакка китереп кысты.

Тегесе үзалдына әйткәндәй генә:

—Хужа ул ханымны башка бүлектән күчереп утыртканда минем белән киңәшеп тормады—дип, җаваплылыкны үз өстеннән төшерергә булды.

—Бәлки ул хатын Фәһим Сабировичның ботак очы булса да туганыдыр, әллә... яшьлек мәхәббәтеме,—дигән фаразлары белән Нәкыйп Вафаның бавырына таш булып утырды, кан басымын күтәрде.

Ахыр чиктә урынбасар бәйләнчек адәмнән туепмы, үзе турында күзле бүкән икән дип уйламасыннар өченме, артка борылып, йөрәгеннән чыкканны әйтеп салды.

—Ул дорфа хатынны җаваплы урынга күчерүгә тешем-тырнагым белән каршы булдым. Фәһим Сабировичның яшь хатыны чибәр, унган, әдәпле кызны иләм тавыш күтәреп, хужа яныннан кудыртты. Мин үзем ишетмәдем, күрмәдем, сезгә дә берни әйтмәдем. Менә сөйләшә торгач, килеп тә җиттек.

Аларны кадерле кунаклар дәрәҗәсендә ипи-тоз, чәкчәкләр белән урамда ук каршы алдылар. Зал укучылар, укытучылар, авыл зыялылары белән шыгрым тулы иде. Кунаклар болай ук кирәкмәс дип уйлап куйсалар да каршы сүз әйтергә кыймадылар. Шул арада сәхнәгә күтәрелгән тарих, география укытучысы күтәренке тавыш белән районның уңышларына, колхозга амин тоткач, таркалып яткан авылның якты киләчәге, бу мәсьәләләрдә зирәк, алдан күрүчән җитәкче Юзликәевнең унай роле турында шактый тәфсилле итеп сөйләде. Укучылар концерты да байтакка сузылды. Сценарий буенча сорауларга җаваплар да каралган иде.

Шуннан соң ягымлы чырайлы, булдыклылыгы күзеннән, үзен тотышыннан күренеп торган кырык яшьләрдәге директор ханым ике кунакка да кыр чәчәге букетлары тоттырып, ашханәгә чакырды.

—Администрация сезне тукландырып җибәрергә кушкач, озак уйлаганнан соң, башкалабыздан килгән җаваплы иптәшләр укучыларны ничек ашатуыбызны күреп китсеннәр дип, нәкъ шул рационны тәкъдим итәргә булдык,—дип, район үзәгеннән «тук» килгән кунакларны ашханәнен бер читендәрәк торган өстәл янына алып килде. Күп итеп куелган йомшак кәгазьләр янында кәбестә салаты белән өч өлеш тәлинкәсе, бер өем шәнгә һәм компот салынган сырлы стаканнар кадерле кунакларны көтеп тора иде.

Нәкыйп белән Талип, мөлаем хуҗабикәне рәнҗетмәс өчен, өстәл янына утырып, ашказанындагы көндез эчкән чәйне компот белән болгатып, башка ризыкларга кагылмыйча (хакимият башлыгы кунаклары ич, теләсә кая ашап абруй төшерәсе түгел) ни өчендер зур рәхмәтләр әйтеп, урамга чыктылар. Шул арада йокысын туйдырып алган Вафа, киерелеп, тән күзәнәкләрен уятып алгач безне ашыктырды:

—Хужа тизрәк кайтып җитегез, дип шалтыратты!

Машина кузгалып китүгә Нәкыйп терсәге белән дустының янтавына төртеп алды, янәсе, «көтә, ашыктыра, әзерләткән нигъмәтләре суына торгандыр, бәлеш кайнар чакта гына тәмле була».

Машина янәдән Нәрәстә ягына юл алгач, Вафа сораулары белән интектермәсеннәр тагын дигәндәй, игътибарын музыка тыңлауга юнәлткәч, хакимият башлыгы ягыннан җылы им килүгә кәефләре рәтләнә башлаган мосафирлар икесе өчен дә газиз уртак теманы бөҗрага алдылар. Күңел тыныч булганда ир-ат йә сәясәт, йә хатын-кыз турында гына сөйләшә. Озак еллар дәвамында үзләрен ташлап киткән Мәдинәне искә алу Нәкыйп белән Талип өчен табу салынган, тыелган тема булып кала килде. Мәхәббәте җимеш бирмәсә, биеклек алынмаса ир-ат хурлык баганасын әйләнеп үтәргә тырыша.

Нәкыйп белән Талип үзләренә тиң дөнья бизәкләрен очратып, гаилә корып, балалар үстереп яшәсәләр дә, очрашканда мин «тегене» йөрәктән чыгарып ташладым дип мактанышсалар да, үзен кешегә санамаган тәүге мәхәббәтне онытү кеше мөмкинлегеннән өстен торган кичереш, аң төпкеленең аръягында торган халәт иде. Ул аларның йөрәген тырнак астына кадалып, алып булмый торган шырпыдай гел чәнчеп, әрнетеп торды. Кызның зәңгәр күзләре, «чао» дигән соңгы сүзе үз шәүләләре кебек алардан калмады, эзәрлекләвен белде. Йокылары качкан төннәрдә Мәдинәнең җазибәле күзләре, назлы тәне, моңлы тавышы аларны сынавын,газаплавын дәвам итте, һич югында төшләренә кереп бимазалады. Мәгәр аларның горурлыгы, хатыннары, балалары алдында җаваплылык хисе кызны эзләү, язмышы белән кызыксыну юлына чыгарга мөмкинлек бирмәде.

Сөекленәре хакында нисбәтән хәбәргә ия булган Нәкыйп, Талипның ярасына тоз сибүе турында уйламыйча, сүзне башлап җибәрде.

—Теге вакытта безнең мәхәббәтне аяк астына салып изгән кыз язмышы турында кое-что ишеттем.

Йокымсырый башлаган Талип колакларын сагайтты:

—Йәле, йәле, ниләр җимереп ята икән ике асыл егеттән йөз чөергән мәхәббәтебез. Бездән котылып үз бәхетен таба алдымы икән?

Олы дәүләт серен сакларга ант иткән кешедәй, Нәкыйп нечкә иреннәрен бер-берсеннән аермыйча, шактый көттерде.

—Озак интектермә, абзый. Характерымның бер тиенгә тормаганын беләсең. Теге вакыттагы кебек сугып җибәрергә дә күп сорамам.

—Сугу мәсьәләсе катлаулы. Ияк астыгызга гомергә истәлек булып калырлык сдача алганыгызны онытып җибәрмәскә тәкъдим итәм. Бездән котылып кына кызчыгыбыз тормышында әллә ни майтара алмаган бугай. Чибәрлеген бирсә, Ходаебыз бер кешегә күп була дип, бәхетен кызгана, адәм балаларын шулай тигезли диеп ишеткән идем. Яратып йөргән бай егете ике балалы ир булып чыккан. Атна-ун көн генә торып калганнар, хатыны кайтып төшеп, Мәдинәкәйне куып чыгарган.

—Шуннан,—дип, Талип йомгакның очын көтеп пырдымсызланса да, Нәкыйп үзенә мәгълүм хәбәрне арзан бәягә чыгарып салырга ашыкмый.

—Шуннан ул янәдән утырган да шуган. Икенче ире хәмер колы булып чыккан, ни өчен миңа чыкканда кыз түгел идең дип бәйләнгән, ханым кыйнавына, җәберләвенә түзә алмыйча, анысын үзе ташлап киткән. Хәзер Мәдинә ялгыз яши, малай үстерә, кечерәеп ябыккан—кәҗә бәтие чаклы гына ди, элеккеге кыргый матурлыгының эзе дә калмаган дип ишеттем. «Яшьлек җүләрлегем белән нинди егетне югалттым» дип, еш кына яшьләренә буыла-буыла җылый дип тә ишеттем. «Нинди егетне югалттым» дигәндә мине күздә тота торгандыр инде,—дип Нәкыйп карашында яшен чаткылары уйнатып, Талип ягына борылды. Мәдинәнең кемне сагынганын үзенчә юраган игътисад белгече ахмак шаяртуны кабул итмәде.

Хатыныңны ташлап, ике яшь балаңны ятим калдырып, беренче мәхәббәтеңә әйләнеп кайта аласың, Талип иптәш. Байлыкка бик кызыга иде, фәннәр кандидатыннан баш тартмас дип уйлыйм. Бу трит сугыш юлына чыкмаска вәгъдә бирәм,—дип пафослы юмор белән сүзен төпләп куйды Нәкыйп.

Безне ташлаган өчен шул кирәк сиңа дип сөенергәме, барыбер якын кеше иде дип көенергәме? Һәрхәлдә, Талип дустының беренче мәхәббәт өлкәсендәге фаҗигале язмышына нисбәттән ирониясен уртаклашмады. Партшколада чыныгу алмаган укытучыга кадерле әйберен җуйгандай, үтә күңелсез, ифрат моңсу булып китте. Кайчандыр яратып йөргән кызларының, үзләрен ташлап китсә дә, бәхетсез булуын теләми иде ул.

Кешенең, хәтта дошманыныың (хатын-кыз дошман була алмый) бәхетсезлегенә сөенүне ислам дине дә хупламый бугай. Дустының эчке халәтен аңлап булса кирәк, Нәкыйп тә мәхәббәт низагларын куертмады, сүзне башкага күчерде.

Чакырып алынган дуслар күтәренке күңел белән икенче катка күтәрелделәр. Нәкыйпнең башын ягулык мәсьәләсе борчыды. Юзликәев белән партшкола хәлләре турында сөйләшеп китеп, онытмаска иде дип күңеленә беркетеп куйды.

Мосафирларны хуҗа кабул итү бүлмәсендә үк баягыча таза кулларын җәеп, елмаеп каршы алды. Минем сабакташның нинди киң күңелле икәнлеген күрсен әле мескен югары мәктәп укытучысы. Алар арасында хөсетлек, көнчелек өстенлек итә, ихласи дуслык сирәк кунак дип ишеткән идем.

—Хуш киләсез, ничек йөреп кайттыгыз, кадерле кунакларым. Мөршидә Габбасовна сезне бик яхшы кунак итеп, әйбәтләп сыйлап җибәргән дип уйлыйм. Шулай кушылган иде. Мәктәп директоры булып икенче ел гына эшләсә дә, бик толковый ханым булып чыкты. Әйдәгез, теге бүлмәгә күчик, башка дуслар да шунда көтеп утыра,—дип өстәлдән сигарет пачкасын, кабызгычын онытмыйча, иртән чәй эчкән бүлмәгә алып китте.

Анда чуаш гәзитәсенең редакторы янында тагын бер кеше утыра иде. Сары чәчле, ак пиджаклы, шактый тулы гәүдәле кешене «Эхо Москвы» радиостанциясеннән Сергей Олегович дип тәкъдим итте. Дөрес, анысы сүз башлаганчы ук чыгып та китте.

—Утырышыйк, дуслар. Кызлар, чәй кертегез!

Вакыт кадерле. Иртән башлаган сүзне тәмамламыйча туктасак, тәлинкәдә аш калдыру кебек булыр иде,—дип Фәһим Сабир улы татар тарихына сәяхәтне дәвам иттерде.

Нәкыйпнең кашы җимерелү, борыны җәелеп төшү, уч төбе кычыта башлау турында әйтеп тә торасы юк. Үтә хисле Талип юлда сөйләшкәннәр тәэсирендә яшәп, үзен битәрләвен дәвам итеп, нотыкчыны тыңламады да. Дөресен әйткәндә, күбрәк үзе өчен сөйләгән тарихчыга аудиториянең аны кабул итүе кирәк тә түгел иде.

Бик кызып киткәндә Юзликәев тыңлаучылар утыруын да онытып җибәргәләде. Исенә төшкәч, җөмләсендәге сүзләрне тәртипкә китереп сөйли башлый да, янәдән онытылып китә.

Аңа көндәлек мәшәкатьләрдән читләшеп, шул чорда яшәп алу кадерле икәне күренеп тора иде.

—Алтын Урданың Ауропаның алдынгы, гайрәтле илләре югарылыгына күтәрелеп, Чыңгыз оныкларының үз шәхси мәнфәгатьләре турында гына уйлап, хакимият өчен көрәшүләре, олы илне кисәкләргә бүлгәләүләре нәтиҗәсендә таркала, юкка чыга баруына тәфсилле тукталып тормыйм. Минем бире дә дөньяны калтыратып торкан Алтын Урда, Елдырым Баязет чорындагы төрек дәүләтләренең юкка чыгуында Аксак Тимернең тискәре урыны турында гына искәртеп үтәсем килә. Ул гел төрки халыкларга каршы сугышып, үзе дә сизмәстән, Ауропа илләрен ышыклап, көчәйтеп калдырган.

Вакытның чикләнгән булуы сәбәпле, тарихыбызның бу буынын сикереп үтеп, Казан ханлыгының юкка чыгу сәбәпләренә генә үз карашымны сезгә әйтеп үтәсем килә. Көчле, бай Казан ханлыгының шулай аз яшәп, тиз юкка чыгуының сәбәбен тарихчылар ахыргача аңлатып бирә алмыйлар, минемчә.

Янәсе, явыз Иванның гаскәре биш тапкырга күбрәк булган, аңа бөтен христиан дөньясы ярдәм иткән. Анысы да бар. Университет янындагы

бакчада кукраеп утырган Бутлеровның ерак бабасы Казанны штурмлаган артиллерия белән житәкчелек иткән. Сатлык Шаһгали гаскәренең дә урысларга ярдәме аз булмаган. Иң аянычы шунда: татарга каршы татар сугышкан. Тик жиңелүнең сәбәбе башкада. Казанның бер ханы да жирле халыктан үскән кеше булмады. Барысы да привозной, Урдадан, Кырымнан, хатыннары Әстерханнан булган. Ил белән килмешәкләр житәкчелек иткән. Ул бәкләр, биләр үзләрен вакытлы идарәчегә санап, типтереп, рәхәт яшәп, баеп калу турында гына уйлаганнар. Беришесе алдан ук Мәскәү кубызына биегән, шуңа күрә алар урысларга Казанның түше астында шәһәр корып куярга мөмкинлек биргән. Хәзерге атама белән әйтсәк, Казан ханнарына патриотик хис, үземнеке, туган халкымныкы дип күтәрелеп бәрелү житмәгән. Иманым камил, Кубрат хан идарәдә булса, Казанны урысларга бирмәс, хәтта Шаһгали дә аңа каршы кылычын күтәрмәс иде. Ниһаять, Казан ханлыгында ирекле сайлау, демократия, күп партиялелек өстенлек иткән. Вәзгыять, аң үсеше өлгереп житмәгән жирдә демократия яхшыга алып бармый. Күсәкнең бер башы үзеңә китереп тондыра,—дип нотыкчы үзе дә сизмәстән, йомарланган олы йодрыгын ялтыравык өстәл өстенә шапылдатып куйды.

Казан ханлыгының жимерелү сәбәпләренә шактый озак тукталганнан соң, сөйләшүнең дәвамын икенче вакытка калдырып, «Эхо Москва»дан корреспондент көтеп утыруы, беришә кунакларның юлга чыгарга ашыгуы турында кайгыртып, киң итеп елмаеп хужа сүзен тәмамлады. Нәкыйп белән Талипка аерым игътибар, хөрмәт күрсәтеп, бүлмәдән чыгу ишегенә тиклем озатып куйды. Коридорда онытылып барган көйне исенә төшергәндәй, кунакларның салпы ягына салам кыстыруны кирәк тапты.

—Без бит Нәкыйп белән сабакташлар, партшколада бергә белем алган кешеләр. Алтын заманалар бар иде. Ашау байдан, үлем ходайдан дип түшәмгә төкереп яттык. Стипендия зур, буфетта ризык үз бәясенә сатыла, күршедә генә ял паркы... Ул елларны онытмадыңмы, Нәкыйп?

—Саратовта укыган чорны онытып буламы соң?—дип килешергә ашыкты тегесе.

—Хәерле юл сезгә. Берәр төрле йомышыгыз, кирәк-ярак әйберләрегез булса, сезгә Вафа Садриевич беркетелгән.

Тамак ялгау, ягулык мәсьәләләрен хәл итү нияте белән, урынбасарны эзләп киттеләр. Хакимият каршысында да, йортта да машинасы да, үзе дә күренми иде. Янәдән өскә күтәрелеп, сәркатип ханымнан белештеләр.

—Районның ерак бер авылында пожар чыккан. Ферма яна башлаган. Хужа әле сез чәйгә кереп киткәнче үк, Вафа Садриевичны шунда жибәрде.

Хакимият кунаклары булган акчаларын кырып-себереп жыеп, машиналарына бензин салып, ашарга алырлык та калдырмыйча, кичке сигезләрдә шәһәр статусын алырга торган район үзәгеннән өйләренә таба юл алдылар.

Ач кешенең фикерләү дәрәжәсе бик түбән, жирдән шуышып, үрмәләп бара дип дөрес әйтәләр икән.

—Мәктәп ашханәсендә тәкъдим ителгән кәбестә салаты белән эремчек пәрәмәчен бөкләп куймаганыма үкенеп бетә алмыйм. Укучылар диетасы озак яшәү өчен иң кулай диета дип ишеткән идем,—диде Нәкыйп, зур гөнаһ эшләгән кешедәй көрсенеп.

—Төрмә диетасы тагын да отышлырак икәне дә мәгълүм. Чөнки анда бер кәррә дә артык калория булмый,—дип шаяртырга булды дусты.

«Кунакка барып кайту, һавага чыгып керү» мажарасының авторы Нәкыйпкә ачуы көчәйгәннән-көчәя барган Талип күңелендәгесен әйтергә ниятләде. Бер көнебезне суга салдык, «Кычытмаган жирне кашыту өчен

Әстерханга барган» гыйбарәсенең дөреслеген расладык, заманча сый, түрәләр кунакчыллыгы сүздән пешерелгән ботка икән, Юзликәевнең имтиханга әзерләнгәндә синең язмалардан файдалануы шик уята, бәйсез тотышына, иркен кыйлануына караганда, нәкъ киресе булырга тиеш, кебегрәк фикерләре белән Нәкыйп йөрәгенә агулы ук җибәрмәкче иде, дусты ягына борылып карагач, бу уеннан кире кайту гына түгел, хәтта куркып китте. Тәмле ашап, тыныч яшәргә күнеккән Нәкыйпнең йөзендә кан әсәре калмаган, агарынган борынына, колакларына, бит алмаларына чаклы мәет төсе керә башлаган иде. Нервысының тартылып куйган кыл кебек киеренке халәте күзенә, бөтен гәүдәсенә чыккан.

Талип дустының хәлен анлап, аны чын-чынлап кызганып куйды һәм йөртүчегә җайлырак җирдә машинаны туктатып, багажниктан портфелен алып бирүне сорады. Лекцияләрен, китапларын, чыганакларны йөртә торган кара портфеленнән бер ярты коньяк, ак кәгазь төргәк чыгарды. Кәгазь кыштырдавы Нәкыйпнең дә игътибарын җәлеп итте. Ул көчле яңгырдан соң күкшел офык чите ачылганны көткәндәй, бөтен дикъкатен төргәккә юнәлтте. Аннан... эссе табада кетердәтеп кыздырып алынган, Нәкыйп мөкиббән китеп, авыз суларын корыткан итле пәрәмәчләр килеп чыкты. Суынган булсалар да, тәмле ис Нәкыйпнең борын яфраклары аша үтеп, бөтен тәненә таралды.

Уйламаганда лотереяга зур акча откан кеше кебек, Нәкыйп шатлыктанмы, гарьләнүдәнме сүз таба алмыйча, тотлыга ук башлады.

—Эн... та... син нишләп Талип шул әйберләрең турында берни әйтмичә, мине көне буена интектердең?

Тегесе инде ниһаять шаяртырга да була дигән фикергә килеп:

—Соң мин шашлык белән бәлеш алдыннан аппетитны бозмыйк дип уйлаган идем. Түрәләр сыеның нindирәк булуын күрәсе килгәние...

Нәкыйп өчен шатлыгы-кайгысы, уены-чыны барысы бергә буталган, төрттерү, чеметү ише әйберләрне кабул итәрлек хәле калмаган иде.

—Әйдә, теленә салынма. Йөз граммыңны кой да, итле пәрәмәченне кулыма тоттыр. Ни әйтсәң дә, үзебезнең өйдәге ризыклардан да затлы, тәмле, туклыклы ашамлыклар юктыр җир йөзендә.

Күнелләре бөтен дөньяга сөенеч чәчәр хәлгә килеп җиткәнче, дуслар машинада гөрләшеп утырдылар. Адәм баласына йөрәге белән җиһанны инләр, игелек нурлары кою өчен күп тә кирәкми икән.

Мосафирлар өйләренә кайтып җиткәндә, инде таң атып килә иде.

*2008*

♣



Фидаил

# ЙОЛДЫЗЛЫ БОЛЫТЛАРДА

* * *

Газизләрдән-газиз Чулман буе—
Узган саен өзелә үзәгем,
Нур сирпегән ярымайда күреп
Каракошның кара эзләрен...

Нигә аңа Ходай канат биргән,
Ничек менгән шундый биеккә?!.
Җиз тырнагын батырып җаныбызга,
Әверелмәк була бөеккә.

Айны гына түгел, кояшны да
Каплар иде, килсә көченнән.
Нәфрәт белән канат җилпүеннән
Кирмәннәр дә хәтта ишелгән...

Җаны имгәнеп, теле йолкынганнар
Арасыннан атлыйм, аптырап:
Тагын күпме без яшәрбез икән
Кара күләгәдән калтырап?!.

Тагын күпме ул сагалап барыр,
Очрак эзләп тотып таптарга?!.
Сөбханалла, сабырлыгын бирдең,
Кыюлык та иңдер Татарга,
Азатлык бир, Ходам, Татарга!

* * *

Август төне—иң матур чак,
Фасылларның асыл чагы.

Фидаил (1984)—*яшь шагыйрь; «Сагышлар да алтын була икән» исемле китап авторы. Чаллыда яши.*

Төнге күктә йолдызларның
Шаулап чәчәк аткан чагы...

Хуш ис бөрки төнге һава,
Йолдыз исе—томаннарда.
Мин мәңгегә гашыйк булдым
Шул йолдызлы болыннарга.

Йолдызлардан чатыр кордым,
Уртасына элдем айны.
Галәм кунагы булдым мин,—
Онытылды Җир, бар кайгы...

Кирәк түгел гарешләре,
Йолдызларым балкыганда.
Киек Каз Юлларын күреп,
Өмет күгем яктырганда...

Калыр идем бу чатырда,
Чакырмаса таң нурлары.
Хыял—бары татлы мизгел,
Ә без исә—Җир уллары...

## Синең исем

Йөрәк тагын яңа ритм белән тибә,
Строфаларга булә сагышны.
Ноталарга сала, әвереләдерә моңга
Җаннан килгән әрнү тавышын.

Маэстро үзенең иске скрипкасыннан
Яңа бер көй көткән шикелле,
Тыңлап йөрим әле йөрәк кайтавазын,
Кабатлыйм да синең исемне...

Югыйсә бит инде күпме җырларымны
Багышлаган идем мин сиңа...
Йөрәк кенә һаман, илһам скрипкасыдай,
Яңа бер көй эзләп ымсына.

Композитор түгел лә мин, ләкин сиңа
Җыр язарга күптән күнектем.
Шулай булыр микән әллә—өзелгәнче
Соңгы кылы җанда өметнең?!.

***

Сирәк кенә җемелдәгән утлар
Сагыш булып күчә күңелгә.
Кайттым әле тагын ераклардан,
Авылым урамнарын күрергә.

Эңгер төшкән авыл урамнары
Сыкрап сызлый хәтер җиленнән.
Карт наратлык кына һаман яшел,
Күпме язмыш анда күмелгән...

**Бергә кайткан сагышларым белән**
**Авылымдагы сагыш кушылып,**
**Елга өстендәге томаннарга**
**Күтәрелде, талгын моң булып.**

**Табылмады җырга кушылучы,**
**Ишетелмәде хәтта кайтаваз...**
**Тик без генә һаман—кайтаваздай—**
**Туган туфракларга кайтабыз.**

*******

**Бәйләмәгез, каерып, канатларым,**
**Мин очарга тиеш, очарга!**
**Үзем генә белгән галәмемдә**
**Йолдызларны җыеп кочарга!**

**Тырышмагыз җиргә төшерергә,**
**Күтәргәндә күккә хыяллар.**
**Очып калыйм канатларым барда,**
**Куркытмыйлар мине кыялар!..**

**«Биеклектә башың әйләнер»,—дип,**
**«Очма!..»—диеп үгет бирмәгез.**
**Юк, курыкмыйм, биек булса булсын,**
**Хисләремә генә тимәгез!**

**Кометалар белән очрашып,**
**Куырылса әгәр канатлар,**
**Үпкәләмәм, бары иреннәрем:**
**«Мин бәхетле...»—диеп кабатлар...**

---

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

Нурмөхәммәт
Хисамов

# ГАЗИНУР—БАТЫРЛАР ИСЕМЕ

## ГАЗИНУР МОРАТКА 50 ЯШЬ

Улларына әти-әнисе, әле аның шагыйрь буласын башларына да китермичә, «Газинур» дип исем кушканнар. Әмма аның легендар каһарман исеме икәнлеген истә тоткан алар. Фидакарьлекнең иң югары өлгесе саналган һәм халыкның абруен күтәргән Газинур Гафиятуллинга тирән хөрмәт саклаган игенчеләр эшләгән моны. Газинур Моратның әти-әнисе югары фикерле кешеләр булган. Исемнең кеше язмышын, аның тормыштагы юлын алдан юрап куюына бу—иң тапкыр мисал.

Шагыйрь Газинур Моратның иҗатына хас әйдәүче сыйфатны мин батырлык итеп күрәм. Югары һәм тулы канлы талантка ия бу затның барлык әсәрләрендә, хакимияткә булсын, нинди дер кодрәтле төркемнәргә булсын ярарга тырышу, коньюнктура һәм реверансның бер генә эзен дә күрергә мөмкин түгел. Ул—карьерага омтылмаган, беркемнән дә курыкмаган һәм үз көченә нык ышанган ир-егет.

Шагыйрь замана эчендә үзен гайяр каһарман итеп тоя.

*Җаныбызга баскын булып*
*Аяк басса берегез,*
*Без—тулпарның дагаланган*
*Дүрт тоягы. Белегез!*
*Кушаяклап тибәрбез бер,*
*Шундый итеп тибәрбез!..*
*Сөрлегә калса замана,*
*Безне генә тиргәгез...*

Газинур җәмгыятькә, хакимияткә һәрвакыт югары таләпләр куеп яшәде. Аның тоталитаризм дәверендә язучылар мөнбәреннән ясаган чыгышлары сискәндерерлек дәрәҗәдә кыю, кискен янгырашлы иде. Үзгәртеп кору чорында исә аның үткәнгә һәм үз заманы тәртипләренә тәнкыйте тагын да тәвәккәлрәк булды.

Әдәби мирасны яклау, онытылган ядкарьләрне кайтару мәсьәләсендә аның басма сүзе кайнар дәрт һәм ярсу иман белән янгырады. Җәмәгатьчелек күз алдында үткән барлык аңлы гомере бу егет туганда ук житлеккән гражданлык иманына ия булгандыр дигән тәэсир калдыра.

Мин аның «Кыйссаи Йосыф» юбилее унае белән бастырган публицистик чыгышларын хәтерлим. Һәр яна мәгълүматны һәм фәнни фикерне хуплап, җуплап сөенүендә изге ялкын сизелеп тора иде. Аның яшьлек максимализмы белән тулы публицистикасы халыкның иҗтимагый-милли аңын уятуда җитди роль уйнады. Ул үзенең фидакарь батырлыгын сүз белән генә түгел, гамәл, эш белән дә күрсәтә алды. Суверенлык өчен кискен көрәш барган көннәрдә уннарча һәм уннарча мең мәйдан халкы алдында Газинур Казан һәм Чаллы милләтпәрвәрләре белән атналар дәвамында ачлык тотты.

Шагыйрьдәге каһарманлык дигән әхлакый һәм гражданлык сыйфатының әйдәүче чыганагы һәм төп этәргече—милләт гаме. Газинурның асылда бөтен иҗаты

шушы хис белән сугарылган. Ул хис татарда һәрвакыт батырлык сораган. Бер дә юккамыни Тукай:

*Курыкмыйм сөйгән халкым бу татар булса да,—*

дип язган. Татарның милли мәнфәгатьләре рәхимсез сынауларга дучар ителгән бу дәвердә мәзкүр сыйфат аеруча кирәк. Халык язмышындагы бу парадоксны шагыйрь шушындый ачынулы юлларда чагылдыра:

*Алып буйлы халык идек юкса,*
*Яралган соң нинди каннан без?*
*Илсез калмас, телсез калмас өчен*
*Ачлык тотар көнгә калганбыз.*

Ул халыкның бүгенге халәтенә тарих аша карый һәм милли югалтуларның гаепчесен баскыннарның комсызлыгында күргән кебек, үз халкының ваемсызлыгында да күрә.

*Арба тәгәрмәче буйлы калган*
*Тарих тәгәрмәче буйлы халык.*

Газинур—антитеза остасы. Антитеза ачы хакыйкатьне үзәккә үткәреп җиткезә. Ул милли бердәмлекнең булмавын, моның исә фаҗигале нәтиҗәләре тарих буйлап килүен үтә кискен хәлләр аша бирә.

*Татар башын татар ашый-ашый,*
*Дуңгызлык та бетте татарлашып.*

Тарих—шагыйрьнең уйланулар мәйданы. Тарих аңа үзенең хисапсыз гыйбрәтләре, сабаклары белән халыкны саклау юлларын өйрәтә, фаҗигале вакыйгалары белән һәлакәттән кисәтә.

Мәдәни-рухани тарихыбыздан да үкенечле гыйбрәтләрне күп табарга мөмкин. Әйтик, менә ничә гасыр буе татар Казан ханлыгының бөек шагыйре Мөхәммәдьяр мирасын саклап килгән. Ләкин аның зирәк шигърияте анлап бәяләү XX гасырда гына мөмкин булды. Фаҗига—татарның сибелеп яшәвендә. Кавемдәшләребез башларын һәм иманнарын саклау өчен Казаннан ераккарак—Пермь төбәгенә дә—барып чыккан. Кадерле кульязманы да үзе белән алган. Ә аны төшенү һәм шәрехләү өчен XX йөз татар фәне кирәк булган. Шагыйрь шушы хакыйкатьне менә мондый юлларга салган:

*Кайчак шәхесне аңларга,*
*Кайчак шәхесне данларга*
*Биш гасыр кирәк була.*

Шул рәвешле, әлеге ачы гыйбрәтне шагыйрь бөтен тарих һәм әдәбият өчен гомумиләштерә. Тарих аңа ачынулы икърар өчен дә, үз-үзебезне шелтәләү өчен дә, гамәли мәсьәләләр кую өчен дә бәрәкәтле җирлек булып тора.

*Дәүләт арты дәүләт корган—*
*Булган шундый сәләте дә.*
*Төшенмәгән үзе ләкин*
*Дәүләт тоту сәнгатенә...*

*Исән калган нугай булып,*
*Әйләнеп тә керәшенгә.*
*Бүленгән ул, бүлгәләнгән,*
*Инде вакыт берләшергә!*

(«Татар»)

Газинур милләтнең хәлен төрле яктан төшенергә омтыла, аны төрле аспектта ачып карый. Халкының драматик хәлен дөнья буйлап сибелүдә күрә ул.

*Ач торабыз. Ачыгабыз.*
*Качкыннар без. Качаклар.*
*Бәхет эзләп чәчелгәнбез—*
*Без—бәхеткә ач татар.*

Хәлбуки безнең авторыбыз—киң күңелле шагыйрь. Ул үз милләтенең фаҗигале һәм каһарман язмышы турындагы уйларга бикләнеп калмый, башка халыкларның газабын да йөрәгенә якын ала. Аларның азатлык һәм гаделлек көрәшендә татар балалары өлешен дә күрә. Мәсәлән, Литвада танклар юлына кулга-кул тотынып баскан яшьләр арасында татар кызы да һәлак була. Ул—Лорета Асанавичюте (Хәсәнова). Шагыйрь моны болай яктырта:

*Кара эшләр караңгыда,*
*Кара төндә кылына.*
*Литва төне ясин чыга*
*Мөэмин татар кызына.*

1991 елгы Ригада булган канлы вакыйгалар шагыйрьне татарның азатлык көрәше турындагы уйларга этәрә. «Төнге Ригада латыш кызы белән сәяси сөйләшү» дигән шигырендә ул болай яза:



Нурмөхәммәт Хисамов (сулда) һәм Газинур Морат.

*Без дә, дисең, күп татыдык*
*Кимлекне вә тарлыкны.*
*Тик җиңеп булмый Иреккә*
*Һәйкәл куйган халыкны.*
*Сездә бар Роза Турайдас,*
*Бездә бар Сөембикә...*

*Тарихлар сере—йозакта,*
*Тарихлар сере—биктә.*
*Син дә юллар ябык, дисең,*
*Азатлык алласына.*
*Әйт алайса, нишләргә соң*
*Мин—татар баласына?!*

Төньяк Кавказ халыкларының, Карабахның катлаулы тарихында шагыйрь үз халкының да фаҗигале үткәннәренә аваздашлык күрә. Аның күз алдында каһарманлык өлгесе булып Шамил сыны калка. Ә тарихта алмашка килгән «намус сәүдәгәрләрен» Ишми ишан гәүдәләндерә. «Минем Дагыстаным»ны укыгач» шигырендә бу хакта ул болай ди:

*Шамилләр йөрәге тибә,*
*Тибә һәрбер халыкта...*
*Кара мантия бөркәнеп*
*Кайчак чорлар калыккан.*
*...Ишми ишан ише кайбер*
*Намус сәүдәгәрләре*
*Печән базарында саткан.*

*Саткан иң асылларны.*
*Ыңгырашканын ишетәм*
*Мин гүя гасырларның.*
*Чор шаһитләре—шәһитләр.*
*Ә кемнәр—ялчы, хадим.*
*Бөркетен җуйган кыя-тау*
*Барыбер үксез, ятим.*

Газинур—чынлыкта дөнья гражданины. Ул дөнья шигърияте стихиясендә яши. Аның шигырьләрендә XX гасырның бик күп күренекле шагыйрь һәм

әдипләренең исемнәрен очратабыз. Тукай, Дәрдемәнд, Межелайтис, Евг. Евтушенко, Хемингуэй, Х.Туфан, Пастернак, А. Гыйләжев, Т. Миңнуллин, Р.Фәйзуллин, Пабло Неруда һ.б., һ.б. аның шигъри карашының ничаклы киң булуын күрсәтә. Элегрәк чорлардан Франсуа Вийон, Бальзак, Толстой исемнәре аның әдәби-эстетик критерийларының югарылыгы турында сөйли. «Кара базар» шигырендә ул базар шартларында рухи кыйммәтләрнең дәрәҗәсен төшерүгә ризасызлык белдерә:

*Карамагыз бөекләрнең*
*Милләтенә, теленә—*
*Күтәрегез бәяләрне*
*Пушкин биеклегенә!*
*Тукай биеклегенә...*

Газинур—галәм масштабында фикер йөртүче шагыйрь. Галәмдәге барлык әверелешләр һәм айкалышлар аның җаны аша уза. Аның шигырьләрендәге катлаулы сурәтләр галәми колачка ия. Күп кенә әсәрләрен аңлап уку һәм аларның бөтен мәгънә тирәнлекләрен ачу өчен шигърият белгече булу гына җитми, плазма физикасы белгече булу да сорала кебек.

*Төн—гүяки арфа...*
*Һәрбер кылы*
*Ай нурыннан аның үрелгән.*
*Тынлык сонатасы аһәңенең*
*Шавы килә галәм түреннән...*
*Синең гүзәллекне көйгә салып*
*Уйный арфа...*
*Күзләр камаша.*
(«Төнге идиллия»)

Үз халәтен, үз язмышын күрергә, төшенергә омтылганда да аның төшенчәләре галәми колачка ия; бик күпләрнең ачы тәҗрибәсен дә шагыйрь шулай гомумиләштерә:

*Ядрә булып йолдыз атылганда,*
*Сискәндереп куя ал тынлык.*
*Мескенлектә узган гомер төсле*
*Чиксезлеккә сеңә яктылык.*

Табигатьне сынландырганда шагыйрь аңа кеше чалымнарын бирә, зур-зур күренешләрне кеше кәефе итеп конкретлаштыра. Мондый алымнарда ул кыю, иркен һәм тапкыр эш итә.

*Сөмсере коелган күкнең,*
*Көннең кәефсез чагы.*
*Козгыннар каркылдый.*
*Кемгә*
*Ясин чыгалар тагы?*

*Кара шәлен бөркәнгән көн,*
*Кулында—төн гөлләре...*
*Дулкыннар көлә шаркылдап—*
*Йоткан диңгез кемнәрне?*
(«Элегия»)

Таңның көнгә авышуыннан шагыйрь шушындый масштаблы метафорик сурәт ясый:

*Көнгә авышты таңнар.*
*Кояшка узган Зөһрә кыз*
*Тузгыган чәчен тарар...*
(«Дүрт мизгел»)

Газинурның лирик каһарманы—тирән хиссиятле шәхес. Аның шигъри дөньясы колачлы, мәгълүм темалар кысасына бикләнеп кала торган түгел. Шунлыктан аның палитрасы да төсләргә бай. Ул, зур шагыйрьләргә хас булганча, кешелек яшәешенең барлык эре мәсьәләләрен күтәрә. Әхлак, намус, бәхет—аның зур-зур темалары шулар. Бу төшенчәләр тирәсендә уйланулар аңа кыйммәте җуелмас афористик хакыйкатьләр ачарга, үз язмышында һәм замандашлары тәҗрибәсеннән гыйбрәтләр алырга мөмкинлек бирә.

Шагыйрьдәге мәхәббәт темасы—үзе зур дөнья. Ул дөнья аның галәми карашы, космик колачы белән бердәмлектә һәм тиңлектә яши.

Байронның: «Если не могу быть любимым, Все же я хочу любить»,—дигән юллары Газинурның мәхәббәт темасына кереш була ала. Ул үзе болай ди:

*Синең өчен, бәлки, чыклы иртә,*
*Бәлки, шыксыз төн мин.*
*Күкләреңдә тик йолдызлар янсын—*
*Яратырга телим.*
(«Яратырга телим»)

Аның бик күп шигырьләрендә мәхәббәт хисе шагыйрьлегенең дә сәбәпчесе икәнлеге аңлашыла. Бу хәл барлык шагыйрьләргә дә хас. Әмма аны тарихта калырлык колоритлы итеп әйткән шагыйрьләр күп түгел. XV йөздән Сәйф Сараида мондый юллар бар:

*Сәңа бу шивәләр берлә күңел алмак кем үгрәтте,*
*Җәмалеңне күреп, заһид, тотып гыйшкың, йулын кәсте.*
*Мәнем кауме кабилемнең камусы галим ирделәр,*
*Сәнең бу гыйшкың устады мәңа шагыйрьлек үгрәтте.*
*(Сиңа бу назлы кыланышлар белән күңел яулауны кем өйрәтте?*
*Матурлыгыңны күреп, заһит, гыйшкың тотып, юлын кисте.*
*Минем нәсел-нәсәбемнең барысы да галим иделәр,*
*Синең бу гыйшкың остазы миңа шагыйрьлек өйрәтте).*

Ә Газинур «Мине шагыйрь иткән кызга» шигырендә болай яза:

*Ак кәгазьгә бүген каным белән*
*Язып куйдым синең исемне.*
*Исемеңне кабат яд иткәнгә*
*Үпкәләрсең, бәлки, каргарсың.*
*Тик барыбер син җырыма минем*
*Тугзак аңа булып каласың.*

Мәкүр темада шагыйрьнең тормыш борылышлары, газаплы хатирәләре, кешелек хисләре тирән булып, бай булып чагыла. Ул үзенең драматик, ләкин якты икрарында мәгънәле һәм нәфис шигъри гыйбарәләр куллана.

*Мин дөньяга шигырь белән тулы*
*Бәллүр касә аша карадым.*
*... Үкенмә дә, сагынма да мине,*
*Мин кичерәм сине, кичерәм.*
*Элеккечә кояш нуры эчеп,*
*Яфрак шавы тыңлап исерәм.*
(«Хатыңны алгач»)

Лирик каһарманның сөеклесе белән юллары аерылган очракларда да ул игелекле, олы җанлы булып кала белә. Аның теләкләре үзенең кешелекле асылын саклый.

*Сиңа илтер юлларымны*
*Зилзилә-вакыт күмә.*
*Мине онытсаң да,*
*Берүк*
*Бәхетсез була күрмә.*
(«Сине уйладым бүген дә»)

Пушкинның «Я вас любил...» дип башланган шигырендәге соңгы юлларга әдәбият белгечләре аһ! итәләр, аларның кешелекле, олы җанлы яңгырашына сокланалар.

*Я вас любил так искренно, так нежно,*
*Как дай Вам бог любимой быть другим!..*

Шагыйрьнең мәхәббәткә багышланган һәр шигырендә диярлек драматизм сизелә.

*Бүген менә сулык-сулык*
*Үксетәбез бәгырьне.*
*Кадер эзләп килгән ярлар*
*Чынлап микән кадерле?!*

Шигырьләрдә ялгызлык мотивы, гадәттә, зар авазына өртелә. Газинурның бер шигырендә ялгызлыкны кунакчыл каршылау яңгырый. Бу бик сәер тоелырга мөмкин. Әмма иҗат кешесенең психологик ихтыяҗында мондый нәрсә дә бар.

*Тартынма, чишен, кил миңа,*
*Юк уемда азгынлык.*
*Кем башыннан узмаган ул,—*
*Түремнән уз... ялгызлык.*
(«Ялгызлык»)

Шагыйрьнең лирик шигырьләрендә форма төрләнеше дә матур тәэсир калдыра. Менә аның бер матур шигыре. Ул кыз кешегә киңәш-теләк белдерүгә корылган.

*Елмай, сеңелем,*
*Кояш булу*
*бик килешер сиңа.*
*Җырла, сеңелем,*
*Бәхет булу*
*бик килешер сиңа.*

*Җыла, сеңелем,*
*Сабый булу*
*бик килешер сиңа.*
*Ярат, сеңелем,*
*Әни булу*
*бик килешер сиңа.*

Газинурда көйдереп алырлык кайнар шигырьләр белән бергә аксакаллар теленә килешә торган мисраглар, олы фикерләр бар. Алар гадәттә илгә мөнәсәбәтне чагылдыралар.

*Нотык сөйләү түгел,*
*Кылган гамәл кыйммәт.*
*Шушы юлда Илнең*
*Олтаны бул, кешем!—*
*Илдә олтан булу*
*Солтан җаннар эше.*

Мәгълүм мәкальгә ул шушындый тапкыр борылыш бирә. Табигать кайгысы да анарда үзенчә, мәгънәле, борчулы, кырыс чагыла.

*Кемнең кулы җитте икән,*
*Табигать, әйт, тизрәк—*
*Каршы алган торналарым*
*Озатканнан кимрәк.*
(«Яралы көз»)

Газинурның шигъри осталыгы, фикер үткенлеге аеруча афористик юлларда уңышлы гәүдәләнә. Андый шигъри парчалар үзәк өзгеч трагизмны да, дәлилле оптимизмны да эченә ала.

*Фидакарьләр эше дәверләрнең*
*Каны булып тама бәгырьгә.*

Яки икенче мисал:

*Бәекләрнең бәхетсезлеге дә*
*Биләүдән үк килә, бишектән.*
(«М.Ә.»)

Аның якты ышанычына төп таяныч—Кеше.

*... Тик бүленмәс, Кешем, җаның*
*Җете кара йә акка—*
*Иман дәүләтең чигендә*
*Вөҗданың торыр сакта.*
(«Җете»)

Фәлсәфи фикер анарда әнә шулай һәр очракта тирән.

*Бөекләрен барлау өчен бу Тарихка*
*Әйтерсең лә зиндан кирәк булган.*
(«О'Генри»)

Газинур Моратның тарихка багышланган шигырьләрендә милләт язмышы һәм аның бүгенге халәте өчен әрнү һәм дәгъвалар тулып ята, дидек. Тик ул—зур тәҗрибәгә ия үткен күзле ил агасы. Ул үзенең тарихи оптимизмында хәзерге чынбарлыгыбыздагы сәламәт факторларга, реаль мираска таяна.

*Казан каласы—таш кала,*
*Сөембикәле кала.*
*Кыйшайса да, авар, димә—*
*Алыплар саклап бара.*
(«Казан»)

Газинурыбызга, ниһаять, 50 яшь! Аның бай, тирән шигъриятеннән тыш милләт һәм республика өчен үзен аямый эшли торган мәдәни мәйданы—ул безнең кадерле «Мәдәни җомга» гәзитебез бар. Газинур үзенең иҗатташ дусты һәм хезмәттәш аркадашы Зиннур Мансуров белән анарда туган телебезне саклау өчен җан атып эшли. Меңләгән укучыларына кушылып, бу затлы дустыма тагын да зуррак уңышлар телим.

# АМАЗОНКАЛАР ИРДӘҮКӘМЕ?

Мин Рәдиф Сәгъдине күпләгән драмалар авторы дип кенә белә идем. Ә күптән түгел дөнья күргән китабындагы әсәрләрнең роман булуы аерым бер кызыксыну уятты. Китапның исеме дә үзенчәлекле—«Ирдәүкәләр». Ул затлы тышлыкта атка атланган, ук-җәясен тарткан гүзәл хатын-кыз сурәте белән (Булат Гыйльванов эше), Татарстан китап нәшриятында басылган.




Ни өчен «Ирдәүкәләр»? Автор кемне шулай дип атый? Ирдәүкә ул ир-атка охшаган, ир-ат төсле хатын-кыз дигәнне аңлата бит. Хатын-кызны ирдәүкә дип атыйлар икән, бу ана карата бер дә мактау сүзе булып яңгырамый. Ни өчен Р. Сәгъди китабын шулай атаган? Тарихта билгеле амазонкалар турында сүз барамы биредә? Бу исемне ничек кабул итәргә соң? Әйе, сер бар кебек монда. Шушы серне ачу теләге үзе ук бу матур китапка тарта.

«Ирдәүкәләр» китабы ике романнан гыйбарәт. Беренчесе «Ике кояшлы дөнья» дип аталган фантастик роман булса, икенчесе—китапка исем биргән маҗаралы-тарихи әсәр. Ркаил Зәйдулланың «Җан хөрлеге» исемле кереш сүзен укып чыккач та, беренче нәүбәттә бөтен игътибарымны «Ирдәүкәләр»гә бирдем.

Әсәр ни турында?

Тереклек итү һәм үлем, мәңгелек турында дияр идем. Романда бик борынгы тамырларыбызның яшәеше мисалында шушы өзлексез яшәү һәм үлем процессы сурәтләнә. Катлы-катлы меңьеллыклар пәрдәсен кыю гына ачып, автор сөн, анагыр, сармат һ.б. ыруларның өч-дүрт буынлык чорына күз салып алырга мөмкинлек тудыра. Шушы борынгылык фонында рухи кыйммәтләр хакында сөйли. Романда чагылыш тапкан вакыйгалар безнең эрага кадәрге дәвернекеләр булса да, алар бүгенге көн белән гаҗәеп аваздаш. Чорлар төрле, ләкин кыйммәтләр бер. Адәм баласы ясый торган хаталар да шул ук. Затсыз нәселдән зирәк илбашы чыга алмый, атабабасы рухын санламаган кеше юньле тормыш кора алмый. Кылган гамәлләрен өчен бәя дөньялыкта ук бирелә, моннан качып котылып булмый, табигыйлектән тайпылыш беркайчан да уныш китерми. Әсәр менә шулар хакында.

Романда әһәмиятле символик образ бар. Ул—имән. Әсәр имәнне яшен сугу күренешен хикәяләүдән башлана. Гади генә имән түгел, ә ыруның изге агачы—карт имән була ул. Әсәр сюжетында әле бу образ кат-кат телгә алыначак. Романның нәкъ шушы образ белән тәгалләнүе дә игътибарга лаек. Чөнки имән яшәү символы буларак та гәүдәләнгән. «Мәңге яшәр кебек тоелган шул изге имән бүген пыскып җирдә аунап ята иде». Әйе, бернәрсә дә мәңгелек түгел. Имән ауган. Бу—бетү, үлем дигәнне аңлата. Әйтерсең, шуңа бәйле рәвештә, җай гына яшәп яткан ыруга да афәт килә.

Дингез буе сөннәре ыру-ыру булып яши. Төп йортлары—Көлтау. Көлтауда Байбөре нәселеннән килүче Тотым бәк идарә итә. Аның улы Әсән бинең ике хатыннан ике улы туа. Затлы Тутук бәк нәселеннән булган Айгөл бикәдән—Алчын баһадир һәм зинадан туган нәсел-нәсепсез Мөнҗүк улы Талгун баһадир.

Биредә борынгы төрки-татар әдәбия-

---

Рәдиф Сәгъди. Ирдәүкәләр. Татарстан китап нәшрияты, 2007 ел.

тыннан ук килүче зирәк, миһербанлы ил башлыгы идеясенә тап буласың. Әлеге бар яктан камил зат—үзенең акыллы сәясәте нәтиҗәсендә ыруларны, кабиләләрне берләштереп, гаять көчле дәүләт төзергә сәләтле, халкының яхшы яшәвен тәэмин итүче шәхес. Акыллы сәясәтче идеясе әсәрнең буеннан-буена сузылып исбатлана-исбатлана килә дә, ахырда нәтиҗә ясала: дәүләтнең иминлеге, уңышы, иң беренче чиратта, ил башында кем утыруга бәйле. Романда бу идея Алчын бәк образында тормышка ашырыла. Әмма мәкер, хөсет хәтта шул акыллы илбашын да аямый.

Алчын бәк тынычлык белән хәл итәргә алынган мәсьәләгә Талгун агулы таягын тыга. Атҗан житәкчелегендәге күчмә анагырларны автор сөннәргә тугандаш кабилә дип бирә. Анагырларның сөннәр белән берләшү уе Талгун мөртәт аркасында бөтенләй башка юнәлеш ала. Талгун үз туганы Алчынны үтерә, үзе илбашы булып кала. Шулай итеп тугандаш анагырлар белән бер дә кирәкмәгән дошманлык башлана, хәл кискенләшә.

Кем гаепле? Беренчедән, Алчын илбашы ерак сәфәргә үзенең уң кулы итеп Талгунны ала һәм беркатлы адым ясый. Икенчедән (монысы инде әсәрнең фәлсәфи эчтәлегеннән килеп чыга), зинадан туган Мөнҗүккә илбашы кадәр илбашыннан түгел, гади бер көтүчедән дә бала табарга ярамаган. Әсәрдә кабатланып барган әлеге фикер шактый зур идеягә этәрә: затсызлык, бозыклык бәла китерә, илне тарката. Зинадан туган бала илгә-көнгә үчле булып үсә, аның рәхим-шәфкатьле, акыллы булуы шикле, чөнки аның тамыры юк, горурланып, курыкмыйча багарлык үткәне юк.

Талгун—менә шушы затсызлыкны мул чөмергән бер бәндә. Аның әбисе—сихерче, анасы зинадан туган, ата ягыннан бабасы Тотым карт аның белән санлашмый, атасы Әсән би дә, соңлап булса да хатасын аңлап, Талгунны дөньяга бар итүе өчен үкенә. Әмма берни эшләр хәл юк: хата инде кылынган. Хата аркасында бер гөнаһсыз Айгөл бикәнең җаны кыелган. Әлеге хата илбашы гаиләсен эчтән таркатып кына калмый, әкренләп сөн кабиләсеннән тулаем тынычлык китә, ялагайлар, әләкчеләр һәм үз ырудашларын корбан итеп, дан-дәрәҗәгә ирешергә омтылучылар үрчи.

Бу фаҗигането башы кемдә? Әлбәттә, хатын-кызда! Җәмгыятьтә үз урының, дәрәҗәсен белгән затлы хатын-кыз—иренә тугры дус, яхшы киңәшче, балаларына изге ана була. Моңа әсәрдә мисаллар шактый. Бу—Әсән бәк хатыны Айгөл бикә, Алчын бәк хатыны Чәчәк бикә, Әскәр баһадир хатыны Айсылу, сөйгән ярларына тугрылыклы Үчәния, Түгәрәк һ.б. Әмма арада сихерче Мәнти карчык, аннан туган Мөнҗүкләр дә бар. Болар да—хатын-кыз. Тик болар—үз өсләренә төшкән изге бурычны—йөз суын ахыргача саклауны булдыра алмаган, үз урынын белеп бетерми әллә кая сикерергә омтылган тәрбиясез-бәхетсезләр. Менә шулардан туган балалардан Талгуннар үсеп чыгып, зур бәлаләргә сәбәп булалар да инде.

Автор шулай ук дип әйтергә телидерме, юкмы, әмма әсәрнең бай потенциаль эчтәлеге ирексездән нәкъ менә шушы фикергә этәрә.

Романның «Ирдәүкәләр» дип аталуы да югарыда әйтелгәннәргә дәлил. Бу исем белән автор җәмгыятьтә хатын-кызның нинди әһәмиятле урын биләвенә басым ясый. Ыруга афәт килүгә төп сәбәпче, барлык матавыкларның башында торучы—бозык, затсыз хатын-кыз иде. Хәзер килеп шул ук бәхетсезлекләр ырудагы, гомумән бөтен сөн кабиләсендәге бәндәләргә төшә, шул исәптән барча хатын-кыз да коточкыч зыян күрә.

Рим империясенә сәфәре вакытында Талгун коллар белән, бигрәк тә сугышчы коллар белән сәүдә итүне күреп кайта. Комсыз Талгун ыруның тол калган хатын-кызларын орыш серләренә төшендерер өчен колизейларда бәндәләр сугыштыруның рәтен белгән грекны яллый. Максаты—орышчы хатын-кызларны Рим империясенә коллыкка сатып акча эшләү. Әмма акылсыз илбашының бу уе да барып чыкмый, киресенчә, үз башына бәла булып әверелә. Ни өчен дигәндә, батыр йөрәкле сөн хатын-кызлары, үзләрен төркем-төркем итеп кая алып баруларын белеп ала һәм Кавказ тауларына җиткәндә урманга кача, шунда хатын-кызлар патшалыгы төзеп яши башлый.

Алар бик оста сугыша, менә дигән җайдаклар була, талау белән дә шөгыльләнәләр, ир-атлардан тәмам диярлек ваз кичәләр, хәтта ыруда туган ир-ат балаларны да юлдагы сәүдәгәрләргә ияртеп озата торалар. Әмма саксызлык аркасындамы, әллә ахырын уйлап бетерә алмыйча, хискә

бирелепме, хата арты хата кылалар... Кыскасы, алар ничарадан бичара дигәндәй ир-атларсыз яшәп карыйлар. Моны тарихта б.э.к. 490-425 елларда яшәгән Геродотның амазонкалар турындагы язмаларын авторның бай фантазиясе белән кушуы һәм безнең бик борынгы әбиләребезгә күчереп сурәтләве дип аңларга кирәктер.

Әйе, Геродот скиф амазонкаларын тасвирлый, алар хакында: «Кыпчак хатын-кызлары ат өстендә ир-ат төсле көчле сугыша беләләр»,—дигән сүзләр әйтә.

Тарихта скифларның үзләре хакында да, амазонкаларга мөнәсәбәттә дә төрле фикерләр бар. Скифлар—борынгы төрки һәм төрки-иран кабиләләре—галәмәт зур территорияне биләп яшәгәннәр. Гомумән, «скиф» сүзе ул «чит кеше» дигәнне аңлата, ә нинди дә булса этник мәгънә белдерми.

Тарихи чыганаклар хәбәр иткәнчә, амазонкалар—шушы скиф хатын-кызлары, аларны сугышчы һөнәренә махсус өйрәтеп үстерә торган булалар. Бер күкрәкле гаять оста яугирәләр чорын Геродот «Амазонкаларның алтын чоры» дип атый. Төрки амазонкалар—гаҗәеп кызыклы, бәхәсле тема, биредә хакыйкать эзли башласаң, фәкать бик борынгы легендаларга гына барып тоташасың. Күренекле галим, филология фәннәре докторы профессор Фатих Урманчиевның бу хакта шактый күләмле фәнни хезмәте дә бар. Ул 2002 елда «Казан утлары»нда басылып чыкты (№ 7, 8). Галимнең бу мәкаләсендә амазонкалар турында бай тарихи мәгълүмат бирелгән.

Р. Сәгъдинең төрки амазонка образлары тарихи чыганаклар хәбәр иткән әлеге амазонкаларга туры килә. Ләкин аларны «ирдәүкә» дип атау гына ямьсез кебек. Әмма әсәр эчтәлегеннән чыгып, моны аклап та була.

Романдагы амазонкалар никадәр генә гаҗәпләнү катыш соклану тудырмасын, әсәр эчтәлегендә шунысына игътибар итәсең, бу патшалык чарасызлыктан килеп чыккан бер галәмәт, язмыш тарафыннанмы, Тәңре каһәре төшепме рәнҗетелгән һәм Талгун, Бузай сәүдәгәр кебек юньсез ир-атларга карата бәгыре каткан бичаралар иле булып күз алдына килә. Менә ни өчен «ирдәүкәләр» дип атый аларны автор. Яугир хатын-кызлар дип, йә булмаса башкача атый алмыйсың, нәкъ менә ирдәүкәгә әйләнәләр икән шул алар! Болардан чыгып караганда, романның «Ирдәүкәләр» дип аталуына зур мәгънә салынганын аңлыйсың,чыннан да бу исем әсәр эчтәлеген тагын да тулыландыра.

Әйе, ирдәүкәләр ирләрдән башка озак яши алмый, ахырда гүзәл затларыбыз әкрен-әкрен барыбер табигать кушкан яшәү рәвешләренә әйләнеп кайталар. Ни генә дисәң дә, бер генә җәмгыять тә табигатьне узып, башкача яшәүне уйлап таба алмаган шул әле: гармония ир-ат һәм хатын-кыз бердәмлегендә генә була ала. Хатын-кыз үз урынында булырга тиеш, ирдәүкәлек аңа хас түгел, ди автор, әмма шул ук вакытта ул ирләрдән дә батыррак, кыюрак һәм житезрәк була белгән сөн чибәрләрен бик яратып сурәтли, аларга соклануын белдерә. Үчәния, Түгәрәк, Нурсибә һ.б. исемле батыр сөн кызларын күргән чит кавем ирләре дә телсез калып гашыйк була. Ирдәүкәләр искиткеч кыю, көчле, житез дә, шул ук вакытта сылу, назлы да, ярата һәм яраттыра белүләре белән дә таң калдыра алар.

Ничек кенә булмасын, Тәңре бу затларга мәрхәмәтле: алар, бик күп югалтулар кичереп булса да, эчкән антларының, үзләре тудырган кануннарның дөреслегенә үзләре үк шикләнә башлаган хәлдә, туган җирләренә якынлашалар. Бәхетле очрак аркасында сарматлар ыстанында үз ыруыннан булган Күркәч батыр белән очрашу Чәчәк бикәгә ирдәүкәләрне кире туган җиренә, алай гына түгел, Тәңре кушкан үз урыннарына алып кайтып урнаштырырга мөмкинлек бирә.

Әсәр ахырында Имән образының янә калкып чыгуы юкка гына түгел. Чәчәк бикә, хәзер инде илбашы булган улы Надир, кызы Чулпан белән күрешеп, яшь имән көүсәсенә терәлеп, ире кабереңдә тынычлап җан бирә. Яшь имәндәй янә буын килә, нәселне көчлеләр дәвам итә, сөннәрне дә уңышлар көтә, алар, тарихта билгеле булганча, соңрак төркиләр дип аталачак зур халык барлыкка килсен өчен яшәүләрен дәвам итәләр.

Карт имән төбенә көлтаулар үлгән яки үтерелгән илбашларын күмәләр. Яшәү символы Имән һәм теге дөнья ишеге булган кабернең янәшәлеге дә яшәү һәм үлем, үлем һәм яшәү процессының өзлексезлегенә бер ишарә кебек. Әсәрнең буеннан-буена искәртелеп килгән мондый параллельлек, аның өстенә теге һәм бу дөньяларны бәйләүче, кылган гамәлләрең

өчен кайчан да бер җавап бирәчәгенне искәртүче серле образ—Тотым бәк өрәге—романның тәэсир көчен бермә-бер арттыра.

Әсәр тарихи вакыйгаларга нигезләнә, биредә тарихи шәхесләр телгә алына, орыш-сугыш, канлы бәрелеш күренешләре җентекләп сурәтләнә (Алчын, Сатык, Надир, хатын-кыз яугирләр һ.б.). Ат, кылычка, борынгы бабаларыбызның, хәтта хатын-кызларыбызның да сокланырлык дәрәҗәдә житез җайдаклар булуына аерым әһәмият бирелә. Бу яктан әсәр хәтта героик дастанны хәтерләтә. Борынгы җырулар, сарыннар әсәр тукымасына зур осталык белән үрелә бара. Әйтик:

*Ил-йортларданиләр бар,*
*Бүген кем бар, кемнәр юк...*
*Ике яхшы берексә,*
*Яхшыдан яхшы булыр.*
*Ике яман берексә,*
*Илендә ачы булыр.*

Әсәр зур ышандыру көченә ия. Тарих белән чагыштыра башласаң, әлбәттә, роман тирәсендә шактый гына бәхәс туарга мөмкин. Әмма конкрет гасырларны атамый гына сурәтләгәндә реальлек белән әдәби әсәр арасында каршылык әллә ни күзгә чалынмый, оч очка оста гына ялгана, чама чамага туры килә. Ахыр килеп, бу—мажаралы-тарихи роман бит, әдәби әсәр, шуңа да ул тарихи төгәллеккә дәгъва итми, шул ук вакытта биредә тарихны бозып күрсәтү дә юк. Автор хыялында тудырган ыруларга, геройларына үзе уйлап чыгарган исемнәрне бирә, вакыйгаларны бүгенге татар укучысына таныш җирлеккә күчерә, сюжетны оста кора, бүгенге көндә дә актуаль булган мәсьәләләр хакында сөйли, шул рәвешчә, ялыктырмый гына үз артыннан ияртә. Әсәр җиңел укыла, авторның теле камил, күп кенә урыннарда «шәп әйтелгән бит!» дип сокланып куярлык отышлы җөмләләргә дә тап буласың.

Сөннәрнең бергәләп яз каршылау бәйрәме уздырулары, җыру әйтүчене чакырып җыр көйләүләре, яз бәйрәмендә ат өстендә егыш, аркага салыш көрәшләре, кыз тоту уены оештыру, Җир анабыз Умайны телгә алу, Тәңрегә табыну, табын йоласы, җеназа йоласы һ.б.—романның әһәмиятле бизәкләре. Алар сюжет калыбында үз урыннарын әйбәт тапканнар.

Йомгак ясап әйткәндә, әсәр яшәү дәверендә кешеләрнең бәхетле булырга омтылулары хакында. Шушы омтылышны автор үзенчәлекле сюжет, вакыйгалар, образлар аша яктырта. Яугир хатын-кызларның тормыш рәвешен сурәтләве генә дә Р. Сәгъдинең татар прозасына алып килгән зур яңалыгы була ала. Моны күрми калу мөмкин түгел. «Ирдәүкәләр» романы борынгы дастаннар рухына да туры килә һәм икенче яктан ул гүя бүгенге татар мохитенә яраклаштырылган озын бер тарихи дастан.

«Ике кояшлы дөнья» әсәрен исә автор «фантастик» дип тәкъдим итә. Биредә сюжет гади генә кебек тоелса да, асылда ул шактый тармаклана. Фантастик әсәрендә автор бүгенге җәмгыятьтә безнең милләт кешеләренең яшәешен яктырта.

Автор үз героен башка кешеләр белән, тирәлек, җәмгыять белән бәйләнештә күрсәтеп кенә калмый, аны башка дөнья белән бәйләнештә, шул дөньядагылар белән мөнәсәбәттә күрсәтә. Нәкъ менә шул факт романны фантастик әсәр итә дә.

Романның төп сюжет сызыгындагы үзәк каршылыклар милли яссылыкта сурәтләнә. Ул монда геройларның холыкфигылен, эш-гамәлләрен, кискен ситуациядә үз-үзләрен ничек тотуын тасвирлау аша ирешә.

Роман каһарманнарын башка дөнья вәкилләре үзләренә алып китә. Ә бу дөньяда—Тимершаһ планетасында—роботлар идарә итә. Алар биредәге җирле халыкны—биокешеләрне—кол итеп яшиләр, көнкүрешләре дә җан ияләре ихтыяҗын түгел, ә үзләрен—тимер акыл ияләрен—канәгатьләндерү рәвешендә төзелгән. Цивилизациянең иң югары баскычына ирешсәләр дә, ике кояшлы дөньяда тереклеккә, табигыйлеккә куркыныч яный. Шахталарга ябылган җан ияләре «ирек» төшенчәсен бөтенләй онытып бара. Җирдән килгән өч кешенең берсе Радиф, Тимершаһ патшабикәсе Алтынчәч, Абу Табу һ.б. белән берлектә, биредәге кешеләрне роботлар идарәсеннән коткару өчен тырыша. Әмма моның өчен Радифкә күрше Балчык планетасына ярдәм сорап барып кайтырга да туры килә.

Сюжет Радифнең үзе белән килеп чыккан мажаралардан тыш Җирдә калган Әкрам тормышын сурәтли, Тимершаһта Илгизәр белән Фәрит Садыйковның кыланмышларына аерым туктала һәм бу дө-

ньяда роботлар хакимиятенең эшләү рәвешен күрсәтеп, шахталарда гомер сөрүче—бил бөгүче кешеләр тормышын, Балчык планетасындагы хәлләрне яктыртып тагын да тармаклана, катлаулана. Ләкин шулай булса да, әсәр композицион яктан бөтен, аның сюжет тармаклары пропорциональ, алар чама хисен тоеп үстерелә. Әсәрнең интригасы да көчле, конфликтлар оста корылган. Персонажларның һәр хәрәкәте, автор сурәтләгән портрет, күренеш—барысы да җанлы булып күз алдына килә. Әйтик, «Азатлык яугирләре» дигән бүлектә Тимершаһ кешеләрен азат итү өчен сугыш-көрәшне автор шулкадәр бирелеп, җентекләп тасвирлый, моны ышанмыйча уку һич мөмкин түгел.

Әсәр комиклык эффекты белән дә сугарылган. Хәзерге яшәешебез өчен бер дә ят булмаган эчеп исерү, бераз төшереп алгач, шапырыну, тукмашып алу, нәфесне тыя алмау, комсызлык аркасында әдәп-әхлак кагыйдәләрен бөтенләй санга сукмау, ришвәтчелек кебек хәлләр кызык та, кызганыч та.

Китап геройларында (азат ителгәннән соң да үзләре теләп коллыкны сайлаучы куркытылган җан ияләре—Тимершаһ кешеләре, идарә итүче роботлар, Әкрамны тиләләр йортына озаттыручы милиция бүлеге начальнигы Алекс Исмаеч һ.б.) без үз замандашларыбызны таныйбыз, алар кылган гамәлләр—бүгенге Рәсәй җәмгыяте җимешләре, чорга хас кануннар. Әйтик, төп герой Рәдиф Тимершаһтан алып кайткан байлыгына милли университет салдырырга уйлый. Эш гөрләп башланып та китә. Тиешле кешеләр белән сөйләшенә, вәгъдәләр алына. Әмма ахырда милли университет барыбер салынмый, аның урынына түрәләрнең менә дигән коттеджлары үсеп чыга, героебыз әле кемнәргәдер тиеш тә кала. Түрәләрнең бу пычрак гамәле исә мөһерле кәгазьләр белән ныгытылган, барысы да законлы төстә башкарылган. Күпме акча сарыф ителгән, ә эшләнәсе эш эшләнмәгән!

Тимершаһ планетасындагы вакыйгалар турында сөйләгәндә автор боларны Җирдәге тормыш белән чагыштыра бара. Әйтик, Балчык планетасы вәкилләре ярдәмендә коллыктан азат ителгәч тә, шахтада туып-үскән Тимершаһ кешеләре үз теләкләре белән яңадан коллыкны сайлыйлар. «Бу хәлне аңларлык түгел иделәр шул үз дәрәҗәләрен белгән, коллыкның ни икәнен кинолардан гына күреп үскән балчыклылар... Моны аңлар өчен безнең кебек җирдә—Татарстанда—туып-үсәргә кирәк иде».

Әйе, шулай шул, дип, авыр сулап куярга гына кала бирәдә.

Тагын бер кызыклы күренеш. Роботлар кешеләрне шахтадан чыгарган очракта, җәмәгать урыннарында башларына тимер савыт киеп йөрергә мәҗбүр итмәкчеләр. Сөйләшүләре дә робот теленә охшаш булсын. Безнең дә телебез бүгенге көндә шул Тимершаһ җан ияләре хәлендә түгелме? Уйландыра бу!

Әйе, әлеге дөнья белән Татарстан, шул дөнья вәкилләре белән Татарстан кешеләре, Тимершаһ роботлары белән шул ук дөньяның кол ителгән җан ияләре арасында бик күп янәшәлек бар. Биредә авторның үткен кинаясен сизми калу мөмкин түгел. Шуңа да комиклык эффекты белән сугарылган әлеге әсәр шактый зур проблемаларны күтәрә. Милләт өчен иң әһәмиятлесе, әлбәттә, азатлык проблемасы, милли тормыш һәм милли мәдәният мәсьәләләре.

Рәдиф Сәгъдинең әлеге китапка кергән ике романы да—шактый камил әсәрләр. «Ирдәүкәләр» дә, «Ике куяшлы дөнья» да эчтәлек белән сәнгатьлелекне әйбәт яраштыра. Болар—укучыны рухи үстерә торган әсәрләр. Аларны бераз тәнкыйтьләргә, күп кенә урыннарында автор белән бәхәскә керергә дә мөмкин, әлбәттә. Әмма шунысы бәхәссез: аларга битараф калып булмый. Бигрәк тә «Ирдәүкәләр» борынгы тарихыбызга, әле тиешле тирәнлектә язылып бетмәгән үткәнебезгә, миф, легендаларга карата кызыксыну, эзләнү теләге уята. Йөрәктән чыккан гына йөрәккә җитә, сәнгатьчә оста сурәтләнгән фикер генә укучыны дулкынландыра. Автор биредә шуңа ирешә алган, димәк, яхшы китап дөньяга килгән дигән сүз. Укымый калмагыз!

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

# СӘХНӘДӘН—ФРОНТКА...

*Татарстанның халык артисты Һидаят Солтановны, минемчә, белмәгән кеше сирәктер. Берничә ел элек миңа шушы күренекле шәхес белән Республика медицина диагностика үзәгендә бер палатада дәваланып ятарга туры килде. Без—ике фронтташ, әдәбият-сәнгать темасына ялгап, дәһшәтле сугыш маҗаралары турында төннәр буена сөйләшеп ята идек. Һидаят абыйның үзе турында сөйләгәннәрен мин гаҗәеп бер кыйсса шикеллерәк кабул иттем.*

### «Алла бүләге»

Һидаят абый Чүпрәле районының өч түгәрәк күл белән уратылган Татар Убие авылында туа. Анын этисе–оста куллы Айниатулла абзыйны 1915 елда герман сугышына алалар. Хатыны Фәрхисәйран шушы елнын көзендә гаиләләре өчен бик тансык булган ир бала таба. Сафиулла мәзин ана Һидаятулла, ягъни «Алла бүләге» дигән исем куша. Әтиләре герман һәм гражданнар сугышы мәхшәрен кичеп өенә әйләнеп кайтканда, улы Һидаятулла инде алтынчы яшенә киткән була. Тумышыннан ук таза, шук малай башлангыч классларда укыган чагында ук үзеннән олы мәктәп балалары белән сәхнәгә чыгып җырлый-бии башлый.

Ләкин менә шулай матур гына яшәп ятканда, утызынчы еллар башында, Айниатулла абзыйны кулакка санап, бөтен байлыгын тартып алып, унбер кешеле ишле гаиләсе белән өеннән куып чыгарып, кечкенә генә бер мунчада яшәргә мәҗбүр итәләр. Айниатулла абзый–бөтен байлыгын калдырып, гаиләсе белән авылдан чыгып китә һәм Баку каласындагы бер туганы янына барып урнаша. Һидаят анда интернациональ мәктәптә татарча укуын дәвам итә, уку алдынгыларыннан санала.

1933 елнын җәендә "Казаннан Татар академия театры килә икән» дигән хәбәрне Бакудагы татар кешеләре шатланып каршы алалар. Һидаят та айга якын барган спектакльләрнен берсен дә калдырмыйча карый. Сара Садыйкова белән Ситдыйк Айдаровнын моңлы җырлары анын күнеленә аеруча хуш килә. Шакир Шамильскийнын «Зәңгәр шәл»дәге ат карагы монологын да мөкиббән китеп тынлый ул. Укытучылар мәктәп укучыларын өлкән артистлар белән таныштыралар һәм алар да кунакларга үз һөнәрләрен күрсәтәләр, Һидаят Солтанов Такташ шигырьләрен укый. «Синдә, егет, артист сәләте бар. Нигә Казанга барып үзеннең бәхетенне сынап карамаска? Анда театр училищесы бар. Синен буй-сынын, тавышын да әйбәт»,–дип әйтеп куя Һидаятка Шакир Шамильский. Бу сөйләшү Һидаят күнелендә мәңге сүнмәс сәхнә уты кабыза. Ләкин анын этисе Айниатулла абзый «артист» сүзен ишетергә дә теләми: «Юк-юк, улым, артистлар алар килде-китте ышанычсыз халык, гаилә тормышына да ярамыйлар. Син бухгалтер булырга тиеш",–дип кырт кисә. Һидаят иртүк укытучысы Махмед Ализадәнe очратып үзенен хәлен сөйләп бирә. «Нинди бухгалтер? Син–коеп куйган артист! Хәзер үк сиңа театр училищесына керергә гариза язып бирәм. Ә этиенә «Энергетика училищесына барам, инженер булам» диярсен, каршы килмәс»,–дип җавап бирә укытучысы.

## Адәм баласын тәкъдир йөртә

Менә шулай итеп, 1934 елның көзендә Һидаят пароходка утырып Казанга килеп төшә. Ә иртәгесен–имтихан. Укытучылар ана сокланып карыйлар: буе да әйбәт, тавышы да ярыйсы гына, тик… теле генә–чеп-чи мишәр теле. Димәк, артист була алмый. Һидаят әнә шул хәбәрдән кайгырып утырганда, яңа гына ГИТИСта укып кайткан Гомәр Исмәгыйлевне очрата. Ул Һидаятне залга чакырып ала һәм аның «һөнәрләрен» сынап карый. Һидаят бүре белән очрашу күренешен шулкадәр әсәрләнеп уйнап күрсәтә ки, хәтта янындагы урындыкны ватып, челпәрәмә китерә! Ул абитуриентны училище директоры Сәед Булатовка күрсәтә.

Режиссер Исмәгыйлев беренче дәресеннән ук Константин Станиславский методын алга куя. Зәйни Солтанов, Мөхтәр Мутин, Хәлил Әбҗәлилев, Фатыйма Ильская һәм башка артистларны мисалга китерә, Һидаятькә уку җинел бирелә. Ул Вера Минкина, Хәй Вахит, Гамир Насрый, Сәед Шәкүров белән бергә укый.



Беркөнне, һич көтмәгәндә, Һидаят Хәлил Әбҗәлилев белән очраша. «Безнен театр актеры буларга телисенме?»–дип сорап куя аннан күренекле артист. Һидаят үз колагына үзе ышанмыйча аптырап кала. «Хәлил абый, минем бит әле укыйсым бар. Ничек итеп аласыз мине?»–ди ул сорауга каршы сорау белән.

–Нигә алмаска? Буен-сынын бар, тавышын отлично. Анда өйрәнерсен.

Бу көтелмәгән тәкъдимнән Һидаятнең башы күккә тия. Үзен инде чын артист итеп тоя башлыйм дигәндә генә…

Тәкъдир дигән нәрсә үзенекен итә икән шул. Ташкенттан күңелсез хәбәр килә: апасын чаян чагып үтергән икән. Аның өч баласы ятим кала. Һидаят ятимнәр янына ашыга.

Шулай итеп, Татар академия театрында уйнау ун еллар буена Һидаятнең хыялында гына кала. Шулай да… тәкъдир дигән нәрсә аңардан бөтенләй үк баш тартмаган икән әле. Ятим туганнарын урнаштыргач, ул Ташкент татар театры режиссеры Бакир Юсупов янына килеп, Казанда театр училищесының өч курсын тәмамлап кайтканын сөйләп бирә. Һидаятькә бер-ике көннән үк «Кандыр буе» спектакленнән бер роль өйрәнеп килергә кушалар. Ләкин озак та үтми пьесаның авторы Кәрим Тинчурин репрессиягә эләгә һәм Һидаятькә бу спектакльдә уйнарга насыйп булмый. Сәхнәдә Тажи Гыйззәт әсәрләре куела башлый, Һидаят «Чаткылар»дагы Сабир ролен бик уңышлы башкарып чыга. Аннан соң «Наемщик», Мөхәммәт Аблиевнын «Шәмсекамәр»е, Шиллернын «Мәкер һәм мәхәббәт»е. Артист тиз арада театр сәхнәсенең түренә күтәрелә.

## Беренче мәхәббәте көтәрме?..

Ләкин, әлеге дә баягы, тәкъдир дигән нәрсә һаман да аның юлына киртә булып төшә–ул Урта Азия бизгәге белән авырып китә. Табиблар ана Ташкентның эссе мунча ташы кебек климатыннан Рәсәйнең уртача климатына күчеп яшәргә тәкъдим итәләр. «Китми калсаң, бу чир бөтенләй аяктан егачак»,–диләр. Башкортстандагы дусты режиссер Бәширов аны Башкортстанның Яңавыл шәһәрчегенә алып килә. Һидаят Солтанов Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» спектаклендә Галимҗан ролен бик оста башкарып, үзен тиз арада танытып өлгерә.

Биредә ул үзенен булачак хәләл җефете–Уфа театр техникумында укыган Рәхилә туташ белән дә таныша.

Менә 1940 ел да килеп җитә. Башкортстан театрына иялэшеп кенә беткәч, Һидаят ялга эти-әнисе, туганнары янына Бакуга кайта. Беркөнне Айниатулла абзый Һидаятне янына утыртып бик җитди темага сүз башлый: «Улым, син кайсы армиядә хезмәт иттен сон әле?»

«Мине, эти, театрда бронь белән калдырдылар бит»,–ди Һидаят. Ана каршы этисе үз кинәшләрен бирә: «Хәзер, улым, дөньялар тыныч түгел, Гитлер зәхмәте ярты Европаны басып алды. Ул барыбер безгә ташланачак. Мин үзем сугышнын "тәмен" татыган кеше. Сугышка әзерлек белән кермәсән, надан солдатларны сарык көтүе кебек беренче көннәрдә үк кырып бетерәләр. Кинәшем шул: син тизрәк армиягә китәргә тырыш. Сугыш серенә алдан ук өйрәнеп куй, броненны ташла да гариза биреп кит». Һидаят этисенен кинәшен тотарга вәгъдә бирә һәм үзе теләп Кызыл Армия сафларына китә. Сөйгән кызы Рәхилә аны күз яшьләре белән озатып кала, егете кире әйләнеп кайтканчы көтәргә сүз бирә. Тик ул чакта әле Рәхилә сөйгән егетен җиде ел буена өметләнеп көтәчәген күз алдына да китерә алмый, билгеле.

## Беренче чыныгу

1941 елнын 22 июне. Һич көтмәгәндә хәрбиләр өстенә хушынны алырлык сиреналар акыртып, фашист козгыннары бомба яудыра. Кыямәт көне диярсен!.. Солтановлар бригадасы, үзенен авыр гаубицаларын шартлатып, немец танклары чолганышыннан кача-кача, алга ыргылган фашистлар белән сугыша-сугыша, Псков шәһәренә кадәр чигенә. Солдатлар бу паникалы чигенүне бик авыр кичерәләр...

1941 елнын илле градуслы зәмһәрир суык көннәре. Солтановлар часте Ржев тирәсендәге каты сугышларда катнаша, Һидаят яраланып, ансыз хәлдә салкын кар өстендә ятып, ике аягын да өшетә, Һидаятнен ярым үле гәүдәсен шәфкать туташы кар өстеннән сөйрәп госпитальгә алып кайта. Ә анда докторларнын хөкеме бер була–ампутация! Бу–яшь артист өчен үлем белән бер. Чибәр кыз сугышчы егетне кызганып, елый-елый докторлардан анын аякларын кисмичә калдыруларын сорый: «Ради Бога, не губите этого красавчика–я его сама вылечу». Шуннан сон ул һәр көнне, салкын кар һәм төрле дарулар белән ышкып, анын каткан аякларына жылы жан индерә, Һидаят әкренләп терелә, аяклары да исән кала.

Сталин: «Артиллерия–бог войны» дигән лозунгысын бәян иткәч, армиядәге урта белемле сугышчыларны, шул исәптән Солтановны да, кече лейтенантлар әзерли торган Выкса шәһәренә укырга җибәрәләр. Һидаят сугышка кадәр үк наводчик һөнәрен үзләштергәнгә күрә, училищены унышлы тәмамлап, кече лейтенант чины алып чыга. Шуннан сон аны орудие командиры итеп куялар.

## Туры наводкадан—дошманга!

1943 ел Солтанов өчен гаять истәлекле ел була. Язгы көннәрнен берсендә Солтановлар артполкы, пехотадан аерылып, Кудрино авылын азат итәргә кереша. Көтмәгәндә Солтанов батареясе дошман засадасына эләгә. Немецлар, пехотасыз калган ялгыз батареяне жинел генә кулга төшерергә өметләнеп, һөҗүмгә ташлана. Солтанов югалып калмый, батареясен тиз генә борып, немец пехотасы өстенә шрапнельле снарядлар яудыра. Турыдан төгәл атып немецлар батареясен дә юкка чыгара.

Икенче бер вакыйга шул елнын җәй көненда була. Безнен гаскәрләр һөҗүмнәрен унышлы гына дәвам итеп, көнбатышка таба барганда Осиновая роща янындагы түгәрәк бер калкулыктагы дотларыннан немецлар ут янгыры яудыра башлый. Кат-кат атакага барган сугышчыларыбыз, бу каһәр төшкән биеклекне ала алмыйча, күп корбаннар калдырып чигенергә мәҗбүр. Шунда Һидаят Солтанов, төн карангылыгыннан файдаланып, яшерен генә немецларнын борын төбендә үк үзенен

тупларын урнаштыра. Иртән, яктыра башлагач, туры прицель белән пушкалардан атып дотларын җимереп ташлый һәм безнең пехота зур югалтуларсыз гына бу биеклекне кулга төшерә. Ләкин бу операция Солтановка да бик кыйммәткә төшә. Умыртка сөяге каты яраланып, ул госпитальгә озатыла. Күрсәткән тапкырлыгы һәм батырлыгы өчен лейтенант Солтанов I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Госпитальдә дәваланып чыккач гвардия өлкән лейтенанты Һидаят Солтановны Свердловскидагы «Уралмаш» заводына–үзйөрешле СУ-100 пушкаларын алырга җибәрәләр. Ул, яңа коралларны төяп, Германиягә сугышны дәвам итәргә ашыга. Җиңү көнен Берлинның төньягында урнашкан Нойштриц шәһәрендә каршылый.

## Артист—фронтта да артист

Сугыш уты сүнү белән Һидаят Солтанов ротасы Стендаль шәһәрендә урнаша. Беркөнне сугышчылар арасында зур абруй казанган полк командиры, Һидаятне үз кабинетына чакырып ала һәм шунда ук төп мәсьәләгә күчә: «Иптәш Солтанов! Сугыш алдыннан артист буларак театрда шактый гына эшләгәнсез икән. Солдатлар сугышта арыдылар. Сез аларга кино залы оештырып бирсәгез иде. Сезгә кирәкле ярдәмчеләрне беркетермен».

Һидаят җиң сызганып эшкә керешә. Аның планы белән уртача җиһазландырылган сәхнәле клуб төзиләр. Биредә атна саен кино күрсәтелә, җыелышлар уздырыла. Һидаят хәрби хезмәткәрләр, солдатлар арасыннан талантлыракларын җыеп, үзешчән сәнгать коллективы да оештырып җибәрә. Магдебург шәһәрендә үткәрелгән конкурста армиянең үзешчән сәнгать коллективлары арасында Солтанов труппасы беренче урынны алуга ирешә. Сәхнә эшендәге һәвәслеген искә алып, аны штабка чакырталар һәм Магдебургтагы «Офицерлар йортын» җитәкләргә тәкъдим итәләр, әгәр шунда эшкә калса, хәтта майор чинын да бирергә вәгъдә итәләр.

Билгеле, армия командованиесе ныклап теләсә, өлкән лейтенантны «Офицерлар йорты»ның директоры итеп калдыра алган булыр иде. Ләкин Солтановны бернинди чиннар да кызыксындырмый, аны туган иле, яраткан театры һәм түземсезлек белән көткән сөйгәне–Рәхиләсе үз янына тарта.

## Җиде елдан соң очрашу

Гвардия өлкән лейтенанты Һидаят Солтанов ике Ватан Сугышы ордены һәм күкрәк тулы сугышчан медальләр тагып, армиягә китүенә нәкъ җиде ел да ике ай тулгач, әти-әниләре, туганнары янына кайту бәхетенә ирешә. Алардан хәер-фатиха алып Казанга юл тота. Шулай итеп, Һидаяткә үзенең яраткан театрына унөч елдан соң гына кайтып эшкә алыну насыйп була. Эшкә керешкәч, ул шатланып сөйгән кызы Рәхилә янына Уфага ашыга. Алар бер-берсенә биргән вәгъдәләренә тугры калып, шатлык белән кавышалар. Уфада бер атналап туй мәҗлесләрен уздырып, туй сәяхәте итеп Казанга юнәләләр. Юлда сөйләшеп сүзләре бетми.

Рәхилә 1943 елның җәй айларында 13 кешелек концерт бригадасы белән Смоленск якларында булуын әйткәч, Һидаят гаҗәпкә кала: «Кара әле, без синең белән янәшә генә булганбыз икән бит,–ди ул.

Рәхилә Башкортстан яшьләренең фронт бригадасы составында өч ай буена бер частьтан икенчесенә йөреп, көненә дүртәр-бишәр концерт бирә. Аңа да ире кебек үк алгы фронт линиясендә дары исен татырга туры килә. Алар труппасы, машинага төялеп икенче частька күчкән чакта, машиналары минага эләгеп шартлый. Шофер каты яралана. Рәхиләне шартлау дулкыны бер снаряд чокырына алып ташлый һәм колагын җәрәхәтли (ул җәрәхәт хәзер дә үзен сиздерә–аның колагы начар ишетә). Конферансье Газимәнең бармаклары өзелә, ә аның ире–баянчы Хәлилнең кулы яралана...

Шулай итеп, Бөек Җиңүгә фронт солдатлары гына түгел, аларның күңелен күтәреп, дошман снаряд-миналары астында йөрүче үзешчән фронт артистларының да өлеше керә.

## Коеп куйган артист бит ул!

Театрга кайтуынын беренче көннәреннән ук режиссерлар Һидаяткә баш рольләр тәкъдим итә башлыйлар. Әлеге дә баягы, «Ходай бүләге»–төсе-буе, кыяфәте, тавышы белән дә коеп куйган артист бит ул!

Театрга килеп керүенен икенче көнендә ук режиссер Ш. Сарымсаков фронттан яна гына кайткан Һидаяткә Риза Ишморатнын «Якты юл» спектакленнән Фәттах ролен тәкъдим итә. Фәттах та–Һидаят кебек ук сугыштан яраланып кайтып, тыныч тормышка аяк баскан кеше.

Премьерадан сон Солтанов грим бүлмәсенә керсә, анын янына Р. Ишморатов килеп: «Молодец егет! Сине дебютын белән котлыйм. Пьесамны нәкъ синен өчен язганмын икән!»,–дип мактап ала. Һидаятнен күнеленә кереп калган икенче зур роле–Нәкый Исәнбәтнен «Мулланур Вахитов» пьесасындагы Әҗем роле. Ул–Мулланурнын яраткан ординарецы. Бу юлы да Нәкый Исәнбәт артистны чын күнелдән тәбриклэп чыга. Шул елларны ул «Хужа Насретдин»дагы Дәрвишне уйнап, тамашачыларнын күнелен җәлеп итә. Һидаят Солтанов инде сәхнәдә үзен өлгергән артист итеп сизә башлый, дистәләрчә рольләр тудыра. К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр»ендә–Даут, Н. Исәнбәтнен «Муса»сында–Зоммерфельд, Д. Вәлиевнен «Суд хөкеме»ндә–Мансур һәм башкалар. Ул татар язучылары пьесаларыннан башка рус һәм Европа классикларынын әсәрләрендәге рольләрне дә зур талант белән уйный. Шулардай М. Горькийнын «Минем университетларым»ында–Никифоров, Б. Горбатовнын «Бер төн»ендә–Максим, Шекспирнын «Король лир»ында–Эдмонд һәм башкалар.

## Бәхетле кеше

Һидаят Солтанов–бәхетле артистларыбызнын берсе. 50 еллык иҗат гомерендә ул, Үзбәкстан, Башкортстан театрларын да санасан, 172 (!) рольдә уйнаган кеше. Ана милли театрыбыз сәнгатен тудырган Фатыйма Ильская, Мохтар Мутин, Хәлил Әбҗәлилев, Хөсәен Уразиков, Зәйни Солтанов белән бергә уйнарга туры килгән.

«Мин үземне бик бәхетле итеп саныйм. Халкым, тамашачым яратты мине. Шәһәр транспортында барганда да, мине танып, ихтирам йөзеннән, хәтта олы яшьтәге ханымнар да урын тәкъдим итәләр. Урамда очраган кешеләр дә: «Зинһар, театрдан китмәгез, без Сезне яратабыз»,–дип әйтәләр»,–ди артист.

Әйе, күпчелек тамашачылар кебек мин дә Һидаят абыйнын сәхнәдәге рольләрен бик яратам. Бер бүлмәдә бер атна уздырган сәгатьләрем ана булган ихтирамымны тагын да көчәйтә төште. Кемнәр генә ләззәт табып карамады икән Т. Миннуллиннын озын гомерле «Әлдермештән Әлмәндәр»ен! Евстегней картны ничек килештереп уйный бит Һидаят абый.

Алар, җәмәгате Рәхилә ханым белән өч бала үстереп, никахларынын 50 еллыгын–«алтын туйларын» бәйрәм иттеләр. Казан радиосында «Пар канатлар» тапшыруында чыгыш ясадылар.

Һидаят агага Әлмәндәр-Евстегнейларнын озын гомерен телибез. Әле анын иҗат чишмәләренен шифалы сулары мөлдерәмә тулып тора. *Дербышки* бистәсендә ул оештырган Халык театры бүгенге көндә дә ярты гасырдан артык яшәп килә. Бирелә Һидаят Солтанов житәкчелегендә утызга якын спектакль Дербышки бистәсендәге культура сараенда куелып килде.

Ике фронтовик– Һидаят һәм Рәхилә Солтановлар кулга-кул тотынышып, гомерләренен тугызынчы баскычына атлыйлар.

**Нәгыйм МӨХИБУЛЛИН,**
*Россия һәм Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы, Бөек Ватан сугышы ветераны.*

## Харис Якупов



Якупов Харис Габдрахман улы (1919)—нәкышче, график. Россия сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы (1997). РСФСР һәм СССРнын халык рәссамы (1963, 1980). Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе. ТАССР рәссамнар берлеге идарәсе рәисе (1951—1975). «Зур Идел» («Большая Волга») зона күргәзмәсе рәисе (1964—1980).

1948-52 елларда ук инде Казан сәнгать училищесында укытучы, Россия сәнгать академиясенең Казандагы нәкыш остаханәсе житәкчесе (1977 елдан).

Төп әсәрләре: нәкыш—«Хөкем алдыннан» (1954), «Казан студентлары. 1887 ел» (1970-80), графика—«Г. Тукай һәм Федор Шаляпин» (1970), «Татар халык әкиятләренә иллюстрацияләр» (1957, Л. Фәттахов белән берлектә). СССР Дәүләт, РСФСРның И. Репин исемендәге һәм Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты (1951, 1976, 1958).

## Мөсәгыйт Хәбибуллин



Мөсәгыйт Мөдәррис улы Хәбибуллин 1927 елны Оренбург өлкәсенең Абдуллин районы Габдрахман авылында туа.

Булачак язучы, уку белән бергә, яшьтән үк колхоз эшендә актив катнаша. Аннары, һөнәр мәктәбен тәмамлап, токарь һәм мастер булып төрле оешмаларда эшли, тормыш университетларын уза. 1971 елда исә Казан дәүләт университетын тәмамлый.

Ул—Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (1978, 1988), Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы (2008). Ижаты: совет чоры тормышының катлаулы мәсьәләләрен күтәргән повесть һәм романнары; Идел буе Болгарының тарихи юлын тасвирлаган тарихи романнар циклы: «Кубрат хан» (1985), «Илчегә үлем юк» (1990); Казан ханлыгы чорын чагылдырган «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» (1994), «Хан оныгы Хансөяр» (1998), «Батый хан һәм Ләйлә», «Айбиби» һ.б. романнары.

**Альфрет ӘБДРӘШИТЕВ**

# ПСЕВДОНИМ—КУШАМАТ ТҮГЕЛ

Псевдоним—грек сүзе. Сүзлекләрдә аның уйлап чыгарылган исем, фамилия булуы, чын исем, фамилияне яшерү өчен сәясәтчеләр, язучылар, артистлар тарафыннан кулланылуы әйтелә. В. Дмитриевның 1970 елда Мәскәүдә чыккан «Скрывшие свое имя» дигән китабында да ана мондый билгеләмә бирелгән: псевдоним—уйлап чыгарылган яки үзгәртелгән исем һәм фамилияләрне алыштырган имзаларның гомуми аталышы.

Псевдоним күптән, әле китап бастыру уйлап чыгарылганчы ук барлыкка килгән. Кешеләр цензура эзәрлекләвеннән куркып, яисә яшерен исем белән үзләренен әсәрләрен бастырырга омтылып, йә унышсызлыкка очрармын да гаеп ташларлар, дип уйлап һәм башка сәбәпләр белән псевдоним алганнар. Ә менә теге яки бу язучы, артист, галим, сәясәтче ни өчен нәкъ менә шундый псевдоним алган, башкасын түгел? Бу сорауга һәрвакытта да дөрес җавап табу кыен. Чөнки ул кешенен характеры, туган ягы, яшәгән урыны, нәсел-нәсәбе белән бәйле булырга мөмкин.

Псевдонимнар куллану XVII гасырда аеруча киң тарала. Янарыш дәверендә фән һәм мәдәният өлкәсендә халыкара тел булып латин теле саналган. Шуңа күрә псевдонимнар турында беренче сүзлекләр дә латин телендә язучы авторларга багышлана. Шундый беренче сүзлек 1652 елда нәшер ителә. Аның авторы—И. Суарес. Китап «0 подписях и знаках, под коими скрыты истинные имена» дип атала. 1669 елда Лейпцигта немец телендә Ф. Гейслерның «Үзгәртелгән исемнәр һәм аноним язучылар турында» дигән хезмәте басылып чыга. 1806—1809 елларда француз телендә Наполеон Беренченең китапханәчесе Антуан Барбье үзенен исемен яшергән авторларның әсәрләреннән дүрт томлык сүзлек бастырып чыгара. Кеннидиның инглиз телендә нәшер ителгән 7 томлык сүзлегендә 60 меңгә якын псевдоним тупланган.

Мондый сүзлекләр һәр илдә диярлек бар. Хәтта кечкенә генә Даниядә дә псевдонимнар турында сүзлек төзеп чыгарганнар.

Рус телендә исә шундый хезмәт 1874 елда басылып чыга. Ул «Рус телендә чыккан аноним китаплар, аларның авторлары исемнәре һәм тәрҗемәчеләре исемлеге» дип атала. 1865—1889 елларда псевдоним белән чыккан әсәрләрнең авторлары турында Н. Голицинның библиографик сүзлеге нәшер ителә. 1891 елда «Рус язучылары псевдонимнары сүзлеге тәҗрибәсе» дөнья күрә. Шуннан соңгы чорда танылган библиограф И. Масанов аеруча актив эшли. Ул 80 меңнән артык псевдоним җыйган. Әмма революциягә кадәр аны китап итеп чыгарырга рөхсәт бирмиләр. Ләкин ана карап И. Масанов эшен туктатмый. Күп еллардан соң ул теләгенә ирешә. 1936 елда китабының беренче томы чыга. Вафатыннан соң аның эшен улы Ю. Масанов дәвам иттерә.

Татар телендә псевдонимнар турында аерым бер китап булып чыккан хезмәтләр юк. Ләкин безнең татар язучылары, артистлары арасында исем, фамилияләрен яшереп, яисә үзгәртеп үзенең әсәрләрен бастырган һәм бастыручы әдипләребез, олы сәхнәләрдә уйнаган, җырлаган һәм җырлаучы артистларыбыз аз түгел. Әмма псевдонимнар белән кызыксынучылар булган. Мәсәлән, язучы һәм журналист Мәхмүт Бөдәйли аларны җыеп, сүзлек төзегән. Бу хакта «Казан утлары» журналының 1969 ел, 1 санында хәбәр ителә. М. Бөдәйли җыйган псевдонимнарның бер өлеше кереш сүз белән бирелгән.

1956 елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан нәшер ителгән «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә болай диелә: «Псевдоним—кайбер язучыларның үз әсәрләрен матбугатта чыгарганда куйган кушаматлары». Моңа ачыклык кертү кирәктер. Беренчедән, псевдоним алу язучыларга гына хас нәрсә түгел, аннан артистлар да,сәясәтчеләр, галимнәр дә, рәссамнар да файдалана. Икенчедән, псевдоним—кушамат түгел. Кушаматның үз мәгънәсе, үз урыны бар. Аның кайберләре кешенең килеш-килбәтенә, холык-фигыленә, тышкы кыяфәтенә карап бирелгән. Мәсәлән, борынгы Рим шагыйре Клавдийны Сукыр Клавдий дип йөрткәннәр. Римның атаклы ораторы Марк (бүтән исеме Туллий) битендәге сөяле өчен Цицерон кушаматы алган. Цицерон—цицеро дигән сүздән ясалган. Ул борчак бөртеген аңлата; күрәсең, Маркның сөяле шуңа охшап торган булса кирәк. Шулай да псевдонимнарның килеп чыгу тарихы, кемнең ничек башка исем, фамилия артына яшеренү очраклары шактый кызыклы.

Кемнәр генә заманында нинди генә псевдонимнар алмаган?! Марк Твен, Мольер, Вольтер, Стендаль, Анатоль Франс бу псевдонимнарны үзләре уйлап тапканнар. Язучылык эшенә керешкәнче аларның чын исем, фамилияләре бөтенләй башка булган. Горький, Серафимович, Д. Бедный, Багрицкий, Гайдар, Светлов та әти-әниләре биргән фамилияләреннән ваз кичкәннәр.

И. Масанов үзенең сүзлегендә Владимир Ульяновның 99 псевдонимын китерә. Ләкин ул тарихка Ленин булып кереп калган. Бу псевдоним беренче тапкыр 1901 елда «Заря» гәзитендә күренә. Аның ничек килеп чыгуы төгәл генә билгеле түгел. Бериш тарихчылар, В. Ульянов унтугызынчы гасырның сиксәненче елларында Ярославль губернасында яшәгән Николай Егорович Ленин фамилиясен алган, диләр. Николай Егоровичның вафатыннан соң аның паспортын туганнары В. Ульяновка биргәннәр. Рәсми документларда Ленин сүзенең Лена елгасыннан алынуы фаразлана. Ул елларда Джугашвили—Сталин, Бронштейн—Троцкий, Розенфельд—Каменев, Родомышельский Зиновьев фамилиясен ала. Сергей Костриков Кировка әйләнгән. Ул «Терек» гәзитәсендә эшләгәндә мәкаләләрен Миронов псевдонимы белән бастыра. Бу аның үзенә бик ошап бетми. Редакция коллективы белән бергәләп аңа башка псевдоним эзлиләр һәм «Кир»га тукталалар. Кир Персия патшасы, полководец исеме булган. Шуннан соң Костриков Киров булып киткән.

Мәгълүм бер чорда әдәбият, сәнгать, гомумән, мәдәният, фән хезмәткәрләренең псевдоним алулары модага кереп китә. Атаклы артист Качаловның чын фамилиясе Шверубович, эстрада җырчысы Леонид Утесовныкы—Лейзер-Вайсбейн, язучы һәм журналист Михаил Кольцовның—Фридлянд, тюрколог, академик Василий Радловның—Фридрих Вильгельм, режиссер һәм артист Станиславскийның Алексеев икәнлеген күпләр белмидер дә әле.

Яки менә атаклы артистыбыз Габдулла Кариев кем ул? Бу—Чистай өязенең Күлбай Мораса авылында туып-үскән Миңлебай Хәйруллинның сәхнә псевдонимы. «Габдулла Кариев турында истәлекләр»дә Миңлебайның Такталы авылы мәдрәсәсендә укыган чагында бик зирәк малай булуы хакында әйтелә. Ул унике яшендә Коръәнне яттан белгән, димәк, карый булган /карый дип Коръәнне яттан белүче, аны кычкырып укучы кешегә әйтәләр/. Мондый зирәк баланың Миңлебай дип аталуы мәдрәсә мөдәррисе Зариф муллага ошамый. Ул аңа Габдулла исемен куша. Моны белеп алган авылдашлары Миңлебайны Габдулла карый дип йөртә башлый. Габдулла Уральск шәһәренә укырга китә. Аннан ул бу шәһәрдә чуалышлар башлангач качып кайта һәм полиция эзәрлекләвеннән куркып, Хәйруллин фамилиясен Кариевка алыштыра. Шулай итеп, авылның ярлы крестьян Хәйрулла малае Габдулла Кариев булып, сәхнә йолдызына әйләнә. Замандашлары һәм аны белгән-күргән кешеләрнең истәлекләреннән күренгәнчә, ул үзенә шундый псевдоним алуына һич тә үкенмәгән.

Гомумән, заманында күп кенә артистлар псевдоним алырга яратканнар. Гөлсем Болгарская /Өммегөлсем Мостафина/, Гөлсем Камская /Гөлсем Ильясова/, Бари Тарханов /Бари Гафаров/, Газиз Айдарский (Газиз Вәлитов) һәм башка кайбер артистларны моңа мисал итеп китерер идем.

Күп кенә михнәтләр күргән, ГУЛАГ зинданнарында да рухы сынмаган аксакал әдибебез Хәсән Туфан да чын фамилиясен псевдонимга алыштырган. Ул вафатына кадәр шуна тугры кала. Туфан мәдрәсәдә укыган елларында Хизбулла Хәзрәтев була. Аннары Хәсән Кусинов булып киткән. Бабасын Туфан дип йөрткәннәр. Күрәсең, бу анын холык-фигыле, табигате белән бәйле булгандыр. Хәсән Кусинов бабасынын кушаматын үзенә псевдоним итеп алган.

Элек әдәбиятта псевдонимнар сер итеп сакланган. Хәтта шул тирәдә кайнаган кешеләр дә озак вакыт анын кем икәнлеген белә алмыйлар. Күренекле галим Мөхәммәт Гайнуллин—«Татар әдипләре» дигән китабында Закир Мөхәммәтсадыйк Рәмиев турында болай дип яза: «...Кин күпчелек, хәтта әдәбият дөньясына якын торучылар да «Дәрдмәнд» /Дәрдеменд/ псевдонимы астына яшеренгән шагыйрьнен кем булуын берничә ел буена белә алмый киләләр». Мәжит Гафури да башта «Дәрдмәнд» имзасы белән басылган шигырьләрнен авторы кем икәнлеген озак вакыт белми. Ул шул хакта «Шагыйрьнен алтын приискасында» исемле повестенда да искә ала: «Еллар үткәннән сон гына Дәрдмәнд имзасы белән язылган шигырьләрнен иясе Закир әфәнде Рәмиев булып, анын шул ук прииска хужасы икәнен белдем. «Профессор Габдрахман Сәгъдинен 1911 елда «Шура» журналынын 23 нче санында чыккан мәкаләсендә мондый юллар бар: «Дәрдмәнднен кем идеке безгә мәгълүм түгел, бәлки идарәгә мәгълүм булса кирәк».

Ни өчен Закир Рәмиев Дәрдмәнд псевдонимын алган? Дәрдмәнд сүзе үзе кайгылы кеше мәгънәсен анлата. Бу, бәлки, чыннан да, Закир Рәмиевнен холык-фигыленә туры килгәндер, ул үз ихтыяры белән шушы псевдонимны алган бит. Ә, бәлки, алтын приискасы тоткан кешенен шигырь язуын, шагыйрь йөрәкле кеше икәнлеген өнәп бетермәүчеләр дә булыр дип уйлагандыр.

Ә Габдулла Тукайнын псевдонимы булганмы?—дигән сорауга Галимжан Нигъмәти сүзләре белән җавап бирәм: «Тукайнын яратып кулланылган псевдонимы да татар фольклорынын усал, кытыклап үтерә ала торган, рәхимсез, капризлы, мифологик «Шүрәле»дән гыйбарәт».

Фатих Әмирхан үзенен әсәрләрен «Ташмөхәммәт» псевдонимы белән бастырган. М. Бөдәйлинен язуына караганда, Ф. Әмирханнын «Имгәк», «Марксист» псевдонимнары да булган.

1914-15 елларда вакытлы матбугатта «Гыйффәт туташ» имзасы белән шигырьләр күренә башлый. «Гыйффәт туташ шигырьләре» исемле җыентык та басылып чыга. Шушы псевдоним белән шигырьләре басылып чыккан кешенен Заһидә Бурнашева икәнлеге беленгәч, әти-әнисе аны бик нык рәнжетә. Китаплары яндырыла. Ахыр чиктә Заһидә йортын ташлап китәргә мәҗбүр була. Әмма ул әдәбият тарихына «Гыйффәт туташ» псевдонимы белән кереп кала.

1927 елнын 20 апрель санында «Кызыл Татарстан» газетасе «Ишетүче» псевдонимы белән «Казан урамы күренешләреннән» дигән шигырь бастырып чыгара. Анын Һади Такташ икәнлеге ачыклана. Такташнын псевдонимнары күп була. Нигездә ул икесе белән—«Аллан» һәм «Мокамай» псевдонимнары белән басыла.

Кайбер әдипләр, артистлар үзләре яшәгән төбәк-район, шәһәр, авыл исемнәре белән бәйле псевдонимнар ала. Мәсәлән, 1906—1917 елларда «Йолдыз», «Ан», «Ялт-йолт», «Мәктәп», «Ак юл» газит-журналларында заманнын иҗтимагый-сәяси тормышын яктырткан үткен публицистик мәкаләләр басылып чыга. Аларга «Сәйфи-Казанлы» имзасы куела. Бу язучы Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин була. Анын башка псевдонимнары да бар: Ф. Камалов, «Исәнбай», «Бакыр күз», «Батыр күз», «Чәпи Камали малае»...

Күп кенә әдипләр чын фамилияләрен псевдонимнарга алыштыралар һәм без аларнын кайчандыр бүтән фамилия йөрткәнлекләрен күз алдына да китермибез. Ә бит иҗат эшен башлаганчы Гомәр Толымбай—Габделхак Шаһиәхмәтов, Миргазиз Укмаси—Миргазиз Зәбиров, Мәхмүт Галәү—Мәхмүт Мәржани, Газиз Иделле-Габделгазиз Усманов, Нәкый Исәнбәт—Нәкый Закиров, Нәжип Думави—Нәжип Тахтамышев булган.

Мәшһүр артисткабыз Фатыйма Ильскаянын да сәхнә псевдонимы алуы кызыклы. Ул Оренбургтан Казанга килә. Анын кыз чагындагы фамилиясе Хуҗасәетова була.

Фатыйма Хуҗасәетованы театрга кабул иткәндә кайбер артистларга аның фамилиясе ошап бетми. Габдулла Кариев, Кәрим Тинчурин, профессор Фатих Бәкер өчәүләп утырып киңәшәләр. Шул вакытта Г. Кариев тәкъдиме белән Ил кызы дип йөртергә карар кылалар. Шулай итеп, Оренбург кызы Хуҗасәетова Фатыйма Ильская булып китә. Бу псевдоним аның үзенә дә ошый һәм тамашачы күңелендә дә ул Фатыйма Ильская булып калды.

Милләте белән татар булган әдипләрнең, русча яңгырашлы исем, фамилия алып, аны үз фамилиясе итү очраклары да бар. Мәсәлән, танылган язучы Роман Солнцевның Ренат Суфиев икәнлеген беләбез. Ул Минзәлә районының Күзкәй авылында туган.1962 елда «Юность» журналында аның беренче әсәре Роман Солнцев имзасы белән басыла. Константин Симонов Ренат Суфиевка, китабыңа кереш сүз язам, әмма моның өчен сина Роман Солнцев булырга туры килер, ди. Бу вакытларда инде ул Красноярск шәһәренә күчеп киткән була һәм шул псевдоним белән басыла башлый. Үзен рус шагыйре дип йөрткән Михаил Львов та бит—татар егете Рифкат Дәүләтша улы Габитов. Ул татар авылында туган. Фронт гәзитләрендә шигырьләре Михаил Львов исем-фамилиясе белән басыла. Журналист һәм галим Мәхмүт Әхмәтҗанов Рифкат Габитовның Михаил Львов псевдонимы алуының мондый сәбәбе бар дип фаразлый. Читтә яшәп, яһүд гаиләсендә тәрбияләнеп, аларга рәхмәт йөзеннән Львов фамилиясен алмады микән?

Кайбер кешеләр үзләренең иң якын туганнарының исем, фамилиясен псевдоним итеп ала. Шагыйрә Анна Горенко әнисенең кыз чагындагы фамилиясенә—Ахматова фамилиясенә күчә. Авар халык шагыйре Гамзат Цадасаның улы Рәсүл Цадаса Рәсүл Гамзатов буларак таныла. Серафимович атасының исемен псевдоним итеп алган. Шәриф Байгильдеев та атасының исемен алып, Шәриф Камал булып йөри. Псевдонимнарның нәселдән нәселгә күчкәннәре дә бар. Мәсәлән, язучы Аркадий Голиковның ике псевдонимы була: Гайдар һәм Райдар. Ул беренчесен фамилия итеп ала һәм аның улы Тимур да, оныгы Егор да Гайдар фамилиясен йөртә.

Бериш әдипләргә псевдонимнар шулкадәр ошап китә, алар аннан аерылырга да теләмиләр, чын фамилияләреннән дә ваз кичмиләр. Шул сәбәпле, псевдоним чын фамилиясенә кушыла: Салтыков-Щедрин, Новиков-Прибой, Мамин-Сибиряк, Сергеев-Ценский (Ценский псевдонимы авторның туган шәһәре Тамбовның Цен елгасы буенда утыруы белән бәйле), мәшһүр артистка Гыйззәтуллина-Волжская.

Язучылар, рәссамнар арасында күмәк псевдоним алучылар да бар. Мәсәлән, Козьма Прутков—рус язучылары Александр, Алексей, Владимир Жемчужниковлар һәм граф Алексей Толстойның уртак псевдонимы. Рәссам Кукрыникслар—Куприянов, Крылов һәм Соколов фамилияләреннән барлыкка килгән. Остап Бендер турындагы китап авторлары Ильф һәм Петров—Илья Файнзильберг белән Евгений Катаев псевдонимнары.

Ләкин кайбер псевдонимнар тиз онытыла. Әйтик, Гоголь кайчандыр Алов, Константин Федин Нидефак фамилияләрен йөрткән. Гомәр Бәширов үткән гасырның утызынчы еллары башында Г. Разин псевдонимы белән яза. Аның «Сиваш» повесте башта Г. Разин псевдонимы белән басыла. Аннары инде ул Г. Бәширов фамилиясенә күчә һәм шуның белән таныла.

Язучылар арасында фамилияләрен кыскарту юлы белән яки шуңа бер-ике хәреф өстәп псевдоним алу гадәте дә бар. Рус телендә чыккан сүзлекләргә карап фикер йөртсәң, аларны да псевдоним дип әйтергә мөмкин. Мәсәлән, «Псевдонимнар энциклопедиясе»ндә, Әхмәт Фәйзуллин—Әхмәт Фәйзи, Мирхәйдәр Фәйзуллин—Мирхәйдәр Фәйзи псевдонимын алганнар, диелә. Шул ук хезмәттә Муса Җәлиловның псевдонимы Җәлил булуы әйтелә /М. Җәлилнең «Шахмай» псевдонимы да булган/. В. Дмитриевның «Скрывшие свое имя» дигән китабында Мусаның псевдонимы Җәлил дип турыдан-туры әйтелмәсә дә, ул псевдонимның бер төренә—проксонимга кертелгән. В. Дмитриев фикеренчә, проксоним автор исеменнән яки фамилиясеннән кыскартып ясалган сүз. Димәк, безнең күпчелек татар язучылары һәм шагыйрьләре дә әсәрләрен псевдоним белән бастырганнар һәм бастыралар. Әйтик, Габдулла Тукай, Фәтхи Бурнаш, Шәйхзадә Бабич, Галиәсгар Камал, Абдулла Алиш, Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни, Гариф Гобәй,

Тажи Гыйззәт, Ибраһим Гази, Гадел Кутуй, Салих Баттал, Хәй Вахит, Шәрәф Мөдәррис, Кави Латыйп, Гамил Афзал, Әхсан Баян, Рәшит Гәрәй, Ренат Харис, Айдар Хәлим, Рәфикъ Юныс һәм башкалар.

Мәхмүт Бөдәйли моннан тыш Шәехзадә Бабичның—«Шөпшә», «Чытырман», «Башкорт», Фәтхи Бурнашның—«Мишәр», «Кәбәй», Гадел Кутуйның—«Казбек», «Руслан», Галиәсгар Камалның «Ишан», «Әүлия» псевдонимнары булуын искә ала.

Боларга тагын бер-ике хәреф өстәп ясалганнарын да псевдоним дип санасак, татар әдәбияты псевдонимнарга бик бай икән: Садри Максуди, Һади Атласи, Жамал Вәлиди, Каюм Насыйри, Мәҗит Гафури, Гаяз Исхакый, Кави Нәҗми, Гамир Насрый, Нәби Дәүли, Мөхәммәт Садри...

Әдәбиятта псевдонимнарның башка төрләләре дә кулланыла. Мәсәлән, кайберәүләр үзен бер исем белән генә атап йөртүне хуп күрә. Шагыйрьләр Сирин /Сирин Батыршин/, Зөлфәт /Дөлфәт Маликов/, драматург Аманулла /Әмир Камалиев/, җырчы Витас /Виталий Грачев/ h.б.

Кайвакытта бер үк исем, фамилия белән аталып йөргән әдәбият яки сәнгать эшлеклеләре укучы яисә тамашачы бутамасын өчен псевдоним алырга мәҗбүр булалар. Мәсәлән, Илсур Сафиннар күбәеп киткәч, аларның берсе—эстрада җырчысы Илсафка әйләнде. Халык та моңа тиз күнегеп китте. Халык Илсаф концертына аның кем икәнлеген белеп бара. Яки миңа таныш композитор Азат Хөсәенов белән җырчы Азат Хөсәенов. Җырчы кешегә сәхнәдә композиторга караганда ешрак күренергә туры килә. Хәзер аны тамашачы Азат Тимершәех дип белә.

Безнең байтак кына урта буын язучылар һәм шагыйрьләр дә әсәрләрен псевдонимнар белән бастыралар. Бу табигый күренеш. Моңа мисал итеп Рабит Батулланы /Роберт Батуллин/, Мөхәммәт Мирза /Илфак Ибраһимов/, Гәрәй Рәхим /Григорий Родионов/, Рәдиф Гаташ /Рәдиф Гатауллин/, Зиннур Хөснияр /Зиннур Хөснетдинов/, Әхмәт Гадел /Әхмәт Гаязов/, Рашат Низами /Рашат Низамиев/, Госман Садә /Госман Зәйнетдинов/, Ләбиб Лерон /Лемон Леронов/, Мансур Вәли-Баржылыны /Мансур Вәлиев/ һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

Мин псевдонимнар турында сөйләп кемнедер шаккатырырга җыенмыйм. Псевдонимнар—кеше биографиясендәге гади генә бер исем түгел, ул аның визит карточкасы да, аның девизы да. Кайвакытта псевдоним автор ихтыярына буйсынып, аның чын йөзен яшерә, аны көтелмәгән күңелсез хәлләрдән саклап кала. Бу, әлбәттә һәр язучы һәм журналист, псевдоним куеп язсын, яисә һәр артист һәм галим, сәясәтче үзенә псевдоним уйлап тапсын, дигән сүз түгел. Татар әдәбиятында, сәнгатендә һәм фәндә булганнары да бик җитәрлек. Алар җентекләп өйрәнүгә генә мохтаҗ. Бәлки, псевдонимнарны җыйган, татар мәдәниятында аларның барлыкка килү тарихы, урыны һәм роле белән кызыксынган кешеләр бардыр. Без дә башка халыклар үрнәгендә саллы гына бер сүзлек яки энциклопедия төзеп чыгара алсак, бик игелекле эш эшләр идек. Без башкалардан киммени?!

**Мөнир АБДУЛЛИН**



БДБ илләре җитәкчеләренең Казанда үткән саммиты.
Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткән көннәр. Август 2005 ел.



Татарстан суверинететы өчен көрәш еллары. Казан. Азатлык мәйданы. 1991 ел.



*Язучылар Аккош күлендә очраштылар. Беренче рәттә сулдан: Николай Шамшурин (Түбән Новгород), Валерий Тургай (Чувашия); икенче рәттә сулдан: Мөдәррис Вәлиев, Илфак Ибраһимов, Туфан Миңнуллин, Зиннур Хөснияр, Равил Фәйзуллин, Станислав Куняев (Мәскәү), Рауль Мирхәйдәров (Мәскәү), Факил Сафин. 2005, 30 август.*



*Скульптор Альфрет Әбдрәшитев. 2000 ел.*



*Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясе комитеты утырышы. Сулдан уңга: Комитет әгъзалары— дирижер Анатолий Шутиков, композиторлар Рәшит Кәлимуллин һәм Мирсәет Яруллин. 2002 ел.*



Миргазиян Юныс

# БАТЫП БАРГАН КАРАБНЫ КЕМ, НИЧЕК КОТКАРА АЛЫР?

## 1

***«Казан утлары»ның 2008 елдагы 12нче санында Рәфикъ Юнысның «Карабыбыз батып барганда» исемле язмасы басылган иде. Аны мин кат-кат, кайта-кайта укыдым. Бу язма авторның озак еллар дикъкать белән күзәтеп йөрүләреннән, газаплы уйлануларыдан, йөрәк әрнүләреннән, аянулы кичерешләрдән туган...***

Рәфикъ язмасының һәр кисәгенә исем бирә барган. Беренче кисәк «Мин калырмын җирдә соңгы татар булып» дип аталган. Ничек инде—калырмын?! Татар кая китә? Әйе, кая китә татар? «Соңгы булып»? Барысы да китәмени? Тарих безгә шундый тәкъдир биргән: без татарлар, туган туфрагыбызда яши алмыйча, каядыр китеп олагырга, кире кайта алмыйча ят җир куенына кереп тынычланырга тиешбез... Явыз Иван безгә холокост оештырган. Бу турыда искә алып әйтергә куркабыз. Көчләп чукындырулар, гасырларга сузылган сөрелүләр—без шуны, геноцид дип атау урынына, «халыклар дуслыгы» дип йөртәбез. Шуңа өстәп, без әле «батабыз» да икән. Язмада гаҗәеп сәер, ишетергә күнегелмәгән вәгъдә—иң «соңгы татар булып» үлү турында сүз бара. Җан чиктән тыш аяулы. Беркемнең дә иректә көннән үләсе килми. Иректә көннән!.. Ә ирексез көннән? Ирексезлектән үлү бөтенләй икенче.

Укырга керешү белән фикерем үзгәрә башлады. Бигрәк тә татар җәмгыятенең бүгенгелеген бата башлаган караб белән чагыштыру тетрәндерде.

«...Әнә Казанның меңьеллыгында төп бәйрәмне алып барырга да Мәскәү артистларын чакыртып, аны «татар оялмаслык итеп» үткәрттеләр бит...» Мин гомер буе баш ватам: без нигә татарлыгыбыздан оялып һәм дер калтырап яшәргә тиеш икәнбез?! Татар теленең Татарстанда дәүләт теле булуына карамастан, «җитәкчеләребезнең чыгыш ясаганда үзебезчә бер-ике җөмлә» кыстырудан уза алмаулары ничектер сәер тоела, борчуга сала. Рәсәйнең Конституциясе урыс белән татар үзара тигез дип законлаштыра. Татар каршында урыс тартынмыйча рәхәтләнеп үз телендә сөйли, ә без ни дип шул тигезлекне бозып телебездән баш тартабыз?.. Хокукларыбыз тигез булган очракта урыс та нәкъ безнең шикелле татар каршында үз телендә сөйләшүне оят санарга тиеш бит. Бу хәл Конституцияне бозу түгелмени? «Президент Конституция гаранты» дип авыз чайкарга күнеккәнбез. Ул нигә вазифасын үтәми?

Туган телебез әле күптән түгел генә кухня теле санала иде. Соңгы елларда ул мескен кухнядан да кысрыклап чыгарыла башлады. Бу турыда Рәфикъ Юныс менә

нәрсә әйтә: «Әнә шулай иң югары кимәлдә тел сабаклары алып... торган шәһәр татарларыбызның «транспорт теле» генә түгел, инде «кухня теле» дә үзгәреп ятуы (сөйләшү—урысча, яшь буын ишетмәгәндә аз-маз такылдап куйгалау—татарча) гаҗәп микән?»

Чыннан да, татар карабы батып ятканда тел мәсьәләсе, болай көнкүрештә бәләкәй тоелган нәрсә, чиктән тыш мөһим проблемага әверелә. Капитан биргән боерык коткаручыларга аңлашылмый башлый. Исән калырга теләүчеләр үзара аңлашыр өчен барысы да бер телдә сөйләшергә, бер-берсен аңларга тиешләр. Карабка ургылып су бәреп кереп тора... Капитан биргән боерык идарә телендә. Коткаручылар һәм пассажирлар бары тик икенче, рәсми эзәрлекләнгән телне генә аңлыйлар. Нишләргә?!

Туган телкәебез буыннан-буынга, дистәләгән гасырлар, бөртекләп, яшәеш тәҗрибәсен, гореф-гадәтләребезне, милли йолаларыбызны җыя, туплый килгән. Бүген без батып барган карабыбызны ташлап, башкага утырып исән калырга өметләнәбез. Өмет карабында ят, чит тел... «Вечно самовоссоздающийся механизм духовности»,—дип атый бөек немец философы Мартин Хайдегер адәм баласын Аллаһы Тәгалә һәм җәмгыять белән элемтәдә тоткан рухи җайланманы. Бүгенге көндә без кабул итеп бетерә язган өлкән абзыкайлар теле безгә колониаль аң ярдәмендә кимсенү, түбәнсенү тойгысы тудырып тора. Ә без татарлар колониаль бәйдә иканлегебезне татарга хас рәхимсез үҗәтлек белән күрмәмештә тотабыз. Туган телебез белән бергә ата-бабадан калган йортны, андагы гореф-гадәтләрне, яшәеш тәҗрибәсен, күп гасырлар бөртекләп җыелган халык иҗаты—фольклорны югалтып, рухсызлыкта сукбай булып яшәргә җыенабыз. Урыс теленә күчү—тел үзгәртү генә түгел. Без туган йортыбызны югалтып, өлкән абзыкайларыбызныкына гастарбайтерлар дәрәҗәсендә генә фатирга кереп яшәргә мәҗбүр булабыз. Кабат уйлап карыйк. Аңларга зиһенебез җитмәүдән генә түгел бу чиктән тыш куркыныч фаҗига... Яулап алучыларның рухи дөньясына күчү, йорт хуҗасы булудан колак кагу мәҗбүрияте тамак туклыгы, тормыш тынычлыгы шикелле матди өстенлекләр бирә. Безгә югалту булса, алар өчен зур табыш бу. Алар телендә белем алган, туган телен кайтарып булмаслык дәрәҗәдә югалткан татар империя властe өчен урыс кешесеннән күпкә ышанычлырак. Туган телендә сөйләшеп яшәгән татарны авторитар хакимият федераль министр итеп куяр идеме? Бездән министрлардан тыш академиклар, генераллар, хәтта Лубянкада кәнәфидә утыручылар да чыга башладылар. Моны ничек аңларга? Башыгызны ватмагыз..

## 2

Рәфикъ Юнысның һәр соравы тагын да кайнаррак яңа сорау уята. Рухият өлкәсенә багышланган мәкаләләрнең көн тәртибендәге иң мөһим, иң изге милли проблемаларны еректан урап үтүенә без инде күнегеп беткәнбез. Милләт? Нәрсә соң ул? Бу илдә милләт юк. Рәсәйле генә бар. Паспорт шуны раслый...

«Бер яһүдкә бер яһүдне кушсаң, ким дигәндә ике ярым яһүд килеп чыгар. Иҗатта булсын, сәясәттә булсын—шулай бу. Бер татарга тагын берне өстәдең исә, нәтиҗә һәрвакыт диярлек икедән ким булыр»,—дип аңлата мәкалә авторы. Авыр, катлаулы, хәтта газаплы уйлар тудыра торган мисал бу. Тетрәндерә торган мисал. Яһүд нинди генә милләт кызына өйләнсә дә, аннан һәр очракта яһүд туа. Яһүдә никахы да нәкъ шулай. Татар егете маржага өйләнсә дә, татар кызы урыска чыкса да балалары тик өлкән абзыкайлар милләте булып дөньяга килә һәм шуларча яши башлый. Алай гына да түгел, татар егете шәһәрдә туып-үскән татар кызына өйләнсә дә, авыл кызы шәһәр җирендә туып-үскән милләттәшенә чыкса да бала ярымтатар, ярымурыс маргинал булып үсә. Урыс булып яшәү отышлырак бит... Гомумән, татарны яһүд белән чагыштыру урысча әйткәндә некорректно. Бөекбританиянең иң зур, иң көчле чагында премьер-министр постын биләгән Дизраэли чип-чиста яһүд иде. Франциянең бүгенге президенты Николя Саркази нинди милләттән? Бу милләтнең бер-берене яклауда, бер-берене өскәрәк күтәрүдә безгә үрнәк була алырлык сыйфатлары бинһая. Шулар арасында безгә иң кирәге аларның талантны эзли, таба, һәр бөртеген саклап үстерә, уртакулдан тәрбия һәм реклама ярдәмендә

талант ясый белүләре. Без татарлар шәхеснең талантлы икәнлеген күрү белән аңа каныга башлыйбыз да, тәмам юкка чыгарганчы таптапмы-таптыйбыз. Яһүдләр, һич шигем юк, «железобетон шагыйрь» (Нурихан Фәттах бәяләве) Ренат Харис урынына Мөдәррис Әгъләмовны, яисә Равил Рахманины күтәрерләр иде...

Татарны яһүд белән чагыштырудан сак булырга кирәклекне ничек аңлатырга? Татар милләтле урыс язучысы дистәдән артамы икән? Урыс язучыларының якынча алтмыш-житмеш проценты этник яһүдләрдән. Татар түрә булса, чабатасын түргә элә. Бусы мәгълүм. Ә менә татар урыс язучысы булуга ирешә алса, ул беренче чиратта туган телдә иҗат иткән каләмдәшләрен таптарга, пычратырга керешә. Соңгы елларда татарлардан Рәшит Сюняев масштабындагы галимнәр барлыгы күренә башлады. Ә яһүдләрдә? Бу турыда мин уйларга да куркам... Ә инде дәүләтчелек өлкәсенә килсәк! Инде ничә еллар Кырымның урысныкымы, әллә украиннарныкымы булуын даулап аяусыз бәхәс бара. Ярыматаунның чынбарлыкта исә татар жире булуы турында бер генә сүз, хәтта киная булганлыгын сезнең ишеткәнегез бармы?! Максимилиан Волошинның Кырымга һәм татарларга багышланган иҗаты турында без белмибезме, әллә бу турыда искә алырга теләмибезме? Татар турында Волошин менә нәрсә дип яза: «...В XVIII веке Дикое поле затопляет Крым новой волной варваров. На этот раз это более серьезно и длительно, так как эти варвары—русские. За их спиной не зыбкие и текучие воды кочевого народа, а тяжелые фундаменты Санкт-Петербургской империи...» «... Крымские татары—народ, в котором к примитивно-жизнеспособному стволу монголизма были привиты очень крепкие и отстоянные культурные яды, отчасти смягченные тем, что они уже ранее переработаны другими эллинизированными варварами. Это вызвало сразу прекрасное цветение, которое совершенно разрушило первобытную расовую устойчивость и крепость. В любом татарине сразу чувствуется тонкая наследственная культурность, но бесконечно хрупкая и неспособная себя отстоять. Полтораста[1] лет грубого имперского владычества над Крымом вырвало у них почву из-под ног, а пустить новые корни они уже не могут...» *(М. Волошин. «Коктебельские берега», стр. 215-216. Симферополь, 1990).*

Атилла заманыннан, Алтын Урда, Казан ханлыгыннан калган эзләр әле һаман исән. Без әле һаман шул эзләрне күреп һәм тоеп яшибез. Безнең сәясәтчеләребез исә шул туфракны, «татар җире» дип атасак юрист милләтле Жириновский ишеләргә ошамас дип шөлләп, «татарстанлылар җире» ялагайлыгына алыштырдылар. Бу бәхәстә минем: «Татарстан һәм диаспора татары урыс телен урыстан остарак белә, ә татар теле белгән һәм белергә теләгән урыс бармы татар җирендә?!»—дигән соравыма: «Республикада урыс теле һәм татарстанлылар теле дәүләт теле санала. Мин ике дәүләт телен үзләштерер өчен чуаш, удмурт, мукшы, әрмән телләрен дә өйрәнергә тиешмени?»—дип җавап кайтардылар.

Ликбез белемле надан Панкратова, татарофоб Минцләр язган дәреслекләрдәге «татар-монгол золымы» белән кыйный торгач, безнең милли горурлыгыбызны манкортлаштырдылар. Без гомер буе татарлыгыбыздан ваз кичеп, Шакирҗан Матросов, керәшен генералы Карбышев, Муса Җәлилләр үрнәгендә империя иминлеге өчен үз-үзебезне корбан итүләр белән аклануларга ышанып, үз җиребездә, ата-бабаларыбызның сөякләре өстендә өркә-курка, як-якларга каранып, килмешәк булып көн күрәбез.

Соңгы вакытта чал тарихның тагын бер күнелсез мәрәкәсе ачыкланып алды. Галимнәр, тарихи чыганакларында чокына торгач, урыс дәүләтен коткарып калган Түбән Новгород сәүдәгәре Кузьма Мининның керәшен татары Кирәй Миңлебаев булганлыгын ачыкладылар. Кызыл мәйдандагы куш һәйкәлдән Мининның сынын кисеп алып, Рәсәй парламентына мәңгелеккә менеп кунаклаган Жириновский боерыгын үтәп, «Монголиягә, сифилис оясына озатырга» кирәк түгелме икән?

Р. Юныс башлаган чагыштыруны дәвам итеп, яһүдләрнең «обетованный җир»дә һәм безнең үз җиребез Татарстанда ничегрәк яшәвебезне чагыштыра башласам, аяныч тагын да көчәячәк. Рәфикъ язмасындагы һәр җөмлә бүгенгелекнең иң

[1] Хәзер инде ике гасырдан артыкка китте (М.Ю.)

кайнар, иң сызлангыч проблемасына китереп тондыра. Бәлки моны аңлаучылар, мәсьәләне дулкынланып кабул итүчеләр инде әз калгандыр? Рәсәй күләмендә, юк, тулысынча дөнья күләмендә онтологик яшәешне әдәбият сурәте аша тоеп яшәүчеләр бик тә әзәйде. Гламур тәэсире әдәбиятыбызны тормыш-көнкүрештән читкә, ясалма сәясәт, кәжүннәй патриотлык тарафына илтеп ташлады. Әдәби журналларның битләрен илһам белән җанланмаган, хисләр кайнарлыгы белән җылытылмаган шәрә графоманлык язмалары басып китте...

Бүгенге көндә татар әдәбияты минем өчен—тоташтан торган йөрәк әрнүе. Язмада телгә алынган мәсьәләне укып чыгу белән туктала алмыйсың... Һәм—нинди генә проблемага ягылма, соңгы чиктә—телгә, җан биреп яткан туган телкәебезгә мангаен белән килеп бәреләсең.

## 3

«Бер шагыйребез матбугатта Казанга Башкортстаннан килгән татарларны «мафия» кебек сүзләр кулланып хурлап язып чыкты... Татар мондый «фаш итүләрне» ярата инде, автор үзен каһарман санап та йөргәндер әле...»—ди Рәфикъ язмасының «Кем килмешәк, кем китмешәк» исемле бүлегендә. Мин Мәскәүдә «Новая газета», «Аргументы и факты» (бигрәк тә Вячеслав Костиковның һәр аналитик мәкаләсен) юнәлешендәге газеталарны даими укып, «Эхо Москвы», «Свобода», «Би-би-си» радиоларын тыңлап яшим. Вакытлы матбугат белән контактны югалтмау ориентир өчен генә кирәк. Сине тормыш-көнкүреш чорнап алган. Шул тормыш-яшәеш дип аталган китапны инде житмеш ел чамасы йотлыгып укып торам. Бераз аңлый да башладым шикелле. Цензура рәсми рәвештә бетерелсә дә, авторитар хакимият үзенә буйсынырга теләмәгән дөрес сүзнең тамырын корытып тора. Рәсми, хакимият оештырган тәнкыйтьнең тактикасы тулысынча үзгәртелде. Совет чорында фаш итүләр, чынбарлыктан гаеп табучының маңгаена «халык дошманы» тамгасы сугуның тактикасы гына үзгәрде. Бүгенге көндә тәнкыйть сүзе халыкка барып житмәсен өчен вакытлы матбугатны һәм телеэкранны Жириновскийларның иблис-фарисейлеге, Ксения Собчак оештырган эт туен күрсәтүләре белән каплап тора башладылар.

Минемчә, әдип газета-телевизор куерткан ясалма, күз буяу «хакыйкатеннән» өстенрәк булырга тиеш. Р. Юнысның язмасындагы үзәк фикер җебе шуннан гыйбарәт. Язучы һәр очракта дөреслекне тирәннәнрәк, сәясәт пәрдәсе каплап торган ялган астыннан эзләргә тиештер. Әдәбиятыбызда фикер йөртү, рухи эзләнүләр елдан-ел зәгыйфьләнә бара шикелле. Куркыныч бит бу.

Таныш хәл. Нәкъ шушы язмадагы рухи эзләнүләр Равил Рахманиның «Мең чакрымга мең чакрым» исемле җыентыгында лейтмотив итеп куелган. Шул ук проблема Рәфикъның язмасының башыннан ахырына кадәр дәвам итә. Без инде татарча язылган күп текстлардан акыллы фикер көтүдән күптән кул селтәдек шикелле. Бу язмадан бер фикерне аерып алып, шуның хакында сүз йөртәсем килә. «Карабыбыз...»ның калган өлешендә тагын да мөһимрәк проблемаларны күреп беразга югалып каласың.

Автор Юрий Афанасьевның[2] алар үзара әңгәмә корганда әйткән («Идел»дә чыкты[3]) фикерләрен кабатлый: «Урыс булмаган халыкларга өстән торып карау исә Рәсәйнең бөтен зур әдипләренә, философларына, мәдәният әһелләренә дә диярлек хас булган... Күпләргә исә иң шәп дигәндә баягы «без барыбыз да урыслар инде!» дигән караш хас булган».

Юрий Афанасьев урысның әдипләренә, философларына, мәдәният әһелләренә хак бәя бирә. Һәр очракта ул татарның хакимияткә яраша торгач маргиналлашып беткән әдипләре, хакимият өстәленнән ыргытылган сыныкка ымсынып яшәүче философларыннан, шоу-бизнестан өскәрәк күтәрелә алмаган сәхнә таптаучыларыннан тирәнгәрәк карый һәм яхшырак күрә. Безнең татарда да

2 Ю. Н. Афанасьев—А. Сахаров һәм Б. Ельцин белән бергәләп СССР Югары Советының мәшһүр төбәгара депутатлар төркеменә җитәкчелек иткән күренекле сәясәтче,академик. Әйтелгән әңгәмә вакытында ул Россия дәүләт гуманитар институты ректоры иде. *Ред.*

3 Ю. Афанасьев: Рәсәйне коткаруның төп юлы—төбәкләргә бәйсезлекне күбрәк бирү!—Идел, 1995, № 1.

Юрий Афанасьевлар бар. Алар әз. Күбәю мөмкинлеге күренми.

Моннан берничә атна элек Мәскәү телевидениесенең «Достояние республики» рубрикасында Татарстан турында тапшыру булды. «Достояние республики» абруйлы рубрикаларның берсе санала. Татарның шундый тапшыруга ирешә алуына горурланып карый башладым. Артист Тукаебызның урысчага уртакул тәрҗемә ителгән шигырьләрен укый. Шундый примитив, тупас янгырый классикның сүзләре. Тукай иҗатының туган телдәге тәмен белмәгән, милләтебезне «татар-монгол золымы» контекстыннан гына ишетеп белгән бәндә укыганда да тамашачы каршына без искиткеч артка калган, примитив милләт булып килеп басабыз. Өстәвенә Мәскәүдән килгән телеоператор Казан каласын килбәтсез күренешле «ветхий» йортлардан гына әтмәлләп күрсәтте. Кремльнең классик панорамасы да, Кол Шәриф һәм Сөембикә манаралары да, Казанның Иделдән ачылган әкияти сурәте дә күрсәтелмәде. Бу тапшыруда без тамашачы каршына артта калган кыргый халык булып килеп басабыз. «Татар» урысның аңына «татар-монгол золымы» булып кереп оялаган. Без үзебез шуна инанганбыз һәм жае чыкканда шуны расларга тырышабыз. Көндәлектә бер хәл. Ә менә бу тапшыруда—безгә шовинистлар таккан имиджне раслау! Юрий Сенкевичның «Сәяхәтчеләр клубы»нда телевизор караучыларны Татарстан белән таныштыруы искә төште. Тапшыру башыннан ахырынача Раифа монастырен күрсәтү белән чикләнгән иде. Телекүрсәтүнең икесендә дә «татар» дигән сүз, шул сүз белән исемләнгән халыкның әле һаман бар икәнлеге, аның Идел буенда Мәскәүгә тез чүккән республика рәвешендә яшәве турында сынар бер сүз, хәтта бер генә кинаягә дә урын табылмады.

Татар милләт буларак юкка чыгып бетсә дә, административ берәмлек буларак яши бит әле. Дөрес, Татарстанда «татар» дип аталган милләт юк, «татарстанлы» гына бар. Бу милләт «дөрес» көндәлек тормышта урысча сөйләшә. Теннис чемпионнары Сафиннар, Рудольф Нуриев, тоташтан диярлек татар кызларыннан торган нәфис гимнастика чемпионнары Кабаева, Үтәшева, Зариповалар, күренекле артистлар, зур галимнәр, генераллар бар. Аларның татардан чыканын без беләбез, ә урыс бит аларның татар икәнлекләрен аңларга атлыгып тормый. Рәсәй күләмендә дан казанган татарның исемен атаганда да сак булырга кирәк. Милләтен ачыклау аңа зыян китерүе бар. Әле сугыштан соң гына да (Рәсәй гомер гомергә «сугыштан соң» вәзгыятендә яши) Мәскәү татарын дворник яисә носильщик итеп күз алдына китерәләр иде. Бүгенге көндә татар дворникларының кулыннан себеркене кыргызлар һәм таҗиклар алдылар. Дворникларга алмашка татарлардан Роберт Нигъмәтуллин, Камил Вәлиев, Вил Мирзаянов, Эдуард Кульпин дәрәҗәсендәге галимнәр килде. Бүгенге көндә «Новые Известия»нең беренче баш мөхәррире журналист һәм нәшир Раф Шакиров, «Эхо Москвы»ның үз хәбәрчесе Лилия Вәлиева, «Постскриптум» тапшыруын әзерләүче Рамил Гатауллин, «РЕН ТV» хәбәрчесе Артур Вәлиев, «Россия» каналының иң өлгер үз хәбәрчесе Айрат Шәвәлиевкә тиң журналистларыбызны телеэкраннан даими күреп торабыз. «Комсомольская правда» штатында да биш татар журналисты эшли. Үзгәртеп кору елларында НТВда Алим Йосыпов Англиядә хәбәрче булып эшләде. Сәнгать темасын ул чорда гаҗәеп төгәл һәм талантлы рәвештә татар хатыны Нэлли Закирова алып бара иде. Сүз дә юк, татар тырыш, зирәк, ул эшчән, талантлы. Әмма күренеклерәк урынга күтәрелү белән аның татарлыгы юкка чыга, аянычлы хәл бу. Без, кызганычка каршы, урыс арасына татар булып керә алмыйча, урыслашабыз. 2008 елда Рәсәй күләмендә уздырылган «Большая книга» ярышында компьютер аша тавыш биргәндә жюри карары буенча өченче урынны Рөстәм Рәхмәтуллин яулады. Китап «Две Москвы или метафизика столицы» дип атала. Зур көч түгеп, гаҗәеп күп материал туплап язылган фәнни һәм иҗади яуланыш бу. Мәскәүнең барлыкка килүен, аның үсеп зураюын, көчәюен Рәхмәтуллин ике хәлиткеч көчкә бәйләп аңлата: православие дине һәм абсолют монархиягә, алар арасында барлыкка килгән мөнәсәбәтләрнең көчле тәэсиренә. Бу хакыйкать аңгыра сарык башына да барып житә торгандыр: Мәскәүнең үсеп зураюы турыдан-туры татар калалары җимерелүгә, шуннан агып кергән ганимәткә бәйле. Китапта бу турыда ләм-мим сүз юк... Патриарх Кирилл мәктәпләргә «Носарилык культурасы» фәнен кертергә җыена, һәм хакимият тоткан динне тагын да гайрәтләндерү максатыннан чыгып махсус телеканал ачарга уйлыйлар. Рәхмәтуллинның лауреатлык алган китабы

шушы сәясәткә терәк хезмәтен үтәячәк. Элегрәк татар урыс арасында милләттәшен җәберләп яхшы атлы булырга тырыша иде. Бүген бу гадәт тагын да көчәйде. Хәзер инде урыс карап тормаганда да татар үз милләтен җәберләп кимсетүдән тәм таба. Иң аянычлы милли фаҗига—дәрәҗәгә ирешә алучыларның урысның үзеннән дә уздырып өлкән абзыкайлар җырын җырлап яшәве...

## 4

«Мәче әни әнә балаларын мәче итеп тәрбияли... Каз әни каз итеп, аю әни аю итеп тәрбияли... Күпме татар әни исә үз баласын татар кешесе итеп тәрбияләү тиеш икәнен, шулай эшләмәсә, туган халкына гына түгел, балага да, үзенә дә яманлык кылуын уйлап та карамый булса кирәк»,—дип аһ ора Р. Юныс. Зур, аянычлы, куркыныч фаҗига бу. Искиткеч авыр бу турыда фикер йөртү. Балакайларыбызның урыс булып тәрбияләнүләре безгә буйсынмый башлады. Аның хәрәкәткә килүе безнең тәэсир итә алу мөмкинлекләребездән тирәндәрәк ята. Бу фаҗига каршында без көчсезбез!.. Эш менә нәрсәдә. Аналар газиз балаларын нужа күрмәсен, рәхәтрәк яшәсен, күренеклерәк булсын дип үстерергә тырышалар...

Бу язманы укыганнан соң башыма әллә нинди катлаулы, авыр уйлар килә башлады. Алтын Урда чорында карабыбыз Евразия киңлекләре белән генә канәгатьләнмичә, мәмлүкләр Мисыры, Әндәлүс маврлары, Багдад хәлифәлеге җирлегендә дә йөзәргә сәләтле булган. Алтын Урда тәхетен яулар өчен канлы көрәш кабынып киткәннән соң ерак бабаларыбызның иң күренеклеләре бата башлаган карабтан качкан комыклар шикелле урыслар ягына качып китә башлаганнар. Күренекле тарихчы А. Халиков урыс алпавытлары теркәлгән «Бархатная книга»дан 500 татар фамилиясен сайлап алды. Тикшерә башлагач, ачыклана: бу биш йөз берәмлек фамилия генә түгел, ә тулы бер династия икән. Мәсәлән, Чыңгыз ханнан туган балалардан үрчегән варислар саны бүгенге көндә ике миллионнан арткан. Ике миллион! Бу бит тулы бер милләт! Аерым дәүләт төзергә җитәрлек сан! Чыңгыз ханның варислары арасында кемнәр бар соң? Александр Македонский, Юлий Цезарьлардан да сәләтлерәк, кешелек тарихында иң күләмле яулап алуларга ирешкән, бүген дә кулланырга яраклы сугыш тактикасын уйлап тапкан, «Яса» дип аталган конституциясе маддәләре шушы көнгә кадәр урыс империясендә кулланышта булган бөек шәхеснең нәселен дөньяга таратучылар кемнәр? Алар арасында дөнья күләмендә дан казанган галимнәр, сәясәтчеләр, эшмәкәрләр бар. Шуларның берсен генә алыйк. Пушкинның якын дусты, урыс философиясенә нигез салучы Петр Чаадаев та Чыңгыз нәселдән чыккан икән. Урыс дәүләтенең нигезен тәшкил иткән ярты мең алтын багана! Шуңа гасырдан гасырга бүселеп киңәя барган империянең чикләрен саклап торучы йомышлы татарларны, генерал Карбышевны (Карабашев), җәлилчеләрне, Рейхстаг түбәсенә байрак кадаган Заһитовны, воевода Пожарскийны, Мәскәү тәхетен ләхләрдән азат итеп урыс империясен коткаруны оештыручы Миңлебаев-Мининнарны һәм тагын бик күпләрне өстик. Нигә соң аларның урыс дәүләтенә күрсәткән тугрылыклары комга сеңгән яңгыр суы шикелле онытыла-югала барып, урысларның хәтерендә һаман, гасырдан гасырга көчен, карагруһларның ялган яласы—«татар-монгол золымы» гына кала килгән?!

Тагын бер башваткыч парадокс. Гомере урыс җирлегендә узган татар белә: синең урыс күршең, хезмәттәш-коллегаң һәрдаим сиңа мәрхәмәтле, дустанә мөнәсәбәттә. Чиновниклар токымы исә... Минем, мәсәлән, чиновниклар арасында татарны дошман күрмәгән бәндәне очратканым булмады диярлек.

## 5

«Наука и религия» журналында эшли генә башлаган чагым. Казанның «Оргсинтез» заводында эшләүче бер марҗадан хат килде: «У них ни стыда, ни совести,—дип башлаган ул мескен,—при нас татары открыто, громко бормочут на своем диком тарабарском...»

Мин армиягә киткәндә Баулы районында татар теле «язык межнационального общения» иде. Райондашларым рәхәтләнеп үзләренең туган «тарабар» телендә

сөйләшәләр иде. Армиядән ялга беренче тапкыр кайтуымда мине Баулының музыка мәктәбенә чакырдылар. Мин бит инде «сталинский сокол!» Абруемны төшереп туган телемдә сөйләүдән... Алла сакласын! Чыгышымны урысча әзерләп бардым. Мәктәп директоры Нина Сергунина очрашуны саф әдәби татар телендә ачып җибәрде. Арада, билгеле, урыс балалары да булгандыр. Сорауларны мина гел татарча биреп тордылар. Нина Казанда профессор гаиләсендә туып-үскән булып чыкты. Аның: «Җирле халыкның телен өйрәнмәгән шәхеснең үзен зыялы санарга хакы юк» дигән фикере әле һаман, һаман хәтеремдә.

Баулы райкомын чын зыялы Ансель Рахманкулов җитәкләгәндә татар теле тулысынча кулланышта иде, концертлар, спектакльләр туган телдә бара иде. Администрация тәхетенә Наил Зарипов менеп утыру белән туган телгә вәхшиләрчә һөҗүм башланды. Ул чорда акча төшә торган эш әрмәннәр кулында иде. Зарипов: «Сезнең мокыт телегезне урыс та, әрмән дә анламый, урысча сөйләшегез»,—дигән боерыгын гел эшкә ашырып торды. Соңгы кайтуымда күзәтеп йөрдем. «Цивилизациягә» ирешкән дистәләгән татар үзара «милләтара аралашу» телендә сөйләшеп торалар. Яннарына тагын бер татар килеп туктый: «Здравствуйте!» Мин: «Нишләп үзебезчә исәнләшмисез?»—дип сорыйм. «Арада урыс булса, нишләрсең?» Урыста исә беркайчан да «арада татар булса?» соравы тумый, һәм хәзер инде тумаячак та. Ә бит чынбарлыкка, Мартин Хайдеггер тәгълиматына таянып бәя бирсәк, җир-су, матди байлык—тел хуҗаларыныкы. Табигать, табигый байлыклар, тулаем алганда, көнкүреш-яшәеш шулай ук тел хуҗаларыныкы. Көнкүреш нинди телдә булса, яшәеш тә шул телнең хуҗаларыныкы. Бөек немец философы: «Тел—яшәеш йорты. Адәм баласы тел куенында яши»,—дип аңлата. Шушы хакыйкатьне урыс колонизаторлары бездән тирәнрәк, алданрак аңлый алганнар. Без татарлар, әле һаман шуңа төшенергә теләмичә, надан бер үҗәтлек белән телебезне таптап юкка чыгаруны дәвам итәбез... Юк, төшенә алмаудан түгел, аңгыралыктан гына бу. Төп сәбәп—туган телдән ваз кичү көнкүрештә файдалырак булганлыктан. Идарә итү, хакимлек өчен Татарстанның үзендә дә туган тел ярамый башлады.

Әле күптән түгел генә туган телебез тирәсендә давыл кубып алды. Телебезнен язмышы турыдан-туры, котылгысыз рәвештә милләт язмышына бәйле. Мәскәү моны яхшы аңлый, үтерелергә тиешле вак халыклар (нацмен) теле уяна, җанлана башлау белән шундук чара күрә. Җан биреп яткан «авыл теле» белән «ваклашып» маташырга теләмәүчеләргә бу фаҗигане берничек тә аңлатып булмаячак... Сүз мәгариф министры Фурсенконың Казанга татар теленең исәнме-түгелме икәнлеген тикшерергә килүе хакында бара. Татар-монгол теле үлеп бетмәгәнлеген күргәч, аңа ияреп килгән хатын туган телебезгә (яшәеш йортына) котырган эт булып ташланган. Шул киңәшмәдә президентыбызның туган телне яклап чыгуы минем дусларымны чиксез куандырды. Шул ук вакытта... Тирәннәнрәк уйлап карасаң, бу инде чыпчыкка туп ату шикеллерәк тоела. Әгәр Минтимер Шәрипович, әйтик, Рәсәйнең Дәүләт Думасында, яисә президент Медведев үткәргән киңәшмәдә чыгышын туган телдә ясаса һәм тәрҗемәче аны урысчага әйләндереп торса, бу очракта, бәлки, тәхеттәгеләр «федерация» дип аталып йөртелгән Рәсәйдә урысныкыннан тыш башка милләтләрнең дә телләре барлыгын аңлый алырлар иде... Үлеп яткан телебезнең җан биреп үк бетмәгәнлеге генә дә империя шовинистларына мылтык тотып мөстәкыйльлекне яклаудан куркынычрак тоела, күрәсең. Авторитар хакимият шартларында урыс теленнән тыш һәр автономиянең үз теле булуы мөмкинме соң? Әгәр Мәскәү хакимияте каршында Чуашстан президенты чуашча, Башкортстанныкы башкортча, калганнары да үзләренең туган телләрендә сөйләшеп, урысчага тәрҗемә иттерсәләр, бу дәүләттә урыстан тыш башка милләтләр, хәтта аларның үз телләре дә бар икәнлеген аңлый башларлар иде... Конституциягә Рәсәй «Российская Федерация» исемендә теркәлгән. Путинның, аның белән бер тандемдагы Медведевның, шулар тирәсендәге түрәләрнең авызларыннан «федерация» сүзе чыкканын ишеткәнегез бармы сезнең?!

Узган айны мин Мәскәүдәге татар мәктәбендә булдым. Бу мәктәп башкаланың

ин яхшы мәктәпләренен берсе саналган уку йорты. Мин аны сокланып карап йөрдем. Яна бина, иркен, якты класслар. Һәр класста диярлек компьютер, зур, иркен китапханә, музей, рәсем ясау, балет, жыр-бию, тагын әллә нинди үзешчәнлек түгәрәкләре эшләп тора. Бу затлы бинага тик бер генә гамәл—туган телне өйрәнү, шул телдә сөйләшү генә сыя алмаган! Китапханәсендә татар китаплары да юк. Аларны тикшерүчеләр күзеннән яшереп, мәктәп музеена кертеп бикләп куйганнар. Туган телне кимсетү башта мине рәнжеткән дә иде. Сәбәбен аңлагач, тынычлана төштем. Әгәр мәктәп туган телне өйрәнүне максат итеп куйса, татар балаларына шундый яхшы бина бирерләр идеме? Бу очракта Муса Җәлилгә һәйкәл кую өчен жиде миллион сум акча да бирмәсләр иде.

## 6

«Карабыбыз батып барганда...»ны Рәфикъ Юныс каләмен йөрәк канына манып язган. «Чирен яшергән үлгән»,—ди татар мәкале. Яшерүләргә татарның вакытлы матбугатында чик-чама юк. Фикерсез, эчтәлексез мәкаләләр, чиле-пешле һәм чип-чи сүз камырыннан әмәлләнгән вакытлы матбугат ташкыны. Юкка чыккан тәнкыйть. Мөхәммәт Мәһдиевкә, Нурихан Фәттахка, Гамил Афзалга һәм Илдар Юзеевкә алмашка килгән күпчелекнең төссез, төче иҗатлары... «Рәхәт бит ул сарык булу!..»—ди автор. Аның бу фикерен урысча «крик души» сүзе белән генә аңлатып була.

Язмыш миңа бер тапкыр караб батуын да кичерергә насыйп итте... Ил карабы Дәрдемәнд сурәтләгәнчә күкрәге белән дулкын ерып, артыннан хакыйкый тарих эзе калдырып бара. Караб йөзүчеләрне Дәрдемәнд сурәтләми. Штурвалны кулларында тотучылар да, караб бата башласа, кайвакыт шул Рәфикъ телгә алган сарыкка әверелә башлыйлар... Рәфикъ язмасының эчтәлеге бүген юкка чыгып бетә язган рухи терәк—хакыйкатькә омтылудан тора. Шунысын онытa күрмик, бата башлаган карабтан әүвәл иң хәйләкәр, иң өлгер күселәр кача башлый. Алар ничектер карабның батасын алдан сизеп өлгерәләр. Җаны һәм иманы булган кеше күрә торгандыр, бездә дә шул батарга дучар ителгән карабтан качкан комыклар вәзгыяте... Бу хәрәкәт елдан ел котылгысыз рәвештә көчәя килә. «Карабыбыз батып барганда»да бу фикер ышанычлы мисаллар белән расланган. Аны дикъкать белән уку гына кирәк.

Татар тарихына күз сирпеп алыйк әле. Урта гасырларда безнең «Алтын урда» атлы карабыбыз чиктән тыш зур, галәм киңлегендә йөзәргә яраклык булган. Шул карабны батар хәлгә житкергәннән соң, без татарлардан торган экипаж «Казан», «Кырым», «Хажитархан», «Себер» исемле бәләкәйрәк карабларга бүленеп утырган. Аларның дүртесен дә «Мәскәү» исемле каперлар судносы абордаж ясап буксирга алган. Без, мөстәкыйльлеген югалткан дүрт буксирның командасы, пиратлар карабының басып алуларында, иң хәтәр кан коюларда һәрдаим алгы сафта булганбыз.

Соңгы вакытта татар карабында иминлек юк. Аның күселәре башка карабларга кача башладылар. Бу хәл безне уйландырырга, карабның тишелгән жирләрен эзләп табып, чара күрергә мәжбүр итәргә тиеш иде юкса... Ә без?.. Без әлегә чара күрүдән шактый ерак. Үткәндәге жиңүләр белән масаю—шул тынычландыра зур карабның командасын... «Караб ышанычлы капитан кулында бит»,—дип юанып яшәү шундый рәхәт ул!

Караб йөртү тарихында гыйбрәтле бер мисал бар... 1912 елның 14 апреле. Якшәмбе. «Уайт Стар» компаниясенең иң зур горурлыгы, диңгезчелек тарихында иң кыйммәткә төшерелеп, техниканың барлык казанышларын кулланып төзелгән «Титаник»ның хронометры Гринвич вакыты белән 23 сәгать 40 минутны күрсәтә. Тоташтан эре, якты йолдызлар каплаган матур төн. Океанда штиль. Алга карап баручы Фредерик Флитнең тавышы: «Караб каршында айсберг, сэр!»

—Рәхмәт.—Капитанның беренче ярдәмчесе Уильям Мэрдок рулевойга:

—Лево на борт!—дип боера һәм машина телеграфының тоткасын «Полный вперед»тан «Стоп»ка һәм шундук «Полный задний ход»ка күчерә. Шушы мизгелдән соң «Титаник» лайнерынданиләр булуы турында берничә йөк әсәр язылган, берничә кинофильм төшерелгән. Карабның су өстендә йөзеп баруын илнеке белән чагыштырып була. Ә миңа карабның батуын илнеке белән чагыштыру—куркыта.

Карабта капитанның һәр кылган гамәле экипаж әгъзаларының һәм пассажирларның күз алдында. Караб йөртүченең уңышларын да, ялгышларын да күреп һәм бәяләп була. Ил белән идарә итүчеләрнең ялгышулары, аларның җинаятьләре сәясәт пәрдәсе артына яшерелгән. Чын капитан, гадәттә, караб белән бергә бата. Илен батыручылар каршында закон көчсез, батучылар илнең капитанын хөкемгә бик сирәк тарттыра алалар...

«Титаник»ның капитаны Эдвард Джон Смит, чорның иң оста, ин тәҗрибәле һәм абруйлы караб йөртүчесе, караб белән бергә батып үлгән. Аның язмышына кагылышлы берничә легенда әле һаман яши бирә. Берәүләр аның үзен-үзе атып үтерүе турында сөйлиләр. Икенче берәүләр, имеш, бер кулы белән сабый баланы кочаклап, океанда йөзеп баруын күргәннәр. Аның шлюпкага утырудан баш тартуы —бусы тулысынча расланган.

Рәфикъ Юнысның «Карабыбыз батып барганда...» исемле язмасын җитәкчеләр дә укысыннар иде! Беләм, аларның журнал мәкаләсен уку теләкләре һәм тәҗрибәләре юк. Вакытлары да юк аларның. Мәшәкатьле эш бит ул идарә итү. Бигрәк тә кризис вакытында.

«Карабыбыз...»ның авторы милләтебез язмышын бүгенге кризис вәзгыятенә таянып бәяләгән. Бәя, кызганычка каршы, кискен, юанырга урын калдырмый...

«Карабыбыз батып барганда...» дигән сүзтезмә миңа, дингезчегә, метафора булып кына яңгырамады. Язманы укыганда ачыктан ачык күреп һәм тоеп тордым: «Татарстан» исемле көймәне «Рәсәй» дип аталган лайнерга көчләп такканнар. Буксир бавы юан, өзелмәс нык, шунлыктан лайнер баткан очракта көймә дә батарга тиеш. Бауны кисәргә рөхсәт юк. Аны кисү «сепаратизм» дип атала һәм кисәргә теләүчеләрне Чечня язмышы көтә. Без һәр очракта бергә батарга тиешбез...

Исән калыр өчен безгә нишләргә соң? Бу хакта Рәфикъның анык фикерләре бар. Асылда алар белән килешәм мин.

*2009 ел, апрель.*
*Мәскәү.*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

Альфред
Халиков

# БОЛГАР–ТАТАР ЧЫГЫШЛЫ 500 РУС ФАМИЛИЯСЕ

**ВЕЛЬЯМИНОВ-ЗЕРНОВЛАР**. ОГДР да (I, 43; IV 26) язылган: «1330 елда Урдадан Чета «(Чота-Чотта-Четти; кенәз чыгып китте, чукынганнан соң ул Захарий исемен алды. Чета кенәзнең Дмитрий Александрович исемле, «Зерно» кушаматлы оныгы була. Шушы Дмитрий Зерно улы Иван Дмитриевичның Иван Годун (Годуновлар нәселе шуннан башлана) һәм Федор Сабур (Сабуровлар нәселе аннан башлана) исемле уллары булган. Дмитрий Зерноныа «Күз» кушаматлы оныгы Андрей Константиновичның Вельямин исемле улы була—аннан Вельяминов-Зерновлар нәселе башлана. Күп кенә тикшеренүчеләр яклаган бу таныклык 30нчы елларда ук Веселовский С. Б. тарафыннан кискен тәнкыйтьләнде. Ул, хронологик төгәлсезлекләр барлыгын әйтеп, Захарий малае Александр Зернонын 1304 елда ук, ягъни әтисе Руська күчеп килгәнче 26 ел элек үтерелгәнен ачыклады (Веселовский 1969, 163). Шулай да фамилияләренен нигезендә төрки «Вәли Әмин»нен булуы (к. Вельяминовлар) Вельяминов-Зерновларнын да асылы төрки булырга тиешлеген күрсәтә.

**ВЫШИНСКИЙЛАР (ЮШИНСКИЙЛАР).** XVII йөздән үк кенәз Юшинскийлар исемен йөрткән поляк-литва татарлары булганнар (Вышинский—поляклаштырылган форма—B., D. 1986, 213). 1591 елдан дворяннар. Нәсел гербларында вертикаль торыштагы уксыман билге-тамганың булуы чыгышларын «сахир» угыз-башкорт ыруы белән бәйләргә мөмкинлек бирә *(B., D. 1986, 229)*.

**ГАРШИННАР.** Иван III (1462—1505) вакытында Урдадан күченгән Гарша яисә Горша морзадан. XVII-XIX йөзләрдә бөлгенлеккә төшкән дворяннар нәселе, анын иң күренекле вәкиле танылган рус язучысы Гаршин Всеволод Михайлович (1855—1888) була (РБС IV, 246-258). Фамилияләренен гарша ~ курша «курку белмәс, батыр» төрки-фарсы сүзеннән ясалуы бабаларынын төркиләрдән чыкканлыгы турында сөйли (Гафуров 1987, 158).

**ГИРЕЕВЛАР.** Фамилияләре Алтын Урда ханы Туктамыш (XIV—XV йөзләр) нәселеннән булган Гәрәйләрдән башлана. XV йөзнең ахырыннан, хезмәттә русларда булганнар. Иртәрәк тә булу ихтималы бар, чөнки Мәскәү дворяннары буларак Василий Михайлович Гиреев 1526 елда, Андрей белән Юрий Васильевич Гиреевлар 1570 елда телгә алына. Мәскәү янындагы Гиреево-Губкино белән Новогиреево авыллары аларныкы булганнар (Веселовский 1974, 78). «Фамилияләре төркиләрнең (татар-башкортларнын) гирей-кирей «кара бәрән» сүзләренә нигезләнеп ясалган *(Баскаков 1979, 188)*, к. Киреевлар.

*Дәвамы. Башы 2009 елның 5нче санында.*

**ГЛИНСКИЙЛАР.** Кенәзләр. Аларның төрки-урда чыгышлары турында ике төрле фикер булса да, алар 1380 елда Куликов кырында Дмитрий Донской тарафыннан җиңелгән Мамай кенәз исеменә барып тоташалар. Беренче риваять буенча, Глинскийлар нәселе 1380 елдан соң Днепр буйларына төпләнеп, Глинск (әүвәл Глинитца) һәм Полтава шәһәрләренә нигез салган Мамай улы Мансур-Кияттан башлана. Ә беренче шәһәр исеменнән Глинскийлар фамилиясе китә *(MERSH*[1]*, 12, 200).* Икенче риваятькә караганда, нәсел Литваның Бөек кенәзе Витовтка хезмәткә күчеп, Глинск һәм Полтаваны бүләккә алган Мамай улы Мансуксан (Мансур Хәсән) малае Лехсадан (Лекса—чукындырылгач Александр) башлана *(РБС V, 37).* А. А. Зимин (1980, 142-43) уйлавынча, Мамай кушаматын йөрткән туганнар Михаил һәм Иван Львович Глинскийлар 1508 елда Литва кенәзлегеннән Руськa күчкәч, аларга Мәскәү тирәсендәге Ярославец, Медынь, Боровеск авыллары «тамак туйдырырга» бирелә. Шулай итеп, Глинскийларның йомышлы кенәзләр рәтенә кереп, удел-ташламалы җир эшкәртү системасына ия булалар *(Зимин 1980, 122).* XVI йөздә Глинскийлар Россия дворянлыгы тарихында иң күренеклеләрдән саналалар: Иван Львович (Мамай) Кырымда илче була, соңрак Киевның воеводасы итеп билгеләнә *(РБС V, 319-20)*; Михаил Глинский—Василий IIIнең бертуганының кызы Елена Глинскаяга өйләнә—Смоленск һәм Казанга оештырылган походларның башлап йөрүчесе, Глинскийлар оештырган заговорда катнашучы, 1536 елда зинданда үлә. XVI йөз уртасында Казанны басып алуда Михаил Васильевич белән Василий Прокопьевич Глинскийлар зур активлык күрсәтәләр, соңгысы 1562 елда Казан идарәчесе дә була (Бычкова[2] 1977). Соңыннан—галимнәр, хәрбиләр *(РБС, V, 319).*

**ГОГОЛЬ (ГОГЕЛЬ).** Шактый соң Польшадан күченеп, 1775 елдан Россия дворяннары булып киткән кешеләрнең фамилиясе (ОГДР I, 141). Н. А. Баскаков (1979, 76-78) фикеренчә, фамилия төрки-болгарларда (чуашларда) кош исемен белдергән гогул ~ когул «зәңгәр кош» сүзеннән ясалган. Әмма В. С. Веселовский ( 1974, 81) фикеренчә, әүвәл дә мондый исемнәр булган: 1459 елда Новгородның Иов Гоголь исемле крестьяны телгә алына; Гоголево—XVI-XVII йөзләрдә Мәскәү өязендәге станнарның берсе.

**ГОДУНОВЛАР.** Бәхәс уяткан фамилияләрнең берсе. Ике төрле риваятькә нигезләнгән рәсми шәҗәрәләрендә Годуновлар 1330 елда Алтын Урдадан Иван Калитага күчкән Чета кенәздән һәм алар Сабуровларның туганы (ОГДР I, 4), яисә Алтын Урданың Иван Годун дигән кешесеннән, диелгән. А. А. Зимин (1980, 80, 192, 208, 303), бу фикерләрне гомумиләштереп, фамилиянең XIV гасырдан Костромалы Дмитрий Зерно (ул Алтын Урдадан рус хезмәтенә чыккан Чета кенәз оныгы) улы Иван Зерноның малае Иван Годуннан башлануын чыгара. Бу фикергә С. Веселовский (19695 287-88), бигрәк тә Р. Г. Скрынников[3], бернинди дәлил китермичә, кискен каршы чыкты; ул ереләнебрәк: «Годуновларның бабалары татар да, кол да булмаган»,—дип язды *(Скрынников 1983, 5).* Шунысын әйтергә кирәк, С. Б. Веселовский, гадел тикшеренүче буларак, алай да, Годуновларның төркиләрдән чыгу мөмкинлеген инкарь итмәде һәм хәтта Годуновларның, ихтималлык төсмере белән, XIV йөздә яшәгән бабалары Әсән (Хәсән) Годун исемен күрсәтте *(Веселовский 1974, 81).* Н. А. Баскаков (1979, 58) фикеренчә, Годуновларның фамилиясе годун ~ гудун «ангыра, акылсыз кеше» төрки кушаматы белән бәйле. Төрки булганлыкка Әсән—Хәсән исеме дә ишарәли. Россия тарихында барыннан да элек XVI—XVII йөз араларында рус патшасы булган Борис Годунов билгеле, ул аңа кадәрге рус патшасы Федор Иоанович хатынының кардәше була.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

[1] MERSH—The modern Encyclopedi of Russin and Soviet history // By jos. V. Wieczynski. akademie International Russ. Virginia politechnic Institute and State University. Vasary I. (Lstvan) The Hungarians or Mozars and the Misers (of the Middle Volga Region). 1976.
[2] Бычкова М. Е. Родословные книги XVI-XVII вв.М.,Наука,1977.
[3] Скрынников Р. Г. Борис Годунов. М.,Наука,1983.

Гомәр
Бәширов

# КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕ

## ДҮРТЕНЧЕ ДӘФТӘР

Күптән түгел композитор Фасил Әхмәтовның иҗатына багышланган концерт булды. Композитор аерым әсәрләрен ничек язуы турында сөйләде, артистлар аның җырларын башкардылар. Мин бу концертны телевидениедә күрдем, иртәгесен Әхмәтовның махсус рәвештә чакыруына карамастан концертына бара алмавым өчен гафу үтендем.

Телефонда шул хакта сөйләшкәндә мин аның белән Глинканың бер фикерен ничек аңлавы турында сораштым. (Мин бер мәкалә язып утыра идем, шуна кирәк булды).

Глинка үзенең мемуар тибындагы бер әсәрендә болай ди: «Музыканы халык иҗат итә, ә без композиторлар, аны аранжировать кына итәбез»—ди.

Фасил моны ничек аңлый икән? Глинка композиторның музыкаль әсәр язуда ролен халык иҗат иткән музыкаль әсәрне язып куюга гына кайтарып калдырмый торгандыр бит?

Мин Глинканың бу фикерен әдәби әсәрләр иҗат итү өлкәсенә күчереп тә әйткәләгән идем. Әмма бу соңгы мәкаләне язар алдыннан бу фикернең әдәби иҗатка бәйләнештә алганда дөрес булуына шикләнә башладым. Фасил Әхмәтов тә минем фикеремә кушылды.

—Алай булганда Глинка нигә ул фикерне әйтте икән, нинди максат?—дидем.

—Ихтимал, ул бераз кокетничать иткәндер. Ул бөек композитор булуын белә, бу фикерне әйтү белән ул берни дә югалтмый, ул моны әйтү белән үзенең халыкка якын торуын белдерәсе килүе ихтимал. Музыканы иҗат итү баштанаяк композитор хезмәте. Дөрес, композитор халык җырларын ишетеп, шуларда тәрбияләнеп үскән. Ләкин халык иҗат иткән җырны күчерми, бәлки музыканы үзе иҗат итә. Мин Глинканың барлык әсәрләрен дә беләм, мин аларны җентекләп өйрәндем. Глинка бер әсәрендә дә халык музыкасын турыдан-туры үз әсәренә күчерми,—диде Фасил.

Билгеле, мин дә аның фикеренә кушылдым. Глинканың ул фикерен әдәби иҗат өлкәсенә күчереп куллануым дөрес булмаган икән.

Фасил Әхмәтов соңгы елларда бик һәйбәт җырларга музыка иҗат итте, аның популярлыгы торган саен арта бара. Гади генә, беркатлы гына кебек күренсә дә бик төпле, акыллы егет. Һәр мәсьәләгә үзенең мөстәкыйль фикере барын сизәсең. Бу исә кешенең чын кеше итә торган төп сыйфатлардан берсе. Аның белән сөйләшү яхшы тәэсир калдыра.

**15 май, 1982.**

Картлык уйландыра. Сиксәннән узгач гомернең калган өлеше озын булмаячагы хакында уйланмыйча хәлең юк. Һәрхәлдә тормышына элекке кебек ваемсыз карый алмыйсың. Тагын ничә ел гомерем калды икән? Ике елмы, өчме, дүртбишме? Шуннан артмас. Артыгы кирәк тә түгел. Ул яшьләргә җиткәч организм зәгыйфьләнер, акыл да саега төшәр. Кемгәдер йөк булып, кемнедер борчып яшәгәнче вакытыңны, кадереңне белеп үз вакытында китеп баруың яхшырак.

Картлар хакында төрле күңелсез сүзләр дә ишетергә туры килгәли. Аккош күлендәге

*Дәвамы. Башы 11,12 (2008) һәм быелның 1,3 саннарда.*

язучыларның иҗат дачаларына союз идарәсе һәм литфонд тарафыннан игътибар җитми. Монда телефон кертмиләр, йортларга ремонт ясарга да ашыкмыйлар. Нигә алай дисәң, «Әй, анда картлар гына ич инде»—дип тә куялар. Әйтерсең, ул картларның хәзер кирәге дә юк. Шул картлар әдәбиятка матур гына өлеш керттеләр түгелме соң? А.Шамов, Хәсән Хәйри, Нәби Дәүли, С.Хәким, шулар арасында мин дә, Р.Ишморат та әдәбиятта бөтенләй үк эзсез югалырга тиешле кешеләр түгелдер бит?!

**17 май 1982.**

Гайбәтчеләр картлар турында тегесен-монысын сөйли торсыннар, ә мин язып торыйм. Моннан берничә ай элек «Казан утлары»на «Бибек нигә җылый?» дигән хикәя язып тапшырдым. Редакция кешеләре яратып кабул иттеләр, гуманист каләме белән язылган һәйбәт хикәя диделәр. Бәрәкалла, шулай булсын, барлык укучылар да шулай яратып укысыннар.

Бүген «Дәү әни» дип атап бер мәкалә язып тәмамладым. Монысын «Азат хатын» журналына бирәм. Әгәр ошаса, алар бу мәкалә белән ниндидер яңа рубрика ачып җибәрергә телиләр. Иртәгә менә шул хакта «Түгәрәк өстәл» янында сөйләшергә редакциягә барырга тиешмен.

Киләчәккә тагын иҗат планнарым бар. Озын бер повесть язырга кирәк. Ул минем гражданнар сугышыннан соң башымнан узган вакыйгаләргә багышланыр. Әгәр дә хыялымдагы барлык уйларыма, теләкләремә лаеклы итеп яза алсам, күренекле әсәрләремнән берсе булачак.

**17 май, 1982.**

Хәсән Туфан, Шәйхи Маннур дусларымның вафат булуларына берсенә бер ел, икенчесенә ике ел тулып килә. Шул уңай белән «С.Т.» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире Миргалим Харисовка аларга багышлап әдәби сәхифәләр чыгарырга киңәш иттем. Каршы булмады, хуп күрде. Шундый тәкъдим кузгатканмын икән, үземә дә катнашырга кирәк бит. Ш.Маннурның «Чын сөю бармы?» дигән повесте хакында матбугатта берни дә булмавы борчып тора иде. Шушы арада шул повесте турында газетага рецензия яздым. «Бар ул, чын мәхәббәт, бар!» дип атала. Казанга кайткач Ш.Маннурның каберенә таш кую мәсьәләсен тизләтәсе булыр. Ай-һай калын тиреле дә инде без! Ике ел тулып килә бит үлгәненә, ә без аның каберенә шул ташны гына да куя алмыйбыз. Оят!

Хәсән Туфан авырганда 2-3 көндә бер мин аның янына кергәләп йөрдем. Һәр күреп кайткан саен шушындый дәфтәргә тәэссоратны язып куя идем. Әмма «авырая башлагач ук мина хәбәр итегез» дип Мөнҗиягә әйтеп куйган булсам да вафаты вакытында янында була алмадым, бер сәгать соң гына барып җиттем.

Хәсәннең соңгы көннәре турында минем үтенүем буенча аның абыйсының кызы—Гамбәр сөйләп бирде:

—Аккош күлен теленнән төшерми башлагач мин дачага барып аннан чәчәкләр бәйләме алып кайттым да күренерлек итеп Хәсән абыйның аяк очына куйдым. Ул чәчәкләрне озаклап иснәде, матурлыгына сокланды. Шунда иртә өлгерә торган бер гөл бар иде. Хәсән абый бер мәлне иреннәрен кыймылдатып нәрсәдер исенә төшерергә тырыша башлады. Мин аннан сорадым:

—Хәсән абый, берәр нәрсә кирәкме әллә?—дип.

Ул әйтә:

—Менә бу чәчәкнең исеме юк, ә үзе бик матур. Ул «Тургай чәчәк» булсын. Чөнки бу гөл тургай килгән вакытта чәчәк ата,—диде.

Ун көн ятканнан соң мин Хәсән янына икенчеме, өченчеме мәртәбә бардым. Ул йокымсырап ята иде. Исәнләштем, янына утырып хәлен белештем. Ул гадәтенчә:

—Ярый әле...—диде.

Мин аның бу җавабының мәгънәсен беләм инде. Ул хәлен сораучыны борчымас өчен генә әйтелә торган сүз. Хәсән никадәр авыр булса да ул дөресен әйтмәячәк. Хәсәнне азрак сөйләштерәсем килеп, мин ана Аккош күлендә аның ояларына сыерчыклар килүе, аларның бала чыгарулары турында сөйләдем. Шулай да Хәсәннең күңелен кузгатмас өчен Аккош күлендәге җәйге матурлыкларны бик кабатларга ярамый, өстән-өстән генә кагылып узарга кирәк иде. Шулай да мин аны нигәдер сөйләштерә алмадым.

Хәсәннең беләген тотып пульсын санадым. 70 чамасы иде. Аның хакында Мансур Хәсәнов белән сөйләшүемне әйттем, аны бу палатада ялгызын гына калдырырга тиеш иделәр. Хәсән бераз гына башын селкетеп куйды. Әмма теле белән берни дә әйтмәде. Ул мин сөйләгәннәрне игътибар белән тыңлап ята, әмма җавап бирми иде.

Биш-алты минут чамасы шулай янында утырып та сөйләштерә алмагач минем күңелемә шик төште, бәлки авыруы бик көчәйгәндер, ана ялгыз калырга кирәктер дип уйладым да хушлашып китеп бардым. Әмма Хәсәннең шундый хәлдә калуы миңа бик авыр тәэсир итте.

Шул хакта Гамбәр болай, ди.

—Сез чыгып киткәннән соң мин Хәсән абыйдан шул хакта сораштым. Хәсән абый, нишләптер син Гомәр абый белән сөйләшмәдең. Ул бит сиңе якын дусты итеп, яратып килгән, хәлеңне белергә дип килгән,—дидем.

Хәсән абый әйтә:

—Ә мин Гомәр белән сүзсез генә сөйләштем. Ул минем йөземнән, күзләремнән нәрсә әйтергә теләвемне һәммәсен дә аңлады. Без аның белән сүзсез дә күңелләребездә ни булганны аңлаштык,—диде.

Хәсән абый 1981елның 10 июнендә 10с.30 минутта өзелде.

Ул көнне мин Аккош күлендә идем. Иртә белән Зөфәр килеп кергәч имәнеп киттем. Житди сәбәп булмаганда эш вакытында килеп йөрми инде ул. Шулай булып чыкты да: ана Мөнҗия Хәсән абыйның хәле авыр дип хәбәр иткән.



*Композитор Нәҗип Җиһанов белән. 1980 еллар.*

Мин палатага барып кергәндә Хәсән янында сенлесе Сагыйдә генә иде. Хәсән йоклаган кебек тыныч кына койкасында ята, йөзендә һичбер үзгәреш юк. Маңгаена кулымны куйдым, суынып та житмәгән иде әле. Күзләремә яшь тулды, моннан элек килгәндә дә «Бу аяклар белән ничек Аккош күленә барырмын икән?»—дигән иде. Менә бит, Аккош күленә барасы урынына Яңа Бистәгә китәргә язган икән, аңда да үз аягың белән түгел.

Бер баруымда Хәсән сенелләренә, миннән соң менә шушы абыегызга сыенырсыз инде дигән иде. Алар тирәсендә ир затыннан берәү дә юк, күмү мәсьәләсен союздагы кешеләр белән миңа кайгыртырга кирәк иде.

Рәис Гариф Ахунов белән кабергә урын сайлар өчен Яңа Бистә зиратына киттек. Хәсәнгә үзенең дәрәҗәсенә лаек урын сайларга кирәк иде, әмма андый урын башта күренмәде. Безне каядыр агачлар арасына алып кереп тар гына бер урынны күрсәттеләр. Ул урынны ошатмадык. Капкадан кереп бераз баргач та аллеяның уң ягында калку урын күзгә чалынды. Ләкин зират канторасының мөдире ул урынга күмәргә рөхсәтне шәһәр Советының зур түрәсе бирүен, аның министрларга дип саклануын әйтте. Шул вакытта Гариф Ахунов үзенең егетлеген күрсәтеп алды.

—Кем ул министр? Кирәге бетә икән, аны артына тибеп урыныннан төртәләр дә төшерәләр. Ә Хәсән Туфан мәңге халык күңелендә яшәячәк кеше. Менә шушы урынга күмәбез!—диде. Шулай итеп Хәсән Туфанның мәңгелек квартиры яхшы урыннан сайлап алынды.

Ул көнне Хәсән үз өендә кунды, икенче көнне яшь язучылар белән без аны Татар Академия театры фойесына куйдык. Митингта Г.Ахунов, Мансур Хәсәнов, С.Хәким, тагын кемнәрдер сөйләде. Зиратта халык ул кадәр күп түгел иде. Моңа минем йөрәгем әрнеде. Һади Такташны, Салих Сәйдәшне күмгәндә күмү мәрасимына катнашкан халык санын меңнәр белән санаилар. Ә монда күп булса берәр йөз булгандыр. Хәзер халык андыйларга торган саен азрак катнаша. Хәсәннең дәрәҗәсе теге өстә әйтелгән талантлардан ким булудан түгел, халык аның шигъриятен ярата, үзен ихтирам итә. Әмма соңгы елларда халыкта ваемсызлык, битарафлык чире көчәйде. Монда да шул сиздерде.

**3 июнь, 1982.**

Үзем өчен шатлыклы бер хәл турында языйм әле.

Яшем сиксәннән узып китүгә карамастан, мин әдәби иҗатны дәвам итәм. Бик теләп, дәртләнеп язам. Бигрәк тә шунысы шатландыра: минем хәзер язган әсәрләрем элеккеләренә, мәсәлән, 40, 50, 60, 70 яшьләрдә язганнарыма караганда яхшырак. Ул вакытта язганнарым сайрак булган, ә хәзергеләренең философик эчтәлекләре тирәнрәк (дип уйлыйм инде. Бәлки ялгыша торганмын?)

**30 август, 1982.**

Аккош күленнән кайтып китәр алдыннан бу дәфтәргә тагын берничә бит язып калдырыйм дидем.

Соңгы елларда үлемгә багышлы истәлекләр хакында ешрак язарга туры килә башлады. Карт кешеләр өчен бу табигый хәлдер инде, күрәсең. Чөнки безнең әйләнә-тирәбез картая һәм акрынлап китә бара. Нихәл итмәк кирәк.

Сентябрь ахрында көндез Аккош күленә Зөфәр килеп төште. Аның көндез килүе нинди дә булса, шундый бер фәукылгадә хәл белән бәйләнгән була. Мин аңа шикләнеп карый башладым. Чыннан да шулай булып чыкты. Ул «С.Хәкимгә хат килгән. Анда Разия[1] апа турында язганнар, хәле авыр икән...» дигән сыман итеп әйтте. Казанга кайткач Мәскәүгә чылтыраттым. Гөльяр белән сөйләштек. Разияга 26 августта Литваның бер кечкенә шәһәрендә инфаркт булган, аны шуннан табутка салып машинада алып кайтканнар.

Мәскәүнең «Мөселманнар каберстаны» дигән зиратына Әминә ханым, Гөльяр, мин—өчәү бардык. Җыйнак кына чардуган эчендә Разиянның атасы Зыятдин абзый кабере икән, кызын да атасы янына күмгәннәр. Разиянның сугышта үлгән энесе Чыңгызның да исемен шушы чардуган ихатасына элгәннәр. Мәскәү зираты шәһәр эчендә калып бик кысылган, шул сәбәпле бер гаиләне бер кабер тирәсенә күмәләр икән.

Кабер янына килеп житкәч, мин «Разия, без килдек» дип тавыш бирдем. Әминә сүзен әйтә алмыйча җылый башлады. Гөльярның да күзләре яшьләнде. Мин алып килгән чәчәкләрне кабер өстенә тезеп куйдым. Без Разия ханымны искә алып тынып калдык. Менә ничек соңгы мәртәбә хушлашырга туры килде Разия белән.

Разия ханым белән мин 1950 еллардан бирле үк таныш идем. Ул татар әдәбиятын рус халкына, гомумән русча укучыларга җиткерү өчен бик күп эшләр башкарды. Г.Ибраһимов әсәрләрен, минем барлык зур күләмле әсәрләремне ул тәрҗемә итте. Тәрҗемәдә аңа тиң юк иде. Ул рус һәм татар телләрен яхшы белүе сәбәпле, шуның өстенә, бик намуслы кеше булганлыктан чын күңелдән тырышып эшли, бик яхшы тәрҗемә итә иде. Шулай итеп татар әдәбияты безнең әдәбиятыбызны киң рус әдәбияты дөньясына алып чыгучы иң талантлы тәрҗемәчеләрдән мәхрүм калды.

Разия ханым минем «Җидегән чишмә» дигән романымны тәрҗемә иткәндә вафат булды. Нихәл итмәк кирәк, андый тәрҗемәче табу мөмкин түгел инде.

**17 октябрь, 1982.**

Менә 83нче елга да килеп чыктык. Димәк, миңа 82 яшь! Бу бик күп түгелме? Күп инде, күп. Ләкин шулай да дөньядан китәсе килми. Гаҗәп комсыз икән бу кеше дигәнең тормышка. Берәүнең дә «Бик күп яшәлде инде, китәргә вакыт!» дигәне юк. Мин дә шулай.

Әмма кешедә картлык белән бергә нindидер элек булмаган психик үзгәрешләр пәйда була икән. Мәсәлән, мондыйлар:

Күптән түгел безнең союзга алынган яшь язучылар картларны чакырып «аулак өй» уздырдылар. Һәтта керосин лампасына охшаган лампа да тапканнар, бүлмә дә ярым караңгы иде. 10лап яшь шагыйрьләр, драматурглар килгән, шулар янына Б.Урманче, Ә.Еники, Риза Ишморат, мин, Туфан Миңнуллин һ.б. Стеналарга чиккән сөлгеләр эленгән, өчпочмак пешергәннәр, тагын шундыйлар. Ишектән болай гына кертмиләр, нинди дә булса табышмакка җавап бирергә кирәк яисә тапкыр сүз әйтергә кирәк иде.

Г.Ахунов берничә сүз әйтте, үзе Мостафа Ногман кичәсенә университетка китеп барды. Яшьләр шигырь укыдылар, җырладылар. Соныннан безгә, картларга сорау бирә башладылар. Мәсәлән, сезнең буын (ягъни безнең, өлкәннәр буыны) мәдрәсәләр

[1] Бу биттә искә алынган шәхесләр: Разия Фаизова – тәрҗемәче, Гөльяр – аның кызы, Әминә ханым — Муса Җәлилнең хатыны.

турында гел кире тәэсир калдыра торган итеп язды. Без, яшьләргә ул чордан өйрәнерлек берни дә юк диярлек. Революциягә кадәрге хатын-кызны театрларда тәмам изелгән, тапталып кешелеген югалткан итеп күрсәтәсез. Димәк, безгә элекке хатын-кыз хәрәкәте тарихыннан үрнәк алырлык берни дә күрсәтә алмыйсыз,—диделәр.

Мәдрәсәләр хакында Бакый ага сөйләде. 1905 елдан соңгы мәдрәсәләрдә барлык укыту эшләре схоластикага корылмаган, аларда фән дә укытыла, хәтта рус теле дә өйрәтелә иде, бик тәртипле низамнамәсе бар иде. Башка мәдрәсәләрнең дә кайберләре, мәсәлән, Уфадагы Галия мәдрәсәсе шәкертләргә төпле белем биреп чыгарды. Анда укып чыккан шәкертләрнең йөзгә якыны җәмгыять тормышына соңыннан актив катнаштылар, комиссарлар (мәсәлән Г.Ибраһимов һ.б.) җитәкчеләр булдылар, аннан байтак язучылар чыкты: Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш һ.б. Шунда ук Бакый абзый үзенең Кәрим Тинчуриннын «Мәрҗәннәр» җыентыгыннан канәгать булмавын әйтте. Ул җыентыкта гел тискәре типлар гына бирелгән. Алай гына түгел инде бит, арада совет властен хуплап каршы алган шәхесләр дә күп иде. Бу китапны укыганнан соң «һәммәсе дә болай тискәреләр булгач революция ясарга кем катнашты икән соң?» дигән сорау туа.

Мина баштарак сүз биргәч, мин яшьләр белән өлкәннәрнең ешрак очрашуы кирәклеге турында сөйләдем. Яшьләр гадәттә баштарак әдәбияттагы фәукыльгадә дип әйтерлек затлар иҗаты белән, мәсәлән, Хэмингуэй, Экзюпери, Гарсия Маркес һ.б. мавыгалар, аларга охшатып язарга тырышалар. Бу табигый күренеш, чөнки яшь кеше үзен, үз алымын, үз стилен тапканчы эзләнергә тиеш. Әмма чын мәгънәсендә яхшы әсәр язу өчен үз халкының иҗатын, аның әдәбиятын, тарихын, гореф-гадәтен яхшы белергә кирәк. Хәзер безнең әдәбиятның иң камил чагы дип әйтергә мөмкин. Сез бик бәхетле яшьләр. Сез классикларны да (Кол Галидән башлап хәзергә кадәр) хәзерге язучыларны да өйрәнә аласыз. Безнең арадан күптән түгел генә китеп барган Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Шәйхи Маннурлар да әдәбиятта еш кабатланмый торган бик үзенчәлекле талант ияләре иделәр.

Инде яшьләр әйткән сорауларга килгәндә әдәбияттагы ул аңлашылып житми торган күренешләр күбесе ТАПП[2] чорында булып алды.Толымбай «Татар буржуа теле безнең тел түгел» дигән мәкалә белән чыкты, Ф.Әмирханны буржуа язучысы итеп күрсәтергә тырышты. Болар мөмкин кадәр сулрак, революционрак, кызылрак булып күренергә омтылудан, бу мәсьәләдә башкалардан уздырып җибәрергә тырышудан килеп чыга иде, күрәсең.

Татар хатын-кызларын чиктән тыш изелгән, мыскыл ителгән итеп күрсәтү дә бар. Г.Ибраһимов һәм Ф.Әмирхан татар хатын-кызлары турындагы әсәрләренә прототип итеп хезмәт иясе вәкилләрен түгел, бәлки шәһәр сәүдәгәрләре, муллалары тормышын алганнар. Хәлбуки эшче-крестьян хатын-кызлары андый хәлдә булмады, алар тормышның авырлыгын ирләре белән бергә күтәрделәр.

Ф.Әмирханга һәм Г.Ибраһимовка ул вакытта шулай язу кирәк булгандыр. Чөнки мөселманнарның хатын-кызны җәберләвен, кимсетүен фаш итәргә, хатын-кызга ирләр белән тигез хокук яулап алырга кирәк иде. Шуның өстенә, алар фәкать татар хатын-кызларын гына түгел, гомумән бөтеншәрекъ мөселман хатын-кызларын, шулар эчендә үзбәк, төрекмән, таҗик хатын-кызларын да күздә тотып язганнар. Хәзерге көндә сәхнәгә куйганда исә ул татар хатын-кызы булып кына күренә. Моны истә тотарга кирәк. Менә мин шул хакта сөйләдем. Яшьләр дөрес аңлады.

**1 гыйнвар, 1983.**

Кичә Кратово санаториеннан кайтып «Казан утлары»ның быелгы 2нче санын карап укыштыргалап утырдым. Гомумән журнал яхшыра бара, элек булмаган бүлекләр ачылган, материал да күп төрле. Арада «Бүгенге проза, геройлар, проблемалар» дигән бүлектә Аяз Гыйләҗевнең «Тынычлану зарарлы» һәм Тәлгат Галиуллинның «Нәфисәләр юксындыра» дигән мәкаләләре игътибарны җәлеп итте. Аяз Гыйләҗевнең хәзерге прозаның ваклана баруы турында, «уртача» әсәрләр күбрәк хакында язуы һәм борчылуы урынлы. Бездә әсәргә карата талымсызлык, ваемсызлык күзгә бәрелә, уртача әсәрләрне дә «үтереп» мактыйбыз.

**20 март, 1983.**

---

[2] 1928елда Татарстанда оешкан Пролетар язучыларның ассациациясе. Русча – Татарская ассоциация пролетарских писателей.

«Кеше үзе бер дөнья» дибез. Әмма без бу гыйбарәне мәгънәсенә артык әһәмият бирмичә, «болай» гына, җиңелчә генә әйтеп куйгалыйбыз. Вәхаләнки аның тирән эчтәлеге бар. Һәр кеше объектив дөньяны, тормышны күңелендә яшәтә, ул аны үзенчә итеп, үзе аңлаганча күрә. Димәк, бөтен дөнья үзенең тарихы, бүгенгесе, киләчәге белән, кешеләре, табигате—гомумән бөтен барлыгы белән аның күңел түрендә яши. Кеше шул тышкы дөньяны ничек аңласа, аңа шуннан чыгып бәя бирә, аңа үзенчә мөнәсәбәттә була, башкаларныкына охшамаган мөнәсәбәттә. Кеше үлү белән аның күңелендәге әнә шул «дөнья» да юкка чыга. Ул дөнья башка кешедә кабатлана алмый. Язучы әсәрендә әнә шул бүтәннәрнекенә охшамаган үз дөньясын тасвыйр итәргә тырыша.



Кешенең, һәр образның объектив дөньяны ничек аңлавын никадәр тирәнрәк аңласаң, аны никадәр остарак, үтемлерәк итеп күрсәтә алсаң, әсәрең шулкадәр уңышлырак чыгачак.

**23 март, 1984.**

Нәкый Исәнбәт абзыйда булып бераз сөйләшеп утырдык. Фразеологик сүзлекнең икенче томын әзерләп утыра. Янәшә куйган ике өстәл кульяулыгы кадәр кечкенә кәгазьләр белән тулган. Һәр кәгазьдә бер җөмлә, бер фраза, аның төрле вариантлары. Нәкый абзыйның кулында шул кәгазьләрдән берсе. Гарәп хәрефләре белән аңа «урынтын» дигән сүз язылган, шуның берничә варианты бирелгән. Урынтын юл, уртын юл, ортын юл... Нәкый абзый әйтә:

—Шул өч вариантның һәркайсының мәгънәсен ачарга, шуның кайсы төп вариант булуын ачыкларга кирәк, —ди.

Мин әйтәм:

—Безнең Арча ягында урынтын юл дип олы юлның киресен әйтәләр, ягъни билгеле бер урынга хас, мәгълум урыннан, күбесенчә күзгә бәрелеп тормый торган яшерен урыннардан уза торган юлны әйтәләр. Мәсәлән, революциянең беренче елларында спекулянтлар безнең Яңасаладан Казанга кадәр бер авылга да кермичә, гел урман, болын, басу юлларыннан гына йөриләр, менә шундый юлны «урынтын юл» дип исемлиләр иде.

Нәкый абзый бу вариантка каршы килде.

—Әмма Себер татарлары, мәсәлән, уртын юл дип атыйлар. Аның төп чыганагы «угры» булырга мөмкин. Фразеологик сүзлекне төзегәндә сүзләрнең барлыкка килү чыганагын да ачыкларга туры килә. Чөнки бездә шушы көнгә кадәр этимология сүзлеге юк. Ә чуашлар андый сүзлекне күптән чыгардылар инде.

Аның зур-зур ике өстәленең өсте, тагын стенага терәп куелган стеллажлары әнә шундый аерым сүзләр, фразеология үрнәкләре белән тулган. Н.Исәнбәт тел, әдәбият һәм тарих институтында бөтен бер сектор яки бүлек эшен (ул бүлектә 10-15 фәнни сотрудник булырга мөмкин) башкара алмаган эшне берүзе башкара. Ул шулай берүзе эшләп өч томлык халык мәкалләрен чыгарды, аның аңлатмасын, тарихи чыганакларын аңлатып бирде. Күптән түгел, «Балалар фольклоры» дигән калын китап чыгарды. Әйтүенә караганда, аның «Аңлатмалы сүзлек»нең берничә томын чыгарырлык әзерләгән материалы бар. Ләкин ул хәзер 85 яшендә инде, бер күзенә операция булды, бер күзе бик начар күрә, ул хәзер бик сакланып, сәгатьләп кенә эшли ала, «Аңлатмалы сүзлек»не эшләп чыгарырга аның үзенең генә көче җитмәячәк. Безгә, ягъни язучылар союзы идарәсенә менә нәрсәне кайгыртырга, бу талантлы галимгә, язучыга һәм безнең әдәбиятта таланты, эшчәнлеге ягыннан күпкырлы бу фикер иясенә һәрьяклап ярдәм итәргә тиешбез.

**4 ноябрь, 1984.**

Бу арада Н.Исәнбәткә, С.Хәкимгә һәм миңа «Татарстан халык язучысы» дигән мактаулы исем бирелде. Безнең әдәбиятта бу мактаулы исем бу өч язучыга беренче

булып бирелә. Билгеле, бик хөрмәтле исем. Чит республикалардан һәм үзебездән бик күп тәбрикләр килде. Газеталарда язып чыктылар, радиода сөйләделәр. Бик күп хатлар килде. Рәхмәт инде. Ул исемгә лаеклы әсәрләрне моннан соң аеруча ышанып көтәрләр инде.

**21июнь, 1986.**

Бик аяныч хәл: бүген иртәнге 11дә Сибгат Хәким вафат. Ул берәр айдан бирле шифаханәдә ята иде. Узган елгы инфаркты янарган, башка авырулары да кузгалган диделәр. Шулай да берәр атна элек инде утыра башлаган, хәле яхшыруга таба бара дигәч, бераз сәламәтләнер бәлки дип өметләнгән идек. Әмма берничә көн элек ана янадан приступ булган. Шуннан соң Сибгат әйткән: Монарчы яшәргә өметем бар иде, хәзер өметем өзелде инде, яшәп булмас, ахрысы,— дигән.

Шуны ишеткәннән соң без дә бик борчылган идек, ниһаять, бүген 11 тулгач Маһирә фаҗигане хәбәр итте.

Сибгат белән без бер якныкы, Казан арты тумалары. Иҗат тормышыбыз да 40нчы еллардан бирле янәшә барды, заманында бик якын дуслар да идек, менә күптән түгел, берүк көнне халык шагыйре, халык язучысы дигән хөрмәтле исемгә лаек булдык. Әмма, кызганычка каршы Сибгатка ул исемне йөртү насыйп булмады.

Сибгат үзен Тукайның шәкерте, аның ин якын варисы дип саный, ул мона чыннан да лаеклы иде. Г.Тукайның 100 еллыгы алдыннан ул Тукайның истәлеген мәңгеләштерү өчен күп хезмәт куйды. Әмма үзе юбилейда катнаша алмады, каты авыру иде инде. Менә бүген ул бу фани дөньядан соңгы сулышын алды.

Ветераннар китә, ветераннар азая, әдәбият үзенең төп таянычларын югалта бара.

Бу көннәрне бик авыр кичерәбез. Әле күптән түгел генә Сара Садыйкованың вафатын да бик авыр кичергән идек, аның хакында язарга кул бармый тора иде... Менә бүген—Сибгат.

С.Хәким татар картларына хас сабырлык белән үзенең үлемен алдан ук көтеп алды. Шулай булуы мөмкинлеген алдан ук күрә белде, аһ-ваһ итмәде, зирәк акыллы картларча аңа алдан ук хәзерләнде, бәлки, бәлки дип күнелен дә чуарлатмады. Ул, мәсәлән, үләренә берәр ай чамасы каларак, М.Мәһдиевкә, нәшрият директоры Гарәф Шәрәфетдиновка соңгы көннәре якынлашып килүен сиздерерлек итеп хатлар язды. Ул хатларында ул тормышыннан, авыруыннан зарланмый, һәммәсе өчен, аңа күрсәткән яхшылыклары өчен бу иптәшләргә рәхмәтләр әйтә. Аларның эшләренә уңышлар тели. 6 ай алдан газеталарга язылып, алдан ук квартира хакын түләп куя. Шифаханәдә ятканда аның янына Рауза Газизова[3] кереп хәлен белешкәннән соң, аның күнелен күтәрү өчен

—Әйдә тизрәк тазар да менә Аккош күленә дачага китәрбез. Җәйнең бик матур вакытта, анда сәламәтлегең тагын да ныгыр,—дигән.

Мона каршы Сибгат үзен-үзе юатырдай ясалма оптимизмга бирелү юлына басмаган.

—Юк инде, мин Аккош күленә бүтән бара алмам ахрысы, мин башка җиргә китәрмен,—дигән.

Шагыйрь Илдар Юзиев тә аны юатып шундыйрак мәгънәдәге сүзләр әйткән.

—Ел саен туган авылыгыз Күлле-Кимегә кайта торган гадәтегез бар иде. Больницадан чыкканнан соң анда кайтасыгыз бардыр әле,—дигән.

—Быел миңа Күлле-Кимегә түгел, Яңа Бистәгә юнәлергә туры килер ахрысы,—дигән.

Вафат буласы көнне (Зиюль) иртә белән ул юынган, үзе кырынган. Әгәр ялгышмасам, хатыны Мөршидәгә шундый фикер әйткән булса кирәк.

—Менә шулай инде, үләсе көнне Әхмәт Фәйзи дә шулай иртүк торып кырынган,—дигән сыман нидер әйткән. Мин моны Мөршидәдән ишеттем.

**3 июль, 1986.**

*Дәвамы киләсе санда.*

[3] Әдәбият галиме Хәсән Хәйринең хатыны.

## Яхъя Халитовка 80 яшь



Тәржемә жанры—зур осталык, ныклы белем, тырышлык таләп итә торган жанр. Сүз сәнгатенең асылын, тәмен тоеп эшләү—үз эшенә фидакарьләрчә табынып хезмәт итүчеләргә генә бирелә. Иҗади сәләтен тулысынча диярлек әдәби тәржемә эшенә багышлаган Яхъя Халитов—әнә шундый осталарның берсе.

1929 елның 22 августында Тәтеш районы Үтәмеш авылында туган Яхъя Мөхәммәтгали улы Халитов Бакырчы җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң белемен Арча педагогия училищесында ала, 1952 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый, 1952-1955 елларда исә Тел, әдәбият һәм тарих институты каршындагы аспирантурада укый. Хезмәт юлын университетның соңгы курсларында укыганда ук «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналында башлап җибәргән егет аспирантураны тәмамлагач та кире журналга кайтып унтугыз еллап журналга хезмәт итә, әдәби хезмәткәр, бүлек мөхәррире вазифасын башкара, татар язучыларының әсәрләрен югары сыйфатлы итеп чыгаруда үзеннән зур өлеш кертә.

Журналда аның белән озак еллар бергә эшләгән хезмәттәшләре Р.Гаташ, М.Вәли-Барҗылы Яхъя аганың авторлар, аларның редакциягә китергән кулъязмалары белән җентекләп эшләве, хезмәтенә үтә дә җаваплы каравы турында яратып искә алалар.

1950-1963 елларда исә Я. Халитов Татарстан китап нәшриятында—редактор, 1976 елдан исә матур әдәбият редакциясендә өлкән редактор булып эшли.

Тәржемә өлкәсендәге эшчәнлеген Яхъя Халитов 1952 елда рус язучысы Н. Тихоновның хикәяләр җыентыгын тәржемә итүдән башлап җибәрә. Шул вакыттан алып үзенең әдәби һәм тәржемә эшендә осталыгын үстерә барып дөнья әдәбияты классиклары, рус язучылары, тугандаш халыклар әдәбияты язучыларының зур күләмле әсәрләрен—роман-повестьларын тәржемә итеп бастыра. Алар арасында М. Шолоховның атаклы «Тын Дон» («Тихий Дон»), «Күтәрелгән чирәм» («Поднятая целина»), татар язучысы М. Галәүнең үз вакытында рус телендә генә дөнья күрергә өлгергән «Болганчык еллар» («Муть») романнары, Ю. Бондаревның «Кайнар кар» («Горячий снег»), күренекле кыргыз язучысы Ч. Айтматовның «Бәхил бул, Гөлсары!» («Прощай, Гульсары!»), «Анам кыры» («Материнское поле») исемле повестьлары, чит ил классикларыннан Майн Ридның «Башсыз җайдак» («Всадник без головы»), француз Дюманың «Өч мушкетер» («Три мушкетера») һ. б. әсәрләре бар.

Матбугат өлкәсендәге хезмәтләре өчен Яхъя Халитов 1980 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек була. 1966 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

## Чыңгыз Мусинга 75 яшь



Чынгыз Мулламөхәммәт улы Мусин 1934 елда Әгерже районының Тирсә авылында туа. 1949 елда ул шул авылнын җидееллык мәктәбен тәмамлый һәм Тирсә МТСында йөкче булып эшли башлый. Ә 1952 елда ул машина йөртүче һөнәре ала, 1964 елга кадәр шофер булып эшли. Аннан соң токарь һәм автослесарь хезмәтен дә башкара.

1968 елда Чынгыз Мусин «Казтрансстрой»нын 5-автоколоннасында эшли башлый, ә бер елдан аны автоколонна житәкчесе итеп билгелиләр. Биредә ул 1973 елга кадәр эшли. 1973-1984 елларда Ч. Мусин—Әгерже районының «Сельхозтехника» берләшмәсендә баш инженер. Шул ук елларда ул Тирсә МТСы тарихын да яза.

Соңгы елларда Ч. Мусин Ижауда басыла торган «Янарыш» газетасында актив катнаша, 5 ел редакциядә дә эшләп алды.

Район һәм республика матбугатында Ч. Мусин шигырьләре 1944 елда ук күренә башлый. Хәзер ул күпләгән шигырь китаплары авторы. Анын «Язмышым—үзәннәрдә», «Тамырлар», «Кадер кичендә», «Баганалы юллар», «Гомер юлы» һ. б. китапларын укучы жылы кабул итте.

Чыңгыз Мусин 1999 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

***Каләмдәшләребезне юбилейлары белән ихлас котлыйбыз, аларга ныклы сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез!***

## КИЛӘСЕ ЕЛГА ЯЗЫЛУ – БЫЕЛГЫ БӘЯЛӘР БЕЛӘН

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

**2010 елның 1 яртысына быелгы бәяләр белән генә язылырга мөмкин. Әлеге подписка 30 августка кадәр генә дәвам итәчәк. Арзан хакка "Казан утлары"на язылып калырга теләсәгез, ашыгыгыз!**

## Сәгыйть Сүнчәләйнең тууына 120 ел

XX йөз башы танылган татар шагыйре, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе Сәгыйть Сүнчәләй 1888 елның 2 августында Саратов губернасы Хвалын өязе Иске Моастак авылында туа. 1891 елда әтисе Хәмидулла агай ачлык газабыннан котылу нияте белән гаиләсен Әстерхан шәһәренә алып китә. Сәгыйть башта «Ваhhабия» мәдрәсәсендә укый, аны тәмамлагач ике ел балалар укыта. 1907 елда ул Казанга килә, абыйсы Шәриф артыннан Казан татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. Ләкин матди хәленең авыр булуы укуны тәмамларга мөмкинлек бирми. 1909 елда абыйсы белән икәүләп алар Пермь губернасы Оса өязендәге Сараш авылының дүрт сыйныфлы земство мәктәбендә укыта башлыйлар. Сүнчәләйнең әдәбиятка килүе шуннан. Гомумән, 1909-1915 еллар—аның иҗатының иң актив чоры. Шигырьләрен ул елларда чыгып килгән күпсанлы татар газета һәм журналларында бастыра. 1913 елда беренче җыентыгы да дөнья күрә (соңгысы—1929 елда). 1915 елда ул Уфага күчеп килә, шәһәр китапханәсенең татар бүлегендә мөдир вазифасын башкара, «Авыл халкы», «Көрәш» газета редакцияләрендә эшли. 1919 елда ул кабат Казанга килә, партиягә керә һәм үзәк органнарның кушуы буенча Кырымга агитацион эшкә җибәрелә, вакыйгалар катлаулангач, Төркия аркылы качып, Мәскәүгә кайта. 1921-1922 елларда Кырым АССРда Милләтләр эше халык комиссариаты вәкиле сыйфатында эшли, 1923-1924 елларда коллегия әгъзасы, 1925 елда Башкортстан АССРның Укыту-агарту халык комиссариатының сәнгать бүлеген житәкли, 1926-27 елларда СССР Тышкы эшләр халык комиссариатының Измир шәһәрендәге (Төркия) генераль консуллыгында тәрҗемәче булып эшли. 1927 елда Уфага кайта, 1928 елда Казанга килә. «Контрреволюцион солтангалиевчелектә" гаепләп, аны 1929 елның 28 февралендә кулга алалар, 1931 елда ун елга хөкем итәләр һәм Соловкига җибәрәләр. 1937 елның 9 октябрендә шагыйрь атып үтерелә.

Романтик иҗатының төп темалары арасында—ватан («Йиргә», «Туган ил»), милләт («Агиев турында», «Шагыйрьгә мәктүб»), инкыйлаб («Октябрь», «Инкыйлаб вә син»), сәнгать («Операда», «Бер көй»), табигать («Чәнечкеле чәчкә», «Кышын»), мәхәббәт («Татар кызына», «Ямь»). Сүнчәләйнең яхшылык-яманлык, гомер-үлем, мәхәббәт-нәфрәт турында язган шигырьләрен лирик көндәлеккә тиңләп була. Берничә шигыре һәм истәлеге Тукайга багышланган, сакланып калган хатлары да ул чорны күз алдына китерер өчен бер чыганак булып тора. Бөек шагыйрь белән өч ел буенча дәвам иткән дуслык эзсез калмый: Тукай аңа үзенең киңәшләрен бирә, тәрҗемәләрен төзәткәләп матбугатта бастырып чыгара. Шигырьләреннән тыш Сүнчәләйнең мәкаләләре, хикәяләре һәм пьесалары да бар. Тәрҗемә өлкәсендә дә үз эзен калдыра шагыйрь. Ул тәрҗемә иткән авторлар арасында Байрон («Шильон тоткыны»), Гейне («Әлмансур»), Гете, Гюго, Жуковский, Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Тургенев, Крылов, Шевченко, Майков, Никитин, Надсон һ.б. 1958 елдан соң гына Сүнчәләйнең иҗатын татар халкына кайтару мөмкинлеге туа, 1961 елда аның "Сайланма әсәрләре" дөнья күрә, 2005 елда "Әсәрләр һәм хатлар"ы басылып чыга.

## Кишер чәе

К р у п с к а я. Исәнмесез, Мулланур иптәш! Әйдәгез, түрдән узыгыз. Тик менә чәе генә—кишер чәе.

Л е н и н. Архикысыр чәй! Ләкин *(көлеп)* хәзер кунакларны моның белән гаҗәпләндереп булмый!..

В а х и т о в *(көлеп)*. Ә без үз сыебызны алып килдек! *(Портфеленнән ипи кыерчыгы ала.)* Менә нинди тәмле ипи кыерчыгы!

---

К р у п с к а я. Әйдәгез, утырышыйк, чәй суына. Сүз уңаеннан сорыйсым килә: кишер чәе чын чәйгә караганда тизрәк суына икән, игътибар иткәнегез бармы?

**Әхәт ГАФФАР.**
*«Сызылып таңнар атканда» пьесасыннан.*

## Күрде безнең башлар!

Академик Роальд Сәгъдиев коттеджында ун көн **яшәдем**, бөтен җир шарын көлдереп йөргән клоун, СССРның халык артисты Олег Поповка студент чагымда ук сюжет саттым, СССРның халык артистлары, бөек җырчылар Мөслим Магомаев белән Тамара Синявскаяга Казанның спорт сараенда туй **ясадым**, балет сәнгатенең шигъри моңын ачкан атаклы биюче Ирек Мөхәммәтов белән аның хатыны Мариягә Зеленодольск районында никах **укыттым**, җиһанны таң калдырган композитор София Гобәйдуллинаның чын исемен **ачтым**, татарның дөнья тоткан кино һәм театр артисты Чулпан Хаматованың Казанда яшәүче әти-әнисе өенә кунакка **йөрдем**, СССРның халык артисты прима-балерина Майя Плисецкая белән Шале урманында гыйшык **тотыштык**, җыр сәнгатендә җир йөзендә дан казанган Алсу Сафинаның туган көнендәге банкетта Чибәркәй белән чәкештереп шампан шәрабы **эчтем**, СССРның халык артисты җырчы Людмила Зыкина белән **кочаклаштым**...

**Мәгъсүм ГӘРӘЕВ.**
*«Мин Чуен Гәрәй малае» китабыннан.*

## Ашкыну

С радостью сообщаю, что очень скоро обязательно вернусь в Казань. Недолго осталось ждать. Первым же поездом! Как только произойдут перемены во власти, обещаю, приеду первым же поездом.

**Ринат МӨХӘММӘДИЕВ.**
*«Не стало интриг и нервотрепки»,*
*«Вечерняя Казань» газетасы. 6 декабрь 2008.*

## Әйт!

Яктыртасың Җирне, җылытасың!—
Коммунистмы әллә син Кояш?

**Рөстәм МИНГАЛИМ.**
*«Әйт, Кояшым» китабыннан.*

## Зөләйха Минһаҗева



Минһаҗева Зөләйха Мөхит кызы (Идиятуллина) 1955 елны Баулы районының Салих авылында туа. 1971 елны шул ук районның Яңа Шалты авылында урта мәктәпне тәмамлагач, хезмәт юлын Яңа Каразирек авылында Мәдәният йорты директоры буларак башлап җибәрә. 1973-77 елларда Казан мәдәният институтында белем ала, режиссер белгечлеге алып чыга. Югары белем алганнан соң Мөслим халык театрында режиссер була. Ике ел эшләгәч, Чаллыга күчеп килә һәм анда да сайлаган хезмәт юлын дәвам итә: Чаллы халык театрының режиссеры булып эшли. Ул елларда театр коллективы Татарстаннан тыш, Башкортстанда, Самара һәм башка төбәкләрдә еш була, тамашачылар спектакльләрне яратып карыйлар. Монда, әлбәттә, режиссерның роле зур. Шәһәр җитәкчелеге Зөләйха Минһаҗеваның нәтиҗәле эшчәнлеген танып, 2002 елда аны Чаллы шәһәре мәдәният идарәсе башлыгының урынбасары итеп билгели. «Егерме ел буе танышлык дәверендә Зөләйха Минһаҗева Чаллы каласының мәдәният идарәсендә иң четерекле, иң җаваплы вазифаларда эшләде һәм мин гомер буе аны татар милләте, татар мәдәнияте дип янып йөрүче фидакарь дип беләм», дип яза Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе Вахит Имамов. Хәзерге вакытта З. Минһаҗева шул ук идарәдә милли мәдәниятларны үстерү буенча баш белгеч булып эшли.

Зөләйха Минһаҗева иҗат эше белән дә актив шөгыльләнә. Ул, нигездә, шигырьләр яза. Аның берничә шигырь җыентыгы бар. Башта алар Чаллыда—җирле нәшриятта чыксалар, ә «Җилләр чакырам» дип исемләнгәне 2006 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде һәм аны һичбер ташламасыз шагыйрә китабы дип атап була.

З. Минһаҗева драматургия өлкәсендә дә уңышлы эшләп килә. «Бакча карачкылары» дигән әсәре «Яңа татар пьесасы-2006» конкурсында икенче урынны алды һәм Уфаның «Нур» татар дәүләт драма театрында сәхнәләштерелде. Композитор В. Әхмәтшин белән бергә иҗат ителгән «Әтәч нигә кычкыра?» дигән балалар опереттасы Чаллы дәүләт театрында куелды.

Ул—1997 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек була.

Татарстан Язучыларының 27 майда үткән Идарә утырышында, Берлекнең Кабул итү коллегиясе карары нигезендә, Зөләйха Минһаҗева (тәкъдимнамә бирүчеләр: Вахит Имамов, Рәшит Бәшәр, Әнвәр Шәрипов) Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул ителде.

## КАЗАН ДА ИСЛАМ ШӘҺӘРЕ

Ислам башкалалары һәм шәһәрләре оешмасы (ИБШО) үзенең XXVII күчмә утырышын беренче тапкыр Россиядә, ягъни мөселман дәүләте саналмаган илдә үткәрде. Мәккә, Анкара, Тунис, Җиддә, Дәмәшкъ, Тәһран кебек 20дән артык мөселман шәһәрләреннән килгән вәкилләр июнь уртасында Казанда җыелышты.

Мәгълүм булганча, әлеге халыкара оешма 1980 елда Ислам Конференциясе оешмасы каршында барлыкка килә һәм хөкүмәтнеке дә, коммерциячел дә булмаган оешма санала.

Ислам башкалалары һәм шәһәрләре оешмасында 54 мөселман иленең 140 шәһәре даими рәвештә әгъза булып тора. Оешманың штаб-фатиры—Мәккәдә, ә генераль секретариаты Җиддәдә урнашкан. Моннан тыш, 6 дәүләтнең 8 шәһәре, шул исәптән Россиянең Казан һәм Грозный шәһәрләре әлеге оешмада күзәтче әгъза булып тора.

ИБШО сәясәт белән шөгыльләнми, дәүләт эшләренә катышмый. Аның төп максаты һәм бурычы—мөселман чаралары оештыру.

ИБШОның чираттагы утырышын Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев ачып җибәрде, әлеге мәртәбәле чараны борынгы Казанда, ин төньякта урнашкан Ислам цивилизациясе мәркәзендә үткәрелүенә горурлануын белдерде.

—Без моны халкыбызга карата зур ихтирам һәм хөрмәт, Татарстанның бүгенге мәдәни һәм рухи янарышын, икътисади күтәрелешен тану буларак кабул итәбез,—диде ул.—Безнең җирлектә Ислам дине тарала башлауга 1120 ел. Татарстан мөселманнары үзләрен Ислам дөньясының бер өлеше буларак хис итә һәм дөньядагы дин кардәшләре белән аралашып яши.

Бүгенге көндә Ислам кыйммәтләре дөньяда барган һәртөрле тискәре процессларга каршы иң төп әхлакый альтернатива булып тора. Ислам илләре үзләренең этник составлары һәм сәяси карашлары буенча күптөрле, әмма аларны үзара хезмәттәшлеккә, аңлашуга омтылыш берләштерә.

Мөселманнар үзләре яшәгән шәһәрләренең үзенчәлеген саклап калырга омтыла. Әлеге оешма вәкилләре дә шәһәр инфраструктурасы үсешенең актуаль мәсьәләләрен хәл итү өчен җыелыша. Бу җәһәттән башка дәүләтләрнең тәҗрибәләре белән танышу безнең өчен бик файдалы.

Республикабызда халыкара мөселман оешмалары һәм дәүләтләре белән хезмәттәшлек ныгыганнан-ныгый бара. Күптән түгел генә Казанда Ислам яшьләре форумы, Ислам фәннәр академиясе сессиясе, Ислам үсеш банкының инвестицияләр буенча конференциясе булып узды. Бүгенге көндә Татарстан Ислам Конференциясе оешмасына кергән 37 ил белән хезмәттәшлек итә.

Казан шәһәре мэры Илсур Метшин үз чыгышында нәкъ менә Казан типографиясендә Россиядә беренче Коръән басылуы турында әйтте.

Россия Федерациясенең Ислам конференциясе оешмасындагы даими вәкиле Камил Исхаков әлеге утырышны мөһим сәяси чара дип билгеләп үтте. Ул Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавровның котлау хатын укып ирештерде. Анда министр мөселман илләре белән элемтәләрне ныгыту Россия җитәкчелегенең өстенлекле эшчәнлеге саналуы турында ассызыклап әйтә.

ИБШОның генераль секретаре Омар Абдулла Кади исә Камил Исхаковның үз вакытында Казан ИБШО шәһәрләре арасына керсен өчен күп тырышуы турында әйтте. Чираттагы форумны үткәрүдә дә аның өлеше зур.

Утырыш делегатлары шәһәр хуҗалыгына кагылышлы актуаль мәсьәләләрне тикшерде.

Кунаклар Россия Ислам университеты белән танышты, КДУның сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә булды, Сабан туенда катнашты.

## УРТАК БЕЛДЕРҮ КАБУЛ ИТЕЛДЕ

Татинформ хәбәр иткәнчә, Бөтендөнья Башкорт корылтае һәм Бөтендөнья татар конгрессы Н. Н. Миклухо-Маклай исемендәге Этнология һәм антропология институты эшләгән проектка каршы чыкты

Чабаксарда Урал һәм Идел буе халыклары милли конгресслары һәм ассоциацияләре җитәкчеләренең координация советында Бөтендөнья башкорт корылтае һәм Бөтендөнья татар конгрессы «Россия Фе-

дерациясе халыкларының этномәдәни төрлелегенең конституцион нигезләрен саклап калырга!» дигән исемдә уртак белдерү кабул итте. Белдерү авторлары Россия Фәннәр академиясенең Н. Н. Миклухо-Маклай исемендәге Этнология һәм антропология институты эшләгән «Россия Федерациясендә дәүләт милли сәясәте нигезләре турында» Федераль закон концепциясе проектын тәнкыйть утына тота.

Башкорт һәм татар иҗтимагый оешмалары, концепция проекты РФ Конституциясенең «РФ милли-дәүләт төзелеше» нигезләмәләрен ревизияләүгә юнәлдерелгән, һәм ул күпмилләтле Россия Федерациясенең яшәешенә куркыныч белән яный, дип белдерә. Белдерү авторлары фикеренчә, концепция проектында милли республикаларның яшәеше һәм аларның республикаларда милли сәясәт алып баруга хокукы инкарь ителә. РФ суверенитеты вәкиле булып торучы «РФнең күп милләтле халкы» (РФ Конституциясенең 3 статьясы нигезендә) төшенчәсен «Россия гражданлык нациясе» төшенчәсенә алыштыру илнең төп халыкларын кысрыклауга юнәлдерелә.

Документта, телне, мәдәниятләрне, тарихны саклау һәм үстерү проблемаларын хәл кылуда милли республикаларның ролен санга сукмау омтылышы һәм аларны үзешчән милли-мәдәни автономияләргә алыштыру Россия Федерациясе территориясендә яшәүче төп халыкларның телен, мәдәниятен һәм тарихын юкка чыгаруга юнәлдерелгән, диелә. Әлеге концепция проекты белдерүдә, «халыкка каршы, милләтләргә каршы булып, Россия Федерациясе Конституциясенең төп нигезләмәләрен ревизияләүгә юнәлдерелгән проект», дип бәяләнә.

## ЯШЬЛЕК ЯЗЫ ТАНТАНАСЫ

Берничә көн дәвамында Казанда яшьлек тантана итте. Россиянең 70кә якын төбәгеннән башкалабызга студентлар җыелган иде. «Россия студентлары язы—2009»ның финал өлеше узды. Иң зур делегацияләр Сарытау, Төмән, Ростов өлкәләреннән, Ханты-Манси (Югра) автономиясе округыннан һәм Алтай Республикасыннан иде.

Казанның мондый бәйгене беренче тапкыр гына кабул итүе түгел инде. Студентлар арасындагы иң дәрәҗәле бәйге 2001 елда да бездә үткән иде.

«Баскет-холл» спорт комплексында фестивальдә катнашучыларны Татарстан Премьер-министры Р. Миннеханов республика җитәкчелеге исеменнән котлады һәм Россия Президенты Д. Медведевнең сәламләү хатын укыды.

Казан мэры И. Метшин Казанга җыелган студентларны бирегә яшәп калырга чакырды, аларны Россия яшьләренең иң яхшы өлеше дип атады.

Студентлар тамашачы һәм жюри алдында музыка, бию, театр һәм оригиналь жанрда осталыкларын күрсәтте. Татарстан даның республикабызның 12 югары уку йорты вәкилләре яклады. Биш көн дәвам иткән конкурста аларның чыгышлары югары бәяләнде.

Концерт мәйданчыкларына керү ирекле иде. Анда фестивальнең махсус газетасы «Веснушка» таратылды. Кунаклар сыйфатында Казанга продюсер, КВН югары лигасы экс-мөхәррире Михаил Марфин, Россиянең халык артисты Олег Газманов, театр һәм кино артисты, пародияләр остасы, фестивальнең оригиналь жанр буенча жюри рәисе Александр Песков та килгән иде.

«Россия студентлары язы» программасы дирекциясенең башкаручы җитәкчесе Анна Махнова, 17 ел дәвамында үткәрелеп килгән фестивальнең иң шәбе быел Казанда булды, дип билгеләп үтте.

Фестивальнең гала-концерты «Пирамида» комплексында узды. Аны «Яңа Гасыр» телеканалы аша да күрсәттеләр. Фестиваль 2013 елда үтәчәк Универсиада алдыннан үзенчәлекле бер репетиция дә булып торды.

## ПЕТЕРБУРГ СӘХНӘСЕНДӘ—«ШҮРӘЛЕ»

Петербургтагы Мариин театры сәхнәсендә, күренекле композитор Фәрит Яруллинның 95 еллыгы уңаеннан, аның «Шүрәле» балеты кабат сәхнәгә куелды. Премьерада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты.

Беренче мәртәбә «Шүрәле» («Али-Батыр» исеме белән) балеты бирегә 1950 елда куелган булган. Шушы спектакль өчен бер төркем артистлар СССРның Дәүләт премияләре белән бүләкләнгән. Соңрак бу спектакль илнең байтак театрларында сәхнәләштерелгән.

Петербург театры сәхнәсендә «Шүрәле»нең янадан куюе—«Ак төннәр йолдызлары» VII Халыкара фестиваленең иң күренекле вакыйгаларыннан берсенә әйләнде.

«Бөек шагыйребез Габдулла Тукай әсәре буенча күренекле татар композиторы Фәрит Яруллин музыкасына язылып, Мариин театры сәхнәсенә чыккан«Шүрәле» балеты татарстанлылар өчен гаять зур горурлык һәм милли мәдәниятебезне тануга дәлил ул»,—диде Фәрит Мөхәммәтшин. Ул әлеге театрның сәнгать җитәкчесе Валерий Гергиевка «Фидакарь хезмәт өчен» медале, анда биегән солистларга Татарстан Дәүләт Советының Мактау кәгазьләре тапшырды.

## ТӨРКИЯДӘ САБАНТУЙ

Сабантуе быел Истанбул каласында гына оештырылды. Узган елларда ул Искешәһәр яки Кютахия төбәгендәге татар авылларында да үткәрелә торган иде. Быелгы сабан туе, узган еллардагыдан аермалы буларак,

урман аланында түгел, шәһәр уртасындагы Тоткалы мәдәният паркында оештырылды, чөнки паркның Төрки дөнья мәхәлләсендә Татарстан мәдәният йортының ачылышы булды. Кызыл тасманы Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева белән Истанбул шәһәре мэры Кадир Толбаш кистеләр.

Хөрмәтле кунак булып чакырылган Россия Федерациясенең Төркиядәге гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе Владимир Ивановский чыгышында сабан туенын дуслык, бергәлек өчен әһәмиятле бәйрәм икәнлеген ассызыклады.

Профессор Туран Язган җитәкчелегендәге «Төрки дөньяны өйрәнү фонды» тарафыннан уздырылган XV Төрки дөнья балалары сәнгать фестиваленә Зәйдән килгән «Мирас» балалар чыгышы бәйрәмгә үзгә ямь өстәде. Татарча көрәш бәйгесендә милләттәшебез, Мәрмәрә университеты студенты Ринат Кагиров батыр калды.

### ДЕРЖАВИН ЯКТАШЛАРЫН ҖЫЙДЫ

14 июль көнне Татарстан җирендә туып-үскән, рус шигъриятендә зур урын билгән атаклы шагыйрь, дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинның тууына 266 ел тулу уңаеннан тантана уздырылды. Бәйрәм тантанасы Казанда шагыйрьнең М. Горький урамындагы һәйкәленә чәчәкләр салу белән башланып китте. Анда ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева һәм күпсанлы иҗат әһелләре, танылган шагыйрьләр һәм язучылар катнашты.

Чәчәкләр салынгач, язучылар һәм шагыйрь иҗатын яратучылар бәйрәмне дәвам итү өчен, автобусларга утырып, Гавриил Романовичның туган җире—Лаешка юл алды.

Биредәге бәйрәм тамашасында ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты һәм чыгыш ясады.

Мәгълүм булганча, бу көнне Татарстанда әдәбиятны, мәдәниятне үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән иҗат әһеленә Гавриил Державин исемендәге премияне тапшыру гадәткә кергән. Быел бу бүләккә күренекле шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче Рөстәм Кутуй «Профиль ветра» исемле шигырь китабы өчен лаек булды.

Шигъри митингта И. Ибраһимов, Р. Вәлиев, Г. Рәхим, Х. Миңнегулов, И. Иксанова, Н. Алешков, Ф. Тарханова, О. Левадная һ. б. чыгыш ясады.

Лаештагы тантананы шагыйрә, Г. Державин исемендәге әдәби бүләк иясе Лилия Газизова алып барды.

### МАСШТАБЛЫ ТАМАША

Казанның Ярминкә мәйданында «Сотворение мира—2009» II Халыкара музыка фестивале булып узды. Анда 13 илдән килгән 20 җырчы Казан тамашачысына 11 сәгатьлек бәйрәм ясады. Бу юлы оештыручылар фестивальгә төрле юнәлештәге коллективларны чакырганнар иде, сәхнәдә рок, джаз, электроника стилендәге җырлар яңгырады. Казанлылардан аеруча Мубай аерылып торды. Ул халык җырларын һәм Салих Сәйдәшев әсәрләрен акустик гитара һәм кларнет аккомпанементы астында башкарды. Поп-музыка остасы Андрей Макаревич, Грузиядән килгән җырчы Нино Катамадзе, якташыбыз, актриса Чулпан Хаматова чыгышларын халык көчле алкышлар белән каршылады. Англиянең «The Ritles», Россиянең «Мумий Троль», «Маша и медведи», Украинаның «Вопли Видо-плясова» төркемнәренең чыгышлары да уңышлы булды. Испаниядән килгән Ману Чао сәгать ярым дәвамында җырлады. Танылган җырчы Юрий Шевчук һәм «ДДТ» төркеме чыгышы тамашачыны аеруча тәэсирләндерде. Фестиваль барышында һавага 200 кара һәм ак шар очып китте—шул рәвешчә күптән түгел генә вафат булган поп-король Майкл Джексонны искә алдылар.

Музыка бәйрәмен йөз меңнән артык кеше тамаша кылган дип фараз итәләр.

### ФОЛЬКЛОРЧЫЛАР КИҢӘШТЕ

ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оешуга 70 ел тула. Шул уңайдан биредә 29 июнь көнне «Хәзерге фольклористиканың актуаль проблемалары»на багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция уздырылды.

Аның эшендә Төркия, Әзербайҗан, Казахстан, Калмыкстан, Чуашстан, Мордовия, Башкортстан, Бурятия, Тыва, Алтай, Якутия һәм шулай ук Мәскәү, Төмән, Архангельск, Новосибирск галимнәре катнашты.

Конференция эшендә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР Фәннәр академиясенең баш гыйльми секретаре, филология фәннәре докторы, профессор Дания Заһидуллина, Россия тюркологлар комитеты рәисе, филология фәннәре докторы Игорь Кормушин (Мәскәү), филология фәннәре докторы, профессор, Төрек лингвистик җәмгыяте рәисе Шүкрү Халюк Акалын (Анкара) катнашты һәм чыгыш ясады.

Форум кысаларында күпсанлы гыйльми докладлар тыңланды, фикер алышулар булды. Конференция уңаеннан 42 басма табак күләмендәге монография дөнья күрде.

Конференция кунаклары шулай ук Башкалабызның тарихи истәлекле урыннарында булды, махсус картиналар күргәзмәсе белән танышты.

### ТЮРКОЛОГЛАР ҖЫЕНЫ

Июнь аенда татар дәүләт гуманитар педагогия университетында Казан тюркологлар мәктәбенең 200 еллыгына багышланган

«Күпмилләтле дәүләт шартларында туган телләрне саклау һәм үстерү: проблемалар һәм перспективалар» дип исемләнгән II халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Аны ТДПГУ белән берлектә ТР Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Фәннәр академиясе, Казан шәһәре хакимияте, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты һ. б. оештырды. Конференциядә Бөекбритания, Германия, АКШтан, шулай ук Ульян, Тубыл өлкәләреннән, Казахстаннан, Татарстан, Башкортстан, Саха республикаларының төрле шәһәрләреннән килгән тюркологлар катнашты. Алар арасында исемнәре дөньяга билгеле галимнәр Мария Магдолина Татар (Норвегия), Мокато Моринага (Япония), Әл-Аммари Мөхәммәд Салих (Йәмән Республикасы), Алмас Шәйхуллов (Башкортстан) һ. б. бар иде. Тюркологлар җыенында Россиядә татар һәм рус булмаган башка халыкларның телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт сәясәте, телләрне чагыштырма планда өйрәнү, мәктәпләрдә туган телләрне укыту тәҗрибәсе, туган тел укытучыларын әзерләү мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

### «АЛТЫН КАЛӘМ—2009»

Башка еллардан аермалы буларак, быел балалар, үсмерләр һәм яшьләрнең «Алтын каләм» фестивале «Борис Полевой» теплоходында түгел, ә коры җирдә үтте. Чараның финал өлеше кысаларында яшь каләм тибрәтүчеләр Татарстан Дәүләт Советында да булды. Бина белән танышканнан соң, фестивальдә катнашучылар парламент җитәкчесе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова белән очрашты. «Алтын каләм» фестивале яшьләргә журналистиканың асылын гына аңлатып калмыйча, аларга һөнәр сайлауда да этәргеч булып тора»,—диде Римма ханым. Финалга чыгучылар Казанда өч көн буе көч сынашты. Биредә алар танылган журналистлар, төрле күренекле шәхесләр белән дә очраштылар.

Бөтендөнья яшьләр көнендә конкурста җиңүчеләрнең исемнәре һәм Гран-при иясе билгеләнде. Шулай итеп, Эльвира Вафина (Байлар Сабасы), Алисә Җамалиева (Яшел Үзән) һәм Иван Скрябин (Яшел Үзән) КДУның журналистика һәм социология факультетына ташламалы шартларда укырга керә алачак.

### БЕЗНЕКЕЛӘР—БЕРЕНЧЕ!

26-29 июньдә Төркиянең Денизли шәһәрендә «Төрки караш» дип аталган халыкара музыка фестивале үтте. Анда барлыгы 17 илдән, аерым алганда, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Казахстан, АКШ, Молдова, Босния һәм Герцеговинадан рок, поп, хип-хоп юнәлешләрендә иҗат итүче музыкантлар катнашты. «Төрки караш» фестивален Төркиянең «ТРТ» телерадиокомпаниясе белән берлектә Денизли шәһәре хакимияте оештырды. Концерт дөньякүләм атаклы Памуккале амфитеатрында ачык һавада үтте. Аны карарга 10 меңнән артык тамашачы җыелды. Төрки телле халыкларның бу бәйгесендә Татарстан данын «Алканат» рок-төркеме яклады һәм беренче урынны алды!

Әлеге төркем яна татар альтернатив музыкасын яратучыларга бик яхшы таныш. 2004 елда Актанышта оешкан «Алканат» бүгенге көндә Казан шәһәрендә яшәп иҗат итә. Фестивальдә алар «Салкын яңгырлар», «160 житез ат» һәм татар тамашачысына билгеле булган башка популяр хитларын башкарды.

### ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

Июль башында башкалабызда «Россиянең мөселман төбәкләрендә архитектура һәм үз-үзеңне тәнгәлләштерү» дигән Германия-Россия семинары уздырылды. Аны Мәскәүдәге Германия илчелеге каршындагы Гете исемендәге немец мәдәнияте үзәге, КДУның Мәгариф, фән һәм мәдәният буенча немец үзәге, Европа-ислам диалогы кысаларында Германия Тышкы эшләр министрлыгы оештырды.

Семинар барышында «Россия һәм Татарстанда ислам һәм архитектура», «Хәзерге татар мәчетләре: гореф-гадәтләр һәм стиль», «Татарстандагы диннәр. Евроислам» дигән темаларга фикер алышынды. Табигый ки, үз-үзенне тәнгәлләштерү, ягъни кайсы милләт, кайсы дин тарафдары булу, үз-үзенне дини яктан танып белү хакында фикер тартышлары булды, сүз көрәштерүләрдә КДУда укучы яшь мөселманнар актив катнашты.

### ЛАУРЕАТЛАР БҮЛӘКЛӘНДЕ

ТР Министрлар Кабинетында 2008-2009 еллар өчен М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреатларын бүләкләү тантанасы булды. Бу юлы премиягә автоузышчы, «КамАЗ» ААҖнең махсуслаштырылган техника департаментының оештыру һәм идарә бюросы башлыгы Фирдәвес Кәбиров, «Мизгел» бию театрының сәнгать җитәкчесе Елена Ишбулатова, драматург Илгиз Зәйниев, язучылар Нәбирә Гыйматдинова-Бикчурова һәм Зиннур Хөснетдинов (Зиннур Хөснияр) лаек булды.

### ДӘРДМӘНДНЕ ОЛЫЛАП...

5 июль көнне Казанга «Юрий Гагарин» теплоходы белән «Болгарга сәяхәт» дип аталган мәдәни чарада катнашучылар килеп төште. Әлеге мәдәни-күңел ачу программасы ел саен июль башында уздырыла һәм катнашучылар Уфадан теплоходка утырып китеп, Сергеевка, Түбән Кама, Болгар, Казан, Алабуга шәһәрләрендә тук-

талышлар ясап, яңадан Уфага юл тоталар. Бу проект Башкортстан белән Татарстан республикалары арасындагы дуслык, хезмәттәшлек, мәдәни бердәмлеккә багышлана һәм ел саен нинди дә булса танылган шәхес исеме астында уза. Быелгы сәяхәт олуг шагыйребез Дәрдмәндкә багышланган иде. Теплоход Казанда көне буе торды. Сәяхәттә катнашучылар башкалабызда үзләре өчен махсус оештырылган концерт карадылар. Казанның истәлекле урыннары белән таныштылар. Татарстанның иҗат әһелләре белән очраштылар, соңыннан теплоход залында Дәрдмәндкә багышланган фәнни конференция үтте.

### ОНЫТЫЛМАС ҖЫРЧЫ

Татарстанның халык, Россиянең һәм Башкортстанның атказанган артисты, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Хәйдәр Бигичевның (1949-1998) тууына 60 ел тулу уңаеннан М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында җырчыны искә алу кичәсе оештырылды. Концертта Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Әхмәт Агади (Санкт-Петербург), Башкортстанның атказанган артисты Илһам Вәлиев, Х. Бигичев исемендәге конкурс лауреатлары Руслан Сәйфетдинов, Медет Чотабаев (Казахстан), Илья Говзич (Мәскәү), шулай ук Россиянең һәм Татарстанның халык артистлары Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Татарстанның халык артистлары Зөһрә Сәхәбиева, Мөнир Якупов, җырчы Владимир Васильев һ. б. катнашты.

### 500 КИНО КАРАЯЧАКБЫЗ

«Алтын мөнбәр» мөселман киносы фестивалендә катнашырга теләүчеләр саны 500 гә җиткән. 30 сентябрь—5 октябрь көннәрендә Казанда узачак бу чарага үз фильмнарын 49 ил вәкилләре юллаган. Алар арасында фестивальдә тәүге мәртәбә катнашучылар да бар. Әйтик, без быел Албания, Мексика, Чили, Конго, Мозамбик, Көньяк Африка Республикасы, Судан һәм Израиль режиссерларының да иҗат үрнәкләрен тамаша кыла алачакбыз. Фестивальгә юлланган фильмнарның саны ягыннан, гадәттәгечә, Иранга тиңнәр юк. «Алтын мөнбәр»нең сайлап алу комиссиясенә бу илдән 25 фильм килеп ирешкән.

### ӘЗЕРБАЙҖАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Июль башында Татарстанда Әзербайҗан Республикасы мәдәнияте көннәре булып узды. Бәйрәм С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Әзербайҗан Яшьләр симфоник оркестр концерты белән башланып китте. Мәдәният көннәре кысаларында Әзербайҗан Республикасының мәдәният һәм туризм министры Әбүлфаса Мурсал-оглы Караев Татарстандагы Әзербайҗан милли-мәдәни автономиясе вәкилләре белән очрашты. Шулай ук танылган фоторәссам Фәрит Хәйруллинның «Минем Әзербайҗаным» дип исемләнгән фотокүргәзмәсе дә оештырылган иде.

### ИСКӘР ҖЫЕНЫ

Себердә «Искәр Җыены» дип аталган фестиваль булып үтте. Ул Тубыл шәһәреннән ерак түгел Иртыш елгасы буенда, Себер ханлыгының элеккеге башкаласы булган Искәр шәһәре урынында уздырылды. Бу милли фестивальгә Россиянең Тубыл, Төмән, Омск, Ялутора, Новосибирск, Томск, Казан, Чаллы һәм башка шәһәрләреннән тыш, Казахстаннан да вәкилләр катнашты. «Искәр җыены» инде өченче тапкыр уздырыла һәм Себер татарларының яраткан бәйрәменә әйләнеп бара, аны Төмән өлкәсенең «Мирас» төбәк татар оешмасы уздыра. Ике көнгә сузылган милли җыенда халык үзенең борынгы тарихы белән таныша, дин әһелләренең вәгазен тыңлый, төрле бәйгеләрдә катнаша, тамаша карый.

Бу бәйрәмдә Татарстаннан язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова һәм тарихчы галим Альберт Борһанов катнашты.

### КДУ ТУРЫНДА ФИЛЬМ

«Әл-җәзирә» Халыкара гарәп телекомпаниясе вәкилләре, башкалага килеп, Казан дәүләт университеты турында фильм төшергән. Ике көн дәвамында алар университет тарихына, күренекле галимнәренә һәм «Көнчыгыш-Көнбатыш» бәйләнешләрына багышланган сюжет әзерләгән.

Кунаклар шулай ук КДУ ректоры Мәгъзүм Сәлахов һәм Көнчыгышны өйрәнү институты директоры Җәмил Зәйнуллин белән очрашып сөйләшкән.

### КҮКЧӘТАУДА ГЫЙЛЬМИ ҖЫЕН

Шушы елның 16-19 июнендә Күкчәтау (Көкшетау) дәүләт университетында «Алтаистика һәм тюркологиядәге мөһим мәсьәләләрне комплекслы тикшерү»гә багышланган халыкара конгресс булды. Казахстанның фән һәм мәгариф министрлыгы оештырган бу чарада Польша, Мисыр, Төркия, Украина, Үзбәкстан, Таҗикстан, Казахстан, Кыргызстан, Мәскәү вәкилләре, Россиядәге милли республикаларның күп кенә галимнәре катнашты, төрки, алтай халыкларының тарихына, теленә, фольклорына, этнографиясенә, әдәбиятына, сәнгатенә кагылышлы 100 дән артык доклад тыңланды. Шунысын да искәртик, мөстәкыйльлек алган төрки дәүләтләрдә тюркология бик нык үсә: күпләгән хезмәт-

ләр языла, журналлар дөнья күрә. Мәсәлән, Казахстанның үзендә генә дә берничә телдә «Алтаистика һәм тюркология» һ. б. мәжмугалар нәшер ителә.

Конгресста Казан университеты профессоры Хатыйп Миннегулов, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы мөдире Алмаз Шәйхулов та катнашты, доклад-чыгышлар ясадылар.

### МУЗЕЙЛАР ТӨЗЕТКӘН МӨЖИП

Татар жәмәгатьчелеге озак еллар мәдәният министры урынбасары булып эшләгән дәүләт һәм жәмәгать эшлеклесе, гомере буе халыкка игелекле хезмәт иткән ихлас шәхес Мөжип Низамиевны олуг юбилее белән котларга Тукай музеена жыелды.

ТР Мәдәният министры Зилә Вәлиева юбилярга жылы сүзләрен ирештерде. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Почет билгесе» ордены, күп кенә медальләр иясе Мөжип аганың үткән гомере киләчәк буынларга үрнәк булырлык, дип билгеләп үтте министр. Сарман районының Күтәмәле мәктәбендә мөгаллим буларак үзенең хезмәт юлын башлап, ул халкыбызның милли мәнфәгатен кайгыртуга, рухи мирасын саклауга, мәдәниятен һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертте. Ул министрлыкта эшләгән чорда республикада дистәләгән музейлар ачылды. Дуслары кайчакта шаяртып, аңа «Музей Мөжипович» дип тә әйтәләр.

### ШӘМАИЛ ОСТАСЫ

Кремльнең «Хәзинә» нәфис сәнгать галереясында РФнең атказанган ТРның халык рәссамы Владимир Поповның шәмаилләр, тугралар күргәзмәсе эшли. Күргәзмәләр залының беренче каты тулысынча әлеге рәссам ижаты рухында яши. 80 яшен түгәрәкләгән Владимир Александрович—нәкъ менә шәмаил остасы буларак дөньякүләм танылган рәссамнарның берсе.

### ДИРЕКТОР АЛЫШЫНДЫ

Салих Сәйдәшев исемендәге Зур дәүләт концертлар залының яңа директоры итеп Ленар Айкаев билгеләнде. 37 яшьлек Л. Айкаев халыкка Н. Жиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең «Татарика» оркестры солисты һәм популяр кыллы квартет житәкчесе буларак таныш. Зур дәүләт концертлар залының элеккеге директоры Мансур Шиһапов исә, пенсиягә китү сәбәпле, эш урыныннан азат ителде. ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева М. Шиһаповка мәдәният өлкәсендәге күпьеллык хезмәте өчен рәхмәт белдерде.

### МИЛЛӘТПӘРВӘР ГАЛИМНЕ ЯД ИТҮ

Башкортстандагы танылган татар галиме, профессор һәм татар милли хәрәкәтенең актив әгъзасы Радик Гали улы Сибгатовның тууына 75 ел тулды. Шушы уңайдан Уфада аны искә алу кичәсе булып үтте. Анда атаклы милләттәшебезнең Башкортстан дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасында бергә эшләгән хезмәттәшләре, күренекле галимнәр, татар милли хәрәкәте вәкилләре һем мәрхүмнең туганнары катнашты.

Радик Сибгатов гомеренең соңгы 35 елын Башкортстан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияте кафедрасында мөгаллимлек эшенә багышлады. Шуның 16 елында бу кафедрага житәкчелек итте. Аның филологик фән өлкәсендәге хезмәтләре Башкортстанда гына түгел, Татарстанда һәм башка төбәкләрдә дә киң мәгълүм.

***

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтижәле хезмәте, татар әдәби мирасын саклап калуга һәм үстерүгә лаеклы өлеше өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты әдәбият белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре **Мусин Флүн Мөслах улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

***

Массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә керткән зур өлеше, күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» республика дәүләт учреждениесе үз корреспонденты **Диндаров Илдус Гали улы**на «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә: Казанда—Республика көне.*

*Дүртенче биттә:* язучы-публицист, сәясәтче **Рафаэль Хәкимов**.

# Яңа китаплар




Соңгы дистә еллар эчендә Татарстан китап нәшрияты байтак классик әдипләрнең, шул җөмләдән халык язучылары һәм шагыйрьләренең күптомлык әсәрләрен бастырып чыгарды. Г. Бәширов, Х. Туфан, Ә. Еники, Г. Ахунов, Г. Афзал, И. Юзеев, А. Гыйләҗев..., исәннәрдән—Х. Камал, Ә. Баян, Ш. Галиев, Т. Миңнуллин, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Миңнуллин...

Ниһаять, быел Мөхәммәт Мәһдиевнең дә биштомлык сайланма әсәрләре (элегрәк аның өчтомлыгы чыккан иде) дөнья күрде. I томга—«Без—кырык беренче ел балалары» повесте һәм «Фронтовиклар» романы; II томга—«Кеше китә—җыры кала», «Каз канатлары», «Ут чәчәге» повестьлары; III томга—«Торналар төшкән җирдә» повесте һәм «Мәңгелек яз» романы; IV томга—«Исәнме, Кәшфи абый!» повесте һәм «Бәхилләшү» романы кергән. Ә V томда әдипнең хикәяләре, пьесалары, истәлекләре һәм публицистик язмалары урын алган.

Томлыкларны төзүче—әдипнең кызы Гәүһәр Хәсәнова.



Рафаэль Хәкимов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)